

# Казан утлары

11.1985



**Кама Аланының яңа күренеше**

Тат АЭС. 1985 ел

Рифкать Якупов фотохикәясе



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

11

1985


## *Бу санда*


ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Д. КАЮМОВ. Без — Тукай якташлары . . . . . 3

И. САЛАХОВ. Имәннәр тамыр җәйгәндә. Тарихи роман . . . . . 7

З. НУРИ. Яратам, яратмыйм... Шигырьләр . . . 86

Г. ЛАТЫЙП. Бик кадерле бит ул туган туфрак. Шигырьләр . . . . . 91

И. ЮЗЕЕВ. Онытылмас бәет. Драма . . . . . . 95

З. ФӘТХЕТДИНОВ. Кем — кемне... Повесть . . . 112

Г. РӘХИМ. Оча күңлем. Шигырьләр . . . . . 144

САФА САБИРОВКА 70 ЯШЬ

С. САБИРОВ. Сыерчыклар ни дип сайрый? Хикәя . 147

Ә. ГАДЕЛ. Моң. Шигырьләр . . . . . . . . 159

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

М. ЗАРИПОВ. КамАЗ ныклыгы . . . . . . . 161

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары . . . . . 166

Ф. САФИУЛЛИНА. Шагыйрьнең бер тәрҗемәсе . 167

ИСТӘЛЕКЛӘР

М. ХӘСӘНОВ. Яшел роза . . . . . . . . . 170

ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Ф. ХАТИПОВ. Үткәннәр аша — киләчәккә . . . 180



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 189

АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

Кама Аланының яңа күренеше. Р. Якупов фотолары . . . . . . . . . . . . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Татарстан — родной мой край»: статья первого секретаря Арского РК КПСС Д. К. **Каюмова** «Мы — земляки Тукая».

Роман **И. Салахова** «Когда дубы распускают корни». Детективная повесть **З. Фатхутдинова** «Кто — кого...» Рассказ **С. Сабирова** «О чем поют скворцы?» Драма **И. Юзеева** «Незабываемая легенда» Стихи **З. Нури**, **Г. Латыпа**, **Г. Рахима**, **А. Аделя**.

Навстречу XXVII съезду партии: очерк **М. Зарипова** о буднях и проблемах КамАЗа.

К 100-летию Тукая: статья **Ф. Сафиуллиной** и рисунок **Т. Хазиахметова** из серии «Тукаевские места в Уральске». Эссе **М. Хасанова** «Зеленая роза» (о Хасане Туфане). Творческий портрет **Н. Фаттаха**. Дневник культуры ТатАЭС — литературный пост. Фоторассказ **Р. Якупова** «Новый вид Камских Полян».

На наших обложках: о творчестве молодых художников **И. Самакаеве** и **З. Гимаеве**.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар А. Садыйкова, Г. Салихҗанова.

Производствога җибәрелде 04.09.1985 ел. Басарга кул куелды 29.10.1985 ел. ПФ 05312. Офсет ысулы белән басылды.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетно-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64049. Заказ Ф-394. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.



**Д. К. Каюмов,**

КПССның Арча райкомы беренче секретаре

# БЕЗ — ТУКАЙ ЯКТАШЛАРЫ

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер, кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем...

Бөек якташыбыз Габдулла Тукай туган җиргә чиксез мәхәббәтен әнә шулай тасвирлаган. Һәм миллионнарның уртак фикерен чагылдырган. Чөнки җир — ата-ана, Ватан кебек үк изге. Без беренче сулыш алган, буй җитеп, дөнья көтә башлаган төбәгебезне сөюебез, аның чын патриотлары булуыбыз белән хаклы горурланабыз. Горурланып кына калмыйбыз, ата-бабаларыбызның борынгыдан килгән күркәм гореф-гадәтләрен, матур эшләрен яңа эчтәлек белән баетабыз.

Унҗиденче гасыр башларында ук Казанны саклау өчен хәрби ныгытма итеп салынган Арча үзе дә, тирәсендәге бер-бер артлы тезелеп киткән эреле-ваклы авыллары да бары тик Октябрь революциясеннән соң, күмәк хуҗалыклар төзелгәч кенә, чын-чыннан яңардылар һәм танымаслык булып үзгәрделәр.

Бу партиябезнең, бөек Ленин тәгълиматларына таянып, авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору һәм аны үстерү буенча титаник эшләргә зирәк җитәкчелек итүе нәтиҗәсе иде.

Белгәнегезчә, Арча районы — бүген республикабызда иң зур район. Аның сөрүлек җирләре генә дә 180 мең гектар тәшкил итә. Утызынчы еллардагы 200 ләп күмәк хуҗалык урынына хәзер районда 34 колхоз, 5 совхоз бар. Аларның төп җитештерү фондлары гына да 130 миллион сумга җитә. Район кырларында 1570 трактор, 960 комбайн, 650 йөк автомобиле эшли. Аларга 3400 гә якын механизатор хезмәт күрсәтә. Алар арасында Социалистик Хезмәт Герое Шәрифулла Сәгъдуллин, Ленин ордены кавалеры Хатип Минһаҗев, ТАССРның атказанган механизаторы Вазыйх Шәйхуллин һәм башкалар бар. Алар — Арча ягының бүгенге гүзәл кешеләре, ил табынын бизәүчеләр.

Узган ел районыбыз игенчеләре бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 17,4 центнер уңыш җыеп алып, дәүләткә 60 мең тонна икмәк саттылар, ягъни еллык план 124 процентка үтәлде.

Максатыбыз — якын киләчәктә табигать капризларына бәйлелекне мөмкин кадәр ныграк киметеп, игенчелектә туфракны саклау системасын тулысынча кертеп, органик һәм минераль ашламалар куллануның нәтиҗәлелеген тагын да күтәреп, ачы туфракларны известьлау мәйданнарын арттырып, бөртеклеләрдән кимендә 20 центнер уңыш алу. Ә игенчеләребезгә килгәндә, алар эштән курка торганнардан түгел.

Терлекчеләребез дә ил алдында бурычлы булып калмыйлар. Районыбызда Социалистик Хезмәт Герое Дания Галимова, Ленин ордены кавалерлары Тайбә Баһавие-

ва, Камил Фазлыев, ТАССР Верховный Советы депутаты Әлфинур Хәйруллина кебек һәркайда горурланып сөйләрлек мактаулы терлекчеләребез күп.

Ә авылларыбызның киләчәге ничек, өлкән буынга алмашка кем килә соң? Хәзер парта арасында утыручы укучылар җиргә берегеп үсәләрме? Безне бу сораулар нык борчый. Районда профориентация айлыклары, хезмәт алдынгыларыбыз белән очрашулар, кызыклы кичәләр уздырабыз. Шулай да байтак яшьләребез читкә, шәһәрләргә китә әле. Сәбәп нәрсәдә?

Иң зурысы — авыл кешесенең хезмәтендә, аның абруе нинди булуда дип уйлыйм. Гомумән, бу хакта хәзер, бигрәк тә Азык-төлек программасы кабул ителгәннән соң, бик нык бәхәсләшәләр.

Узган ел мин «Курса» колхозында мәктәп директорыннан: «Чыгарылыш класс укучыларыгыз авылда күп калалармы?» — дип сораган идем. «Бик мактанырлык түгел шул,— диде ул бераз уйга калып,— нигездә мәктәпне тартып-сузып «өчле»гә бетергән егетләр-кызлар кала. Кайчак, китеп, шәһәрдә төпләнә алмаганнары кире кайта...»

Колхоз председателе дә бу сөйләшүдән читтә калмады. «Әлегә үзебезнең балаларда авыл хезмәтенә тиешенчә мәхәббәт уята алмыйбыз,— диде.— Шуңа күрә алар туган йорттан җиңел генә китәләр, кайдадыр читтә яшәүне яхшырак дип уйлыйлар. Мин бу хакта «Искра» колхозы председателе Фәйзи Галиев белән дә сөйләштем.

— Колхозны яшәртүгә мин берьяклы гына карамыйм. Монда мораль-психологик, социаль, материаль-техник факторларны бер бөтен, бер-берсеннән аерылгысыз итеп карарга кирәк,— диде ул.

Председатель яшьләр белән уздырыла торган барлык чараларда катнаша. Бусыннан башкалар да читтә калмыйлар. Әмма Фәйзи Әхмәтовичның яшьләрне үзенә карата алуын — алар күңеленә ачкыч таба белүендә, эш стилендә, дияр идем мин. Ул авылларны яшәртүдә төп игътибарны турыдан-туры яшьләргә түгел, ә өлкәннәргә, ата-аналарга юнәлтә. Гаиләдәге профориентация, микроклимат, өлкәннәрнең шәхси үрнәге, күрәсең, бу мөһим проблеманы хәл итүдә зуррак роль уйный.

Яисә менә, икенче председателебез Социалистик Хезмәт Герое Мирбат Хәстиевне алыйк. Аңа да яшьләр магнитка тартылгандай тартылалар. Утыз ике ел колхоз җитәкчесе булган председатель аларны кылган эшләре, авылдагы гүзәл үзгәрешләр белән «агитацияли».

Ә алар соңгы елларда берәгәйле, күпләрне сокландырырлык булды. «Известия» колхозы уңынчы бишьеллыкны аеруча куанычлы күрсәткечләр белән тәгаллады. Дәүләткә ашлык, ит, сөт һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары сату планнары срогыннан элек арттырып үтәлде. Унберенче бишьеллык нәтиҗәләре тагын да куанычлырак. Дүрт ел эчендә бәртеклеләрнең уңышы һәр гектардан уртача 23,5 центнерга җитте.

Җиңү ни бәрабәренә яуланды соң? Бу — җир юмартлыгымы, әллә сәбәп, сөекле Тукаебыз әйткәнчә, җилнең дә вакытында исеп, яңгырның да вакытында явуындамы? Юк, Арча ягының җире, алда әйткәнебезчә, бик юмартлардан түгел. Соңгы елларда табигать тә игенчене байтак хафага салды, рухын сынады. Шулай булгач, монда хикмәт башкада — колхозчыларның фидакарь хезмәтендә. Җир үзен олылаган һәм үзе турында чын-чыннан кайгырткан кешеләрне генә киендерә дә, туендыра да.

— Без,— ди Мирбат Бәдриевич.— Һәр бишьеллыкта бөртеклеләр уңышын уртача 5 центнерга арттыра барабыз.

Ул мөмкинлекне известиялеләргә КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1984 ел) Пленумы бирде. Анда председатель М. Хәстиев күңелен күптән биләгән мәсьәлә — озак вакытка исәпләнгән мелиорация программасы кабул ителде. Шуңа туры китереп, хәзер Казанбашта Казанка елгасын буу һәм зур гына сусаклагыч булдыру чаралары тормышка ашырыла. Ул сафка баскач, хуҗалыкта 1500 гектар җир, ягъни барлык мәйданның 35 проценты сугарылачак, ирешелгән уңышларны тагын да үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

Мирбат Бәдриевичның план йөкләмәләреннән тыш, үзенең шәхси планы бар. Ул анда һәр яңалыкны теркәп бара. Булганын сакчыл тоту, әрәм-шәрәмнәргә юл куймауның әһәмиятен һәркемгә искәртеп тора. Кирәк-кирәкмәс әйбер сатып алмый. Аның эш кабинетының үзе кебек чын крестьянча, гади җиһазлануы да күп нәрсә турында сөйли. РАПО составына кергән «Сельхозтехника» һәм «Сельхозхимия» берләшмәләренә дә акчаны юкка гына күчермиләр биредә. Бәйләнешләр эшлекле, гадел булсын. Кайчак «Сельхозтехника» ремонтлаган машиналар яки аерым механизмнар начар сыйфатлы кайта, фермада механизмнар ватылса, аларны төзәтергә җаваплы кешеләр үз вакытында килми. Хезмәт хакын мулдан сорыйлар.

Бурычларын тиешенчә үтәмәүләре өчен председатель бу оешмаларны үз вакытында кисәтеп тора. Хуҗалыкта бригада подрядын кертү, игенчелекне дә, терлекчелекне дә җитәрлек кадәр яңа техника белән тәэмин итү турында уйлана, эзләнә.

Эштә булса батырлык, шунда була матурлык,— ди халык. Бу — известиялеләргә атап әйтелгән кебек. Аларның эшләре көйле, ипле бара, шуңа да ил алдында йөзләре кызарырлык түгел.

Узган ел без авылларыбызның киләчәге, аларны социаль үзгәртеп кору турында уйланып, эзләнеп районда бер тәҗрибә сынап карадык. Район үзәгеннән 5 километр ераклыкта гына урнашкан «Авангард» колхозы артта калып килде. 300 ләп йорты булган Кәче авылында колхоз эшенә кеше җитми. Терлекчеләр еллар буена ялсыз эшли. Теге яки бу иптәш авырып киткәндә, сыерлар савылмый кала. Язгы-көзге кыр эшләрендә катнашучыларның яртысына якыны читтән килгән кешеләр. Шул ук вакытта тимер юл буена урнашкан Кәчедән һәр көнне, иртән сәгать 2 дән торып, 300 ләп егет-кыз 50 километрдагы Казан шәһәренә эшкә чыгып китә. Кичен арыпталып шул кадәр үк соңга калып кайталар.

Узган елның мартында без бу авылны «Районның халык төзелеше» дип игълан иттек. Районның һәр промышленность, төзелеш оешмасы колхозга кимендә бер йорт төзеп бирергә булды, «Госкомсельхозтехника»ның район берләшмәсенә машина-трактор паркы объектларын төзүдә ярдәм итү бурычы куелды. Дөрес, мәшәкатьләрнең иң зурысы колхозчыларның үзенә, хуҗалыкны яңа гына җитәкли башлаган Илдар Гарифуллинга төште. Ләкин бу куанычлы мәшәкать иде. Күмәк көч тау күчерә. 10 ай дигәндә 32 квартира төзелеп, шуның 26 сы файдалануга бирелде. Аларның хуҗалары — колхозның үзеннән һәм читтән күчеп килгән яшь механизаторлар һәм терлекчеләр. Механизаторлар йорты, ябык ындыр табагы, җылытылган техника көйләү мәйданчыгы, терлекчеләр йорты, машина-тракторларга техник хезмәт күрсәтү пункты да — соңгы бер елда калкып чыккан объектлар. Хәзер терлекчелектә ике сменалы эш оештырылды, колхоз кыр эшләрен дә үз көче белән башкарып чыгарга исәп тота башлады. Колхозчыларда ышаныч, хезмәткә дәрт артты. Колхозның авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү буенча узган елгы һәм быелның күп айларында уңышлы үтәп чыгуы да шул турыда сөйли. Тиздән авылга табигый газ керәчәк, типовой мәктәп, культура сарае салыначак.

1933 елны Казанга колхозчы-ударникларның беренче Бөтентатарстан съездына килгән М. И. Калинин безнең яклар, аерым алганда, шушы «Авангард» һәм «Заветы Ильича» колхозлары эшчәнлеге белән дә танышып киткән. Бергәләп фотога төшкәннәр. «Күмәк эшләп чыгаручылар ни дигән сүз соң ул? Бу, иптәшләр, мин колхозда барысы өчен дә эшлим, ә барысы да минем өчен эшлиләр дигән сүз,— дигән иде М. И. Калинин колхозчыларга.— Коммунистлар партиясенең идеясе һәрбер кеше бөтен кеше өчен эшләрлек, ә бөтен кеше берәү өчен эшләрлек җәмгыять төзүдән гыйбарәт тә. Коммунистик идеяләрнең мәгънәсе шунда». («Кызыл Татарстан» газетасы, 1933 ел, 111 сан).

Шулай итеп, тәҗрибә үзен аклады. Быел шундый күмәк көч белән Киров исемендәге колхозның Күпербаш авылында эшләячәкбез.

Ләкин шуны истән чыгарырга ярамый: авылларны социаль үзгәртеп кору

комплексны гамәлгә ашырылырга, яшьләрдә авыл һөнәренә хөрмәт, тапшырылган эш өчен җаваплылык хисе һәм ата-бабаларыбыз яшәгән җиргә мәхәббәт тәрбияләү белән үрелеп барырга тиеш. Чылбырның бер генә боҗрасы йомшак булса да, аның белән авыр йөкне тартып бару мөмкин түгел.

Кызганычка каршы, кимчелекләрдән арына алмыйбыз әле. Әйтик, бер колхоз менә дигән итеп терлекчелек комплексы төзи. Анда ял бүлмәләрен, кызыл почмагын, китапханәсен булдыра. Тик бу комплекс авылдан ерак. Транспорт даими йөрми, асфальт юлы юк. Мондый кыенлыклар искиткеч яхшы шартлары булган комплекста да эшләү теләген сүндерергә мөмкин.

Янсә икенче мисал. Бездә, мәсәлән, кайбер хуҗалыкларда урта мәктәп укучыларының практик занятиеләрен иске, начар механикалаштырылган, сөт саву күрсәткече түбән булган фермаларда үткәрәләр. Без, партия, Совет, хуҗалык җитәкчеләре мондый «тәрбия»гә битараф кала алмыйбыз, авыл кешесе һөнәренең абруена күләгә төшерә торган күренешләргә каршы көрәшәбез. Язучылардан безнең игелекле эшебезнең романтикасын, шатлык-борчуларын тирәнтен ача торган әсәрләр иҗат итүне, сәхнәләребездә заманның актуаль проблемаларын күтәргән, авыл темасын яктырткан спектакльләрнең ешрак куелуын сорыйбыз.

Болай мөрәҗәгать итүнең нигезе бар. Чөнки Арча ягы — республикабызда танылган терлекче Дания Галимова, механизатор Шәрифулла Сәгъдуллин, укытучы Стелла Габдрахманова, колхоз җитәкчеләре Нургали Бариев, Мирбат Хәстиев кебек Социалистик Хезмәт Геройларын, Бөек Ватан сугышында каһарманлыклар күрсәткән Нәкыйп Сафин, Гани Сафиуллин, Валентин Ежков, Гатаулла Салихов кебек Советлар Союзы Геройларын гына түгел, илгә, халкыбызга егермеләп язучы да бирде. Курсави һәм Мәрҗәни, Галиәсгар Камал һәм Мәхмүт Галәү, Гомәр Бәширов һәм Сибгат Хәким, Гариф Ахунов һәм Мөхәммәт Мәһдиев, Фәрваз Миңнуллин һәм Хәкимҗан Халиков, Самат Шакир һәм Равил Вәлиев, Нәҗип Мадъяров һәм Илдар Низамов... һәм бу язучыларның таҗы — бөек Тукай.

Шунысы күңелле: Арча җирендә илһам чишмәсе саекмый. Үзендә илһам көче сизүче яшь талантлар мәйданга килә. Бүген, мәсәлән, район газетасы редакциясе каршындагы «Тукай якташы» дигән әдәби-музыкаль берләшмәгә төрле һөнәр ияләре йөри. Вазыйх Рәхимов — ПМКда өлкән прораб, РСФСРның атказанган төзүчесе, Дамир Галимов — Арча педагогия училищесы укытучысы, Газиз Камалов — совхозда инженер... Барысы да күп санлы шигырь-хикәя, берничә китап авторлары. Әдәби түгәрәкне СССР Язучылар союзы члены, Татарстанның атказанган культура работнигы Радик Фәизов җитәкли.

Соңгы елларда районда үзешчән композиторлар да активлашты. Алар үзләренең яңа көйләрен нәкъ менә шул әдәби түгәрәккә йөрүчеләрнең шигырьләренә яздылар һәм язалар. Байтагын район тамашачылары җылы кабул итте, агитбригадалар үз репертуарына кертте.

«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул!» дигән иде Тукаебыз. Моның хаклыгына без бүген аеруча нык инанабыз. Бөтен эшләребезне бөек якташыбызның үлмәс исеменә лаек булырлык итеп башкару, Арча җиренең данын тагын да арттыру — иң олы максатыбыз.

## Ибраһим Салахов

# ИМӘННӘР ТАМЫР ҖӘЙГӘНДӘ

ТАРИХИ РОМАН

1

Арканың тиңсез гүзәл Күкчәтавы —
Һәр таң саен яңгыр юа аның битен;
Иртә-кичен күк болытлар хәлен белә
Тау өстенә бөркәп куеп шәлнең читен.
Сиксән күл Күкчәтауның итәгендә,
Һәркайсысы ахак касә кысасында.
Һавасы дәрткә дару, җофар исле,
Күпме генә суласаң да туясыңмы?

*Сәкен Сәйфуллин, казах шагыйре.*



Имәнтаулыларны йоқыдан торырга, мәчеткә намазга барырга өндәүче азан тавышы иртәнге станица өстеннән узып та өлгермәде — кинәт өзелде. Даладан ургылып кергән көчле җил аны урман ягына, күл өстенә, Казантау кыяларына таба алып китте. Сизелер-сизелмәс кенә яктыра башлаган күк тагын караңгыланды, офыкны кара, кабарынкы болытлар сарып алды. Ул арада булмады,станицаның көньягында, Күкчәтау юлында, «пәри туе» күтәрелде. Давыл бихисап зур орчык булып бөтерелде, борынгы зират өстендәге черегән, ауган такталарны күтәреп-чөеп пыр туздырды, муртайган кирпә-корталарны аударып туп-туры үр өстенә атылды, жиргә чүгеп утырган иң кырыйдагы иске ызбаның салам түбәсен каерып ташлады.

Йорт хуҗасы — агач аяклы, таякка таянган Җәфрәтил карт, төрек сугышындагы кыюлыгы, батырлыгы өчен Георгий крестының берберартлы өч медале белән бүләкләнгән полный кавалер — аны-моны уйламыйча курадан чыгып килә иде. «Пәри туе» картны йомычка кебек зырылдатып бөтереп алды, читән казыгына кибәргә эленгән бер дистә чүлмәк белән бергә капка төбенә китереп сылады. Озын, чандыр гәүдә кармаланып таягын эзләп тапканчы, җил урам буйлап ыжгырып китеп барды, һәм Җәфрәтил карт тагын азан тавышын ишетте. Җил арасыннан шактый талкынып, өзелеп ишетелсә дә, моңлы азан картның йөрәк кылларын тибрәтте, күзләренә кайнар яшь китерде. «Ходам!— диде ул калкынып.— Безнең кияүгә малны бирмәсәң дә тавышны кызганмагансың икән! Выты, ничек яңгырый!»

[1] Роман Аяз Гыйләжевның әдәби эшкәртүендә басыла.

Җәфрәтил карт чүлмәк ватыкларын сыпырып торып ук басты, ватык капканы иңе белән этәреп урамга чыкты. Гадәттә, иртәнге намаз вакытында таң инде алсулана, көн беленә башлый иде. Бүген исә куе эңгер-меңгер, станица өстендә кара-караңгы болытлар өерелә. Ул арада бер-ике эре, салкын тамчы аның битен чылатты. «Әллә яварга итенә инде, ходаның рәхмәте?!» Җәфрәтил шуны уйлап та бетермәде, тыкрык гөлт итеп кабынып, яктырып китте. Карт ирексездән ике күзен дә чытырдатып йомды. «Бак, күк капусы ачылдымы әллә?! Шулдыр, шулдыр, выты! Күк капусы ачылганда бәндә ни теләсә, тәңресе шуны бирә, диләр түгелме? Нинди ашыгыч теләкләре бар соң Җәфрәтилнең?.. Ызба җимерелеп бара. Ат! Сыер... Өс-баш та бик таланган,— карт өстендәге җиләнен капшап куйды.— Мәчеткә баруы да оят... Их, юләр карт! Ни уйланам? Ялгыз оланым Хәбүш служюада. Выты, аның тазасау кайтуын теләргә кирәк!.. Хәерсез... Тагын ни теләргә?!»

Җәфрәтил тәмам алҗыды, сулышы кысылды. Иреннәр көчкә-көчкә пышылдадылар:

— Тәңрем, илгә... илгә ашлык бир! Ачлыктан сакла, мәүләм.— Моннан калган теләкләр сүзгә әверелмәделәр, гөнаһ шомлыгына каршы, карт ичмасам бер генә телиген дә, мәүләсе төшенерлек итеп, чатнатып әйтеп бирә алмады. Ул яхшылап уйлаганчы, тирә-як кап-караңгы булып калды.

— Атакай! Атакай! Ябылды! Күк капусы ябылды, выты, нишлим? Тәңрем!— Хөрмәтле станичник, полный кавалер бала-чага кебек кычкырып елап та җибәрде.— Артык күп шул мохтаҗларым, тәңрем. Кайсын гына санап бетерим?!

Нәкъ шушы зарлы мизгелдә, якында гына, нәрсәдер бик каты шартлады, җир чайкалып киткәндәй булды, гүя Казантау икегә ярылды да станица өстенә убылып ишелде. Колак тонды, тез буыннары дерелдәде. Карама таяк тагын кулдан ычкынып китте, агач аяк сөртенде, колга гәүдә урталай сынган төсле, бөгәрләнеп җиргә ауды.

Ул арада каланчада чаң суга башладылар. Үзәк өзгеч кычкыру, сүгенү, акырыш-елау ишетелде. Сузып, абалап, калын тавыш белән эт улады. Җиргә тып та тып эре, салкын тамчылар тамды. Читән буенда һушсыз килеш исәнгерәп яткан карт, ниһаять, яңгыр тамчыларыннан исенә килеп торып утырды, капшанып таягын тапты, көч-хәл белән яман уфылдап күтәрелде һәм үз күзләренә үзе ышанмыйча шашып калды. Бераздан чак кына аңына килеп яман тавыш белән акырып җибәрде:

— Кыямәт! Кыямәт!

Чыннан да, аның алдындагы күренеш кыямәт көненнән бер дә ким түгел иде. Тыкрык уртасында мәчет манарасы җимерелеп ята, ак калай белән тышланган ае чәчрәп әллә кая киткән. Җәфрәтил карт исерек кеше төсле янтая-янтая бер-ике атлады да, бар тавышына иңрәп, манара җимерекләре астында канга батып яткан гәүдә өстенә ауды.

— Үмәр! Бак, Үмәр кияү, бу синме?

Яшен бәреп төшергән изге хәрабәләр арасында мөселман станичникларын моңлы тавышы белән сихерләп торган азанчы Гомәр ята, аның авыз-борынының туктаусыз кан саркый иде. Инде менә шул тын калган бичара гәүдә өстенә Җәфрәтил карт килеп егылды. Читән аръягындагы янгын телләренең кызуы килеп җиткәч кенә ул күтәрелеп карады. Күзләре шашкан кешенеке төсле акаеп калган иде. Ә читән аръягында — янгын, дулый-дулый мәчет яна! Мәчет янындагы йортлар яна! Каланча як урамнан су тулы мичкәләр, су сиптерүче кул насосларын очыртып пар-пар атлар чыктылар да, инеш аркылы салынган күпер бүрәнәләрен даңгыр-доңгыр сикертеп мәчет ягына чаптылар. Чиләкләр, тимер ыргаклар, көрәкләр шалтырады. Йокылы-уяулы, куркынган күз белән ызбаларыннан атылып чыккан ирләр, хатын-кызлар, бала-чага

кая барырга белми әле бер якка, әле икенче якка ташлана, коточкыч тавышлар һаман аяусызлана бара иде. Агач мәчет алтын баганалары белән балкып ишелде. Урам буендагы салам түбәле ызбалар бер-бер артлы гөлт-гөлт кабына башладылар.

Станица кинәт чайпалып, калтыранып китте — инеш аръягындагы чиркәүнең иң олы, иң калын тавышлы кыңгыравын кага башладылар.

— Даң-доң!

— Доң-даң!

Җил бу дәһшәтле набатны бер дала ягына алып китеп сүндереп, бер кочаклап кире алып кайтып, куркынган станица өстенә ташлады. Урман ешлыгында, чиркәү манараларында йоклаган каргалар куркынып уяндылар, алар нигәдер дала ягына очмадылар, ут өстенә өерелеп килделәр, җәһәннәм кошларына охшап, йөрәкләргә курку өстәп, туктаусыз каркылдадылар. Яман тавышлар белән этләр улады, сыерлар үкерде, аналарыннан аерылган колыннар чинап кешнәделәр, тавыклар кытаклады. Җәфрәтил карт иңрәп як-ягына каранды:

— Я, раббым! Бу нинди мәхшәр?!

## 2

Лобаново станицасыннан чыгуга юл туп-туры урман эченә барып керә. Тар гына өч сукмак булып сузылган юлның ике ягында — төптән үк ботакларын киң җәеп, яшел ефәк тәңкәләргә күмелеп, кабарып торган куншы, юан каеннар. Алар тирәсенә тыгызланып куаклар, мең төрле чәчкә-үләннәр утырганнар. Кызгылт-соры ботаклары эре-эре энәләр белән тырпайган камыр агачы ап-ак күбек чәчәктә.

Иртәнге чыр-чудан соң кошлар яфрак күләгәләренә посып, көндезге эсседән качып ял итәләр, күрәсең, урман эче тып-тын. Ара-тирә генә яшькелт-соры түшле песнәкләр, күмер кара карлыгачлар чырылдап юлны кисеп очалар. Менә тынлыкны бозып, ямьсез тавышлар чыгарып арба шыгырдый башлады, озакламый юл бормасында, шул зарлы арбаны сөйрәп баручы сыңар мөгезле, кызыл өстенә ак ямау салынган чуар тунлы үгез дә күренде. Ул чүп-чар сарган койрыгын уңлы-суллы селтәп, аркасын, корсак астын сырып алган сукыр чебеннәрне куа-куа атлар-атламас кына бара иде. Күпереп торган калку үләннәргә үрелеп, үгез йөрешен тәмам акрынайтты.

Арбаның ике тәртәсе өстенә салынган кытыршы такта кисәгенә утырган, дөя йонынннан тукылган иске чикмән кигән казах уянып китеп башын күтәрде. Карындык бит. Җәлпәйгән борын. Болай да кысык күзләр, инде йокылы-уяулы хәлдә бөтенләй йомылып, ике тар сызык булып кына шәйләнәләр. Маңгайга әллә кайчаннан кунаклаган сырларга караганда бу кеше урта яшьләрне байтактан узган булырга тиеш. Әмма шуңа хас булырга тиешле сакал-мыекның әзе дә юк, хәтта кашлар да өтек, булыр-булмас кына. Төксез бит кояш нурларында яңа гына мичтән чыккан майлы тәбикмәк сыман ялтырап тора. Ул йомык күзләрен ачар-ачмас, кулы белән капшап кына, янында яткан озын тал чыбыкны алды да, түбәндә — тәртә арасында барган үгезгә иренеп кенә селтәнде.

— Әй, тшү! Сәбә!

Казах кичә, арба тутырып төяп, шикәр кебек шылтырап торган каен утынын 70 чакрымдагы Күкчәтау базарына алып барды, аны ярты такта чәйгә сатты. Бүген таңнан чуар үгез тагын юлда. Арыган үгез чыбыкка һич игътибар итмәде, күзен алартып хуҗасына бер карап алды да, юл читендәге сарутларга үрелде.

Арбаның аръягында дуга кебек бөгәрләнеп тагын берәү йоклый, ябынган җиләне өстендә чебеннәр йөри.

Юл ачык, берәү дә комачауламый, шуңа ахры, хуҗа да, чуар үгез дә гамьсез, майланмаган тәгәрмәч кенә тыныч түгел. Тик ул тавыш та җилән астындагы юлаучыга тәэсир итә алмый. Күкчәтаудан чыкканнан бирле йоклый да йоклый.

Ләкин бу рәхәт, кызганычка каршы, озакка сузылмады. Урман эченнән бер күк кигәвен бызылдап чыкты да чуар үгезнең нәкъ койрык астына кадалды. Тәгәрмәчләр кинәт зырлап әйләнеп киттеләр. Арба бер турайды, бер кыйшайды, искиткеч тавышлар белән шыгырдап, дыңгылдап, тузан туздырып йокылы урманны сискәндереп уятты.

Хуҗа, йокысыннан айнып, үгезнең ялгыз мөгезенә эленгән дилбегәгә тотынды, тарткалап, йолыккалап хайванны туктатырга тырышты.

— Әй, сәбә! Тор, тор, ни җен сугып китте! Тор дим, коргыры. Сәбә!

Хуҗа артында йоклап барган кеше чираттагы кыйшыкта арбадан тәгәрәп төшеп калды, ярый әле тәгәрмәч астына төшмәде, читкәрәк ауды. Башындагы кызыл фәсе үлән арасына тәгәрәде. Юл үр менә башлады, чуар үгез чаба-чаба бераз күтәрелде дә, әлсерәп туктады. Үзе мыш-мыш килә, авызыннан туктаусыз күбекле селәгәй ага.

Ул арада артта егылып калган юлчы да арба янына йөгереп килеп җитте, «ага!» дип арба хуҗасына эндәште. Яшүсмерләргә хас буйчан, сөякчел бу егетнең өс-башы сәер генә иде: озын кара постау чалбары тезгә төшеп торган кара сатин җиләнє, бу җирләр өчен ят баш киеме — биек, озын чуклы кызыл фәс аны тагын да озынрак һәм гаҗәбрәк итеп күрсәтә иде. Ул, арбада көч-хәл белән тотынып калган, кәефе яхшы ук кырылган хуҗага тәгәрмәч аша гына үрелеп, йомшак тавыш белән эндәште:

— Ага, анау җаткан капны биреп җибәрегезче. Мин инде җәяү генә китәм. Алыс калмады, гуй.

— Атаңа нәләт...— Хуҗа һаман әле тынычлана алмый, әлсерәп, көчкә басып торган үгезне сүгә-сүгә, җиңе белән шабыр тир маңгаен сөртте.

— Ага!

— И, ни диден?— Ниһаять, фәсленең тавышы аның тузан баскан колагына барып иреште.— Ни диден, шәкерт!

— Выты, капчыкны ташлагыз әле.

— Монау дурбамы?— Хуҗа арба өстендәге капчыкны тартты.— Уй-бай! Монау авыр, гуй. Таш тутырдыңмы?— Хуҗа ике куллап үрелеп капчыкны җиргә төшерде.— Ни салдың монда?

— Китаплар, ага. Рәхмәт утыртып килүегезгә.

— Әй, шәкерт, усынша китапты җалгыз укыйсыңмы?

Монарчы бөтен дөньяга, шул җөмләдән арбасы түрендә йоклап кайткан юлдашына да бөтенләй битараф булган казах фәсле егетнең капчыгын тотып карагач, ничектер, җанланып китте, арбасыннан төште, чуар үгезнең мөгезеннән тартып китереп үләнгә кушты. Бераздан:

— Әй, шәкерт, кай яклардан йөреп кайтасың?— дип сорады. Фәсле егет капчыгын иңенә салып китәргә үк җыенган иде, юлдашының соравын ишетеп, йөген үлән арасына ташлады да казах янына килеп утырды. Беравык тып-тын утырдылар.

— Бәйрүт шәһәренә юл токкан идем мин, хөрмәтле ага.

— Кая, кая?

Казахка аңлатып бирергә туры килде. Үзенең шәһри Бәйрүткә барып, аның мәшһүр мәдрәсәләрендә олуг остазлардан дәрес алмак булып озын сәфәргә чыгып китүен, Кара диңгезне контрабандистларның ишкәкчесе булып ялланып узуын, төрек җирендә бик каты егылуын, төрек солтанының рус җиреннән килүче мосафирларга шәфкатьсез булуын, ничәмә мәртәбә төрмәгә эләгә язып калуын, кайтыр юлының баруына караганда да читенрәк булуын, сары бизгәк авыруына дучар булып Одессага кайтып егылуын, шифаханәдә өч айга якын ятып чыкканнан соң, ата-аналары

янына Имәнтау станицасына кайтып баруын кыскача гына сөйләп бирде. Чуар үгез бөтереп-бөтереп сусыл үләннәрне каба торды, хуҗасы егетне бүлдермичә генә тыңлады, йомык кабаклары арасыннан аның инде йокыдан уянган теп-тере кара күзләре генә ялтырап куйгалады. Ул егетне бирелеп, бүлдермичә тыңлап бетерде.

— Ала-ай,— дип сузып куйды казах арбасына менеп утыргач кына. Ашап бераз хәл алган чуар үгез дилбегә кагуга урыныннан кузгалды. Арба тагын зарланып шыгырдады. Бу борылышта юл икегә аерыла иде, берсе туп-туры үр өстенә — Имәнтауга, икенчесе үрдән сулга — җәйләүгә таба алып бара иде.

Үгез җәйләү юлына төшеп аянлый башлаган гына иде, дилбегә тагын тартылды. Арба шыгырдаудан туктады.

— Әй, шәкерт, тукта. Монда кил.

— Ә? Ни, ага?

Авыр капчыгын юка җилкәсенә салып үргә күтәрелә башлаган фәсле егет туктап кире борылды.

Арба өстенә җайлап утырган казах уң як тәртәгә асып куелган, йоннан тукылган ике олы калталы курҗынны үзенәрәк тартып китерде дә авыз җебен ычкындырды.

— Әй, калпагыңны монда бирче, кем, атың Успан идеме, балам.

Госман аптырап калды: бу таушалган фәс аңа нәрсәгә? Ә Госманга ул бик кадерле, теге, төрек җиренә аяк баскач беренче күргән Босфордагы карт балыкчының төсе бит! Ак күңелле карт «угылым, башыңдагы кәләпүш дигән ят бүрек белән яньчарлар күзенә бик тиз төшәрсең, иске булса да бу фәсне ки, төрек киеме. Хода сакланганны саклармын, дигән!»— шулай дип бирде ич ул фәсне! Ничек итеп истәлекне биреп калдырырга? Әллә инде утырып килгән өчен түләү соравымы?

— Уй-бай, ни катып калдың? Җылдам таста калпагыңны!

Госман фәсен салып арбага таба сузды.

— И, карның ачып калган чыгар, бераз җөрәк җалгап ал,— дип сөйләнә-сөйләнә үгез хуҗасы курҗыннан учлап-учлап сыкма[1] алып фәскә тутыра башлады.

Тәгәрмәчләр тагын шыгырдады, бераз киткәч, Госман казахка борылып кул болгады, сыкманы берәмтекләп ашый башлады. Юл борылган якта, урман читендәге сирәк каеннар арасыннан берничә киез өй күренде. Эт өргән тавышлар ишетелде. Авыл исен сизепме, чуар үгез йөрешен тизләтте, җилдерә үк башлады.

Үргә күтәрелгәндә фәснең төбендә берничә генә сыкма калган иде. Авызга алуга эреп тора шул, әчкелтем каймак тәме килә. Туган җирнең беренче ризыгы. Былтыр, озын сәфәргә кузгалганда, Госманның әнисе дә: «Улым, сыкма үзе туклыклы, үзе юлда озак бозылмый»,— дип өсте алынмаган, каймаклы сөттән генә кайнатып, ап-ак шикәр сыман сыкмаларны капчыкка тутырган иде бит...

Госман үргә менеп киткәч тыны бүленеп туктады, китаплар тагын да авыраеп киткән кебек булды, ул капчыгын мүк сарган таш өстенә куйды.

Я алла, чыннан да бу аның туып-үскән җиреме? Ул менә хәзер туган җир туфрагында басып торамы? Күңел ышана да, ышанмый да... Ничәмә тапкыр әҗәл белән очрашканнан соң, чит җирләрнең ачы тузанын тире, күз яше белән диңгез кичкәннән соң Босфор, Мәрмәрә диңгезләре, Кара диңгез, Одесса, Мәскәү, Катәринбур, Чиләбе, Кызылъяр калалары... Шифаханәдән чыккач та Одесса портында йөкче булып эшләргә туры килде, акча тиенләп җыелды, әле дә ярый тимер юл билетына җитте!..

Кызылъярга кайтып егылганда кесәсендә сукыр бер тиене дә калмаган иде Госманның! Кызылъярдан Күкчәтауга йөз сиксән чакрымлы юл

[1] Сыкма — сыгып киптерелгән төче эремчек.

ята! Әле дә ярый, дөньяда рәхимле бәндәләр аз түгел, юлаучы, йөк-керә тартучы казахлар кайда арбаларына урын биреп, кайда атка, дөягә атландырып бер авылдан икенчесенә җиткерделәр. «Мосафир бала гуй, шәкерт!»— дип аны корт, эремчек, сөт-кымыз белән сыйладылар.

Чуар үгез белән аның кашсыз хуҗасы соңгы юлдашлары иде Госманның. Ниһаять, Кукчәтау!.. Кукчәтауда туктарга да була иде, күрәсе кешеләре дә бар иде, якыннары, туганнары, әмма күңеле аны Имәнтауга тартты...

Тирләгән аркага күлмәк итәгеннән җылы җил үтеп керә. Шундый рәхәт, Госман рәхәтлектән кузгала алмыйча байтак кына ял итте. Аннан ашыга башлады, таш өстеннән җиләнен, фәсен алып киде, кабаланып капчыгын аркага күтәрде. Үрнең аръягында, офык сызыгында, кара-кучкыл болыт булып тау күренде. Казантау! Әнә шул тау итәгендә Госманның туган станицасы Имәнтау. Кояш ашыгып-ашыгып шул тауга авыша. Әйләнә-тирәдә күз күреме сузылган ямь-яшел дала. Үр итәгендә бер төркем сыерлар утлап йөри. Күз күнеккән кадерле төсләр! Госман капчык авырлыгын онытып йөгерә үк башлады. Уе аннан узып әллә кайчан станицага барып җитте, өйгә керде... Аяклар, нигә сез шул кадәр акрын кыймылдыйсыз, нигә сез күңел шикелле йөгерек-тулпар түгел? Ниһаять!.. Бәләкәй үрне дә узды Госман. Аяклар бөтенләй хәлсезләнеп, бер-берсенә чалынып тукталдылар. Ул чак кына егылмады. Сулыш кысыла, иркенләп тын алып булмый... әллә инде йөрәк яна? Мөгаен, янадыр, авыздан сулыш түгел, ялкын бөркелеп чыга! Кипкән иреннәрне чылатырга бер генә йотым су булсачы!

Я, хода, чыннан да ул кайтып җиттеме? Күзе туйганчы карасын әле бер, күңеле ышансын! Йөрәк тибеше салмаклансын!..

Калын карагайлар белән капланган Казантау! Урманның уң ягында, тылсымлы көзге булып күл җәйрәп ята. Күлнең сул ягында станица. Инешнең аргы ягы — казак-урыс очы. Бирге ягы — казак-татарлар очы. Госманнарның нигезе шунда. Ул оч тулаем урман эчендә диярлек, хәзер моннан күренми. Инеш аркылы салынган күпернең бирге ягында яшькелт түбә кыеклары гына шәйләнә. Болары — Кәлимулла байның куралары, өе янында таш кибет, кибет янында калай түбәле озын складлар.

Күренмәсә дә Госман станицаның бөтен сызыкларын күз алдына китерә ала. Күпернең аръягында ук круг — мәйдан. Себер казак гаскәренең наказной атаманы килеп смотр ясаганда да, чираттагы нәрәт белән казаклар службага киткәндә дә, станичниклар аерата әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә дә бу мәйдан аерата мөгътәбәр кешеләр, атлы казаклар, карт станичниклар белән тула. Хатын-кыз, бала-чага да алар артына килеп бөялә, мәйдан умарта күче сыман гөж итеп тора. Бүген исә мәйдан буп-буш. Госман алга атлаган саен бушлыкны ныграк аерды. Әйе, вакыты шундый, төштән авышып, икенде ахшамга җитмәгән ара, көтү дә килмәгән, печәнчеләр дә болында чак.

Мәйданның аръягыннан кырга таба дүрт урам сузылып киткән, эреле-ваклы, кайсы такта, күбесе салам белән ябылган өйләр, читән белән уратылган бәрәңге, яшелчә бакчалары (Җәй уртасында, көнбагыш чәчәк атканда бу бакчалар аерата матур булалар! Мең кояш берьюлы чыга Имәнтауда!). Мәйданның бер кысасында барак сыман озын, ишеге мәйданга ачылган кабак. Хәзер аннан кочаклашып, җыр сузып өч казак чыгып киләләр. Аннан ерак та түгел, чат башында биек өй — станица идарәсе. Аңа башлаш озын-озын тәрәзәсез складлар тоташкан, ул складларда салкын корал, поход кирәк-яраклары, провиант, ияр-тукым, ашлык һәм башка вак-төяк саклана. Складлар янында каланча. Аның манарасына кыңгырау асылган. Кыңгырау янындагы нәүбәтче станица тирә-ягын җентекләп күзәтеп, карап тора. Яз коры, куркыныч вакыт. Хода уткыздән саклый күрсен. Әмма бу каралтыларның барысыннан да биеге, тантана белән башын күккә чөйгәне чиркәү. Күк төскә буялган биек бина

өстендә гөмбәзле ике манара. Алтынга манылган тәреләре янып тора. Манаралар эчендә шулай ук дәү-дәү кыңгыраулар. Ул кыңгыраулар кузгалганда, Имәнтау станицасы гына түгел, Казантау артындагы Арык Балык станицасы да дер селкенә! Хәзер әнә оеганнар, ял итәләр. Җилле көннәрдә бертуктаусыз зырылдап әйләнеп, станичникларның күңелләрен күтәреп тау башында масаеп торган җил тегермәннәре дә тымызык һавада йокымсыраганнар.

— Карр, кар!

Госман сискәнеп китте. Зират өстендәге ялгыз карагайга кунган дәү карга яман каркылдап, алама канатлары белән тын һаваны дулкынландырып аның баш очыннан диярлек очып китте. Кыйшайган, ауган кабер ташлары өстеннән кара күләгә шуышты. Егетнең күңеле «жу» итеп китте. Туган җирендә беренче сәламләгән җан иясе карга булсын әле! Әллә борылып китеп торыргамы? Чү! Әнә урман тыкрыгыннан Госманнар ягыннан берәүләр килә түгелме? Әйе, әйе, күбәү үзләре. Менә урамнан чыгып зират калкулыгына менә дә башладылар. «Бак, җилкәләренә нидер күтәргәннәр!» Госман өшеп киткәндәй калтыранды, йөрәге бәла сизеп сызланды.

— Бак!— Ул үзе дә сизмәстән кычкырып ук җибәрде.— Бак! Выты, табут күтәргәннәр. Кемне китерәләр соң алар?

Карга борылып килде, табут күтәргәннәр өстенә кара күләгәсен кундырып тагын бер-ике тапкыр ямьсез каркылдады. Җил исте, шунда гына Госманның борынына төтен, көек, афәт исе килеп бәрелде.

Табут, һавада йөзеп, зират капкасына якынлашты...

## 3

— Выты, бак инде, кәбәм...

Җәфрәтил карт Госманны җитәкләп тыкрык буйлап алып килде.

— Бак, кәбәм, атаң нигезеннән ни калды.

Иң алда очлы башлы, кара киемнәр кигән монахлар төсле ике кара багана шыраеп тора. (Артык юан иде шул аларның капка баганалары, ут та ала алмаган үзләрен, көйдергән, яндырган, киртләч-киртләч итеп калдырган). Баганалар артында янып-көеп аркылы-торкылы ауган, җимерелгән, ишелгән такта кисәкләре, ишек-тәрәзә яңаклары, бүрәнә башлары. Кисәүләр, күмер, көл өемнәре. Шулар уртасында морҗасы яртылаш ишелгән кара, ятим мич. (Кышкы салкыннарда Госманның яратканы әнә шул мич башы иде бит!)

Госманнар урамы — мәчет урамы. Ул, сирәгәйгән урманны ерып, инештән күлгә хәтле сузылган иде. Мондагы йортлар, шушы йортлар урынында үсеп утырган калын-калын карагайлардан салынган иде. Госманнарның өе дә биек, дүрт тәрәзәле иде. Әле үткән язда гына Госманның әтисе, Күкчәтаудан бертуган энесе Миңлебайны чакырып, бергәләп салып чыккан иде. Ә хәзер... хәзер... Бер баштан икенче башка кадәр кара күмер хәрабәләр. Аргы очтагы йорт-ызба урыннары әле дә булса төтенли, ачы исе монда килеп җитеп тамак төбен кычыттыра.

Күпер башындагы Кәлимулла байның унике тәрәзәле алты бүлмәле өе дә, кибете, складлары да исән-сау калган. Аңа каршыдагы Сираҗ мулланың таза йорты да, куралары да, бер нәрсә булмагандай масаеп карап торалар. («Выты, ходай аларга тимәгән бит!»)

Җәфрәтил карт чатанлый-чатанлый мәчет хәрабәләре янына килеп басты, кулындагы таягы белән кисәүләрне кузгаткалап:

— Выты, бак, иблис мәлгунь җәбраилдан качып кайда поскан! Ә?! Тапкан урынын, алла йортына, манарага, ә? Выты, шул мәлгуньне сугам дип тәңренең утлы гөрзесе манарага төште. Байгыш кияү азанын да әйтеп бетерә алмады. Ай-һай, тавышы! Адәм тавышы гына түгел, сандугач иде, байгыш,— дип сөйләнде дә елап җибәрде.

Госман сөйләшерлек хәлдә түгел иде әле, юлда арыганнар онытылды, әле күргән кайгы-хәсрәтләр өстенлек алды. Янган өй, вафат булган әтисе...

Чыннан да, аның этисен куйдыlармы ләхеткә? Бәлки ул түгел, бәлки Гомәр азанчы, гадәтенчә, урманга утын кисәргә генә киткәндер? Ә? Выты, урман ягыннан арба тәгәрмәче тавышы ишетелә. Ул сагаеп тыңлап тора башлагач, арба тавышы ераклашты, сүнде, ишетелмәс булды.

— Улым!— Нәкъ шул секундта, Госманның күңел тавышын ишеткәндәй, Җәфрәтил карт телгә килде.— Выты, бу елны казахлар юкка гына «Дуңгыз җылы» дип атамаганнар. Ату, алтмышка җитеп мондый күк күкрәүне, яшен сукканны ишеткән дә, күргән дә җук иде. Муллаларның «заман ахыры» дигәннәре шулдыр инде. Выты, атаң алла йортында, азан әйткәндә, манарада дөньядан китте. Күз тидеме үзенә...

Нишләргә? Чит юлларда каңгырып йөргәндә, өметсезлеккә бирелгән чакларда ул «илем бар, өем бар, ата-анам бар!»— дип юана иде. Бак, хәзер ызбасы юк, атасы караңгы гүрдә ята. Нишләргә? Язмышы кая таба борылып китәр аларның?

— Әссәламегаләйкем, Җәфрәтил бабай!

Ят тавыш сүзне генә түгел, уйны да бүлде, карт та, егет тә башларын күтәреп тавыш килгән якка карадылар.

Урам уртасындарак ике тәгәрмәчле кечкенә кул арбасы тора. Арбада иске-москы, кием-салым. Аның өстендә ике-өч яшьлек ыштансыз бер малай акырып елап утыра. Арба астында корымлы, яньчелгән чиләк эленгән. Көйгән ике тәртә арасында кара сакаллы бер ир басып тора. Аның өстендә күптән уңып, ямау өстенә ямау яткан иске казачий формасы, козырегы урталай сынган, җәлпәйгән фуражка, ертык гимнастеркасы белән лампаслы чалбары да кояштан, җилдән саргайган, уң балагы ертылган, үзе яланаяк... Госман аңа карады да тетрәнеп китте, сул җиң буш, гәүдә аз гына кузгалуга, буш җиң әле аркага, әле күкрәккә сугыла. Арба артында алам-салам күлмәк кигән бер хатын бар гәүдәсе белән чайкалып, күкрәк баласын юата. Ул да яланаяк. Башындагы шакмаклы иске яулыгы бала өстенә сыдырылып төшкән. Хатын баланы селкеде-селкеде дә, тынмагач:

— Дөмек инде, көчек! Дөмек!— дип каргарга кереште.

— Зариф улым, синме бу?— диде Җәфрәтил карт, учын кашы өстенә куеп.— Бак, төнгә каршы кузгаласыңмы, кәбәм?

— Әй, бабакай, әйтмә инде! Кругом талыйлар.— Җиң шапы-шопы әле аркага, әле күкрәккә сугылды.— Патша кулны алды. Ходай ызбаны яндырды. Бу көчекләрне өстерәп келәнергә генә калды. Выты, мин сугышта крест алган герой! Ә выты битне ертып келәнергә кирәк...

— Дөмегеп кенә кит, җылан чагасы! Яп авызыңны!— Хатын йөгереп килеп акырып елап утырган малайның аркасына берне кундырды.

Иргә дә эләкте:

— Ә син, мәхлук, нәрсә бәбәкләреңне шарландырып торасың? Выты, бу чагаларны эшләргә белдең. Инде әпәй бирергә хәлеңнән килмиме? Тарт чагаларыңны! Караңгы төшкәнче далага чыгып котылыйк. Әйдә!

Тәгәрмәчләр юаш кына кузгалдылар. Арба артыннан ярсып үксүен тыя алмаган хатын атлады.

— Әйдә, улым,— диде карт ниһаять, зират үренә күтәрелеп барган Зарифлардан күзен алып. Анаң безнең өйдә яман чирләп ята. Авызына су салыр кеше дә юк. Сеңелең Мәрфуга Күкчетауга Миңлебай дәдәңә киткән иде. Выты, атаңны күрмичә дә калды.

Карт белән онык, башларын түбән иеп, үргә таба атладылар. Кояш ашыгып-ашыгып офыкка тәгәрәде. Әле генә дала юлына чыгып киткән Зарифлар белән очрашу Госманга бик авыр тәэсир ясады. Ул үз язмышының да аларныкы кебек үк караңгы, билгесез икәнлегенә төшенә башлаган иде инде.

## 4

Җәфрәтилнең чын исеме Җәлаләтдин иде. Заманында ул Имәнтауда гына түгел, әйләнә-тирәдәге станицаларның һәммәсендә атаклы тимерче,

ат дагалаучы иде. Рядовой казак-урыслар гына түгел, офицер-хорунжийлар, сотник, есауллар һәммәсе аңа баш орып киләләр. Хәтта атаманнар да атларын дагалатырга Җәләлетдин алачыгына киләләр, аңа ялыналар иде. Ул күз ачып йомганчы атның тоягын үлчәп ала, даганы таман гына итеп тапый, кадакларны да үлчәп кенә кисә. Стан янына килгән икән, кире китеп тормый, һәммәсе үз урынына кереп, батып кына утыра! Әллә нинди холыксыз, кире атларның җаен көйли, уч төбе белән бер-ике тапкыр аркасын кагып куйдымы, ат дигәнең юаш хайванга әйләнә дә кала. Дагаланганын сизми дә кала бичара! Тормыш аз-маз рәтләнә, тимерчелек даны тамак туйдырырлык кына акча китерә башлады дип куанганда, сугыш башланды. Казак полклары тиз генә җыйналып походка чыктылар. Җәләлетдиннең дә нәрәте җиткән иде, ул да баштанаяк урыс казагы формасын киеп, мылтык-кылыч асып атка менде. (Бу кирәк-яракларны рәтләү өчен Җәләлетдиннең атасы Гыйльметдин муеннан бурычка батты, ахырында түләп тә бетерә алмыйча, улы сугыштан кайтканчы ук, кышын урман кискәндә суык тидереп вафат булды).

Җәләлетдин үз сотнясында кыюлыгы җитезлеге белән бик тиз танылды, һөҗүмгә беренче булып ташланды, сугышның иң хәтәр, иң хәвефле җирләрендә дә сынатмады. Бер атакада төрек янычары сотня командирын чабарга дип кәкре кылычын күтәргәндә әллә каян гына Җәләлетдин килеп җитеп, төрекнең кылычлы кулын чабып өзде. Егетнең күкрәгенә беренче Георгий тәресе менеп утырды. Бераздан полковник аны үзенә драбанд[1] итеп алды. Озак та үтмәде, драбанд үз теләге белән дошман тылына разведкага барып ике француз солдатын әсир итеп кайтты. Тагын бер крест артты. Өченче тәрене аңа разведкага барып бик кирәкле мәгълүматларны табып кайтканы өчен кададылар.Җәләлетдин Георгий крестының полный кавалеры дәрәҗәсенә күтәрелде.

Ә бер көнне, һич көтмәгәндә, полк кухнясына котелок тотып ашка барганда, адашкан бер пуля килеп чыгып, сул аякның нәкъ челтәренә сукмасынмы! Ут эчендә күпме йөреп, кылычлардан башлар тәгәрәгәндә тырналуны да белмәгән Җәләлетдин тамак кайгыртып йөргәндә аягыннан аерылды. Көлсәң дә бер авыз, еласаң да!

Драбанд Җәләлетдин төрек сугышыннан өч Георгий кресты тагып, сул аягы урынына бүкән башы бәйләп кайтты.

Казак сугыштан кайттымы — бу зур вакыйга, күрешергә күршекүлән генә түгел, бөтен станичниклар килде. Шул уңай белән әзерләнгән бер чәйдә күрше хатыны Айшук, гадәтенчә, гайбәт сатып арыгач, Җәләлетдиннең әнкәсенә карап:

— Мәрьям әби, аллага шөкер әле, улың аягын калдырса да башын алып кайтты. Выты, Каз муен Сибайның арысландай ике улыннан берсе юк, улың аяксыз калды дип, берүк, җылама,— диде.

— И, күрше, ни сөйлисең?— диде Мәрьям әби.— Ник җылыйм ди? Аягын кабакта сугышып калдырмаган, патша хәзрәтләре өчен югалткан. Выты, күрдең, улымның күкрәге берче наград. Ут сыман янып тора.— Ана сөйли торгач, кызып та киткән:— Выты, улым әле рядовой түгел, аллага шөкер, әфисәр затыннан. Ни әле, выты, әйтергә телләр әйләнми, ни әле...— Карчык бераз төртелеп торган да, кычкырып әйтеп салган.— Выты, таптым, улым җәфрәтил булып служить иткән. Син, Айшук, юкка канны бозма!

«Драбанд» урынына карчыкның теленә «җәфрәтил» килә. Юкса, казак гаскәрләре кагыйдәсендә ефрейтор чины бөтенләй күрсәтелмәгән! Каян белсен Мәрьям карчык казачий уложениене! Әйткән сүз — аткан ук: кире кайтмый, Айшук иртәгә алып чыга да бөтен халыкка тарата. Шул кичәдән соң Җәләлетдиннең мулла кушкан исеме онытыла, олысы-кечесе аны Җәфрәтил дип кенә атап йөртәләр. Тиктомалдан килеп чыккан кушамат тимерченең үзенә дә хуш килә. «Җәфрәтил» тек «җәфрәтил»— аз булса да дәрәҗәңне күтәреп йөри! Кечкенә булса да — чин!

[1] Драбанд — элек рус армиясендә югары офицерларның тән сакчысы.

Тимерче аяксыз кайткач, тирә-як станицаларыннан казаклар: «Инде атларыбызны кемнән дагалатырбыз!»— дип пошына да башлаганнар иде. Әмма агач аякның мишәйте булмады, тимерче алачыгы тагын ачылды. Агач аяк Җәфрәтил бирешмәде, теше-тырнагы белән эшкә ябышты. Менә дигән елгыр, йөгерек атларга да, үзе әйтмешли, «тимер ката» кигертте. Узып барган офицерлардан, казак-урыслардан рәхмәт алып торды. Төшем дә ярыйсы иде, кайбер офицерлар, бигрәк тә кызмача булганда, аның аркасыннан кагып:

— Молодчина, наш полный Георгиевский! Он и блоху подкует, за это и рубль не жалко!— дип, көмеш, кайчагында алтын тәңкәләр дә ташлап китәләр иде. Шулай бара иде тормыш...

Беркөнне, соңарып кына, кояш баер алдыннан, Җәфрәтил алачык ишеген ябып кайтырга дип кенә торганда, күрше Сандыктау станицасы атаманы Зверев ажгырып торган алмачуарына менеп килеп туктады. Үзе нык кына кызмача.

— Давай, станишник, подкуй моего яблочка, да так, чтобы да самого Петербурга можно было скакать!— диде ул айгырын Җәфрәтилгә терәп туктатып. Атаманның сүзен кире кагып булмый, Җәфрәтил алачыкны ачты.

Алдагы ике тоякны тиз тәпәләде. Арткы тоякларга тотынгач кына, алмачуар холкын күрсәтә башлады. Дулады, куш аяклап сикерде, Җәфрәтил үз җае белән генә ипкә китерә башлаган иде, атаман атка нагайкасы белән берне сыдырды. Хайван шунда ук котырган арысланга әйләнде, ажгырып күккә сикерде, путаларны өзеп, станны аударды, тимерчене тибеп очырды.

Шул кичтән Җәфрәтил ат дагалаудан калды — биле кузгалган иде, гомергә рәтләнмәде, яз-көз үтереп сызлады. Умыртка сөяге мертеккән булырга тиеш! Мунчада кычыткан белән чаптылар, кырмыска мае белән сыладылар, өшкереп тә карадылар, күрше казах авылына шаман-баксыга алып бардылар, ул ут-су белән имләде, файдасы булмады. Җәфрәтил югалткан акчасын эзләп йөрүче байгыш кебек җиргә иелеп йөри торган булып калды.

Авыру бетсә дә, гадәт бетми, диләр. Җәфрәтил картта икесе дә калды: гадәте дә, авыруы да. Станицада ул иң беренчеләрдән булып уяна. Алачыгының төтенгә какланып каралган ишеген төбенә хәтле каерып ачып ташлый. Учак янындагы кара баганага эленгән, үзе белән яшьтәш, кыршылып-көеп, тишкәләнеп беткән күкрәкчәле күн алъяпкычын буа, билен кысып бәйли һәм ишек кырыендагы дәү ташка чыгып утыра. Аннан соң гына станица хатыннары кузгалалар, сыер савалар, шау-гөр килеп көтү куалар, каз-үрдәкләрне ирекkә чыгаралар.

Җәфрәтил агач аягына кыстырып куйган күн тәмәке янчыгын ала, иске китап битеннән бер телем ертып, «кәҗә тәпие» урый. Тәмәкене яратып, пох-пох итеп, куе төтен чыгарып тарта. Күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр коелса да бакчасында үзе үстергән тәмәкене тарта. Узган-барганнар аның янында туктамыйча калмыйлар, урысчалап, казахча, татарча сәлам бирәләр. Җәфрәтил берсен дә җавапсыз калдырмый, һәркайсына үз телендә җавап бирә, шаян-күңелле сүзен дә кыстырып куя. «Кәҗә тәпие» янып бетә, төпчекне теләсә кая ташламый тимерче, сандал янындагы карамай төсле сулы чиләккә ыргыта. Аннан ике учына да яхшылап төкерә, үзе белән бергә картаеп килгән, бик күп тимернең башын ашаган почык борынлы чүкеченә ябыша. Эше хәзер вак-төяк, хатын-калачка — кучарка, кәпкер, табагач, чиләк-миләк, күмер савыты, ир-атка — тырма, сәнәк, көрәк, балта, пычак, капка-ишек тупсалары, келә, тоткычлар... Менә шундый кәкре-чәкрегә калды атаклы тимерченең хәле!

Карчыгы исән чакта җан сакларга була иде әле! Җәфрәтил картның хатыны Мәрьям әби, кылтамак авыруына дучар булып, бер ел чамасы тамагына аш үтмичә интекте. Ниһаять, коры сөяккә калып, былтыр яз

ураза башында вафат булды. Шул ук көзне нәрәте җитеп, картның ялгызак улы Хабушны (Хәбибулланы) хезмәткә алып, себер казак гаскәрләренең дүртенче полк составында Манҗуриягә озаттылар. «Кара, улым, хат язып тор. Выты, ялгыз калдым. Анаң да җук! Онытма!»— дип, кат-кат кисәтсә дә, көз үтте, кыш үтте, Хабуштан кош теле кадәр дә язу килмәде. Карт инде түземен тәмам югалтып, иңге-миңге булып түшәккә егылганда, алачык ишеген калын көрт басып киткәндә, яна ел башында, станица идарәсе писере Иван Петрович хат күтәреп килде. Карт терелеп, торып утырды, хатны кат-кат укыды: «Атакай, үзем хәзер Пртартур дигән калада, диңгез янтыгында служить итәм. Монда берчесе кытай белән япон. Үзләре фанза дигән койты өйләрдә торалар. Без, атакай, иртәдән кичкә кадәр ат өстеннән төшмибез, кылыч белән чабарга, атакага барырга, атарга үрәнәбез. Выты, сигнал! Туган-тумачаларның барысына да сагынып сәлам. Әлегә шанго. Зарыгып, хат көтеп калучы улыгыз Хабуш дип беләсезләр».

Хат картны канатландырды. Чатнама суык булуга карамастан, ул ярты станицаның ишеген ачты. «Выты, Хабушымнан хат, сау-сәламәт. Берчегезгә сәлам әйткән»,— дип, кайда үзе, кайда башкалардан укытып, сөенеп туя алмады. Әмма хатның азагындагы бер сүз аның күңелен тырнады. Карт үзе дә, башкалар да «шанго»[1] дигән сүзнең мәгънәсенә төшенә алмый аптырадылар.

— Мотлак, бу, Җәләлетдин, шәңге дигән сүздер, башкача түгелдер,— диде, хатны иң соңгы укучы Сиражетдин мулла.

— Шәңгене ярата иде анысы... Ул Пртартур дигән калага шәңге җибәреп булырмы соң? Бик ерак җир бит.

— Юлда күгәреп бетәр шул!— дип аның шиген көчәйтте мулла.

Шулай дөнья куып, «шәңге-шанго»лар белән баш ватып язга чыктылар, кыр эшләре бетеп калды һәм, мә сиңа, хәсрәтнең бик зурысы, һич көтелмәгән яктан килеп чыкты. Бер төн эчендә Әминә кызы кияүсез дә, йорт-җирсез дә калды. Җитмәсә, үзе бик сырхау: көч-хәл белән аягын сөйрәп йөри! (Ничек янмагандыр ул, уттан кемнәр сөйрәп чыгаргандыр аны!) Әминәне атасы йортына көч-хәл белән култыклап китереп куйдылар.

Аптырады да калды Җәфрәтил карт — әллә мәет янында булырга, әллә һуштан язып егылган авыру кызын карарга! Бер көндә ызбада өч кашык артты! Ерак сәфәргә, гыйлем эстәргә чыгып киткән оныгы Госман да берни майтара алмыйча кайтып төште...

Дөрес, әлегә ике генә кашык артты, бу казадан бер атна гына элек Гомәр кияве ун яшьлек кызы Мәрфуганы Күкчәтаудагы энесе Миңлебайга кунакка алып барып калдырып кайткан иде. Күңеле сиздеме әллә Өмәрнең? Сабый күңелле кызын бу афәтләрдән азга гына булса да аерга теләдеме? Иллә-мәгәр кыз анда озак кунаклый алмас, Миңлебайның үзендә дә ызба тулы бала (ходай ярлы-ябаганы чага белән тутыра, рәхмәт төшкере!). Әйтергә ансат, бер балтага җиде авыз карап торалар. Миңлебай алсу таңнан кара төнгәчә чаба да чаба, йомычкасы күп оча, акчасы гына төшми. Кайтыр Мәрфук, иртәгә үк кайтуын көт тә тор. Алмачуар айгыр бер бөккән иде Җәфрәтилне, дөньясы инде җиде бөгәргә җыена.

Юанычы бер Җәфрәтилнең — ул да булса Госманы. Төшеп калган түгел, ак өстендәге караны таный, выты, унбиш яшендә кайлардан йөреп кайтты! Бераз шук, дуамаллыгы да бар, кирелеге дә җитәрлек. Выты, Кәлимуллага барып сөйләшсәң, бәлки, кибетенә алып та куяр? Аннан эшләр худка китәр иде!

Кичен йокларга яткач, карт әле бер, әле икенче янбашына авып, ыңкылдап шулай исәп йөртте.

Ә Госман?

Ул үз койрыгына утырып шуыша башлаган көненнән әби-бабасының

[1] Шанго — кытайча, яхшы дигән сүз.

ызбасыннан чыкмады. Мәрхүмә Мәрьям әби «колыным, бәбекәем!»— дип сөеп-сыйпап кына йөртә иде аны. Бала — бал, баланың баласы — җан, дип юкка гына әйтмиләр, күрәсең. Өсте алынмаган каймаклы сөт — аңа, тәмле катык, кызыл эремчек, сыкма, күкәй — Госман алдында. (Җәләлетдиннең бар вакыты иде шул! Курасында сыеры, кош-корты, хәтта мүкләк кәҗәсе дә бар иде! Былтыр алар барысы да Хабушка казачий снаряжение, ат, ияр-тукым алуга китте, хәтта җитмичә дә калды. Кәлимуллага бурычка керергә туры килде, каһәр!)

Бераз үсә-калкына төшкәч Госман, вак-төяк шуклыгы өчен атаанасыннан талчыбык төшәрен сизүгә, бабаларына чыгып кача иде.

Имәнтауда Шәкир хәлфәдә дүрт кыш Иман шарты, һәфтиякләрне ятлап, авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, әтисе Госманны Күкчәтауга алып барып, атаклы Фәхретдин ибне Мифтахетдин кулына тапшырды. Күкчәтау татарлары: «Фәхретдин хәзрәт үтә галим икән, үзе китап язып Казан каласында ташка бастырып чыгара икән»,— дип сөйлиләр иде. Дөрес, Георгийның полный кавалеры драбанд Җәфрәтил бу сүзгә бик үк ышанып та бетмәде, алай да, Миңлебайларга кунакка баргач, күршесе Хәйретдин килеп кереп, ике кич рәттән «Елан патшасы Шаһмара» дигән китапны укыды. Әкәмәт кызык булып чыкты ул кыйсса! Елан патшасы ап-ак була икән, аны алтын табакка куеп, күтәреп кенә йөртәләр икән. Үзе адәм теле белән дә сөйләшә ала икән!.. Кышкы буранлы кичләр иде. Ике кич Җәфрәтил карт онытылып кыйсса тыңлады. Кыйссаның ахыры бик аяныч булды. Үзен тоткыннан коткарган Шаһмараны адәм баласы патшага әйтеп үтертә. Выты, нинди вафасыз безнең брат! Шул китапны, имеш, Фәхретдин үзе язган! Җәфрәтил ышанып-ышанмасрак кайткан иде, соңгы вакытларда хәзрәтнең сүзенә бөтенләй ышанмас булды! Шул Фәхретдин козгын сүзенә бирелеп Гомәр азанчы бердәнбер улын Бәйрүт шәһәренә, муллалыкка укырга юнәлткән иде. Бәйрүтенә барып җитә алмыйча да кайтты! Ерак дөньялар икән ул Бәйрүт дигәннәре!

Уйлар, мич башындагы тараканнар кебек кыбырдап, йокы бирмәделәр.

Бу төнне сәкенең икенче башында яткан Госманның да күзенә йокы эленмәде. Арыган тәне ял итәргә тели иде ләбаса, кайда арбада, кайда дала чирәмендә бөкләнеп ятып ял итеп кайткан зәгыйфь тән изелеп йокларга тиеш иде, юк, күзен йомып кына куя, күз алдында җимерек мәчет манарасы килә. Дулый-дулый ут яна кебек! Ут-ялкын арасыннан Гомәр азанчының тонык шәүләсе күренеп китә. Улының ерак сәфәрләрдән бушка ґына урап кайтканын белми дә китте! Госман авыр ыңгырашып тагын торып утырды. Әнисе әллә кайчаннан тыңланып ята икән, ул тартылып улының юеш маңгаен сыйпады.

— Йокла, улым, йокла...

Күпме йоклагандыр үсмернең җаны, кинәт ызба чайкалып киткәндәй булды. Шау-шу. Госман тагын сискәнеп сикереп торды. Тагын шомлы төш кергәнме? Өнме әллә? Дөп тә дөп! Нәкъ тәрәзә алдында ат кешнәп җибәрде. Кемдер ачы итеп сызгырды. Өн! Идән такталарын тибрәтеп тагын җайдаклар чабып узды. Госман сикереп торып урам якка атылды. Кояш яңарак кына күтәрелә башлаган, салкынча дымсу. Станица уянган, шау-гөр килә. Капка алларында хатын-кыз, карт-коры. Станичниклар атка менеп алганнар, арлы-бирле чабалар. Инеш аръягындагы идарә каршындагы мәйданда ыгы-зыгы тагын да көчлерәк. Атлылар мәйдан уртасына чыгып рәткә тезелә башладылар. Озакламый рәтләр башында тимгелкүк ярсу атта станица атаманы Роман Михайлович Волков та күренде. Кискен команда тавышы яңгырады. Атлы казаклар сафларында тигезләнеп, «шып» калдылар. Тагын команда тавышы яңгырады, алтышар-алтышар тезелгән атлылар берьюлы кузгалды. Уйнаклап торган тимгелкүк ат чабып сотняның бер алдына, бер артына чыкты, атаман өзәнгегә басып күтәрелә төшеп тагын ниндидер командалар бирде.

Зиһененнән төнге шәүләләр чыгып бетмәгән Госман шунда гына аңлап алды. Ат өстендә яшь казаклар, көзен хезмәткә китәсе, чираттагы наряд ич! Барысы да өр-яңа казачий формадан, куе яшькелт гимнастерка, кызыл лампаслы кара постау чалбар, аякларда мул итеп деген белән майланган шпорлы күн итекләр. Күбесенең кунычлары гармун күреге сыман сыерылып төшерелгән. Шпоралар чыңлап куя, итекләр өр-яңа ялтыр өзәңгеләрдә сизелер-сизелмәс кенә сиртмәләнәләр. Казакларның башларында фырт киелгән кызыл каймалы, кара-көзге козыреклы фуражкалар. Фуражка астыннан учма-учма кара, сары, аксыл чәчләр бүселеп тора. Боларда әле казакның төп күрке булган көрәк-көрәк сакаллар юк, борын төпләрендә булыр-булмас кызгылт, кара төкләр генә бөдрәләнеп килә. Монда ике очтан да җыелган рус, татар казаклары, хәзер кемнең кем икәнен әйтү дә мөмкин түгел, туган ата-аналары да юньләп карамаса аерып ала алмас — барысы да янып-пешеп торган егетләр. Беренче тапкыр язгы сборга лагерьга чыгалар.

Тояк тавышларыннан җир тирбәлеп, гүләп тора, житкән кызларның шар ачылган күзләрендә соклану, кызыксыну, тагын әллә нинди яшерен өметләр. Кызларга күз төшкәч яшь казакларның башлары тагын да югарырак күтәрелә, алар юри аякларын селкеп шпорларын шалтырааталар.

Сотня Җәфрәтил карт ызбасына якынлаша, атлар, атлар! Нинди генә юргалар юк монда: күмер кара, җете җирән, күк, алмачуарлар! Берсеннән-берсе төз, коеп куйган муеннар, башлар югары чөелгән, ялларын җилпеп тып-тын басып киләләр.

— Бак, олан, син дә чыктыңмы?

Госман таныш тавышка борылды да имәнеп китте — кем соң бу? Чыннан да аның бабасы Җәләлетдинме? Әллә?! Һич танырлык түгел үзен. Башында иске булса да хәтәр генә менеп утырган кызыл каймалы фуражка, өстендә төсен югалтса да чиста юылган, бәләкләнгән гимнастерка, әйләндереп теккән чалбары да килешеп тора үзенә. Бил ике башлы сәмруг кош сугылган каптырмалы киң каеш белән кысып буылган. Уң аякта туйганчы карамайланган күн итек. (Сул аякның бүкән башы гына Имәнтау бәйрәменә битараф булып һаман искечә калган). А, күкрәк! Күкрәкне күрсәгез иде сез! Ялт иткән көмеш тәреләр, юл-юл чуар ленталар кояш нурында балкый. Сакал-мыек та таралган, урыннарыннан купкан җиз төкләр, очкынланып, менә-менә кабынып китәргә торалар.

— Менә, улым,— диде тамак төбенә утырган каты төерне йотып.— Агаларың язгы сборга китә. Инде, выт, сиңа да ат-сбруй, мундир әзерләргә вакыт! Без, улым, язмыштан казак булдык. Ә син, улым, тумыштан казак! Димәк син, настоящий казак! Чыны. Выты, озакламый, нарядың да килеп житәр. Сизми дә калырсың.

Карт нидер әйтеп фикерен ныгытмакчы иде, сотня алдында, мәһабәт гәүдәле, зур кара сакаллы атаманның якынлашып килүен күргәч, сүзен бүлде дә ашыгып, агач аягы белән чирәмне изә-тишә, юл кырынарак атлады, уң кулын фуражкасына күтәреп «шып» басты. Селкенми. Хәтта, гадәттә чылт-чылт йомылып торган күзләре дә шарланып туктап калганнар. Госман, бабасының бу халәтен күреп, пырхылдарга уйлаган авызын тиз генә учы белән томалады. Ул арада атаман карт белән тигезләште, ул да кулын ялт фуражкасына күтәрде һәм калын, кырку тавыш белән гөрелдәде:

— Здравствуй, полный кавалер Георгия станичник Жамалетдинов!

Әйләнә-тирәдәгеләр генә түгел, аркамак та колакларын тек торгызып, тын алуын өзеп шаккаттылар — атаманның сәламенә агач аяклы сәләмәни әйтер?

— Рад стараться, господин атаман!

Дөрес, соңгы «атаман» сүзе бераз саңгыраурак чыкты, Җәфрәтилнең сулышы житмәде, аның каравы атаман бу җавапка разый булып елмайды, мактап та куйды:

— Молодец, казак, благодарствую!

Атаманның елмаюын беренче күрүе идеме, Госман моны бик нык хәтерләп калды.

Тавышлар тынды, юл тузаннары төшеп инде, тамашачылар үз эшләренә таралдылар. Җәфрәтил карт казакларны озатканнан соң әллә яшәреп калды, әллә дәртләнеп, шушы киенгән шәпкә Сиражетдин мулла янына китте. Озак та тормады, әйләнеп кайтты һәм сәке түренә, иске-москы киемнәр өелгән почмакка кереп ятты. Сәкенең аргы башыннан зәгыйфь кенә хатын-кыз тавышы ишетелде.

— Атай, ни булды? Әллә син дә чирләдеңме, атай?

Җавап булмады. Әллә инде карт ишетмәде, авыр көрсенеп еш-еш сулады.

— Уф!

— Атай дим!— Кинәт еламсыраган ачы тавыш ызбаны телеп уткәндәй булды.— Син дә чирләсәң...

Ниһаять, сырхау хатын торып утырды. Әле җыерчыклар белән дә телгәләнергә өлгермәгән озынча, какча йөз. Әллә авырудан, әллә тәрәзә карындыгыннан төшкән тонык шәүләдән бу йөз зәгъфыран сары күренә. Эчкә баткан күзләрне каймалаган саргылт керфекләр сирәгәйгән сыман. Менә алар калтырандылар, биткә әүвәле бер, аннан тиз-тиз тамчылар коела башлады.

— Атай, ник дәшмисең?

— И, кызым, кызым. Тьфу! Ден дә юк, иман да юк үзләрендә!

Тетрәнүле зәгыйфь тавыш үзәге өзелеп сорады:

— Буш кулмы җибәрделәр? Ник сөйләмисең?

— И кызым, ни әйтим дә, ни сөйлим? Койты, кызым, безнең эшләр. Мулла көн дә мәчеттә вәгазь сөйли иде. Фәкыйрь фәкыйрьгә ярдәм итегез, ди. Выты, бардым, әйләнеп тә бакмый, тәсбих тарткан булып утыра. Аның каравы, абыстай чәң-чәң килә. «Ярты Имәнтау көеп китте, берчесе хәер кели, кайсын тыгындырырга да белгән юк»,— ди. Мин әйтәм: «Көфер сүләмә, абыстай, дим. Каза алладан килгән. Мәрхүм Гомәр кияү, аның ягыннан үзең дә туган кеше, выт... алла юлында, азан әйткәндә каза тапты. Ике чагасы калды. Хатыны, үзең беләсең, өченче ай, түшәктә хәл эчендә ята. Йорт-җирләрен, бар азыкларын ут йотты...» Вәт китте абыстай тезеп, китте сөйләп! «Азан әйтсә ни, савабын да алды, шәһидләрдән китте. Гомәр азанчыны мулла абзаң үтермәде, аллаһе тәгалә үзе алды. Бүген сезгә бер подаука он бирсәң, иртәгә капчык тотып килерсез»,— ди, кан йоткыры!

Карт ярсыган, тулган иде, сүзләрен бушатып, сәке өстенә сузылыбрак ятты.

— И аллам, нинди хурлыкларга дучар иттең безне!— диде хатын гарьлегенә түзә алмыйча рәнҗеп.— мәрхүмем язын-көзен шул мулла абзыйлар абзарыннан чыкмады. Төн йөгерде, көн йөгерде. Әйттем үзенә, Өмәр, нигә шулай өзлегәсең, дидем. Ә ул әйтә: «Әминә, алай димә син, мулла абзый ялгыз, үзе ходая кеше, мин йөрмәсәм кем малын багар?» Выты, инде күзе йомылгач, чагаларына бер подаука он кызганган! Оят юк икән үзләрендә. Ә выты, ашта-суда утырганда абыстай майга салган коймак кебек чыжлый: алла, ди, ятим-ятимәләргә шәфкатьле булыгыз, ди.

Госман ишек катыннан да узарга базмыйча аларның сөйләшкәнен тыңлап утырды. Менә әнисе йөткеренде, сыкрап алды һәм:

— Атакай, әллә Кәлимуллаларга барып карыйсыңмы? Безнең Госман дөм сукыр түгел, укуы бар, урысчаны да яхшы сукалый, кибетенә алмасмы?

— Аны, кызым, үзем дә кичәдән бирле оеткылап йөрим йөрүен. Тик менә Кәлимулла алдына барырга шүрлим.

— Ник?

— Белмисең?— Карт ачуланып тавышын күтәрде.— Ник булсын, Хабуш братыңны службага озатканда кердекме бурычка? Кәлимулладан 60 сум карызга алырга туры килде. Шуның 23 сумы әле түләнмәгән. Инде йөзне ертып булса да, кич кырын, кеше-кара югында, дөкәненә кереп тә чыгармын, ә?

— Хәере белән!— Әминә бераз тынычланып китте.— Эштән курыкмый, тырыш олан, диген.

— Бабакай!— Сүзләрен бүлеп, ишектән тузган чәчле, түгәрәк йөзле, өстенә тигезле-тигезсез итеп күк буяуга манылган киндер күлмәк кигән (итәгеннән кызыл ыштан балаклары күренеп тора) тугыз-ун яшьләр чамасы бер кыз йөгереп керде дә Җәфрәтил карт алдына ак киндер тастымалга төрелгән бер нәрсә китереп куйды.— Выты, бабакай, әнием бирде, сәдакадан булсын, диде.

Карт әүвәле аптырап калды, бер кызга, бер алдындагы төргәккә карады. Аннан тастымалны ачты — ызба эченә хуш ис аңкыды. Әле яңа гына мичтән алынган, кабарып, кызарып, кетердәп пешкән бөтен бер бодай күмәче! Тәмле исе борынны яра, җылысы кулларга үтеп керде. Карт та, Әминә дә, өнме бу, төшме бу, дип күмәчкә карап беравык тынсыз калдылар. Йөзләре яктырып, телләре ачылып китте.

— Бәракалла, бәракалла!— Карт сабый баланы үчтергән сыман, күмәчне учында сикертеп бер кулыннан икенчесенә күчерде.— Сөбханалла, оҗмах бакчасының исе килә!

— Матурым,— диде Әминә кызга борылып.— Син кем кызы соң? Әле, чирләгәч, хәтерем йомшаган.

— Минме, апа?—«Матурым» сүзе килештеме, кызчык кызарып, уңайсызланып китте.— Бибиш кызы ла, Гөлйөзем.

— Әйе... Кара, нинди үсеп калгансың. Бибикамалга рәхмәт әйт, әниеңә, рәхмәт инде, үзе ятим, ызбасы тулы чага. Выты, шунда безне искә алган!

— Атай, әйдә, сәдакага бер дога кыл инде!

Җәфрәтил дога кылды, ул гына җитмәс кебек күренгәч, битен сыпырып «Я раббем, безне сөендергән өчен хода Бибикамалга исәпсез-сансыз куанычлар насыйп әйләсен. Амин».

— Рәхмәт әйт анаңа!— диде Әминә, кызга ягымлы борылып.

— Шуны әйтәм, выты, муллага барып келәнеп бер уч он ала алмадым. Ә монда, Бибикамалны әйтәм, тол хатын, авызыннан өзеп, тегермән ташы сынлы дәү күмәч җибәргән...

Госман кызга ияреп урамга чыкты, аны күз белән озатып калды. Өйгә керим дип борыла башлаганда гына кемдер аның җиңеннән тартты.

— Әйдә, балыкка барасыңмы, Госман?

— Ә, ни?

Караса, күрше Аю Мөхәммәт малае Бәһау. Ул атасына тартым — тыгыз коелган, аз гына бөкресе чыккан, әмма кайдан тотса, шуннан өзеп ала торган нык малай. Бите сипкелле, борыны почык, башында «арыш камылы». Госманның ахирәте.

Станицадан дүрт-биш чакрымга, Казантау итәгенә, култыкка бардылар. Суы тирән, үзе тыныч, җил дә исми, җимгә килгән балыкларны әллә каян шәйләп була.

Күптән мондый рәхәтне татыганы юк иде Госманның, салуы була, калкавычы батып та китә. Алган саен куана егет: «Выты, әнкәйгә уха була! Яратып ашаса, терелеп тә китәр!»

Күл читендә, комда казылган казанда, инде утыздан артык балык!

— Бак, Әптери! Кызылбаш, вын, балык каптыра.

— Выты, шушы йолкышмы?

— Ха-ха-ха!

— Кызылбаш, Кызылбаш, хаҗи!

Калкавыч уйнаклап батып бара иде, арттан мыскыллаган тавышлар ишетелде. Ачуы килсә дә Госман борылып карамады, алай да каушап, эләккән балыгын ычкындырды.

— Йолкыш, борылып та карамый.

— Выты, Мәккәгә барган!

Госман ачуыннан иренен тешләде, кармагына җим саплап күлгә ыргытты, ике куллап корыгына тотынды. Калкавыч бер урында торды-торды да кинәт батып китте. Госман тартып җибәрде, корык сыгылып төште, беләк буе чуртан! Куркуыннан егетнең тыны кысылды, җеп өзелеп харап булмаса гына ярар иде!

Якындагы сандык таш өстеннән Баһау купты, кармактагы чуртанны күреп кычкырып җибәрде:

— Ярга бәр! Малны ычкындырма! Замат!

Госман корыкны күтәреп ярга селтәде, җеп өзелеп тә китте. Әмма чуртан очып барып ярдан шактый еракка ком өстенә төште, бәргәләнә-бәргәләнә сикерә башлады. Госман борылып караганда каныna тоз сибүчеләрнең кем икәнен танып та өлгерде: шулар икән, кибетче Кәлимулланың улы Галимулла да, мулла абзыйның төпчеге Рәхимулла. Әле дә телләрен чыгарып үчекләп торалар. Госман аларга игътибар итмичә, комга бата-бата ярты ай булып сикергәләгән чуртан янына ашыкты. Ул арада Галимулла йөгереп барды да ком өстеннән чуртанны эләктереп алып күлгә ыргытты.

— Выты, чуртаның, Кызылбаш!

Рәхимулла куанычыннан сикерә үк башлады.

— Чуртан Мәккәгә китте, китте!

— Галкәш! — диде Госман ярсып. — Нигә минем чуртанны күлгә бәрдең?

— Бак, Рәхимулла, аның чуртанын! — Галимулла авызын кыйшайтып көлә бирде. — Синең чуртан Мәккәдә ком өстендә йөзә.

Әллә ни арада яр астына 12—13 яшьлек үсмер кыз килеп чыкты. Тулы, түгәрәк йөзле, зәп-зәңгәр күзле, кызыл ефәк тасма белән үрелгән аксыл чәчле кызны күргәч Госман да, әтәчләнергә җыенган Баһау да тынып калдылар.

— Әй, Галка! — диде ул шактый ачулы тавыш белән. — Нигә Усманнан көләсең? Беләсең, әле генә аның әтисе үлде. Әнисе авыру! Ник син аның балыгын күлгә ташладың, оятсыз!?

Галимулла төкерегенә чәчәде:

— Синең, синең монда ни эшең бар, Машка?! Кит моннан! Выты, атаман кызы дип тормам!

Ачык якалы, кыска җиңле, кызыл шакмаклы күлмәк кигән атаман кызы Маша сугышырга торган әтәчкә охшап китте. Ул, чебиләрен явыз тилгәннән яклаган тавык кебек кабарынып, малайлар өстенә килә башлады:

— Яле, карап карыйк!

— Туктагыз! — Арага Госман килеп керде. — Тукта, Маша. Ә син, Галкәш, нигә миннән көлгән буласың!?

— Кит, хәерче! Йолкыш Үмәр малае! Бабаң келәнче!

Галимулла сүзен әйтеп бетерә алмады, Госман яшендәй атылып аның кулларын аркасына каерып кысты да, тыпырчынуына, акыруына карамастан, сөйрәп яр буена китерде, күтәреп алып күлгә, чуртан артыннан йөзәргә ыргытты. Моны күреп Рәхимулла алдын-артын карамыйча станицага таба качты. Галимулланың энҗе белән чиккән бәрхет кәләпүше күл өстендә калкып, йөзеп китте. Баһау белән Маша кул чаба-чаба көләләр иде.

## 5

Икенче көнне Җәфрәтил карт оныгын көтүдән үк уятып, янган нигезгә алып китте. Икесе дә башларын иеп, сөйләшмичә иярделәр, әллә йокылары туймаган, әллә кайгылары бик авыр.

Кояш әле генә күтәрелеп килүгә карамастан, станицада ыгы-зыгы. Урам-тыкрыклардан (бигрәк тә урыс очыннан) мөгри-мөгри сыерлар чыга, аларның чиләк-чиләк җиленнәре як-якка чайкалып бара. Госман ат эчерергә төшеп барган малайларның һау-һуларын ишетмәмешкә салышты. Карт драбанд да кеше күзенә чалынмаскарак тырыша иде, биргән сәламнәренә дә теләр-теләмәс кенә җавап бирә. Урыс очында быргы тавышы яңгырый башлады, аны ишетеп хатыннар сыерларын кыздырып куа башладылар.

— Әйдә, улым,— диде карт, янган йорт нигезенә килеп җиткәч, ниһаять, телгә килеп. Аяк астындагы кисәүләрне таягы белән ары-бире суккалады.

— Выты, бу кисәүләрне җыеп замат арасында өеп куйыйк. Атаң мәрхүм, кышлык утынны,- выты, шунда өя торган иде. Тере кешегә кыш замат килеп җитәр. Утын кирәк булыр.

Гел кайгыга сабышкан бабасы белән Госманның ялгыз каласы килми иде, ул аннан котылу җаен эзләде.

— Бабай,— диде ул.— Син өйгә кайтып анакай янында торсаң, мин монда үзем, замат...

— Кичә кайнар уха ашагач тәмләп йоклап китте. Шифалы булды уха, күрәсең. Ә монда, кабәм, ялгыз булмый. Берең лом белән каерып күтәрсә, икенчең ташып торыр. Вын, баз янтыгында лом белән көрәк ята. Бар, китер әле үзләрен.

Җәфрәтил карт лом белән көл астында калган идән-түшәм такталарын каерып чыгара торды. Госман аларны элекке койма урынына ташып өя барды. Бер башлангач эш кызды, кояш яман да кыздырды, көлсөрем сарган битләрдән тир карамай булып акты. Матчадан калган бүрәнәне кузгату гына читен булды, карт сыңар аяк, көче дә әллә кем түгел, Госманга килгәндә, аның хәл бөтенләй яман иде. Аның эшен ярты юлда ташлап моннан китеп барасы килде, тик бу турыда бабасына әйтергә курыкты. Әйе, кыш килеп җитәчәк. Кышның үз исәбе, ул синең йортың юк дип, ашарыңа аз дип исәпләп-санап тормас, куырып кына алыр...

Төшкә кадәр бик бирелеп, аны-моны сөйләшмичә дә эшләделәр. Өзелеп карыннары ачты.

— Әйдә, улым,— диде карт, маңгаеннан аккан кара тирне җиңе белән сөртеп.— Өйгә барып ярты булса да капкалап килик.

Алар өс-башларын көл-балчыктан каккалаган арада Югары очтан бөкре башкорт әби килеп чыкты. Кулындагы төенчеген элек капка янында утыргыч хезмәтен үтәгән яргаланган ташка куйды да, нәзек, моңлы тавыш белән сөйли дә башлады.

— Иртәнчек кенә Чәүкә Закирларга барганда һезне монда күрдем дә бәгырьләремә тоз һауды! Менә бит калай, ходайның бирмеше, кечәгенәк кенә хәйран булып торган азанчының йорты вәйран булды да калды.— Карчык төенен чишеп бетереп, таш өстенә бер чүлмәк сөт, олы гына түтәрәм калач куйды.— Әрвахның рухына сәдакадан булсын. Әйдәгез, дога кылыйк.

Җәфрәтил карт ашыгып килеп, агач аягын сузып таш кырыена утырды. Карчык баскан җиренә генә чүкте, Госман көлгә тезләнде.

— Амин.

Җәфрәтил, гадәтенчә, башын ия төшеп, белгәне Әлхәм сүрәсен укып, битен сыйпап күзен ачканда янында башкорт әби юк та иде.

— Сөбханалла,— диде ул як-ягына каранып.— Күз будылар дисәм, алдыбызда калач белән сөт.

— Әнә, әби йөгереп барадыр,— диде Госман, күрсәтеп.

Куе, каймаклы сөт белән калачны ашап алгач икесенең дә кәефе беразга рәтләнде. Җәфрәтил карт таш өстенә утырып «кәҗә тәпиен» төрде, чакма чагып ут төшерде һәм рәхәтләнеп «поф-поф» итеп ачы тәмәкесен суыра башлады. Госман җирдән чыбык алыпниләрдер сызып маташты, янәдән көл-корым арасында маташасы килми иде аның. «Әллә Баһауны эзләп табып, тагын күлгә китәргәме?.. Тагын Галимуллалар тап булса?! Кичәге өчен үч алмыйча калмаслар әле алар!» Шулай уйлагач Госманның күз алдына балкып торган Маша килеп җитте. Электән үк белә Госман бу чая кызны! Башкалар янында чәчрәп торса да ул, Госман белән очрашканда нигәдер басылып, юашланып кала. Сөйләшкәндә дә тыйнак кына, оялып кына сөйләшә.

Кинәт егетнең колагына сәер бер тавыш ишетелде. Кемдер ыңгыраша түгелме? Ул бабасына карады һәм тагын танымады. Юк, кичәге сыңар аяклы бөркет түгел иде Җәфрәтил драбанд, аның иң башлары сикереп-сикереп китә, бармаклары арасына кысылган тәтенле «кәҗә тәпие» туктаусыз калтырана иде.

— Бабакай!— Госман аптырап эндәште.— Әллә елыйсыңмы?

Карт эндәшмәде, башы тагын да түбәнрәк иелде, аннан лач итеп борынын сеңгерде. «Кәҗә тәпие» җиргә барып төште.

— Выты, уйлап бак. Бердәнбер дәдәң Хабуш Кытай җирендә. Кем белә, әллә тере, әллә юк...

— Хәзер безнең патша сугышмый бит.

Карт башын чайкады.

— Служба, улым, служба! Анда сугыш булмаганда да үләләр. Выты, бак бу пянук башына!— Карт агач аягын мылтык кебек сузып җибәрде.— Выты, атакага йөргәндә баштан сыңар чәч бөртеге дә төшмәде, каша сорарга барганда аяксыз калдым. Бу арада Хабушым берчә уемда йөри. Хәерлегә микән?

Госман бабасының уен башка якка борып җибәрер өченме, әллә инде күптәннән сорыйсы килеп тә җае килмәгәнгә сузып килгән бер сорауын, хәзер бабасының күңеле үтә нечкәргәндә әйтеп калырга ашыкты:

— Бабай, Аля авылы кай якта?

— Кайда булсын?— Карт нигәдер сүзне ачу белән башлады.— Син, выты, Мәскәүдә булдың. Мәскәүдән ары Пинза бар. Ә Пинзадан Кузнецкий ары. Аннан да ары Аля авылы утыра. Тик, бу Имәнтау сынлы.— Тавышы йомшарды Җәфрәтил драбандның, нәрсәнедер, кадерле, онытылганын хәтерләргә теләгәндәй тирә-якка каранып, уйланып торды.— Аля авылында да бу Казантау сынлы тау бар. Аны Әкәмәт тавы дип йөртәләр. Әкәмәтнең бер ягында нарат урманы. Икенче ягында Аккүз кизләве. Шылтырап агып ята.

— Шундый әйбәт җирне ташлап ник соң монда килдегез?

Госманның бу сорауны әтисенә бирергә уйлаган чаклары да булды, өлгермәде. Хәзер менә бабасы аңлатсын!

Сорау Җәфрәтил картка тагын ошамады.

— Бар белгәнең «ник тә ник!» Тигәнәк сынлы. Кем китерде? Нужа китерде! Әйттем бит кичә, без язмыштан казак, ә син — тумыштан!..

Госман җилкәсен сикертеп бабасына сорау белән текәлде.

— Выты, кичәгенәк тә төшенмәдем. Язмыш та тумыш. Нигә алай әйтәсең, бабакай?

— Мин дөресен әйтәм. Белмәсәң, колагыңа сал. Ник Гомәр атаң Аля авылыннан киткән?— Җәфрәтил карт инде онытына таба борылып утырып ашыкмыйча гына хикәя йомгагын сүтте.— Әйе, улым, әле дә хәтердә, ул елны илдә корылык булды. Язын-җәен бер тамчы яңгыр төшмәде. Игеннәр көеп бетте. Мал-туар кырылды. Үткән елгы ашлык бетте, яңасы юк. Өсте-өстенә, ваба авыруы башланды. Китте кырылыш... Безнең өйдән генә өч мәет чыкты. Зариф дәдә белән ике сеңел: Җәмилә белән Камилә. Анакай белән мин дә авырып ятам. Безнең атай коновал иде. Пинзага барып, Мәскәвенә җитеп, аз-маз ашлык,

яруш, ат ите алып килә иде. Шуның белән җан сакладык. Тукта, улым, булмаса махра төреп алыйм. Ул заманны сөйли башласам, йөрәк көя, әйтерсең алачыкта күмер дөрли!— Карт, сүзен бүлеп, инде әллә кайчан кулыннан төшеп, җирдә аунап яткан тәмәкесенә үрелде, чакма уты ялтырады. «Әле ярый Баһаулар янына чапмадым!»— дип куанып уйлады Госман, бабасы һич көтмәгән урында, янган нигез өстендә ачылып китте.— Сиңа, улым, әкият кенә, ә минем йөрәктә утлы тамга! Халыкның ашамаганы калмады — кычыткан дисеңме, алабута кирәкме! Өстәвенә ваба өйдән өйгә күчә! Кырыла халык! Вәт шул көзне авылга пристав килде, сход җыйды. Әйтә бу: вот, крестьяннар, кем казакка язылып, Себергә күчә, казна шуңа акча бирә. Себердә, ди, кем күпме җир ала, шунча җир. Орлык казнадан, ди. Ул вакытта халыкка, иблискә язып, ярдәм була дисәләр, аңа да язылырлар иде. Урыс әйтмешли, голод не тетка. Выт, авылның иң ярлы илле ызбасы казакка язылып, күпмедер акча ала. Безнең атай да ала, выты шул йомыш белән кышны исән-аман чыгабыз.

— Аннан соң?

— Тукта, бүлдермә сүзне, варнак.— Карт сүнгән төпчеген тагын кабызып, тирән итеп бер-икене суырды.— Шул, хәзрәт әйтә, кем казакка язылган, ул урыс була, ди. Шуннан халык «Себергә күчмибез!»— дип отказ бирә. Нәкъ чәчү алдыннан, авылга бер рота солдат ияртеп пристав килә. Халыкны тагын сходка җыялар. Анда исемлек укыла. «Казнадан акча алган илле йолкыш уртага чыксын!»— дип. Агайларны чыгаралар да солдатлар урап алып Әкәмәт тавына алып китәләр. Ә аннан, шул солдатлар ызбадан-ызбага йөреп хатын, бала-чагаларын куалар. Шау-шу, җылау, каргыш, выты, хәзер дә шуның тавышы колакта чыңлый.

— Ә аннан, бабай?— Госман бабасының авызына кереп китә язды. Ни булды?

— Ни булсын? Әкәмәт тавында бер кая җибәрмичә өч сутки тоттылар. Безнең атайның атасы Аю бабай шунда вафат булды, зиратка күмәргә дә җибәрмәделәр. Выты, шунда, Әкәмәт тавы битендә кул белән кабер казып күмделәр.

— Ә сез нишләдегез, бабай?

— Нишлик, шунда камалып мал сыман тордык. Дүртенче суткыда илле подвод, конвой белән Себергә кузгалдык. Шул киткәннән өч ай интегеп, бары көз көнне шушы Имәнтауга килеп егылдык. Күп авылдашлар юлда калды. Сеңлем Кәтринбур дигән кала янында эч авыруыннан каза тапты. Их, улым, улым!— Карт озак уфтанды.— Нужа дигән карасакал арттан калмый икән! Монда килсәк, ул монда да безне көтеп торган икән! Бездән алда килгән казаклар безгә урын бирмичә сазлыкка кудылар.

— Кайдагы сазлык ул, бабакай?

— Кайдагы булсын, Кара Болакка. Ни йорт салырга, ни иген чәчәргә. Тагын бәла. Шуннан безнең атай Күкчәтауга барып, бер татар тылмачыннан Омскига наказной атаманга прошение яздыра. Янәсе, без казакка язылган, ә җир юк, сазлыкта утырабыз. Берчесен яза тылмач.

— Ә атаман ни әйтә?

— Выты, наказной атаман, кяфер булса да яхшы кеше икән! Прошениене алуга Имәнтауга бер ясавылны җибәргән. Пошто татар казакларын обижайт итәләр дә, нигә аларны сазлыкка куалар? Ясавылга тикшерергә куша, «дөрес хәл итмәсәң, үзем барам!»— дип тә кала. Ясавыл килде, безгә урман уртасыннан җир кисте, рәхмәт төшкере. Без шулай нужадан казак булдык. Ә син, выты, тумыштан! Чөнки этиең Гомәр казак иде.

— Имәнтауның берчесе Аля авылыннанмы?

— Варнак, әйттем сөйләгәндә бүлдермә дип! Сукыр чебен сынлы күзгә керәсең.

— Сорарга да ярамый.— Госман үпкәләп читкә борылды. Бабасы оныгының кәефе кырылуын күреп, аны юмаларга ашыкты:

— Выты, шырт сынасың, арыш сынлы. Сора, ник сорамаска. Менә хәзер тишек капчык сынлы, сөйләгәндә берәү бүлдерсә, уем төшә дә кала. Ни сорадың әле!

— Әйттем бит,— диде Госман киреләнеп.— Имәнтауның берчесе Аля авылыннан килгәнме дип?

Җәфрәтил сорауны аңласа да, үзе җавап бирергә ашыкмады, киреләнеп торды.

— Аля авылыннан без бары иллә йолкыш кузгалдык. Монда килеп җиткәндә кырыгыбыз калдымы, юкмы. Кайсының аты үлде, кайберәүләр үзләре каза тапты. Выты, без, монда татар ягының үзеге булабыз инде. Аннары Торна Зиннәтләр, Аширлар, Каймак Касыймнар, Кыргый Бәкерләр.

— Ә Гали абыйлар?

— Галиләр, улым, алар Казан ягыннан, бездән соң килделәр. Без сход белән аларны казакка алдык, без.

— Әссәләмәгаләйкем.

Ят тавыш күңелле диярлек әңгәмәне бүлде. Бабай да, оныгы та тавыш килгән якка карадылар. Чыпчык Әхмәт икән. Тәбәнәк. Шыр сөяк. Өрсәң очып китәрдәй. Ә тавышы баһадирныкы сыман, каргылдап тора.

— Казаның ахыры хәерле булсын,— диде Әхмәт. Башка вакыт булса наряддашы белән Җәфрәтил ягымлырак сөйләшкән булыр иде, хәзер алар тигез түгелләр шул. Чыпчыкның йорт-җире исән, бүтән казасы да юк. Ул җавап урынына нидер мыгырдады. Чыпчык китәргә ашыкмады, мыек очын бөтереп торды да:

— Выты, наряддаш, ары очка Мачы Гарифларга йөгерәм.— Чыпчык нигәдер як-ягына каранып алды.— Күкчәтауга җыена, ди. Шәймәрдән хаҗи Куянды ярминкәсенә мал әйди, ди. Былтыр Мачы үзенең малаен шунда кушып ярыйсы гына табыш алган иде. Оныкны шунда җигеп булмасмы дим!

Җәфрәтил торып аңа таба кулын сузды.

— Чү, туктачы, кордаш! Әйдә, булмаса ул Мачы белән мин дә бер сөйләшим. Выты, оныкның атасы вафат булды. Йорт-җире көлгә очты. Анасы, кызым Әминәне әйтәм, түшәк тартып ята. Бәлки, хаҗи минем оныкны да алыр, ә?!

Чыпчык алдан барып җитәргә ашыга-чаба, аның артыннан агач аягын сөйрәп Георгиевский кавалер чатанлый иде.

Госман әле алда ниләр буласын бөтенләй күз алдына да китерә алмыйча бабайлары артыннан карап калды.

6

— Әгүзе билләһи...— Ниһаять, Шаһимәрдән хаҗи сәҗдәдән торып, кулларын догага күтәрде һәм тамагын кырып, көчле көр тавыш белән «Сәфәр» сүрәсен укый башлады. Һәр сүзен бүлеп, Мисырдан отып кайткан мәкам белән укыды. Шуны гына көтеп торган арткы сафтагы җылкычылар, малчылар, юлга чыгарга җыенган куй әйдәүчеләр ыгы-зыгы килеп, ашыгып, бер-берсен этеп-төртеп сәҗдәдән тордылар. Картраклар аякларын сузып җибәреп, яшьләр тезләнеп утырдылар һәм хаҗига охшарга тырышып кулларын кавыштырып күтәрделәр. Картлар күзләрен йомып, ихлас күңелдән догага оедылар. Яшьләрнең түземнәре җитмәде, уңга-сулга ялт-йолт карана башладылар, бер-берсенә тел, кәҗә тоягы күрсәтеп шаярырга тотындылар.

Госман сәҗдәдән башкаларга караганда соңгарак калып торды, догага кулларын күтәрә генә башлаган иде, арттан кемдер аның аяк

табанын кытыклады. Госман чак кына көлеп җибәрмәде, ачуланып борылды. Башына эссе җәйдә каешланып беткән сөннәтсез бүрек кигән сары Нигъмәт авызын чабатадай ерып аны үчекләп маташа! Госманның йодрыгы тиз япты тегенең авызын! Малай тәгәрәп тә китте. Хәзер Госман куркуга төште, акырып-бакырып хаҗины бүлдерсә, бетте баш! Тик Нигъмәт әләкче түгел икән, мыштым гына торып утырды, һаман Госманны үчекләргә теләп табанына үрелде. Хаҗи сүрәне укып бетереп, соңгы догага күчте.

— Йа, тәңрем, сәфәремезне уң кылып, бәла вә казалардан имин әйлә. Юлдашымыз Хөзер Ильяс улсын. Илаһи амин!

Арткы сафтагылар да уянып, җанланып битләрен сыйпадылар һәм төрлесе төрле тавыш белән ашыгып, Хаҗига ишеттерергә тырышып, кычкырыштылар:

— Амин, амин!

— Юл уң булсын!

Хаҗи аягүрә басты.

— Ал, Лачынбай, аллага тапшырып кузгалыйк. Малчылар атлансын, атарларны Ялгыз карагай тавына әйдәсен. Яхшы кара, мал бүленеп калмасын. Аллага тапшырдык. Юл алыс, хәере белән. Ал, тиз кыймылдагыз, көннең күзе күренә башлады.

Үрелеп башларына буй җитмәс биек, дулкынланып торган күк яллы, искиткеч гүзәл пар акбүз ыргамак җигелгән, ялт итеп торган өр-яңа фаэтон резин шинлы тәгәрмәчләре белән тавышсыз гына тәгәрәп Хаҗи алдына килеп туктады. Алдагы утыргычта аткуар — яшь кенә казак егете, тутый кош төсле кукыраеп утыра. Башында төлке кырпулы кызыл бәрхет бүрек, күк күлмәк өстеннән яшел бикасап камзул кигән, ботта кара постау чалбар. Аякларда биек үкчәле, очлы борынлы сары күн итекләр. Егет үзе дә күркәм, чибәр — түгәрәк, мөлаем йөзле, борын астында беренче төкләр. Буй уртача. Гәүдә, нәкъ аткуарларга хас, чандыр-җиңелчә, очып китәргә тора. Күрәсең, яшь хаҗиның ярминкәдә үзен дә күрсәтәсе килә! Янәсе Куяндыда гына түгел, Күкчәтауда да затлы байбәтчәләр бар!

Аткуар дилбегәләрне ике кулы белән тартып аргамакларны көчкә генә тыеп тора, ә алар, башларын чайкап, күк ялларын дулкынландырып-таратып җибәреп, озын, сылу аяклары белән җирне тибеп сабырсызланып-ашкынып торалар. Аз гына дилбегә каксаң да ак-караны күрмичә алып качарлар.

Хаҗи вәкарь белән генә бер-ике атлады да, чак кына уйланып торды, аннан җитез генә фаэтон баскычына күтәрелде, әйләнә-тирәгә бөркет күзе ташлады, мөгаен, атарның кузгала башлавын күзәтте.

Мәккәгә сәфәр кылганда ул ярыйсы ук тулы, корсак нык кына алга бүлтәйгән иде, нигәдер чак кына бөкрәеп тә йөри иде. Хәзер Хаҗи бөтенләй башка, бәйгегә әзерләнгән йөгерек-чабышкы сыман тәнгә суырылган, чандырланган. Бөкре югалган. Корсак та шиңгән. Ул хәзер төп-төз, җиңел бәдәнле, урта яшьләрдәге тап-таза ир. Тагын бер үзгәреш күзгә бәрелеп тора: ул теге вакытта сакал йөртә иде, кап-кара, көрәк сакал, хәзер исә ул да шоп-шома итеп кырынган, бары тик кабарып, очлары бөтәрләнеп колакка үрелгән кара мыек кына калдырган. Өс-баш та үзгә, хаҗга баргандагы ак чалма, яшел буй-буй бикасап чапан, читек-кәвеш урынына тек якалы кара постау пиджәк, тәненә килешле чалбар, кунычлары ялт-йолт итеп торган хром итекләр. Башта киң кырыйлы, карлыгач канатысыман кара фетр эшләпә. Яшәреп, матураеп киткән Хаҗи әфәнде.

Менә ул пиджәгенең күкрәк кесәсеннән алтын сәгатен чыгарды, төймәсенә басты, «шылт» итеп капкач ачылып китте, гүя нәни кояш балкыды.

— Ал,— диде Хаҗи әфәнде, сәгатенә күз ташлап,— аллага тапшырдык!

Нәни «кояш» сүнде, Хаҗи мамык түшәлгән арткы утыргычка утырды, күк тимгелле аргамаклар аккош булып очтылар. Карама дугага бәйләнгән пар җиз кыңгырау очынып иртәнге даланы чыңлатты.

* * *

— Әй, шәкерт, ни катып торасың?

Фаэтонга, җитез аргамакларга, сихерле тавышлы кыңгырауларга сокланып, хәйран калып-оеп торган Госман, бу ачулы эндәшүгә уянып, тавыш килгән якка борылырга да өлгермәде, җирән кашка атка атланган кеше аның яныннан, ат җиле белән өркетеп, баса язып чабып узды да кире борылды. Ат кызган, ярсыган, авызлыгын чәйнәп, күбек чәчеп Госман өстенә килә башлады. Ул көч-хәл белән читкә сикереп ат тоягы астында калудан котылды. Алай да атның тояклары аның тезен сыдырып узды. Ә ат өстендәге кеше аның саен атын камчылап җирән кашканы Госман өстенә әйди! Башында кара тасмалар белән җөйләнгән киез эшләпә, өстендә дөя йоныннан тукылган кызгылт чикмән. Аякларында озын кунычлы, очлы башлы, биек үкчәле итекләр. Казах халкында сирәк очрый торган зур бөкре борын. Шул борын астында тычкан койрыгы булып асылынып төшкән соргылт мыеклар һәм ияк очында шундый ук соргылт чөй сакал. Калын кашлар астында бораулап караучы ачулы күзләр. Бая да шәйләп алган иде аны Госман, Хаҗи тирәсендә бик юмакайланып, бөтерелеп йөргән иде... Әйе, кичә дә күрде ул аны!..

Ул камыт аяклары белән атының билен йозаклап кысып, ияргә сеңеп, аз гына алга-ялга иелә биреп, бөкрәеп утырган: әйтерсең корбаны өстенә ташланырга җыенган дала лачыны! Госман башта куркуыннан, ат тоягы астыннан күтәрелгән тузан-туфрактан, бу котны алып йөргән җайдакның кем икәнен абайлый алмаган иде. Ә хәзер таптарга теләп ничә тапкыр бастырып килә башлагач бик ачык таныды! Әйе, кичә дә күрде ул аны! «Заимка»га килгәч, бабасы киез өй түрендә шәбәеп кымыз эчеп утырган бу суык йөзле кешегә ишарәләп: «Улым, выты, шул карчыга борын сез әйди торган атарның өлкән чабаны, ди. Лачынбай атлы. Ишетүемчә, үзе усал адәм, ди. Ничек тә сүзен тыңлый күр, ярарга тырыш, кәбәм»,— дигән иде бит. Җирән кашка мышнап, күбек чәчеп Госманны башы белән этеп җибәрде дә шундук Лачынбай кулындагы салт камчы Госманның аркасын телде.

— Эт! Чучка! Малны чыгармый ни катып торасың, уңмаган!

Камчы, елан булып, тагын өстә боргаланды.

Госман абына-сөртенә «Заимка»га таба йөгерде.

— Әй, мәҗнүн, тукта!— Җан-фәрман чабып барган Госман каршысына тагын җирән кашка атылып чыкты.— Әй, атың кайда? Куяндыга шулай җәяү чабасыңмы, мәҗнүн?

— Ә-ә,— Госман мышнап, егыла язып, абынып туктады.— Нинди ат ул, ага?

— Ой, атаңдың авызын... каңгырган нугай!— Госманның өстенә берсеннән-берсе авыр, хәкарәтле сүзләр яуды.— Атаңа нәләт! Уңмаган! Айтып идем гуй хаҗига, монау ишәгеңнең кирәге җук, дип, тыңламады.— Кашканың борыны тагын Госманның аркасына төртелде.— Ал, ни торасың? Җөр!

Госман ат астыннан чыгып борылырга да өлгермәде, камчы тагын арканы телеп-телеп китте. «Өскә төшсә изә инде!»— дип уйлап өлгерде егет, кулы белән битен каплап. Ат аның тирәсендә дулап әйләнде дә арт аякларына басты, Лачынбайның канәгатьлек уты белән янган күзләре күренеп калды. Лачынбай, җирәнкашканың янбашына камчы сабы

белән кагып, алгы аякларын җиргә төшерде дә «Заимка»дан [1] куй әйдәп чыгучы җылкычыларга кычкырды:

— Әй, Нәсия чал, бу агач муллага Алачапанны алып килеп бир дә арт сабагын укыт мәҗнүн шәкертнең!

Җирәнкашка Госманның битенә тузан чәчрәтеп китеп барды, егет юл читендә нишләргә белмичә, кая барырга да аптырап катып калды. Аның яныннан тере агым булып куйлар уза башлады, әйләнә-тирәдә ыгы-зыгы купты. Куйлар мәэлдәшә, этләр абалап өрә, колак тондыргыч тавышлар зиһенне басып торалар иде.

— Һайт, һайт!

— Ал, китте!

— Уй-бай, кушкар кутанга [2] борылды, ку-ку!

Ул арада тузан эченнән ат җитәкләгән Нәсия чал күренде.

— Менә, балам, мынау бия Куяндыга барып килгәнче саган җулдаш булады. Юаш хәйван, кил, менеп ал.

Атны күргәч, Госман шаккатты. Бу ни мәзәк? Мескен хайванның өстенә әүвәле ак тире япканнар да, ул җитмәгәч, зур-зур кара-кызыл ямаулар салганнар сыман. Ала-кола. Аяклары кыска, корсагы зур. Баш — дүртпочмак! Әллә сыер инде? Чегәннәр шулай ат сатканда юри ала-кола буйыйлар дип ишеткәне бар иде аның...

— Балам, атар кузгалды. Җылдам атыңа менеп ал да минем арттан атарны куа бир. Тагын ходай орып Лачынбай килеп калмасын! Әйдә, әйдә, балам!

Чал, атын җилдереп «Заимка» яктан килә торган атарга — куй көтүенә таба ашыкты. Госман да җитез генә сикереп Алачапанга атланды. Нәсия чалның теләктәшлеге, йомшак сүзләре аңа көч биргән, исенә кайтарган иде.

* * *

Җәфрәтил карт онытын базарга баручы казакларга утыртып Күкчәтауга үзе алып килде. Хаҗи белән сөйләшергә җае бар иде аның барын. Эш шунда ки, Одесса шәһәренә кадәр Госман Шаһимәрдәнне хаҗга озата барган иде. Әгәр ул егеттән канәгать булып калган булса, эш пешә дигән сүз!

Әүвәле хаҗиның олы урамдагы яшел йортына бардылар. Хаҗи өйдә юк икән, кибетенә киттеләр. Кызыл кирпечтән бизәкләп салынган зур таш пулат каланың базар мәйданында бер квартал җирне алып тора. Тәрәзә-ишекләре сырма-сырма тимер япмалы. Госман әнә шул хикмәтле ташпулат-дөкәнне, тәрәзәләрдән күренеп торган кыйммәтле кием-салымнарны тамаша кылып урамда калды, бабасы чатанлап, тамагын кыра-кыра ютәлләп, сырма япмалы ишектән кереп китте. Хаҗи әфәнде белән сөйләшергә!

— Аллага шөкер!— дип, бераздан бик куанып, җилтерәп килеп чыкты да, оныгын кибеттән бераз читкәрәк алып китеп, бер сүзен икенчесенә сөрендереп, ашыгып сөйли бирде.— Хаҗи сине хәтерли! Ул баланы беләм, былтыр хаҗга барганда күп хезмәт күрсәткән ие, ди. Тиктомалдан авырып киткән икән... Терелеп кайтуы да егетлек, ди. Ә монда ходаның хикмәте, атасы вафат, йорты-җире янган... Боларын мин сөйләдем! Күз күргән әһле мөселман, ди хаҗи. Бәс, шулай икән, әйдә, куй әйдәп атар белән Куяндыга барсын, ди.— Карт елмаеп куйды.—

[1] Заимка — рус патшасы казах даласын үз кулына төшергәч, андагы иң яхшы җир-суларны, урманнарны үзенә аеруча хезмәт күрсәткән казак-урыс офицерларына бүләк итеп тарата. Менә шул җирләрне татар байлары вакытлыча, гадәттә 20—30 елга файдаланырга алалар, «занимать» итәләр. Анда йорт-каралты салып мал асрыйлар, ял итәләр. Шаһимәрдән хаҗиның да Күкчәтау янында шундый заимкасы була.

[2] Кутан — авыл уртасы.

Эчем, выты, җылынып китте. Бу сүзне ишеткәч. Тагын әйтә, ни ди, көнлеге йортныкыча — егерме тиен көмеш, ди. Син драбанд картмы әле, ди. Кара, каян белеп алган диген! Шөбһәләнмә, Гомәр мәзин улын рәнҗетмәм, ди. Юл уң булса, хәер-сәдакасы да булыр, ди. Бәхетең бар икән, улым.— Карт оныгының аркасыннан сөеп какты.— Буш түгелсең, кәбәм. Выты, Чыпчык Әхмәт белән Мачының улын «кирәкми» дип кайтарып җибәргән хаҗи... Вот как!.. Иншалла юлың уң булыр. Выты, бак әле, улым...— Карт, җилән чабуын күтәреп, чалбар кесәсеннән нидер алырга тырышты. Агач аягы әле алга, әле артка китеп комачаулады, Җәфрәтил артык дулкынланган иде. Озак азаплангач кына капшаган нәрсәсен тапты.— Бак, улым!

Картның сөялләнеп, катып беткән кытыршы учында ут булып янып торган алтын тәңкә! Госманның күзе дүрт булды.

— Бабакай, каян алдың?

— Мәрхүм мәзиннең хәләл җефетенә юл сәдакасы дип хаҗи үзе бирде.

Карт алтын тәңкәне арлы-бирле шудырып яндырып сокланды да киредән чалбар кесәсенә яшерде.

— Мин инде, улым, юлда сөйләшкәнчә, әфисәр Владимир Яковлевич Куйбышевка барып наказной атаманга прошение яздырыйм. Может өй салырлык агач бирерләр.

— Улы Волик Омскидан корпустан кайткан булса, миннән сәлам әйт. Куяндыдан кайткач та мин аларга барырмын. Әние мөгаллимә урысча укытырмын, дигән иде.

— Ярый, ярый, улым, әйтермен.

Җәфрәтил оныгын калада, тәбәнәк таулар итәгенә урнашкан Шаһимәрдән хаҗи утары янында калдырды да үзе Күкчәтау местная команда начальнигы капитан Куйбышевка прошение яздырырга ашыкты...

## 7

Күкчәтауда Госманның бик якын кешесе бар! Якын гына түгел, дус та ул, серле дус. Ул — Волик Куйбышев...

Күкчәтау да ике очка бүленә: тау ягы — анда бары тик казак-урыслар гына тора. Бу очта йортлар таза, биек. Тәрәзә төпләрендә гөлләр, янбакчаларда сәрви куаклары, сиреньнәр. Ә күл ягы — мещан ягы. Монда — сазлыкта крестьяннар, төрле вак һөнәрчеләр: балтачылар, миччеләр, такта яручылар, касапчылар, ялчылар һәм башкалар, шуңдый ыбыр-чыбыр тора. Мондагы йортлар иләмсез тәбәнәк, иске, күбесе сазга батып кыйшаеп тора. Дөрес, монда да иң олы Воскресенский урамында Шаһимәрдән, Кәлимулла, Хәлиулла, Шәяхмәт байларның, Соколов, Коротков кебек ни гаҗәптәндер бу якта яшәп калган купецларның таш пулатлары, мәңгелеккә дип исәпләп салынган кибетләре, складлары бар.

Тау ягы белән күл ягы кешеләре арасында гомерлек ызгыш бара. Иң әүвәл бала-чагалар бәйләнешә башлый, әгәр мещан як балалары тау ягына эләгәләр икән, көт тә тор, аның җилкәсен каезлап җибәрәчәкләр! Әгәр инде казак-урыс балалары күлгә коеныргa килсә, аларга да якты көн күрсәтмиләр. Шул тирәдә йөргән кызыл авызлар бала-чага сугышын шунда ук зурга җибәрә, алар урамны сасытып: «Безнекеләрне кыйныйлар!»— дип бер акырсалар, җыела халык, туплана сугыш чукмарлары. Ике очта да шулай. Таяклар худка китә, тимер кистәннәр, кайчагында пычаклар да ялтырап ала. Тузгыган сугыш чукмарларын җирле команда солдатлары килеп көч-хәл белән ипкә китерәләр.

Шулай бер көнне, мәдрәсәдә өченче елын укыганда, Госман бер төркем шәкертләр белән тауга уйнарга менде дә, башы авыртып, кире

кайтып китте. Инде тауны төшеп җиттем дигәндә генә бер төркем казак-урыс балалары аны камап та алдылар, «ур-ра» кычкырып бер-берсен котыртырга ябыштылар. Бер-ике малай гына булса Госман әллә ни куркып та тормас иде, монда — чирмеш чирүе сыман!

Кулын кесәсенә тыкса — чуерташ! Бер-икесенең маңгаен күпертергә була! Тик шушы хәтле малайга бер таш нәрсә ул? Әнә ич, тешләрен ыржайтып, йодрыкларын йомарлап божраны һаман кыса баралар, шарык-шырык җил җибәрәләр. Госман кесәдәге ташны учына кысып, иң алдан килүче сары малайга тондырырга дип уң аягын күтәрә генә башлаган иде, арттан берәү кычкырып җибәрде:

— Нишлисез?! Тимәгез!

Балалар да туктап калдылар, Госман да аптырады.

Таудан бер бала йөгереп төшеп килә. Унбер-унике яшьләр чамасы. Буе озын гына, үзе чандыр. Әллә озак авырган инде, ак чырайлы, чәчләре генә күпереп, бөдрәләнеп торалар. Госманны аның киеме дә шаккатырды, ул баштанаяк өр-яңа хәрби-кадет киеменнән, мундир төймәләре ялтырап тора. Менә ул мышнап божраны өзеп уртага керде:

— Туктагыз!

— Нигә туктарга? — «Сары этәч» Госманның өстенә үк килеп йодрыгын уйнатты. — Ул мещан, без хәзер аның кирәген бирәбез!

— Молчать! — Теге үсмер көдерәеп килгән сары малайның күкрәгенә китереп төртте. — Смирно!

Божрадагы малайлар күз ачып-йомганчы рәткә тезелеп, башларын күтәреп «шып» басып калдылар. Госманның күзләре шар булды.

— Гвардии рядовой, минем янга!

Сары малай — Петя икән, суынып, бик җитди кыяфәткә кереп, нәкъ хәрбиләрчә өзеп-өзеп атлап командиры каршысына килеп басты.

— Тыңлыйм, господин командир Волик Куйбышев! [1]

Яшь командир рәт буйлап йөреп «солдатларын» тикшереп чыкты, туктап Госманның куркудан тирләгән аркасын какты.

Волик шактый көр тавыш белән сөйли башлады, ара-тирә тавышы нечкәреп тә китқәләде.

— Без юлбасарлар түгел, без гаделлек өчен көрәшүче гвардеецлар! Шулай икән, һәр очраган баланы кыйнау безнең өчен оят!

— Господин командир, — диде теге Сары этәч, кыза башлап. — Мөмкинме?

— Әйт, Петя!

— Бу бала түгел, бу мещан! Безнең дошман!

— Җитәр! — Воликның тавышы тагын яңгырап китте. — Петя ялгыша, безнең дошманыбыз мещан түгел! Без гаделсезлеккә каршы, изүчеләргә каршы көрәшәбез! Төшендегезме?

— Төшендек! — диделәр рәттәгеләр. Тавышлары тигезле-тигезсезрәк чыкты.

— Алайса, тыңлагыз! Кичке сәгать биштә строй дәресләре! Плацта җыелырга! Ә хәзергә таралырга! Шаго-ом ма-арш!..

---

[1] Патша заманында Себердә, станицаларда казаклардан башка хәрби частьлар да торды. (Батальонга якын солдат). Алар «җирле команда» дип йөртелә иде. Күкчәтауда да андый команда була. 1888 нче елны Акмула генерал-губернаторы (ставкасы Омскида) отставкага чыккан Күкчәтау җирле командасы начальнигы урынына капитан Владимир Яковлевич Куйбышевны билгели. Бу гаилә Күкчәтауга килгәндә (Владимир Яковлевич үзе, хатыны Юлия Николаевна, уллары Воликка бары тик тугыз ай гына була. Валерианны нәни чакта шулай дип атап йөртәләр.

Куйбышевлар Күкчәтауда 1907 нче елга кадәр, ягъни унсигез ел торалар. В. В. Куйбышев йортында хәзер мемориаль музей. Директоры — Валерианның сеңелесе Елена Владимировна Куйбышева. (Автор).

Читтән караганда усал кебек күренсә дә, Волик Госман белән күптәнге дусты сыман ягымлы сөйләште. Сорашты, белеште — кем баласы, өйдә кемнәре бар, кайда укый? Аннан калага кергәч, урам чатындагы зур бер йорт янында туктап:

— Менә, Госман, безнең өй. Тартынма, килеп йөр. Бездә китаплар да күп. Минем әни мәктәптә мөгаллимә.

— Ә балалар кыйнаса?

— Кыйнамаслар!— Волик көлемсерәде.— Мин быел, корпустан кайткач, үзебезнең урамдагы малайлардан команда төзедем. Ул «Гаделлек гвардиясе» дип атала. Көн дә занятие үткәрәбез. Кил.

— Мин бит татар.

— Эх син, Госман!— дип кычкырып көлде Волик.— Әйтәм бит, безнең полк гаделлек өчен көрәшә! Арабызга каракларны, сугыш чукмарларын алмыйбыз. Үзең белән берәр әйбәт бала да алып кил! Ну, ярый, хуш, эти командадан обедка кайткандыр!

Чыннан да, тау итәгендәге сары озын бараклардан чаң тавышы килде.

— Хуш. Күтәм. Иртәгә!

Волик киемнәре, буе белән күзне кызыктырып урам якка чыккан парад-кунак ишегенә таба йөгереп китте. Сирень чәчәкләренә күмелеп утырган, хуш ис аңкыткан йорт янына, резин көпчәкле пролеткага утырып, бер офицер килеп туктады. Өр-яңа мундирдан, иңнәрендә көмеш погоннар. Зифа. Пөхтә. Кара сакаллы. Госман аны ишектән кереп югалганчы күзе белән озатып калды.

Әллә ничек, кинәт бөтен дөнья яктырып киткән сыман булды. Урамдагы өйләр дә, хәтта узып барган кешеләр дә, барысы да, барысы да әйбәт тоелды. Бераз баргач аңа теге малайлар тагын очрадылар. Тик берсе дә бер сүз әйтмәде. Петя гына Госманга күзен алартып карады. Тик ул да аның кәефен кыра алмады. Күкчәтау урамнарыннан ниндидер бер изге — күңелне сөендерә торган нур бөркелә сыман. Нигә шушы кадәр матур икән бу дөнья?!

«Изүчеләр», «гаделлек», «көрәш» дигән сүзләрне Госман беренче тапкыр Волик авызыннан ишетте. Олы, күпне күргән кешедән дә түгел, үз тиңдәшеннән, үсмер егет авызыннан ишетте. Үз чордашының шулай нык, көчле булуы, сүзләренең сихерле акыллылыгы мәдрәсә шәкерте Госманны хәйран калдырды. Ул бик нык үзгәргән иде, шәкертләр аның үзгәрешен сизенсәләр дә, сәбәбен аңламадылар. Сорап карасалар да, Госман әлегә дәшмәде, ачылып китмәде.

Шул көннән ул еш кына Воликларга бара башлады. Чыннан да, алар өендә шкаф-шкаф китаплар икән! Матур сурәтле китаплар! Воликның әнисе Юлия Николаевна да Госманны үз итеп яратып каршылады. Янәшә утыртып чәй эчерде, гел сорашты, төпченде.—«Укып бетергәч нишлисең инде син? Мулла буласыңмы?»— дип егетне кызартты.

— Усман, сиңа русча укырга кирәк,— диде ул икенче килүендә үк.— Мин сиңа русча «Азбука» бирәм. Шуннан башла.

Станицаларында казак балалары белән аралашып үскәнгә, Госман русчаны яхшы белә, бераз хәрефләрне дә сукалый иде. Хәзер китаплар шулай күп һәм кызыктыргыч булгач, аның эшләре алга китте.

Госман Воликларга иптәшен — хәлфәсе Фәхретдиннең улы Һадины да алып барган иде, ул бер-ике тапкыр команда белән тауга барды да «әтием ишетеп калса, җилкәмне каезлар!» дип, йөрүдән туктады. Петя белән дә дуслашты Госман. «Усманка да Усманка!» дип кенә йөри хәзер Сары әтәч, әйбәт кенә малай икән үзе!

Ә бер төнне, бер төнне!.. (Бу серле вакыйганың ахырын да, нәтиҗәсен дә белә алмый калды Госман, әле дә белми!) Шулай, күлдән коенып кайтып килгәндә, Волик туктады да, ничектер, шыпырт тавыш белән:

— Госман, кешеләр йоклагач, бүген төн уртасында безгә киләсеңме?— диде.

— Нигә?— диде Госман аптырап.

— Сер,— диде Волик, һаман җитдилеген саклап.— Сиңа ышанганга гына әйтәм.

— Ярый.— Госман иптәшенең хәтерен саклап кына килеште дә юл буе борчылып кайтты. Әлерәк кенә су кереп чыккан булса да, көн гаҗәп эссе булып тоелды аңа. Эссе дә, озын да! «Төн уртасында нинди уен? Әллә эшме? Барыргамы, бармаскамы?! Һади теге көнне үк берәр хәтәр сизеп йөрми башлагандыр? Ә мин һичнни сизмәдем! Нигә? Волик начар юлга җибәрмәс анысы... Тик менә... нигә төн уртасында? Кешеләр йоклагач? Димәк, кешеләрдән яшерен эш булачак? Нигә?»

Госманның башы чатнап авырта башлады...

Үч иткән кебек төн шомлы иде, җилле, караңгы. Госман Миңлебай абзаларында торып укый иде. Көндәгечә сәке өстенә менеп ятты да, шактый боргалангач, «борча тешли» дигән булып, курага чыкты, абзасы бүген генә чабып алып кайткан хуш исле печәнгә менеп, җиләнен ябынып ятты.

Берәм-берәм этләр өрүдән туктады. Арба янына яткан кызыл сыер да күшәми хәзер, мыш-мыш килә. Вак кына яңгыр да сибәли башлады. Нишләргә?!!

Волик, килешкәнчә, Госманны бакча артларындагы мунча янында көтеп тора иде.

— Усманка! — диде ул.— Көтә-көтә арып беттем. Мә, тот, сиңа бер капчык. Бусын мин алам.

Госман буш капчыкны култык астына кыстырганда тәне чымырдап китте, урланган әйбер алырга баралармы?! Кая?!

Атладылар.

— Тизрәк. Миннән калма. Кычкырып сөйләшмә.

Иптәшенең сүзләре яңгырлы җәйге төннән дә шомлырак иде.

Җил дә, яңгыр да көчәйде. Волик җитез йөри, тауга менсәләр дә, чаба гына. Кылган юеш. Аяклар таеп-таеп китә. Госман атлаган саен диярлек абына, мышный. Инде менеп җиттек дигәндә генә котны алып яшен чартлады, тез буыннары йомшады. Ярый әле Волик килеп җитеп тотып алды, ул булмаса, Госман шәкерт тау итәгенә, Күкчәтауга хәтле тәгәрәп китәсе икән!

— Инде ерак калмады! Хәзер, хәзер, Усманка, җитәбез!

«Юк, юк, яхшылыкка түгел бу! Волик, мөгаен, бик күп акча урлагандыр!» Шәкертнең уе кыска: ул акча урлаудан башканы әллә ни белми шул әле!

Шактый баргач Волик таш өемнәре янына килеп туктады.

— Менә килеп тә җиттек. Син, Усманка, монда тор. Мин хәзер...

Волик яшен кебек тиз арада күздән югалды, Госман тагын да ныграк калтырый башлады. Бөтен өсте лычма су. «Выты, эләктем кармакка!» Ул арада болыт аламалары арасыннан куркынган ай күренеп китте, баш очындагы таш кыяларны яктыртты, алар Госманга үзен тотарга килгән стражниклар булып күренделәр.

— Менә, барысы да тәртиптә!— Волик таш арасындагы куыштан бер кочак кәгазь күтәреп чыкты.— Мә, яртысын син тотыр!

«Акчалар!»— дип тәмам шашынып уйлады Госман.

— Кирәкми, кирәкми!— дип артына чигенде.

— Ач капчыгыңның авызын!— диде нык итеп Волик һәм кәгазьләрне тутыра да башлады. Төргәкләрдә дәфтәр бите сыман кәгазьләр икән, бер дә акчага охшамаганнар, Госманның йөрәге аз-азлап үз урынына кайтты.

— Күреп торам,— диде Волик тыныч кына.— Синең «акча» дип котың калмады. Монда акчадан да көчлерәк нәрсәләр бар! Бу кәгазьләр — прокламацияләр!

— Нәрсә, нәрсә? Ассигнация дисеңме?

Волик тонык кына көлеп куйды.

— Патшага каршы язылган кәгазьләр!

— Патшага каршы?

Шулай диде дә, моннан ары сөйләшергә дә, сорашырга да курыкты Госман. Үзенең бик хәтәр, бик куркынычлы эшкә тарганын аңлап алды. Хәлфә малае Һадиның «белсә... җилкәмне каезлар!» дигән сүзләре исенә төште... Ә Госманның әткәсе?! Ул бит аны: «Укы, улым, тырыш. Тырышсаң, югалмассың, мулла буласың!» — дип озатып калган иде. Тырыштымы Госман?! Менә кая килеп капты!

— Мин мондый кәгазьләрдән куркам,— диде ул, тотлыгып.

Волик кәгазьләрне ике капчыкка бүлеп тутырды да дер-дер калтыраган иптәшен җилдән ышыккарак алып керде.

— Минем апаның Омскида укыганын беләсең,— диде ул.— Ул анда социал-демократлар оешмасында тора. Ул оешманың нәрсә икәнен мин сиңа соңрак аңлатырмын. Бу прокламацияләрне шул оешмадан бирделәр. Аларны халык арасында таратырга кирәк.

— Нигә?!

— Патшаның кем икәнен халык аңларга тиеш. Изүчеләрнең чын йөзен ачарга кирәк.

— Мин нишләргә тиеш инде синеңчә?

— Синме, Госман дус... Капчыгыңны ал да мещан ягына йөгер. Һәрбер кибет янында берәрне калдыр, яңгыр тимәслек ярыкларга кыстыр.

— Сакчы күреп бур дип тотып алса?

— Тоттырма! Күзәтүче ераккарак киткәнне көтеп тор. Спирт заводын, пар тегермәнен әйлән. Юлда өй тәрәзәләренә ябыштыр. Ә мин казармаларга барам. Курыкма, каушама. Ике-өч көннән күрешербез.

Ай тагын болытлар арасына кереп югалды. Тирә-як элеккедән дә караңгырак булып калды. Ярый әле, яңгыр туктады. Алар таудан йөгереп диярлек төштеләр...

* * *

Иртә белән Госманның Миңлебай абзасы базардан тирләп-пешеп йөгереп кайтты, уң яңагындагы миңе кабарып, зураеп калган, күзләре акайган.

— Нәфисә!— Ул ишектән керүгә кычкырып җибәрде.— Мин бүген арба яныннан бер кәгазь тапкан идем!

— Я-я,— дип сорады хатыны, иренең кызуының сәбәбен аңламыйча.

— Шундый ук кәгазьләрне спирт заводы курасыннан да тапканнар! Пар тегермәннәрендә капчыклар арасыннан чыккан! Балтачы Низамыйларның тәрәзә капкачларына кыстырып киткәннәр. Ситдыйкларның...

— Нинди кәгазьләр соң ул?

— Дөньяда ишетелмәгән хәл: патша хәзрәтләренә каршы язылган кәгазьләр икән!

Миңлебай белән Нәфисә чынлап торып куркыштылар, безнең ишегалдына ничек килеп эләкте икән, дип бик озак баш ваттылар. Абзаркура арасын тикшереп керделәр, урам якка чыгып ярык-йорыкларга күз йөгертеп чыктылар. «Бөтен кала купкан, стражниклар чаба, солдатларны кузгатканнар, әзлиләр генә! Базардагы халык шаккатып калган!»— дип, һаман яңадан-яңа хәбәрләр өстәп, Миңлебай Нәфисәнең котын алды.

Госман бу хәбәрдән аңгы-миңге килеп, иртәнге чәен дә эчмәде, «башым авырта» дип курага, лапас астына менеп ятты. «Нәрсә эшләдем мин? Әгәр мин икәнне сизә калсалар?!»

Бәхетенә каршы, Имәнтаудан әтисе Гомәр килеп житте...
Госманны изге жирләргә укырга жибәрү турында әтисе белән элек тә сүз булып алган иде. Бу юлы жай да чыгып тора икән.
— Әйдә, улым,— диде азанчы.— Мулладан ат алып ашыга килдем. Шаһимәрдән бай иртәгә хаж сәфәренә Мәккәгә кузгала. Сөйләштем үзе белән. Сине юлда малай итеп алырмын диде... Бәйрүт шәрифкә барып укысаң, кеше булырсың...
Әллә кайларга еракларга китәргә курыкса да, Госман каршы сүз әйтмәде. Төнге вакыйгалар, прокламацияләр, иртән бөтен Күкчәтауның кубып кемнәрнедер эзләве малайны ике юл чатына чыгардылар. Икенең берсен сайларга кирәк иде. Ерак юл да куркыта, монда калу да хәвефле иде. Госман икенең берсен сайлады: ул Бәйрүткә укырга барырга булды!
Шулай итеп, Волик белән башланган юл кителмәгәндә өзелде. Госман эшнең азагын, ни белән беткәнен белә алмады... Ике дус яңадан очрашмасалар да, Шаһимәрдән белән Госман тагын бик тиз очраштылар. Тик бу юлы ул ятим, әтисез, йорт-жирсез калган бер бичара иде... Госманның кем булуын Лачынбай да ишетеп калган иде. Хажи белән аның да ерак сәфәргә чыгып китүен, кайлардадыр укып йөрүен ишеткәч, егетне күрә алмас булды...
Юлга чыгар көнгә каршы төнне Госман Нәсия чалларда кунды. Госманның укый-яза белүе, коръән хәтем кылуы чалга аерата ошады.
— Бәрәкалла, балам, китап дигәнең бездәй күзе йомыкка арзан, ал, менә сездәй күзе ачыкка мәржән! Укы, балам, укы. И борынгылар әйткән гуй, укыган узар, укымаган тузар, дип...
Һәм ул, казах гадәте буенча, беренче очраган кешене буын-буынлап тикшерде, үзен генә түгел, ата-аналарын, бабаларын төпченеп тикшерде. Аннан ул үзенең хәл-әхвәленә күчте.
— И, балам, мин дә синдәй, бала көннең аягына бозау басканның берсе гуй,— дип башлады ул авыр сүзен. Үзе Балхаш күле араларында туып-үскән, жот елны әти-әниләре ачлыктан үлгән, түгыз яшендә жиз казый торган шахталарга төшеп ат куган, вагонеткаларда руда ташыган. Ахырында ютәл авыруына дучар булып Күкчәтау ягындагы туышларын эзләп китәргә мәжбүр булган. Бер байда жылкычы булып эшләгән, кымыз эчеп аз-маз сихәтләнгән. Былтыр кәмпере кылтамак авыруыннан вафат булган. Шул женазада хатынын жирләр өчен Шаһимәрдән хажидан нәсиягә (ягъни бурычка) кәфенлек, ябу, урамал һәм башка мәет кирәк-ярагын алган булган. Әйткән вакытта бурычын түли алмаган. Шул нәсиядән котылыр өчен хажига килеп ялланырга мәжбүр булган.
— И жараткан тәңрем,— дип ыңгырашты чал,— чын атым минем Бәхетжан гуй. Ни кылаең, атым да югалды, нәсиягә чыкканнан бирле Нәсия чал булып калдым. Илнең хөкеме шулай...

## 8

Түгәрәкләнеп утырган каенлыкка життеләр. Мал әйди торган юл шул каенлык янәшәсеннән уза. Куйлар каен күләгәләрен уза башлаганда эчкәреге юлдан арба тавышы ишетелде. Дала юлында һәр очраган жан олы вакыйга ул — Нәсия чал да, Госман да колакларын торгыздылар. Озакламый үгез жигелгән арба үзе дә күренде. Арбага туралган, ярылган, шыңгырдап кипкән утын төялгән, иң өстә кырык ямаулы чапан кигән ап-ак сакаллы карт утыра иде. Ул, малчыларны күреп, үгезен туктатты, керфексез күзләрен челт-челт йомып сәлам бирде.
— Әссәламегаләйкем, балалар.
— Вәгаләйкем әссәлам! Юл булсын, ата.
Утынчы карт бераз иелә төшеп малчыларга үз хәлен сөйләп бирде.
— И, ни, Күкчәтау базарына бер саржен утын алып бара жатырмын.

Бераз чәй-шикәр алаен дигәнем гуй. Балаларны ходай алды. Инде кимперем белән икәү калдык. Кимперем сырхаулап җатыр. Чәй сорап тынычлыгымны алды. Үзем дә сырхауланып торамын. Монау былтырдан калган утын. Кимпернең күңеле булсын дип ала чыктым.

Утынчының тарихы тулаем шушы сүзләргә сыеп бетте, һәммәсе аңлашылды. Ул сорамыйча да малчыларның кем малын һәм кая куулары рын төшенде бугай, колагын малчылар ягына куеп көтеп калды. Нәсия чал күк биясен арбага якынлаштырып барып туктады да билбау кесәсеннән чакчасын[1] алып утын өстендәге аксакалга сузды.

— Ата, дәмен татыгыз.

— Ә, бәрәкалла!— Карт калтыранган бармаклары белән чакчаны көчкә эләктереп алып, бөкесен ачып, болай да салпы иренен тартып насбай салды, күзен йомып суырды һәм үгез өстенә чырт иттереп төкерде.— Насбаең уңган икән, балам, ачысы миемә китте. Мә, чакчаңны.

Карт белән сөйләшеп торган арада куйлар таралып та киткәннәр, алга, еракка ук узган Лачынбайның камчы белән һаваны айкаганы күренеп калды, Иркәтай белән Нигъмәт тә тынычсызланып Нәсия чалга кычкырдылар. Госман белән Нәсия чал атларын юырттырып таралып өлгергән куйларны җыя башладылар. Акколак белән Сакколак икесе ике якта чабып йөрделәр. Госман утынчы картка каршы юлдан килгән пар ат җиккән повозканы шәйләп алды. Повозканың ике ягыннан ике атлы казак та килә иде. Менә алар утынчы белән тигезләштеләр, нидер сорадылар, кулын арлы-бирле селтәде карт, урысларның ни әйтүен төшенмәде бугай. Үгез койрыгын болгап бара бирде. Госман куйларны эзәрлекләп юлга табарак чыккан иде, казакларның янап кычкырганнарын ишетте. Зур сакаллы, киң җилкәле казак менә нагайкасын күтәрде. Нәсия чал да шуны күзәтеп тора икән: «Уй-бай, монысы ни?!»— дип, ул да аптырап тавыш бирде. Ул арада теге картның җан тавышы ишетелде.

— Үлтерде гуй! Ал-лай!

Яшьрәк казак нагайкасы белән үгезгә китереп сукты. Үгез ялт борылып далага чапты. Повозканың тәгәрмәче ашыгып тәгәрәде, казаклар үз юлларында булдылар. Карт арбадан тәкмәрләп төшеп калды.

Нәсия чал белән Госман килгәндә, теге утынчы карт җирдә аунап ята иде. Авыз-борыны күбекле кан. Сул күзе атылып чыгып, бер тамырда гына асылынып калган.

— Үгезне тот, үгезне!— дип кычкырды Нәсия чал, ни кылырга белмичә. Үгез мескен аркасының әрнүеннән качып, утыннарын чәчеп бетереп, әллә кайдагы әрәмәлек эченә кереп терәлгән иде. Госман аны көчкә эзләп тапты. Үгезне әйдәп килгәндә, Нәсия чал утынчы картны кылган өстенә сузып салган да тезләнеп, кыйблага карап, кулларын догага күтәргән иде. Моңа хәтле тартылып, көйсезләнеп килгән үгез, җирдә яткан хуҗасын күргәч, шып туктап калды. Госман шулай да баш җебен кулыннан ычкындырмыйча гына Нәсия чал артына килеп тезләнде.

Инде нишләргә? Утынчы мәрхүмне карар идең, куйлар таралып бетәчәк. Ташлап китәр идең, күз алдында булып узган хәлләрдән соң, кяфер кулыннан шәһид мөселманны болай ничек калдырасың?! Нәсия чал битен сыпырып урыныннан торды да:

— Лачынбай килеп күргәнче, китик без моннан, балам,— диде. Госман ике куллап чалны кочаклап алды.

— Болай калдырырга ярамый, ярамый,— дип кабатлады ул. Күз яшеннән авызы кыйшайды, тыны кысылды, күзләре томаланды. Ул арада: «Атаңа нәләт, чучкалар, этләр!» — дип яман акырып-бакырып Лачынбай килеп җитте. Ят үгезне, җирдәге мәетне һәм тәмам аптырашта калган малчы юлдашларын күргәч, ул да тынып калды, чүгәләп дога укыды. «Ярар, сез авылга илтеп килегез бу бичараны. Хаҗи әфәнде

[1] Чакча — тел астына сала торган тәмәке — насбай савыты.

белән үзем сөйләшермен»,— дигәч, Госманның сөенгәнен күрсәгез сез!

Мәрхүм, үзе әйткәнчә, каенлык артындагы Сарысу үзәне буена утырган Кара авылдан икән. Чылтырап аккан кечкенә елгачык буенда берсеннән-берсе ярлырак, корымланып, ямалып беткән бу өйләрне күргәч, исеме җисеменә хас икән бу авылның дип уйлыйсың! Кутан буш. Арлы-бирле йөргән берәү дә күренми. Арба өйләргә якынлашкач кына, бер өер эт чыгып ярсып-ярсып өрә башладылар.

Бу тавышка бер-бер артлы киез өйләрнең ишекләре ачылды. Аннан керле кимәчекләр һәм җәенке битләр күренде. Ул арада әллә каян, кычкырып, чуен китеге кебек кап-кара малайлар килеп җитте, алар арбаны урап та алдылар. Шунда гына бирге өйдән кулын маңгае өстенә куеп бер аксакал чыкты.

Яшүсмер егетләр, Нәсия чал, Госман, мәетне арбадан алып, якындагы иң ертык өйгә — куышка кертеп салдылар. Шул вакытта гына өйдә җан иясе барлыгы беленде, киез куышның түрендә өелеп яткан тире-яры селкенә башлады. Кемдер ыңгырашып кузгалды, торып утырды, ертык көпе[1] эченнән тузган аксыл чәч күренде. Чәч чайкалды, таралды, ботак тишеге төсле ике караңгы, хәрәкәтсез күз карады.

— Уй-бай,— ябага көпе авып китте.— Мине кемгә калдырдың?

Тавыш бераз иңрәде дә кинәт өзелеп тукталды. Шау-шу баскан өй эче тып-тын калды. Учак янында тәсбих тартып, тәһлил әйтеп утырган бер кимпер, акрын гына торып, барып көпене ачты һәм чинап җибәрде:

— Уй-бай, Сасыкбайның кимпере дә кайтып китте гуй![2]

Болай да кайгы белән тулган өй эчендә тагын такмаклап елау, чырчу башланды. Һич көтмәгәндә-уйламаганда авылга Шаһимәрдән хаҗи килеп җитте. Ул ияген сыпырып, кыска гына дога укыды да: «Минем ашыгыч эшләрем бар, үзегез җирләшегез, миннән дәфенгә бер куй»,— дип фатихасын биреп китте. Хаҗи кадәр хаҗиның фатихасын алу мәрхүм Сасыкбайның төшенә дә кермәгәндер, мөгаен! Бу ике үлем Госманны тетрәтте, күңелен асты-өстенә китерде, ул барыннан да бигрәк этисен хәтерләде... Халыктан качып, өй артына чыгып елады һәм аз-маз тынычланды.

— Ал, шәкерт — Госман сискәнеп сикереп торды. Лачынбай икән. Чырае караңгы. Ә тавышы басынкы. Баш малчы камчысын күтәрергә дә ашыкмады, Госманны күлмәк итәгеннән тартып үз янына утыртты.— Хаҗи җөреп китте. Бу авылда инде җеназа укый белгән адәм юк. Үзем дә бисмилладан уза алмыйм. Инде җеназа намазын син укымасаң, булмас!

— Юк, ага, мин җеназа укый алмам.

— Шәкерт!— диде Лачынбай ике сөйләшергә мәеле юклыгын аңлатып. — Син инде таһарәтеңне ала тор!

«Шәһид киткән җаннар» дип, ике мәетне дә юмыйча, кәфенләмичә, кигән киемнәре белән арбага салып, зиратка алып килделәр дә, ашыкпошык кына казылган каберләр янына, башларын кыйблага каратып сузып салдылар. Госман, башына яулык бәйләп, мәет башында сирәк сафта торган картлар алдына чыгып басты. Һәм каушап калды. Нишләргә икән? Ике мәеткә бер җеназа чыгаргамы? Әллә һәрберсенә аерымаерым укыргамы?!

Ул коръән хәтем кылган булса да, җеназа укый торган аятьләрне күңеленнән белсә дә, икеләнде, тәртибен белми иде, ике мәет, җитмәсә берсе ир, икенчесе хатын.

Ул арада арттагы картлар тамак кыра башладылар.

— Аллаһе әкбәр!— дип, Госман ике кулын колагына күтәрде дә аять укый башлады. Анысы ярыйсы гына чыккан иде, ә мәнә, тагын

---

[1] Көпе — ябага йоннан тегелгән җылы чапан.
[2] Казах халкы «үлде» димә, кеше вафатыннан соң «кайтып китте», яисә «кайтыс булды» дип сөйли.

бөлдереп куя язды. Ул, башка намазлардагы кебек сәҗдәгә бөгелә башлаган иде, ярый әле, җеназада сәҗдәгә китмәү кылт исенә төшеп, ялгышын тиз төзәтте, турайды һәм ихлас күңеленнән, ышанып, тагын ике аять укып, догасын мәрхүмнәр рухына багышлады. Үзенә карап оеган картларга борылып, нәкъ муллаларча:

— Җәмагать, дәфен ияләре яхшы кеше идеме?— дип сорады.

Озак басып торудан, киеренкелектән аяклары каткан картлар, төрлесе төрле яктан:

— Ия, ия, жаксы адәм иде икәве дә.

— Сасыкбай да, Торсын да жаксы адәмнәр иде.

— Җаннары җәннәттә булсын, амин.

— Әй, көрәк кайда?!— диештеләр.

* * *

Ике мәетне җирләгәч, каберчеләр авылга кайтып, Шаһимәрдән хаҗиның «дәфенгә һибә кылдым» дигән бер сарыгына (аны атардан сайлап, иң симезен табып, Лачынбай үзе алып килде) авыл халкы җыелып кушылган акчага сатып алынган икенче куйны кушып, суеп, пешереп ашап, өлкәннәрнең рухына багышланган бата-фатиха кылдылар.

Менә шушы соңгы аш — ике куй белән Сасыкбай әкә, янә Торсын чишәнең бу фани дөньядагы ризыклары киселде. Алар туып-үскән Кара авылларын ташлап бакый дөньяга мәңгелеккә рихләт әйләделәр һәм онытылдылар. Дөньяга килделәр, киттеләр, юк булдылар. Җеназа укыган Госманның соңгы соравына бирелгән җаваплар аларның җирдәге тормышларына иң соңгы һәм олы хөкем булды. Сасыкбай исән чакта бер авыздан да «жаксы адәм иде!» дигән сүзне ишетә алмады. Ишетергә хакы булуы турында уйламады да. Өлкәннәр ит-сөяк кимергәндә Госман тагын беразга гына ялгызы калды. Ялгызы уйланырга, уйларының очына чыгарга тырыша башлаган чагы килде егетнең. Тиктомалдан, тел белмәгәне өчен генә булса кирәк, картның җанын кыеп киткән камчылы казаклар турында да уйлады ул. Киез өйнең фәкыйрьлеге, карчыгының өс-башының ертык-пыртык булуы аяусыз булып аның күз алдыннан китмәде. Болар да яшәгәннәр инде, гомер иткәннәр... Кинәт аның күңеленә Волик Куйбышев әйткән сәер сүзләр килде. «Изелүчеләрне яклау... Патшага каршы көрәш... Патша иң явыз бәндәләрнең берсе... Социал-демократлар... Оешмалар... Омскидан кайткан прокламацияләр». Һәм яшь, йөгерек уйлары тагын Сасыкбайга, Кара авыл кешеләренә әйләнеп кайтты. Җирнең ике ягында яшәгән Волик белән Сасыкбай... Волик бу тормыш, бу кирәксез үлем турында ни әйтә алыр иде икән?! Әле бу сорауның очына чыга алмады Госман. Юлның, гомернең озын икәнен, алда сорауларның тагы да күп булу ихтималын гына сизә иде ул.

Батадан соң безнең мал әйдәүчеләр куйларны бүлеп-бүлеп Сарысу елгасында сугардылар. Бу эшкә байтак вакыт үтте. Шуның өчен атар Кара авыл җәйләвеннән кичегеп, көннең күзе сүрелә башлаганда гына кузгалды. Бу юлы Кара авыл этләре абалап өрмәделәр инде, алар, мөгаен, үз гомерләрендә беренче тапкыр, туйганчы тәмле, изге сөякләр кимерәләр иде.

## 9

Атар акрынлап барып Кече Чабак күле буена барып туктады. Малчылар аттан төштеләр. Кечкенә дип аталса да ярыйсы ук зур күл икән бу, гранит ташлардан өелгән тау итәгендә җәйрәп ята. Башта, атар якынлашып килгәндә, кыялар янып, кызарып торалар иде. Бераз-

дан алар сүрелеп алсуландылар, шәмәхә төскә күчтеләр. Кичке жил китергән болытлар кыя очларына сарылган.

Куйларны сугарып далага утларга җибәргәч, малчылар кичкә коры чәй генә эчтеләр. Кара авылда җеназа ашында туйганчы ашаганга, арбадагы итне алдагы көнгә саклап, казан асмадылар.

Лачынбай, чәйдән соң, гадәтенчә насбай атты да, учакка чыжылдатып төкереп, насбайның тәмен татыгач, Нәсия чалга төбәлде.

— Әй, чал, бүген төнгә күзәткә Иркәтай белән Шәкертне ал. Өчәү булыңдар. Кара, җоклап малдан аерылып калмаңдар. Монда якында гына өлкән авыл бар, җаман адәмнәрнең дә булуы ихтимал. Мин бик ардым, бер ял итеп алаем. — Улияр-тукымны баш очына тартты да чикмәнен ябынды.

Тау башындагы сиреньнәр сүнде. Тылсымлы күл караңгылыкка чумды. Дала өстенә җылы, аз гына дымсу, күгелҗем төн килде. Күктә бер-бер артлы йолдызлар кабынды. Озакламый, тау башындагы мәгърур кыялар арасында көмеш урак күренде. Урман эчендәге учаклар яктырак яна башладылар. Авылның кайсы якта икәнен бу юллардан күп тапкырлар узган Лачынбай ишарәләгән иде инде. Шул яктан күл өстендә шыңлап авылда көлгән тавышлар яңгырады, сызгырган, күмәкләп әйтелгән үләң-көй тавышлары ишетелде.

Иркәтай атар артына ук чыгып яткан Госман янына килде.

— Әй, шәкерт, ишетәсеңме?

— Ә-ә? — Госман шикләнеп калды. — Ни бар? Бүреме?!

— Җук, курыкма. Тыныч. Монда качкыр килмәйде. Бер җакта су, бер җакта авыл. Әнә, җаштар үләң әйтеп җатыр. Анда авыл җаштары алты бакан тибеп[1] җатыр.

— Тибә бирсен. Анда безнең ни эшебез бар?

Госманның күзенә йокы эленгән иде инде. Тик Иркәтай алай тиз генә тынычлана алмады, юлдашы янына чалкан ятып, кулларын баш астында учлады.

— Беләсеңме, анда ничек кызык булады! Җегетләр думбыра чиртәде, кызлар үләң әйтәде. Чалдан рөхсәт сорап барып килсәк, ә? Алыс имәс.

— Кит аннан! Ерак булмаса ни! Монда куйлар!— Госман кулын гына селтәде. — Лачынбай әкәнең ни әйткәнен ишеттеңме? Кирәгеңне бирер.

Җил исеп китте, төтен исе аңкыды. Кызларның көлүләре нәкъ якында гына кебек яңгырады. Бу тавыш Госманның да йокысын ачып җибәрде.

— Кара, чыннан да кызык уйныйлар, ә!

Иркәтай куанып китте:

— Әйдә, чалдан рөхсәт сораек!

— Ә? — Госман тагын икеләнде. — Лачынбай әкә уянса?

— Аннан курыкма. Ул бер йокласа таң атбай тормайды.

Нәсия чал яшьләрнең сүзен егып ташларга кыймады:

— Карагыз, балалар, озап китмәгез.— диде. «Ул-бу булып калмасын».— дип, Лачынбайдан курыкса да, тәвәккәлләп рөхсәт бирде.

Иркәтай белән Госман авылга килеп җиткәндә, кутан гөж килеп торган халык белән тулы иде. Кутан уртасында бөтен авылны яктыртып учак яна. Халык аны алкалап урап алган. Алда, аякларын сузып җибәреп, ярым кыйшайган авыл өлкәннәре ята — аксакаллар, кәмпирләр. Алар артында азаматлар — урта яшьтәгеләр, кара сакаллар. Алар, чакчаларын чыгарып, бер-берсен насбай белән сыйлыйлар, насбайларының куәте белән мактанышалар. Болар янында кым-кырыч булып, күлмәк изүләрен чишеп ташлап, кабарып торган сөт тулы мул имчәкләрен чыгарып салып, балаларын имезә-имезә гайбәт сөйләүче урта

[1] Тибү — бу урында таган атыну.

яшьтәге хатыннар, тукаллар. Кайсы анадан тума шыр ялангач, кояшта көеп-каралган ыбыр-чыбыр бала-чаганың саны-исәбе юк. Чыр-чу. Елау. Чәкәләшү. Әрләү. Каргау. Монда барысы да бар.

Алканың иң артында аягүрә баскан бүз балалар — егетләр, кызлар, яшь киленчәкләр. Егетләр юри бер-берсен эткән булалар, ялып китеп кызларга елышалар, мутраклары алма-алма имиләрне йомарлап та өлгерәләр. Яшертен генә үбеп тә алалар...

Җыелган халыкның күңеле көр икәнлеге сизелеп тора, сүзләр бетми, сүзләр су урынына ага, димәк, алар аерым бер тантана көтәләр, шуңа әзерләр, шуңа якындагыларны әзерлиләр, котырталар булса кирәк. Госман белән Иркәтай килеп җитеп кенә калдылар, кутан каршындагы олы өйнең ишеге ачылды, аннан кысылып, ишеккә көчкә сыеп чүмәләгә охшаган юан бер кеше чыкты. Аның артыннан ук тагын берәү күренде. Юан кешенең чыгуы сүзсез-ымсыз узган иде, арттан чыккан кешене күреп учак тирәсендәге халык кузгалып шаулаша башлады.

— Әнә, әнә, Җамбыл чыкты! Җамбыл!

— Әссәламегаләйкем, акын ага!
— Хуш килдегез!
— Ай, коргыры, аягыма бастың...

Госман белән Иркәтай акынны кызыксынып күзәтеләр. Егетләрчә тота үзен, килеш-килбәте дә әллә кайдан аерылып күзгә ташлана. Өстендә яхшы дөя йоныннан тукылган кызгылт-соры чикмән, башында яшь бәрән тиресеннән тегелгән кара илтер бүрек, аягындагы итеге дә өр-яңа, озын кунычлы.

Бер-ике егет учакка кочак-кочак чыбык ташлады, тирә-як бер мәлгә караңгыланып китте, ә бераздан гөлт итеп кабынды, чытырдап яна башлады, кутан көндезге кебек яктырды.

Учак янында, очкын төшмәслек ераклыкта ап-ак киез, монда якынлашкач, хуҗа бераз туктап калып, кунакны алга чыгарды һәм вәкарь белән генә:

— Акын, сезнең урын, рәхим итәсез! — диде. Җамбыл, «рәхмәт» дип, шул киез өстенә аякларын бөкләп утыра калды. Хуҗа аннан читтәрәк җәелгән ястыкка таба килде дә кәвешләрен салып ташлап, көч-хәл белән иелеп ястыкка чумды, әүвәле кыйшаеп ятып торды, аннан соң гына көч-хәл белән күтәрелеп, тураеп утырды. Акынның һәр адымын күзәтеп торган тере күзләр хуҗаның ястыкта әвәрә килүен абайлап тыела алмыйча көлеп җибәрделәр. Иркәтай белән Госманга да кызык тоелды, алар бер-берсенең касыкларына төртешеп, хуҗаның һәйбәт ястык кадәр корсагын бер-берсенә күрсәтә-күрсәтә көлештеләр.

Җамбыл утыру белән ашыгып, кемнедер эзләгәндәй, тирә-якка карады, кайсы якка караса да елмаюлы ачык йөзләр белән очрашты, тик эзләгәнен тапмады ахрысы, карашы беркемдә дә тукталмады, аннары киез өстенә куйган думбырасын кулына алды, колагын боргалап, эчәге кылларны бер тартып, бер бушатып, бармаклары белән чиртеп-зыңлатып, нелә төшеп, кылларының яңгырашын тыңлап, «тавыш эзли» башлады.

Әле генә гөжләп, чайкалып торган кутан бердәм тынды. Шуны гына көтеп торган сыман, хуҗа учак тирәсендәгеләргә һавалы бер караш ташлады да, ике учы белән корсагын астан өскә сыпырып алды, тавышын артык күтәрмичә, әмма бар халыкка ишетелерлек итеп, олы өй янындагы кечерәк, ләкин аңа караганда да аграк, затлырак киездән тегелгән өйгә карап, әйтешне башларга вакыт җиткәнен белдерде һәм кызын ил уртасына чакырды.

— Ал, җәмагать: айтысны башласак та булыр. Әй, колыным, Айкөмеш! Син кайда? Килә гүй.

Госман белән Иркәтайның колаклары үрә торды. Менә ни өчен шул кадәр һавалы икән бу хуҗа! Аның кызы Айкөмеш атаклы акын Җамбыл белән ярышырга тиеш икән!.. Бар күзләр киңрәк ачылып киез өйнең серле ишегенә төбәлде. Ак өйнең кызыллы-яшелле өлгеләр белән бизәлгән ишеге җиңел генә ачылып китте. Озын, зифа буй. Түгәрәк, тулы йөз. Зур кара күзләр һәм аларны серле күләгәләп торган сызылып киткән кыйгач кашлар. Аз гына елмайса да бөтен чырайны яктыртып алган матур уелган алсу иреннәр. Егетләр учакка утынны тиккә генә өстәмәгәннәр икән! Әллә чынлап чибәр идеме Айкөмеш, учакның сихерле яктысында ул балачак әкиятләрендә ишетеп күнеккән хан кызларын хәтерләтерлек дәрәҗәдә сылу, гаҗәеп гүзәл иде. Итәкләре кабарып торган дүрт бәбәйтәкле ак ефәк күлмәк өстеннән алтын ука белән каймаланган кызыл, фай камзул кигән, башында киң кырпулы кама бүрек. Аның да сул кулында озын муенлы, ефәк тасма белән бәйләнгән думбыра. Айкөмеш кызу адымнар белән акыннан аз гына читкәрәк, аңа каршы җәелгән тикәмәт[1] өстенә барып утырды, алдына төшкән озын, кара толымнарын чайкалдырып артка ташлады. Думбырасын тез өстенә куеп, әдәп йөзеннән башын түбән иде.

Госман ни арада Иркәтайны күреп алды һәм егетне танымады. Моңарчы утлы күмер кебек көйрәгән күзләрен Җамбыл акыннан алмый утырган бөкре малчы хәзер бөтен барлыгы, ихтыяры, гыйшкы белән Айкөмешкә таба суырылган иде. Аның башкаларны бөтенләй күрми башлавын Госман бик тиз сизеп алды, егет аның ничә тапкыр эндәшкәнен ишетмәде, ничә мәртәбә иңенә кагылганны сизмәде, ул бары тик акын кыз ягына сеңеп беткән иде.

Ниһаять, кутан, сулышын өзеп, учак алдында утырган акын белән кызга төбәлде. Әйтешне, гореф буенча, авылның кунагы, ерак Җидесу иленнән килгән атаклы акын Җамбыл башлады. Думбыра кыллары дерелдәп, бер югары, бер түбән тонга күчтеләр, кыллар озак кына чыңлагач, көй башланды. Җиңел, һәр күңелне кузгата торган көй!

Халык киң сулыш алып колагын торгызды.

> Әдәс, ат тирләтеп килдем туйга,
> Айкөмеш, әүвәлдән үк булдың уйда.
> Дәртемнән тына алмаган җегет идем,
> Ашыгып әйткәнемә гаеп куйма.

Алканың артында сабырсызланып, Айкөмеш алдында егет исемен җиргә төшермәвен теләп торган бүз балалар, акынның бу сүзләрен ишетеп, үләңне күтәреп җибәрделәр.

— Ва диген!

— Мең яшә, Җамбыл ага!

Айкөмеш шау-шуның басылуын да көтмәде, бәйге аты кебек ярсып, думбрасының кылларына чиртте, яшел ефәк тасма җилфердәп кабынып китте, нәфис бармаклар ныгып, көчәеп, кыллардан саф көмеш кыңгырау чыңнары чыгардылар.

> Ашыктың нигә болай амандашмай?
> Әдәпкә өйрәнмәдеңме син яшьләй?
> Асмандагы асылга кулың җитмәс,
> Акыл белән кузгалчы, артык шашмай.

Кутан Айкөмеш яклы икән: ду итеп гөрләде! Бигрәк тә кызлар, яшь киленнәр чишелеп китеп кызны мактадылар:

— Айкөмеш, бирешмә!

— Акынны җыгып сал!

— Әйт, әйт, колыным!

[1] Тикәмәт — бизәкләп эшләнгән киез.

Хужа, куанычыннан, тырпайган бармаклары белән корсагын туктаусыз уа иде.

Акынның намусы бу яраны күтәрә алмады, исеме бар, даны! — ярсып тавыш бирде.

Айкөмеш, ашыкмауга чамам бармы?
Яшьлегем сугылдырды төрле ярга.
Ятсам, торсам, үемда бер син генә —
Жим булып китмәсме дим яманнарга?!

Айкөмешнең кашлары канат какты, иреннәре елмайды. Думбра кыллары аның йөрәк серен кутандагыларга җиткерделәр:

Белерме бәндә мескен үз өлешен?
Чамаңны бел, ят көмешкә орынма син.
Башка җортка боерган җан булырмын,
Акыным, әдәп җуеп үрелмә син!

Кызлар пырх-пырх көлешә башладылар. Егетләр аларның авызын каплаган булып кыландылар. Кызлар йомылып кына аларның кочагына кереп тә чыккалады, шау-шау, тулы җанланыш арасында кем кемне күргән дә кем кемне эзәрлекләгән!

Иркәтай белән Госманның тавышлары аерылды. Госман тулаем акын ягына күчте, ул үләң әйткәндә, сикереп-сикереп алды, ә Иркәтай бөтен җаны-тәне белән Айкөмеш ягында иде! Кызның думбрасы чиртә башлауга ул үзен-үзе белештермичә алга тартыла, онытылып, йотлыгып, кызның сүзләрен йөрәгендә сеңдереп тын да тартмыйча тыңлый иде.

Акын кысылды, кызарды. Тавышын бар көченә күтәреп үз исемен даулады:

Монда хәзер утырсаң да зур булып,
Бер җаманга барырсың син хур булып.
Чебен-черки күзеңә керер әле,
Үлгәнче йөрерсең син сур[1] булып!

Айкөмешнең төсе кинәт карангыланып китте, бармаклары калтырандылар. Моңарчы йокымсырап утырган хуҗа да ястыгыннан калкынды.

Җамбыл-ау! Күперәсең син нигә монча?
Мактанудан ярылыр эчең тулса.
Кулыңдагы тургайдан ник айрылдың?
Тоткасы бу дөньяның синдә булса?!

Тирә-як күк күкрәгәндәй калтыранды. Кутандагы барлык халык берьюлы көлеп җибәрде. Госман да кызның тапкырлыгын мактап икеөч тапкыр тамак кырып алды.

— Уй-бай, Җамбыл үлде!

— Уй-бай!

— Яшә, кызым, алып суктың!

Иркәтай, куанычлы көлә-көлә, Госманга пышылдады:

— Беләсеңме, йорт нигә болай көлә?

— Юк, кайдан белим.

— Болай ул, — Иркәтай, көлүен көчкә тыеп, тотлыга-тотлыга сөйләп китте: — Анау җылны Җамбыл акын Борым дигән бер кызны алып кача. Тик Сарыбай дигән би, ул кызны Җамбылдан тартып алып, туган өенә кайтара. Кызның «тургайдан ник аерылдың?» дигәне шуңа карата.

Кутан, тынычлана алмыйча, озак гөрләде, кызлар бөгелә-сыгыла көлделәр, егетләр аларга ташланды, ыгы-зыгы купты. Җамбыл мондый

[1] Сур — бичара, байгош.

тукмакны һич көтмәгән иде. Айкөмешнең сүзе иткә генә түгел, сөяккә үтте. Әмма акын иң соңгы минутта үзенә-үзе хуҗа була алды, моңарчы ишетелмәгән көчле-яңгырау тавыш биреп, думбрага сукты.

Дөньяда зарлы икән кыз һәм егет,
Йөрим мин күбрәк уйлап, азрак көлеп...
Ярсуы басылмаган әрсез күңел
Әле дә бәйләп тора сезгә өмет.

Айкөмеш башын чайкады һәм ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды. Егетләр, ашыгып-ашыгып, сүрелә башлаган учакка утын ташладылар.

Егеткә өмет йолдыз булып янар,
Көнләшер ул йолдызны җүнсез-җүләр.
«Мин беләм!» дип мактану, Җамбыл ага,
Сездәй егет кешегә ник килешер?

Учакка ташлаган ботак-сатак дөрләп кабынмады, ут сүрелә башласа да, акын белән Айкөмеш арасы кыза гына барды. Бөтен халык тын да алмый акын белән кызның авызына караган — әйтештә кем җиңәр?!

Атаклы акын Җамбылмы?

Әллә сылу кыз Айкөмешме?

Госман акын сүзенең өстен чыгуын көтә. Иркәтай, дөньясын онытып, кызның һәр сүзен генә түгел, һәр хәрәкәтен күңеленә сеңдереп, аның сүзе өстен чыгуын тели. Әйтешләрдә бик күпләрне җиңеп өйрәнгән акын алай гына бирешмәде, турыдан-туры һөҗүмгә күчте:

Ахак авылым җәелеп ята Күксеңгердә:
Сезнең якка сөзеп карап әлсерәдем.
Очып килдем дала шоңкарыдай,
Сине күрү иде минем бар теләгем.

Кутан җитди сүзгә сагаеп калды. Айкөмешнең җавап тавышы, бераз калтырап чыкса да, ачык иде, көчле иде:

Җамбыл-ау, тота алмассың, үпкәләмә,
Син тотасы кошлар юктыр бу туганда.
Яхшы сүз — җан симертер дигән бар гуй,
Шулмы синең яхшы сүзең? Булса, кайда?

— Әй, рәхмәт, кызым!

— Сүзең алтын!

Кызлар аерата нык шауладылар:

— Рәхмәт-рәхмәт, Көмеш-җан!

— Шоңкар да тота алмас диме? Һай, уңганны!

Акын да арган иде, бераз тын алды, җиргә тәгәрәп төшкән илтер бүреген алып киде. Инде соңгы сүз яңгырады.

Айкөмеш, әмәлем юк. Хуш, алайса!
Аерылыйк сер белдерми ят адәмгә.
Атыңны, ак йөзеңне онытмамын,
Күңелемдә мәңгелеккә ут сүнгәндә.

Думбыра кыллары соңгы кат чыңладылар да тындылар. Кутан берике минутка көйдән, җанлы тантананың сихереннән аерыла алмыйча торды да, ниһаять, уянып китте, акын исеменә дә, кыз исеменә дә төрле мактау, хуплау сүзләре яуды. Җамбыл, сикереп торып, кулын күкрәгенә кушырып, ил хөрмәтенә ризалыгын белдерде:

— Зур рәхмәт, аталар! — диде. Хуҗа да җитез генә торып басмакчы иде, йомшак ястыкта авып китте, аны көлә-көлә торгыздылар.

— Өйгә бараек, акын,— дип хуҗа кунакны өйгә сый ашарга чакырды. Алар өйгә атладылар, халык шаулашып тарала башлады. Картлар,

кимперләр туры өйгә — йокларга ашыкты. Ә егет-кызлар өйгә дә кермәделәр, малны да кайгыртмадылар, тугайга «Алты бакан»[1] тибәргә йөгерделәр.

Иркәтай Айкөмеш кереп киткән кечкенә өй ишегенә карап каткан иде. Госман кат-кат аның җиңеннән тартты.

— Тизрәк кайтып җитәргә кирәк. Лачынбай ага уянып калса!..

— И, Успан, син курыкма. Кымыз эчкәч ул озак җоклайды!

— Ә чал?

— Ул рәхимле адәм, рәнҗемәс. Мал төнлә тыныч кына ятады, әйдә, тагын аз гына кызык караек, ә?

— Ну, син — иблис!

Алар килгәндә, биек каеннар, карагайлар белән уралган киң алан эче шау-гөр килә иде.

— Әй, Усман! Карачы!

— Ни булган?

— Шуны да күрмисеңме? Әнә, алты баканда Айкөмеш атына! Нинди сылу, ә?!

Бер егет, тезләрен бөгеп-турайтып, бөгеп-турайтып, бар көченә тибә, Айкөмеш, очып, бакан өстенә диярлек күтәрелә, төшеп китә, тагын оча. Кычкырып та куя.

— Ай, Солтан, акрын! Җыгылам, ай!

Башкалар аларны тамаша итеп җыр башлыйлар. Егет белән кыз таганда түгел, иксез-чиксез бәхет диңгезендә йөзәләр кебек... Айкөмеш тә җырга кушыла. Аның иркә, назлы тавышы башкалардан аерылып тора. Җырга читтәрәк торганнар да кушылгач, ул үсә, яңгырый һәм күгелҗем томанга төренеп, тирән йокыга талган карагайларны, каеннарны һәм зәңгәр даланы уятып, биеккә, таулар арасында моңсу гына йөзгән яшь айга, алмаз йолдызларга үрелә. Нинди изге җыр бу — яшьлек җыры, мәхәббәт җыры! Юк, бу җыр гына түгел, бу гамьсез, йөгәнсез, гүзәл яшьлекнең талпынуы, ярсып канатлануы, илаһи биеклеккә бәхет-сәгадәт дөньясына ыргылуы бу...

Алты баканга алмаш-тилмәш яңадан-яңа парлар күтәрелде, яңадан-яңа уләңнәр әйтелде, яңадан-яңа серләр чишелде...

Ахырда: «алыстан килгән кунаклар, сез дә уенга кушылыгыз!»— дип, Госман белән Иркәтайны да алты бакан тибәргә чакырдылар. Госман, «мин җырлый белмим, әнә, Иркәтай әйтсен!» дип, аны этә-төртә башлады. Шул арада әллә кайдан гына Айкөмеш килеп чыкты да Иркәтайны кочаклап күтәреп алып, таганга менәргә булышты, үзе элмәкнең икенче ягына басты. Шашып, аптырап калган Иркәтай башта таганнан төшәргә ыргылып карады, әмма Айкөмеш аны нык тоткан иде, җибәрмәде. Егетләр, кызлар, көлешә-көлешә, таганны тирбәтә башладылар. Айкөмеш үзе чүгеп-чүгеп Иркәтайны күтәрергә тырышты. Ниһаять, малчыда да егетлек уянды, ул таганны үз ихтыярына буйсындырып, көчле аяклары белән биеккә-биеккә менгерә башлады. Каршысында басып торган нурлы кызны күңеле белән йолдызларга атты, ниһаять, куркуы узып, көчле, яңгырау аһәң белән моңлы җыр башлады. Моңарчы беркемнең дә бу аланда андый моңлы җыр җырлаганы юк иде. Моңарчы бер кыз белән дә шулай якын басып торганы булмаган Иркәтайның, беркайчан да болай матур итеп җырлаганы юк иде...

[1] Бакан — кнез өй теккәндә чаңгыракны күтәрә торган ике җәпле, озын һәм нык каен колга. Яшьләр уен вакытында шул колгаларны җыеп, өчесен бер якка, янә өчесен дүрт-биш адым калдырып, икенче якка җиргә кадыйлар. Өстән ике ныгытмага тагын бер юан бүрәнә салып арканнар белән ныгытып бәйлиләр. Бу — таган, казахча «бакан» була. Таган атыналар яшьләр, ягъни «алты бакан тибәләр», авылның малын угрыдан, бүредән саклыйлар. Шуның өчен «алты бакан тибү» таң атканчы бара.

* * *

Урман куелыгын узганчы Госман белән Иркәтай манма су булдылар, үлән, яфракларга куе булып чык төшкән иде. Таң атты. Таң белән кошлар уянды. Кайдадыр еракта ялгыз көккүк моңайды.

— И тавышы!— дип куйды Иркәтай йөрәк өзгеч итеп.

Әллә Айкөмеш тавышы турында әйтте, әллә күке кычкыруына ишарәләде, Госман аңламый да калды.

## 10

Айкөмеш авылы малчыларга «иртәнге дәм» дип бер турсык әйрән, бер чиләк каймаклы сөт һәм күп итеп таба нан җибәргән.

Малларны сугарып далага утларга җибәргәч, малчылар күл читендәге куе чирәмлеккә тезелеп утырып, «кунак ашы» белән сыйландылар. Акколак белән Сакколакка да өлеш тиде — нан белән сөт ашадылар. Хуҗалар ашап-эчеп, дога кылгач, юлга әзерләнә башлаганнар иде, Лачынбай:

— Сабыр!— диде.

Малчылар, ни булды, хаҗидан бер яман хәбәр бармы дип, хәвефләнеп утыра калдылар. Лачынбай, гадәтенчә, салкын гына карады да әйтте:

— Хаҗидан кеше килде. Үзе Укҗитмәстә өй теккән, кунак чакыра икән. Ике кысыр сарык җибәрергә кушкан.— Ул, сүзен шушы урында бүлеп, һәрвакыт ачулы күзләре белән иң элек Иркәтайга, аннан Госманга төбәп карады. Икесе дә коелып төштеләр, димәк, үткән төндә алты баканга баруны сизгән! Хәзер эләгәчәк! Нәсия чалның да йөзе сүрәнләнде.

— Мин хәзер якындагы авылларга барып, хаҗига ике саба кымыз алып киләм. Ал, Иркәтай белән Усман, сез Алачапанны арбага җигегез дә, ике куйны салып, Укҗитмәскә кузгалыңдар. Әй, чал! Син хәзер ике симез куйны сайлап, балаларның арбасына сал, җылдам, көн чыгып барады.

Китә башлаган чалны тагын туктатты Лачынбай, тагын, сүзен әйтми, текәлеп торды.

— И, ни, хаҗи әйткән, монда бер-ике көн туктап, малны дим[1] алдырсын дигән! Малны борма, утлый бирсен.

Бусы бик куанычлы хәбәр иде! Малчылар куандылар, Иркәтай җиргә ятып, туп булып тәгәрәп тә китте.

Ничек сөенмәскә, ничек тәгәрәмәскә?! Тагын сылу янына! Айкөмеш янына, алты баканга! Әгәр хәзер Иркәтайга «анау авылга хәтле шулай тәгәрәп бар!» дисәләр, мөгаен, эһ тә итмичә, давыл чәчәге төсле тәгәрәп китәр иде, байгыш.

Башка малчылар өчен дә, шул җөмләдән Госман өчен дә, бу хәбәр— алланың рәхмәте булды. Бер яктан, көтелмәгән ял, икенчедән, күршедә генә бай авыл — юмарт хуҗалар катыгын-сөтен, эремчеген җәлләми җибәреп торачак. Туйганчы аша! Куйлар өчен дә рәхәт — куе, сусыл, тәмле үлән, ирен астында гына тәмле су. Ары-бире йөгереп тояк ярырга кирәкми...

Урман эчендәге юлга килеп кергәч, тәгәрмәчләр дә даладагы кебек дыңгырдап, тузан куптарып әйләнмиләр, акрын гына, бер җайга баралар. Алачапан да моны сизде, адымнарын акрынайтты. Болай да буйга бәләкәй Иркәтай, бөгелеп утыргач, бөтенләй күздән югала, бары аркасындагы бөкресе генә бүлтәеп кабарып тора. Менә шушы бөкре аркага терәлеп, яңа чабылган хуш исле печән өстендә ике олы, май койрык

[1] Дим — ял. «дим алдырсын» — ял иттерсен.

куй, нәкъ сабый бала кебек мышнап, гамьсез тәмле йокы белән йоклый. Госман да үзен, гүя, Имәнтауга кайтып баргандагы кебек хис итте. Нинди якты уйлар, җылы өметләр белән ашкынган иде бит ул туган авылына!.. Кайтты, ятим дә, йорт-җирсез дә калды. Җитмәсә, анасы да түшәктә. Терелерме, юкмы — кем белсен... Ә Галимулланың эше көйле! Фаэтонга утырып кына җилдерә Бохарага! Атай үлмәсә, Госман да укыр иде, аның кебек кенә дә булмас иде, Бохарага гына түгел, Казанына китеп барыр иде! Анда да атаклы мәдрәсәләр бар диләр бит! Казан, татар ягы, кадерле як...

Кинәт урман чыңлап китте, Госманның уйлары челпәрәмә килеп ватылды. Иркәтайның көчле тавышы яңгырады:

Күкчәтауның биеге,
Кыясында уйнар киеге.
Гашыйк булдым, Айкөмеш!
Кайчан таркар көегең?!

Җыр ярсып яңгырады да, канаты сынган кош кебек иңрәп, хәлсезләнеп җиргә төште, сүнде. Аннары үксегән тавыш ишетелде.

— Әй, Иркәтай, ни булды? Берәр җирең авыртамы?

— И, Успан дус,— диде Иркәтай, — мин җыламый кем җыласын? Әйт әле, дөньяда миннән бәхетсез адәм бармы?

— Ник алай дисең әле син?

— Җук, җук, әйтмә!— Ул Госманга сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде. — Мин дә, син дә бүз бала гуй. Минем дә яшьләр белән уйныйсым, көләсем килә. Монау, коргыры бөкре...— Егет сул кулын сузып бөкресенә төрткәләде. — Коргыры! Ил-йорт арасына керергә оялам. Ой, Успан жан, кай мизгелдә тәмам аптыраштa калам, җаным бугазыма килеп тыгыла, үземә үзем урын таба алмыйм. Шунда берәүгә үткен балта биреп: «Чап шушы ләгънәт бөкрене!» — дип кычкырасым килә. Чапса да түзәр идем! Болай адәм хуры булып йөргәнче, үлгәнең мең артык!

Госман күтәрелеп Иркәтайның йөзенә карады. Ә бит ул үзе чибәр! Аның йөзендә, ниндидер кешене үзенә тартып торган ягымлылык, нур бар. Хәтта, менә хәзер, ачы-газаплы күз яшьләре белән юылганда да, йөзе чытылмый, киресенчә, һаман яктылыгын саклый. Күзләре һаман сагышлы моң тулып яналар. Аның бите дә килешле — җәенке түгел, борыны да почык түгел, чамалы гына озынча бит, туры борын, аз гына алгарак чыгып торган түгәрәк, килешле ияк. Чибәр егет, чибәр! Әгәр гариплеге дә булмаса...

— Мин туганнан соң әкә-чичәм[1] Иркәтай дип ат куйган. — Ул, үксүеннән чак тыелып, тагын сөйли башлады:— Чичәм мине «иркәм!» дип чын күңеленнән сөючә иде. Ул авырып дөньядан китте. Әкәм бүтән катын алды да, мин «бөкре шайтан»га әйләндем. Кайда утырсам, шуннан куды ул... Әкәм көне-төне далада, өйдә ни булганын да белмәйде. Кай чагында, муеныма җеп салып, бер агачка асылынасым килә!

Госман тетрәнеп китте.

— Кит, кит, язмаганны!— Ул ашыгып Иркәтайны бу куркыныч уйларыннан ничек тә арындырырга тырышты. — Ташла андый яман уйны. Ә бит мин сиңа кызыгам. Синдә әнә нинди көчле, моңлы тавыш! Бөтен халык хәйран кала. Андый тавыш булса... Әнә, кичә алты баканда Айкөмеш тә үзеңне кочаклап, күтәреп алды бит, ә?!

— И, дөрес!— Моңа хәтле иелеп, сыкрап килгән кайгы тулы баш күтәрелде, хәсрәтле күзләр сөенеп еракка карадылар. Менә кайда ул нурлы йөз! Әле генә күгәреп кысылган иреннәр алсуланып тирбәлделәр.— Айкөмеш мине кочты бит, ә?!

Госман тагын бер кат гаҗәпләнде, чыннан да, шушымы әле генә

[1] Әкә-чичәм — ата-анам.

үксеп-елап, асылынып үләргә жыенган Иркәтай?! Ни булды? Нинди илаһи көч аны терелтте һәм яктыртты?

— Беләсеңме, Успан дус, инде унсигез яшькә житкәндә генә мине беренче тапкыр кыз кочаклады.

— Нинди кыз әле, хур кызыдай!

— И-я, черкен, айның ундүртенче кичәседәй тулы, сылу гуй. Айкөмешнең куллары тигән жирләрем әле дә янып тора! Кай вакытта шул жирләремне тотып-тотып карыйм, жакын жулдас булсаң, әйтсе, Успан, Айкөмеш мине чынлап та кочакладымы? Әллә бер тамаша төш кенә булдымы бу? Ә?

Сүзләр ни турында гына бармасын, Иркәтай кичәге алты баканга әйләнеп кайта, һаман шуны тыкырдата: «Төш идеме бу, әллә өнме?!»

Биек-биек карагайлар үскән урманны ярып, Алачапан Укжитмәскә элдерә. Куйлар да төш күрә ахрысы, «бә-ә-ә» дип тавыш биреп алалар...

Тагын дала, тагын урман. Укжитмәскә житәрәк, аларны бер төркем атлы казаклар куып узды. Кызыл лампаслар, ак эполетлар күзне камаштырып янып торалар. Госман, аларга якынлашканда, бик нык шүрләгән иде, казаклар ике яшь юлаучыга күз дә салмадылар, көлешә-көлешә узып та киттеләр һәм кыяның бирге ягындагы зур, ак киез өй янында туктадылар. Алачапан да йөрешен тизләтте, ак киез өй янында ялгызы каранып басып калган берәү аларга, туктарга кушып, кул болгады. Зур, киң өй — Шаһимәрдән хажиныкы булып чыкты, кул болгаучы — аның аткуары көяз егет иде. Юлда куып узган көмеш погонлы казаклар хажиның кунаклары булып чыктылар.

— Эт, чучкалар, көн түбәгә күтәрелде, кунаклар өй тулып утырыр, ә сез куйны яңа алып килдегез! Хажига әйтеп жаныгызны алдыраем, эт, чучкалар! — дип, Хажиның аткуары — бүгенге аш пешерүче егет — Госман белән Иркәтайны куругә үк әлеп алып, селкеп салган иде, куйларны тиз-тиз суеп, тунап, казанга салгач, тынычланды. Иркәтайның кулына күз иярмәде, шулкадәр житез, жиренә житкереп эшләде. Әнә шул аткуарның кәефен күтәрде бугай.

— Жегетләр, казан астына коры-сары алып килегез. Хажилар кузгалганчы, куырдык пешереп, ашап алыйк,— диде һәм сүзендә торды. Утын килүгә үк ике куйның үпкә-бавырын, йөрәген вак кына итеп турап, кечерәк казанда майда куырды. Куырдык гажәп тәмле булды, егетләр яратып, мактап ашау гына түгел, казан төбен ялап та куйдылар.

— Инде жегетләр, әйдәңез, кымыз пешегез [1]!— дип, кучер Госман белән Иркәтайга тагын эш тапты, урман эченә барып, икесе ике жиргә казып күмелгән, муеннары гына күренеп торган саба янына куйды.

— Ал, туктамый бер-ике сәгать тугылагыз!

Егетләр, ике пешкәкне алып, бер югары күтәреп, бер төшереп бутыйбутый, кымызны шапыра башладылар, тирә-якка хуш ис таралды.

Якында гына хажиның киез өе. Аннан гармун, скрипка уйнаган тавышлар ишетелә башлады. Әүвәле хатын-кызлар моңлы итеп татарча жырладылар, аннан казахча. Бераздан калын гөрелдәп торган тавыш белән казак-урыслар үзләренең поход жырларын күтәреп жибәрделәр. Киез өй күтәрелеп китә язды.

— Чиркәүдәге сыман улайды гуй,— диде Иркәтай. — Хажи каян рөхсәт биргән?

Кымыз пешеп-өлгергәч, теге егет:

— Ал, жулдашлар, сезгә юл аягына кымыз!— дип ике зур савытны тутырып кымыз сузды. Кымыз өстендә өрмәкләнеп сап-сары май йөзеп йөри. — Кымыз түгел, бал-каймак!

---

[1] Болгатыгыз.

Кояш баер алдыннан гына атар ягына юлга кузгалдылар. Юлга чыкканда, Госман артына борылып карады. Агачлар ышыгында ике казак җиңел йомышларын үтәп торалар иде. Кинәт Госманның зиһене яктырып китте: ул казакларны таныды. Әйе, тегендә Кара авыл юлында, тиктомалдан гына утынчы картның җанын кыеп узган явызлар иде алар. Һичшиксез, шулар! Көлешә-көлешә, көнгә карап йомыш үтиләр!..

Госманның мие авыр уйлар белән тыгызланды. Ничек алай?! Мөселман җанын кыеп киткән кяферләр ничек итеп мөселманның изгесе саналган Шаһимәрдән хаҗи түрендә җырлап-көлеп утыралар? Ни берләштерә аларны, нәрсә туганлаштыра?! Нигәдер аның уйлары тагын Күкчәтауга әйләнеп кайтты. Ул иптәше Воликның бик күп китапларын күз алдыннан уздырды. Әйе, барын да белер өчен укырга кирәк шул аңа. Волик Куйбышев кебек булырга...

## 11

1752 елда генерал Биндерман Ишим елгасының уңъяк ярында, изге Петр белән Павел рухына багышлап, крепость торгыза. Аны Петропавловск дип атыйлар, татарча — Кызылъяр. Шул ук елны бу генерал Җаектан алып Иртыш елгасына хәтле төче сулы күлләр тезмәсендә хәрби ныгытмалар, курганнар, маяк, редутлар, форпостлар салдыра. Бу хәрби ныгытмалар соңыннан Горькая линия дип атала.

Казах даласының бу өлешендә үз өстенлеген, хакимлеген саклау өчен махсус «Особое линейное Сибирское казачье войско» оештыра. Патша казакларга (җирле халык аларны казак-урыс дип атый) бу яктагы иң яхшы җирләрне — урман, күлләрне бирә, жалованье түли һәм аларны кирәкле фураж, азык-төлек белән тәэмин итеп тора. Шулай итеп, Горькая линия казачествосы даланың төп хуҗасы — казахларны елдан-ел кысрыклый, уңдырышлы җирләрдән чүлләргә куа. Шушы сәясәтнең аңлы дәвамы буларак, 1824 нче елда Күкчәтау форпосты төзелә. Аннары Күкчәтау даласының иң гүзәл почмакларында, урман-суларга бай җирләрендә Чалкар, Имәнтау, Сандыктау, Арык-Балык, Югары, Түбән Бурлук һәм башка станицалар барлыкка килә.

Себер казаклары войскосына руслардан башка җирле халык — казахлар теленә бик якын булган телдә сөйләшүче татарлар да алына, тел якын, дин бер, һәм рус колонизаторларының үз исәбе була, алар татарларны рус казаклары белән бер станицаларда урнаштыралар. Алар бергә хәрби хезмәттә һәм сугышларда булып, бөтен авырлыкны, хәвеф-хәтәрне уртак татыйлар. «Түз, казак, атаман булырсың!» дигән мәкаль татар казаклары арасында да бик киң тарала. Шул сәбәптән рус һәм татар казаклары арасында бернинди дошманлык булмый, алар үзара дус, тату яшиләр, кайбер станицаларда татарларны атаман итеп тә сайлыйлар.

Имәнтау станицасындагы татар казаклары да шушы елларда барлыкка килә...

Казах даласының байлыгы күзгә күренгән дала-мал, җанвар, кошкорт, балык һәм башкалар белән генә чикләнми әле! Аның иң зур хәзинәсе кеше күзеннән читтә, җир астына яшерелгән була.

Менә чүл-дала уртасында Балхаш күле җәйрәп ята. Бу — үзе бер могҗиза һәм хәзергә кадәр ачылып бетмәгән сер! Чал дулкыннар белән чайкалып яткан дәрья уртасыннан ике агым уза — бер агымы — төче су, икенчесе тозлы. Гаҗәбе шунда ки, бу агымнар бер-берсенә кушылмыйлар, составларын үзгәртмиләр... Дөрес, Балхаш тирәләре Сары арка кебек куе яшел үлән, урманнар белән күзне иркәләми. Җирләренең күп өлеше ак тоз катламнары, яки кан кызыл дөя үләне белән капланган. Ялангач һәм арыктыр Балхаш буйлары! Алай булгач, нигә бу дәрья

буенда ыгы-зыгы тукталмый? Нигә монда шушы кадәр атлар, дөяләр, кешеләр тупланган? Кояш астында янып-көеп беткән җирдән кешеләр ни эзли? Эзләгәч, табалар да... Бакыр табалар...

Менә шушы ыгы-зыгыда җирле халык вәкилләре — дала казахларыннан берәү дә юк, аның каравы монда озын, эре сөякле, сары чәчле, зәңгәр күзле инглизләр, немецлар, шведлар тулып ята.

Әнә чакырылмаган кунакларның берсе — француз президентының улы Карно. Аның кулында Успенск җиз-бакыр рудниғы, Спасс-Җизказган бакыр эретү заводы һәм Караганда шахталары.

Икенчесе, Австрия князе Турен Таксис. Аның кулында Алтайдагы кургаш, алюмин һәм алтын прискалары...

Болары ике туз — Америка миллиардерлары Гувер һәм Морган әфәнделәр. Килеп өлгергәннәр! Үзләре әллә кайда, океан артында, ә капшагыч куллары монда үрелеп җиткән, сейфларында «Спасс ширкәте», «Рус-Азия корпорациясе»нең кыйммәтле акцияләре...

Инглиз-капиталисты лорд Уркварт, немец бароннары, Романов династиясенә ялганган бөек князьлар, действительный статский советник Федоров һәм башкалар «Русь акционер ширкәте» төзеп, бер-берсен уздырып ятьмәләр корып, дала асты байлыгына үреләләр.

Монда Бурабайның карагайлы таулары артындагы җәйләүләрдә җиргә күмелер-күмелмәс кенә алтын тамырлары, алмаз трубкалары кабарып ята. Алар барысы да диярлек чит ил гыйфритләре кулында, дала байлыгы аларның төпсез кесәләренә — булат-корыч сейфларга елга булып ага...

Ә Россиянең үзендә ике-өч ел саен кот очарлык корылык кабатлана. Аяусыз ачлык халыкның бугазыннан буа. Урта Россия һәм Идел буе крестьяннары, авыллары-авыллары белән ачлыктан кырыла... Өстәвенә, алар җилкәсендә алпавытлар, ачкүз хуҗалар утыра. Халык, ни кылырга белмәгәч, капчык асып хәер сорашырга чыга, урыннан урынга күчеп карый, анда сугыла, монда бәрелә, «Агыйделнең аръягында бер инәгә бер сыер» икәнен ишетеп, ерак сәфәрләргә агыла, казах далаларына килеп чыга. Я сукбай, я юлбасар булып китә, үткән-барганны курәләтә таларга керешә.

Ниһаять, Александр III галиҗәнаплары 1889 елда Көкчәтау, Акмула далаларына ирекле рәвештә крестьяннарны күчерергә рөхсәт бирә һәм указын игълан итә. Бөялеп торган су кинәт кузгалып-ташып киткән кебек, ярлы-ябагай — рус крестьяннары, Идел буе халыклары — татарлар, чувашлар, мукшылар, чирмешләр, арлар — казах даласына агылалар! Кайсылары ат-арба белән, кайберләре — үгез җигеп, кайберәүләре кул арбасына ябык-ябык балаларын төяп җәяү чыгып китәләр.

Урта Россиядән казах далаларына кадәр юл җиңел түгел, меңнәрчә чакрымнарга сузылган юл тау-урманнар, күл-сазлыклар, иңли-иңли аккан елгалар аша үтә. Халык бата-чума, егыла-тора бара, үлгәннәрне шунда юл читләренә ашыгып-кабаланып күмәләр дә юлны дәвам итәләр. Чөнки алда — бәхет җәйләве! Барып җитеп таягыңны җиргә кадасаң чәчәкле агач булып үсә! Елгаларында балыклар үзләре табага сикерәләр! Бер бөртек орлык ташласаң, подаукасы белән уңыш алырыңны көт тә тор! Алда — өмет! Тереклек!

Горькая линияне әллә кайда калдырып Көкчәтау, Акмула җәйләүләренә элгәрәк килеп чыккан урыс-казаклар җирләрнең асылын үз кулларына эләктереп бетергәннәр инде. Җирбиләүче казах байлары, җирле байлар бу килгән халыкка «килмешәк» дип кенә карап, аларны мылтыккылыч, камчы һәм нәфрәт белән каршылыйлар.

Татарлар аерата күп килә. 1890 нчы елда бары тик Акмула тирәсендә бер исемлеккә дә язылмаган, кеше буларак беркетелмәгән унҗиде меңнән артык Тамбов, Пенза мужиклары (күбрәге мишәрләр) туплана. Казак-урыслар аларны станицаларга кертмиләр, казах-мөселманнар

аларны җәйләүләрдән куалар. Рядовой казаклар һәм гидайлар гына бу каңгыраган, ач-ялангач халыкка аз-маз якты йөз күрсәтә, ачтан үлүдән саклап кала. Бер урында гына унжиде мең татар! Унжиде мең язмыш!.. Яши-яши алар арасында да сыйнфый аермалык башлана, үз байлары калкып чыга, тармаклана, алар, әлбәттә, иң беренче нәүбәттә урыс-казак байлары белән аралашалар. Байлык милләтләрне, динне аерып тормый, байлык комсызларны, явызларны, әрсезләрне берләштерә. Тик боларны белми иде Гомәр азанчының улы Госман. Белә дә алмый иде...

## 12

Акмуладан ерагайган саен, дала, үзенең яшел хәтфә төсен үзгәртеп, ала-кола була башлады. Урманнар да әллә кайда артта калдылар. Таулар күгелҗемләнеп ерак офыкка күчтеләр.

— Менә кайда икән ул, балалар, өстенә ала чапан җапкан дала!— диде Нәсия чал, бер далага, бер Госман атланган Алачапанга карап, башын чайкап. — Суы арыкның җире арык дигәннәр гуй.

Чыннан да арык, ябык икән бу яклар! Көньякта, күз күреме кадәрераклыкта — комлык, кызгылт-соры барханнар. Төньякта киртләчләнеп киткән канәфер үрләр, ялангач таш өемнәре, җемелдәп яткан ап-ак тоз түбәләр (ул якка карап та булмый — күз чагыла!) Сулда, хәзер атар борылган якта — әле анда, әле монда учаклар көйрәп яткан кебек кызыллык. Шомлы кызыллык. Атар, ишелеп, шул учаклар өстенә бара. Әгәр инде, куйлар барып кергәч кенә, бу учаклар гөлт итеп кабынып китсә... Бу хәвефле уйлардан Госманның тәне чымырдады. Җил тузан катыш тоз исе, сасы черемә исе китерә. Борын тыгыла, сулыш алып булмый. Косасы килә.

Куйлар кызыл учаклар өстенә барып чыктылар да борыннарын чөеп, төчкереп ашыгып уза башладылар.

— Балам, мынаны карачы. — Нәсия чал Госманга сузып учын ачты.

— Кит, ата, хәшәрәт бит! — Госман, җирәнеп, йөзен чытты. — Суалчан? Каян таптың? Ташла, косасыны китерә.

— И бала!— Чал тавык башын селкеп кет-кет көлде. — Яхшылап кара, балам, бу корт имәс, төянең сөйгән җиме — кызыл чүп.

Госман әле һаман ышанып җитә алмый, чирканып кырын күз белән генә чалның учына карады, аның учында чыннан да буын-буын бер-берсен кысрыклаган кызгылт үсентеләр икән! Аяк астында да шундый кызыл чүп! Ат тояклары астында алар нәкъ суалчан төсле кыймылдап сытылалар.

Мал аяк астында ни бар, шуны чүпли, хуҗаларының-малчыларның гына эше көннән-көн авырайды. Дала буш, ялангач, арык. Бу якта авыллар түгел, ялгыз куышлар да күренми. Шуның өчен монда «мосафир, менәки сезнең кунак ашыгыз», дип кымыз, таба нан, корт, эремчек күтәреп чыккан ак кимәчәкле кимперләр дә күренми. «Җире арыкның— иле арык» шулдыр инде.

Күкчәтаудан алып чыккан юл азыгы — он, ярма, сыкма, ике карынга тутырган куй мае такырайганнан-такырая. Лачынбай, юлның барасы өлешен чамалап, саранланганнан-саранланды. Иртә-кичкә ашка азык биргәндә «җитәр, булыр!» дип, Нәсия чалның кулын кагып кына тора. Башта тарыны ике савыт бирә иде, түбәләмә итеп сала, хәзер бер савытка калдырды, анысы да тулар-тулмас. Бер табак урынына ярты табак он. Май исә җомга көннәрдә генә елтырый. Каракларның биш куйны урлап китүе бөтен эшне чуалтты.

— Ит ашый белләләр, малны яхшылап карамыйлар, инде менә тары өйрәсе эчсеннәр!— дип, хаҗи куй суюны бөтенләй туктатты.

Лачынбай кичләрен, атар кунарга туктагач, ашык-пошык кына «күҗәгә» дип, аз-маз он, тары бирә дә үзе атына менеп, я алдагы атарга, я хаҗи учагына елышырга юл тота. Калганнарга кысыр өйрә-күҗә!

Малчыларның башлары түбән иелде, күҗәне чүмереп бетерүгә ятарга ашыктылар, элекке кебек, учак каршында аяк бөкләп утырып «аңгәмә чиртүләр» онытылды. Хәтта, бертуктаусыз үлән әйтеп, малчыларның күңелен күтәреп килгән Иркәтай да соңгы көннәрдә тавышсыз-өнсез калды. Адәм баласы бер тире эчендә тула да, сула да, дигән борынгылар. Күкчәтау ягында бер аз тулганнар иде, хәзер коры-сары ашап, дала үләне төсле көннән-көн сулдылар.

Соңгы вакытта хаҗи атарга якынрак җирдә куна башлады, мөгаен шүрлидер... Бу йолкыш далада бүреләр, шакаллар гына түгел, ике аяклы юлбасарлар да җитәрлек диләр. Атарга ул хәзер бик еш килә башлады, көндезен «малның түле төшмиме?» дип, куйларны капшап-капшап карый, ә төннәрен малчыларны тикшерә — йокламыйлармы?! Ходайга шөкер, арада Нәсия чал бар, аның кайчан йоклаганын да белмәссең, көнозын ат өстендә, мөгаен шунда черем итеп аладыр, байгыш. Бай күренеркүренмәстә егетләрне тиз-тиз уята, рәхмәт төшкере. Хаҗи арлы-бирле чаба башлагач, аткуары аш-су әзерләргә өлгерми башладымы, ул үз янына Госманнарның юлдашы Нигъмәтне чакыртып алды. Ул хаҗи янына күчкәч малчыларның хәле бераз рәтләнде, хаҗи намаз укыганда яки ял итеп ятканда Нигъмәт һич искәрмәстән иске юлдашлары янына килеп чыга. Кулы бер чакта да буш булмый, хаҗи дәстәрханыннан калган сынык-санык: тукач, бавырсак, көлчә, нан һәм кара-кисәк ит, коры кабырга. Болар — ачлы-туклы яшәгән малчыларга оҗмах нигъмәтләре!

Беркөнне икенде белән ахшам арасында (хаҗи юлда бу ике фарыз намазын берьюлы укый һәм намазлык өстендә озак утыра иде!) Нигъмәт бер итәк бавырсак китерде дә:

— Иртәгә, җулдашлар, хаҗиның табагы белән сыйлыйм!— дип вәгъдә биреп китте. Малчылар бик ышанып та бетмәделәр...

Икенче көн гадәттән тыш эссе-бөркү булды. Кояш аяусыз кыздырды. Аяк астындагы ком, түбәләре ялангач кыялар мунча ташы төсле кызып, болай да коры-эссе һаваны тагын да көйдерде. Җитмәсә җил кузгалып кызган ком бөртекләрен һавада күчереп йөртә башлады. Малчыларның иреннәре генә түгел, битләре дә ярылды, күзләргә, тамакларга ком утырды. Авызда төкерек кипте. Үч иткән кебек куйлар су эзләп әле бер якка, әле икенче якка ишелеп ак-караны күрми чаптылар. Лачынбай ходайның һәр бирмеш көнендә иртә-таңнан аттан төшмәде, малларга ут, төче су эзләде. Үткән елларда Куяндыга мал әйдәгәндә дә юллар авыр иде, әмма бу такырларны аралап симез булмаса да иренгә тиярлек үлән һәм төче сулы болаклар, коелар табыла иде. Ә бу ел дала пыяла төсле чатнап-ярылып ята, такыр, коры...

— Уй-бай, әллә адаштыкмы?— дип Лачынбай бик аптырап, былтыргы билгеләргә карап юлның дөреслеген чамалап, тагын да ныграк аптырауга төшә иде.

Арыган-талган, кояшта кара көеп янган Лачынбай, бары тик кичкә борылганда гына бер сайда яшел утка һәм төче суга юлыкты.

Үлән күтәрелә алмый катып калган, кәрлә әремнәр. Булыр-булмас кына тибеп яткан ташландык болак, шулай да малчыларның түбәсе күккә тигән кебек булды. Әүвәле үзләре ач корсаклары кап булганчы су эчтеләр, аннан атларны сугардылар, соңыннан гына куйларын аз-азлап, бүлеп алып барып, болакның күзенә әйди башладылар.

Хаҗи да артык озакламый болакның аргы башына килеп туктады, фаэтон янында томак төсле очланып торган ак киез өй күтәрелде, шунда ук куыш янында учак дөрләде.

— Уй-бай,— диде Иркәтай эчен уып. — Хаҗи безгә кунак ашы биръем дип казы-карта салдырып жатыр.

— Кит, юкны лыгырдама!— диде Нәсия чал, ачу белән ияген тартып-йолкып. — Казандагы кара куҗәне бута. Көеп китмәсен.

Өй еракта ук булса да ул яктан искән жил куырдык исе китерде, татлы ис килеп борыннарны кытыклады, ашказаннарына ачы су йөгертте.

Дала өстендә тынчу, бөркү иде, бер кош авазы да, киек-җанвар тавышы да ишетелмәде. Бары тик мыжлап торган черки! Алар мал өстенә дә ябырылдылар, малчыларның авыз-борыннарына кереп тулдылар. Учак кыштырдады, Иркәтай олы агач кашык — ужау белән казандагы куҗәне бутады да, башкалар кебек бөгәрләнеп ятты... Йокымсырадылар. Озак вакыт үткәндерме, белгесез, менә бервакыт якында гына Нигъмәтнең тавышы ишетелде.

— Әй, егетләр, торыгыз. Аш алып килдем. — Госман күтәрелеп карады: сүнеп барган учак янында бер ашлау ит күтәреп Нигъмәт басып тора. Чыннан да улмы, әллә... — Әй, үлеп калдыгызмы әллә? Кулым талды, төшеп китә!

Госман сикереп торып ашлауга сузылды һәм чак кына төшереп җибәрмәде — авыр! Башка малчылар да уяндылар. Госман ашлауны яктырак, учак янына китереп куйды. Ашлауда гәрәбә төсле сап-сары былкылдап торган май кабырга-казы. Аның өстендә божра-божра чожыклар![1] Симез-симез умырткалар, авыздан су китерерлек карталар, бөерләр. Ә нәкъ уртада, бу ит кибәненең өстендә, кабарып торган шикәрдәй, бер бөтен ап-ак койрык мае. Ашлаудан бу күтәрелә. Тәмле хуш ис, казы-карта, сөр исе борыннарны яра, кытыклый.

— Нәрсә катып торасыз, миңа ашлау кирәк. Тизрәк бушатыгыз!— дип Нигъмәт ачуланып, Иркәтайны этеп җибәрде. Егет үлле-мәлле шаккатып басып торган җиреннән чак кына авып китмәде, исенә килеп, йөк арбасыннан ике олы табак алып килеп җиткерде. Нигъмәт кабаланып кына итне ике табакка да бушатты да:

— Киттем! Хаҗига тагын казан асарга кирәк!— дип, ашлауны ике кулына күтәреп киез өй янына йөгерде.

Малчылар шунда гына хәлнең төш түгел икәнenә ышандылар, ике табак түбәләмә тулып учак янында калды. Һәммәсе кабаландылар, әзерләнделәр. Госман чабып кына коры-сары җыеп килде, учакның утын күтәрде. Төн артка чигенде. Тирә-як яктырып китте. Нәсия чал, Иркәтай, Госман ышанып-ышанмас сөенеп тылсымлы табаклар тирәсенә урнаштылар.

— Я, бисмилла... — Нәсия чал билбавына асылынган күн калтадан сөяк саплы пәкесен алды, ачты, катып-ялтырап беткән тире чалбарына ышкып янады, аннан табактагы, егетләрнең күзен яндырган ит-майны өлешләп-өлешләп алдына тезеп торарга кереште. Бер калҗа табакка, бер калҗа авызга. (Инде җитмештән ашса да Нәсия чал итнең ләззәтен татырлык чәйни һәм сөяк кимерә иде!)

Табактагы итне турау — дәрәҗә. Аны бары тик дәстәрхандагы иң өлкән һәм хөрмәтле кеше генә башкара. Турау эше дә нинди кисәк кулга эләкте, шуны ботарлау түгел, табындашларның дәрәҗәсенә, яшенә карап үз өлешен билгеләргә, шуны табарга һәм нәкъ шуны гына өлеш итеп чыгарырга кирәк. Бу дәстәрханда дәрәҗәсе белән иң өлкән — Лачынбай. Ул үзе монда булмаса да аның шобагасы чыгарга тиеш. Нәсия чал шул кагыйдә буенча иң элек: бер бөтен казы, сап-сары май кабырга, ярты карта, бер умыртка, койрыктан яхшы гына бер кисәкне алып аерым табакка алып куйды, бусы өлкән чабанга. Аннан чал үз шобагасын чыгарды. Шуннан соң гына егетләр шобагасы һәркем үз алдына әзерләп

---

[1] Чожык — бер калҗа жылкы мае, бер калҗа жылкы ите аралаштырып, куй эчәгесенә тутырган, төтендә какланган казах колбасасы.

куйган табакларга төшә башлады. Һәрхәлдә, бу шобага да, өлкәннәрнекеннән һич тә ким түгел, казы-карта, ит-майның һәр төреннән калҗа-калҗа булып табакларга өелде. Нәсия чал, дастархан янында дүрт күз белән, авызларыннан суларын агызып текәлгән егетләргә башын селкеп ашарга вакыт җиткәнен белдерде.

Алты -кул берьюлы табакларга сузылды, өч авыз туктаусыз иткә тулды, чәйниләр, чәйнәлмәгәнен голт-голт йоталар. Госман күнекмәгән, бер-ике мәртәбә тыгылып чәчәде.

— Әй, монавың, ни... Мә, мә! — Чал аның җилкәсеннән какты.— Чәйнәп җи, бала!

Башта тын да алмый комсызлык белән тотынсалар да бер-ике майлы калҗадан соң, акрынладылар, ә бераздан ашыгуны бөтенләй онытып, Нәсия чал әйткәнчә, чәйни-чәйни итнең ләззәтен табып, адәм рәтле ашарга керештеләр. Гаҗәп, гомергә туюны белмәс кебек тоелган ач корсак тулды, малчылар кикерделәр, ә табакларда әле күпме ит калды! Ә ит ялгыз хаҗига гына багышланып пешкән бит!.. Бер авызга!

— Ата,— диде Иркәтай.— Мындай ашка фатиха бирмәсәгез булмас.

Нәсия чал эндәшмәде, бармакларыннан агып торган майны ялады, ялап бетерә алмаганын «әрәм булмасын!» дип болай да ялтырап торган чалбар тезенә ышкыды. Госманны Иркәтайның сүзләре гаҗәпләндерде: чал бисмилладан башка бер аять тә белми, аннан нинди фатиха көтәргә кирәк соң? Әмма Нәсия чал Иркәтайның сүзләренә наразыйлык белдермәде, киресенчә, тагын бер кат бармакларын ялады, пәкесен ябып калтасына урнаштырды, тамагын кырды. Бу — әзерләнү билгесе иде. Госман белән Иркәтай бик кызыксынып тезләнеп утырдылар. Нәсия чал «Я, тәңрем!» дип бер аваз салды да шыңшый башлады, бераздан тавыш ычкынды. Ниһаять, сүзләр дә барлыкка килде:

Җарлыкасын ходаем, тарттырмасын ваем.
Афәтләрдән аман кылып, бәлаләрдән сакласын ходаем.
Тәүфыйкъ белән бала бирсен, изгелек дана[1] бирсен!
Берлек, жумартлык, озын гомер җәнә бирсен.
Локман хакимнең яшен бирсен,
Адәм галиәссәләмнең башын бирсен,
Йосыф галиәссәләмнең күркен бирсен,
Хәзерәти Гали арысланның көчен бирсен...

Тавышы нечкәреп, өзелеп китте — тыны җитмәде. Чал туктап хәл алды, еш-еш сулады, кат-кат тамагын кырды. Госман белән Иркәтайга күз ташлады: инсафлы утыралармы? Дога тагын ялганды.

Я ходаем, яздай бир,
Яздай бирсәң, җазмай бир!
Я ходаем, кыштай бир,
Кыштай бирсәң, кысмай бир!
Я ходаем, көздәй бир,
Көздәй бирсәң, өзмәй бир! —
Уңнан бир, сулдай бир,
Ни булса да мулдан бир!
Дәстарханнарымыз мул булсын,
Барган жулымыз уң булсын,
Я, тәңрем, үзең кабул кыл.
Ал, бисмилла, рахман, әкбәр.
Амин!

«Хаҗи табагыннан» соң Нигъмәт берничә көн атар тирәсендә күренмәде. Әллә инде итне урлап китергән булып хаҗи сизеп калдымы? Алай дисәң, андый бурлыкның тавышы ашаучыларга да үч булып килеп җитәр иде! Алай да ул тылсымлы табак каян килеп төште?

Ниһаять, дүртенче тәүлек офыкка китеп барганда алар янына Нигъмәт тагын килде. Үзе генәме сиңа, бер итәк бавырсак кыздырган!

[1] Дана — бердәнбер, асыл бала.

Малчылар өнсез калдылар. Сорашу китте, белешү, «нигә күренмәдең дә кая югалдың?» «беркөнге итне каян алган идең?»

— Ә мин хажины алдадым,— диде Нигъмәт башын артка чөеп.

— Кемне?

— Кемне булсын, хажины!

— Ә?

— Хажины дим...

— Ну шартлатасың! — диде Госман ышанмыйча.— Мин хажи абзыйны беләм, алдарсың аны!

— Выты, алдадым шул,— диде Нигъмәт мишәрчәләп, юри Госманны үчекләп.— Таз булсын да алдый алмасын!

Учак янындагылар бавырсакны бөгә-бөгә пырх итеп көлеп җибәрделәр.

— Ашыкмыйча гына сөйләп бирим әле,— дип башлады Нигъмәт.— Хажи абзый икенде-ахшамны бергә уптым илаһи гына тезеп салды да, ятты. Хәзер ул ясигка хәтле кузгалмый! Мин бит, егетләр, әллә кайчаннан бирле сезне сыйларга уйлап йөри идем. Уйлыйм, уйлыйм, хәйләсен һич таба алмыйм! Вәт, Госман әйтә,урлагансыңдыр, ди... Урлап кара! Хажи абзаң күзеңнән сизә!

— Мин бит болай гына!

— Әй уйлыйм, әй уйлыйм, һич табып булмый. Бер төнне уйлап ята торгач таптым бит!

— Ни хәйлә таптың, балам?

— Бүлдермәгез генә, хәзер чүпләп тезәм, тик көлмәгез! Ул көнне юри кичке казанны мул астым, җомга киче бит! Хажи җомга көнне «тауаф казаны», дип итне җәлләми салдыра. Ә алдар күсә таз шуны гына көтте дә, итне әйбәтләп пешердем, ашлауга төшердем... Хажи куышта дәстархан җәеп, кымыз чөмереп, кулларын юып, пычагын беләүдә кайрап утыра.

— Ай, шуннан?

— Шуннан, ашлауны хажи алдына алып барыр алдыннан, бер чожыкның урта җиреннән бераз кисеп алдым да ашадым. Киселгән чожыкны табакның өстенә, нәкъ хажи күрә торган җиргә куйдым. Уй-бай, чожыкны байдан алда кистеңме?.. Шуннан ни булды дисезме? Ашлауны хажи абзый алдына дәстарханга китереп куйдым да: «Хуш килдегез, хажи абзый!» дидем. Үземнең ике күзем аңарда. Тегe, уртасы киселгән чожык телемен күрсә ярар иде дип, дер-дер киләм.

— Я, я, шуннан? Бу бер гаҗәп икән. Ал, әйтә бир, балам.

— Хажи абзый көмеш саплы пәкесен алды, ашлаудагы өлешләрне тотып-тотып карады, симезме, төгәлме... Ашчы бала, ягъни мин, урлап ашамаганмы? Барлый. Өстәге олы бер казыны алып алдындагы тәлинкәгә салды, чожыкны күрми генә бит! Их, мин әйтәм, хәйләм барып чыкмады! Иптәшләр тагын ач йоклыйлар, димен! Булмады дип, нәүмизләнеп борыла гына башлаган идем, хажи абзаң акырып җибәрмәсенме!? «Әй, бала, монысы ни?» Әллә куркудан, әллә сөенүдән акырып җылап җибәрдем. «Әй, бала! Монау чожык нигә киселгән?» Хажи ышансын өчен тагын да катырак җылый башладым. Үзем тотлыга-тотлыга җавап бирәм: «Аны дим, Хажи абзый, дим, капчыкны тишеп тычкан явыз кимергән», дим. Үзем һаман үксим! «Мин дим, тычкан явыз ашаган җирен, дим, кисеп ташлаган идем», дим.

— Ах, бәдбәхет! — дип хажи ашлауны этеп тә җибәрде.— Алып кит, күздән югалт, тычканнан калганны минем алга куясың! — дип акырды. Тиз генә ашлауга үрелдем, үзем чыдый алмыйм, эчтән көләм! Хажи сизмәсен дип тә куркам. Ә ул аның саен тузына. Алып кит, ди. Шулпасын этләргә бир, ди. Казанны өч тапкыр бисмилла әйтеп ю, хәсис, ди. Ишеттеңме, ди. «Ишеттем, хажи абзый, ишеттем!» — дидем дә ашлауны алып сезгә чаптым. Ике тапкыр абындым, шул кадәр нык йөгергәнмен!

## 13

Бүген юлчыларга ике сөенеч бергә килде.

Тик, аңа хәтле...

Кояш көнозын даланы шәфкатьсез көйдереп, куырып, ниһаять, малны, кешеләрне ахыр чиккәчә сусатып, хәлдән тайдырып, ерак офыкка авыша башлады. Атлар да, этләр дә, куйлар да, куйчылар да сусызлыктан әлсерәп, ни эшләргә, кайда барып егылырга белми сөйрәлделәр. Кояш баеса — юл югала! Өмет өзеләчәк, хәл китәчәк! Аяк асты ком — кыздырылган таба кебек, аякларны, тоякларны пешерә... Тел авызга сыймый, күз алларында караңгылана, саташтыра.

Инде бар өметләр югалып чираттагы үргә күтәрелгәндә малчылар, ниһаять, куанышып, туктап калдылар. Лачынбай:

— Уй-бай, бу сайны[1] ни кылып мин белмәдем! — дип сөенечле гаҗәпләнеп калды.

— Тәңремә мең шөкер! — Нәсия чал атының тезгенен тартып туктатты, калтыранган кулларын өскә күтәрде.— Мең рәхмәт! Рәхим-шәфкатеңнән өзмисең, мәүләм!

Башка малчылар да кулларын күтәреп чалның догасына кушылдылар.

Гаҗәпләнмәслек тә, куанмаслык та түгел! Могҗиза! Үр итәгендә җәйрәп яткан түгәрәк күл! Күл тирәсендә ямь-яшел куе үләнлек. Бөтен атар ишелеп-мәэлдәшеп шушы ком чүле эчендәге көтелмәгән бәхеткә ташланды. Этләр, куйлар, атлар — барысы да, абына-сөртенә, әбелхаятькә ташландылар. Ниһаять!

Акколак белән Сакколак иң алдан күлгә барып җитеп, билдән кереп киттеләр, озын телләре белән шапылдатып суның каймагын ялый башладылар. Куйлар ишелеп төшеп корсаклары кабарганчы башларын күтәрмәделәр. Атлар исә, бик сусасалар да, инсаф белән ашыкмыйча, сафьян иреннәрен кыбырдатып, тәмләп эчтеләр.

Ә Госман белән Иркәтай инде күл уртасында — башлары гына күренә. Лачынбай белән Нәсия чал, ыштан балакларын тарткалап, бит-кулларын юарга, тәһарәт алырга тотындылар.

Су күз яше кебек саф, чиста, җылы. Күл төбендәге эре ком бөртекләре төрле төстәге мәрҗән булып, чекерәеп кызыктырып яталар.

— Бәрәкалла, бисмилла! — Нәсия чал авызын чылатып, бер-ике йотым йотты.— Ширбәт! Зәм-зәм гуй.

Куйлар судан чыгуга куе үләнгә ябырылдылар. Кайчы белән кискән сыман кырт-кырт кына итәләр! Атларны да тышаулап ирекккә җибәрделәр. Этләр йөк-арба янына килеп, ризык исен иснәп, бер дә исләре китмәгән сыман, күзләрен йомдылар. Ул арада Лачынбай (бу юлы үзе!) комлыкка өчаякны корды, кара казанны асты.

— Әй, чал, йөктән бер аяк тары алып кил. Балалар, учакка вак-төяк, коры-сары җыеңдар! Күҗә эчеп алу кирәк, җылдам! — дип эш бүлде. Хаҗи күлнең икенче ягындагы кечерәк каенлыкта туктаган иде. Ул якта да учак төтенләде, казан астылар.

Иркәтай ул яктан күзен алмый иде. Аның ни уйлаганын белү кыен түгел.

— Капкан саен калҗа булмас! — диде Госман.

Тары өйрәсе сыек-арык булса да мул иде, икешәр-өчәр аяк эчтеләр. Корсак тынды, тынычланды. Шундук арыганлык та сизелде. Атарчылар утырган җирдән кузгала да алмадылар, чалкан әйләнеп төшеп гырлый да башладылар. Бары тик Иркәтай гына, гадәтенчә ятырга ашыкмады. Учак янында чәчелеп яткан савыт-сабаны, аякларны, кашыкларны казан эченә тутырды да, күлгә алып барып, ком белән ышкый-ышкый чистарта-юа башлады.

---

[1] Сай — үзән.

Күл төбендә ярты ай. Йолдызлар. Бик күп йолдызлар һәм тынлык. Тирән тынлык. Күрәсең, балыклар да йоклыйлар. Күл үзе дә йоклый. Көндезге эсседән әлсерәгән чүл-дала да тавышсыз-тынсыз. Ара-тирә атлар гына пошкырып куя. Аннары тагын тирән, ниндидер серле, хәвефле тынлык урнаша.

Иркәтай табак-савытны юып, ком өстендә җәеп саркытты да, йөк-арбага килеп, брезент белән урап-җыеп куйды. Эш беткән кебек иде. Тик бөкре егетнең җаны тынмады, нидер эшләргә, ни белән дер мавыгып әнә шул өстән басып торган хәвефле тынлыктан котылырга кирәк иде. Күл буенда җанварлар да күп йөргән. Иркәтай бер кочак тизәкне бик тиз җыеп алды, учакка ташлады, көйрәтте. Инде «тәмам!» дип канәгатьләнеп ятарга гына җыенган иде, этләр, башларын күтәрмичә генә, бер-ике тапкыр һау-һау дип өреп куйдылар.

— И, Нигъмәтулла балам киләме? — Нәсия чал учак янында бөгәрләнеп яткан килеш ыңгырашып-сөйләнеп алды, өстеннән шуып төшкән чапанын тартып ябынды.— Янында тагын бер адәм булса кирәк!

Йокы аралаш каян чамалагандыр чүл пәрие, Нигъмәт чыннан да ят бер егет ияртеп килде. Госман да, Иркәтай да торып утырдылар.

— Выты, саркыт [1],— диде Нигъмәт, Госманны үчекләп, мишәрчәләп.— Бүген бай абзыйга кәттә кунак килгән иде. Павлодарның иң главный бае Балтахан. Алар хәзер кунак ашы ашыйлар, ә без монда гөҗләп бер чәй эчеп алыйк!

Нигъмәт бер олы төен көлчә алып килгән иде.

Менә аның юлдашы да учак янынарак килде. Госман да, Иркәтай да кызыксынып, яңа кунакка карадылар. Буйга Госманнан аз гына тәбәнәгрәк булыр. Ябык. Башында яшел түбәтәй. Өстендә — тезләренә төшеп торган озын киндер күлмәк. Кара чалбар. Яланаяк. Ул учак яктысына кергәч тә нигәдер Госманга төбәлеп-төбәлеп карап торды.

— Танышыгыз, бу егет Сабир була,— диде Нигъмәт.— Балтахан байның җылкыларын ярминкәгә әйдәп килә.

— Бәракалла, хуш килдең! — диде Иркәтай чәй әзерләп яткан җиреннән.

Сабир Нигъмәт янына килеп, дала гадәтенчә, аякларын бөкләп утырды, шуның белән гореф-гадәт мәсьәләләренә бик турылыклы Иркәтайның мәхәббәтен яулап та алды.

— Чәй кайнаганчы авызыгыз кыймылдап торсын! — диде ярым шаяртып Нигъмәт, бер-ике көлчәне ерткалап учак тирәсендәге дусларына өләште.— Күңеллерәк булыр!

— Ия, ия, мең яшә, Нигъмәт дус!

Иркәтай Нигъмәтнең аркасыннан какты, аннан кунакка борылды:

— Ал, Сабир дус, инде әңгәмәнең болагын ач!

Сүз — мосафирга. Нигъмәт аны юкка гына аларның учагы янына алып килмәскә тиеш. Ниндидер сер, алар белмәгән, әмма белергә тиеш сер булырга тиеш монда! Иркәтай, дала горефе буенча, сүзне ерактан килгән кунакка биреп, аның «сөяк-санакларын» капшый башлады. Кайдан? Ата-анасы бармы? Бу якка ничек килеп чыккан?

Сабирның тарихы гаҗәеп кызык булып чыкты. Учак янында әңгәмә куерды. Госман моңарчы ишетмәгән мавыктыргыч әңгәмә...

Сабирның әтисе дә, әнисе дә юк икән. Әтисе Вяткада сал агызганда батып үлгән. Зифа белән Миңсылу исемле сеңелләре Җәләлетдин муллада бала карыйлар икән. Фәттах бай аны, кибетеннән акча урлауда гаепләп, төрмәгә яптырган.

Павлодар өяз начальнигында эшләүче тылмач Габдулла Кадырбаев Сабирны порукага алды һәм, Фәттах байның ялган доносын фаш итеп,

---

[1] Саркыт — күчтәнәч.

Сабир Шәриповны төрмәдән чыгарып җибәрделәр. Шул ук Кадырбаев ярдәме белән малай Балтахан дигән бер байга мал бага рга ялланды һәм менә хәзер инде ул Балтаханның җылкыларын Куянды ярминкәсенә әйдәп килә иде...

* * *

«Озын колак» малчыларга хәвефле хәбәр китерде. Үткән атнада гына караклар Куянды ярминкәсенә кызыл мал белән баручы бер нугай сәүдәгәрен үтереп, бөтен байлыгын талап качканнар. Шушы хәбәрдән соң Шаһимәрдән хаҗи да атардан артык аерылмый, юлда очраган ярминкәчеләр белән бергәрәк булырга тырыша. Аның бәхетенә Павлодар бае Балтахан очрады. Шаһимәрдән хаҗи белән алар уртак телне бик тиз таптылар, тәмле ашарга яратулары да тиң килде, кымызны да бергәләп чөмерделәр. Бу хәл җылкычыларга да, куйчыларга да ошап калды. Алар да таныша, аралаша башладылар, бер-берсенә чәйгә йөрделәр, күргән-белгәннәрен кызганмыйча сөйләделәр. Арада Сабир сөйләгән тарих Госман күңелендә аерата тирән урын алды. Кайсы ягы беләндер аларның язмышлары бер-берсен кабатлыйлар түгелме соң? Госман да укырга барам, дип, күпме җәбер-җәфа күреп, әллә кайлардан әйләнеп кайтты. Сабир әнә төрмә төмен дә татып өлгергән!

Алда шактый мәшәкатьле авыр юл бар әле! Бу очрашу шатлык китерде малчыларга, кордашлар очрашты, уй, сүз, моң килешә.

Ә бергә-бергә иң авыр юллар да кыскара...

## 14

Болак күлгә җиткезә,
Сукмак юлга җиткезә,
Юл морадка җиткезә...

Шулай ди казах мәкале. Борынгыларның менә шушы алтын сүзен дөресләп, көньяк офыкта кара-кучкыл таулар күренде. «Кыбырдаган кырдан үтә» дигәндәй, куй аягы белән шушы җиде йөз чакрым араны уздылар, диярлек. Көкчәтау каласыннан башланган озын юл, явым-чәчем, җилдавыл, ми кайнаткыч җәһәннәм эссесе, сусызлык, ачлык, кимсетелү, хәвеф-хәтәр ашыгыч кына сөенүләр — барысы да булды. Бер көнне куйларны саклап калгач, Госман каты йокыга киткән иде, Шаһимәрдән хаҗиның килеп җитүен сизми дә калды. Камчы тоткан кучерын да иярткән... Йоклый Госман, арыган! Каеш камчы аяусыз сызгырып тагын аның җилкәсен телгәләде. Шушы ара эчендә ничәнче тапкыр кыйналу! Дәшмәде Госман, түзде, сикереп торып атар тирәли әйләнеп чаба башлады. Бәхетенә каршы, маллар барысы да исән-сау иделәр...

— Я тәңрем! — диде Нәсия чал, куанычына чыдый алмыйча, офыктагы тауларны күргәч.— Менә, балалар, морадымыз Каркаралы таулары, пай-пай-пай...

Чал бу кара сүз белән генә сөенечне беркетеп канәгатьләнмәде, иреннәрен бөрештереп, авыз эченнән генә нindидер бер дога укыды, теләкләр теләде һәм ахырда битен сыйпап «Аллаһе әкбәр!» дип куйды. Бу таулар боегып калган Иркәтайны да уятты, ул дога тәмамлануга ук, тагын аның моң тулы көр тавышы яңгырады:

Атыңнан әйналаен Каркаралы!
Синдә болыт, миндә кайгы калмады.
Миндә бер сурлы [1] җан, гуй, Аркадагы!

---

[1] Сурлы — бичара.

— Ой дисәңче! Әйт-әйт, Иркәтай! — диде үләңне җанландырып, тагын да әйтүне үтенеп Лачынбай.

Бу сүзне ишеткәч малчылар да, Иркәтай үзе дә хәйран калды. Бу, һәрвакыт кабакларын төшереп, сөремен коеп йөргән, дуамал холыклы өлкән чабан аз сүзле, сөйләшү урынына күбрәк сүгенә-орыша белә торган ябык «сандык» та һич көтмәгәндә кинәт ачылып китте.

Бу яклар да еракта калган кадерле Сары-Арка даласы шикелле иксез-чиксез, үләне симез, суы татлы икән. Ерактагы Каркаралы, Көн таулары артыннан моңарчы мәрхәмәтсез булган кояш көлеп карады. Даланы каплап сарылып яткан төтенле томан таралды да бетте. Гүяки, чаршауны ачтылар да дала зөбәрҗәт яшел булып китте! Кыякларда, яфраклар битендә, төрле төстәге чәчәкләрнең гүзәл таҗларында санап бетергесез энҗе, гәүһәр бөртекләре! Күзләр чагыла. Нинди илаһи көч, бөек кодрәт бу җәүһәрләрне дала тутырып чәчте икән!?

Исән-аман Каркаралы тирәсенә килеп җитүләре бер сөенеч булса, Госманның тагын бер шатлыгы бар иде, ул да булса — Сабир! Сабир малчылар белән, бигрәк тә Госман һәм Иркәтай белән тиз ияләшеп, дуслашып китте. Башта йомык, кырыс күренсә дә, баштан кичергәннәрен сөйләп, күңелен ачып салганнан соң, малчыларның үзеннән йөз чөермәүләрен күреп, ул җае чыккан саен Госманнар янына килә торган булды. Йөзе дә, теле дә ак, казах әйтмешли, уе — ак, күңеле — моң икән аның. Өстәвенә, Иркәтай кебек үк җырларга ярата икән. Тавышы шыңлап тормаса да, Иркәтайныкы кебек колакка йомшак, моңлы җырлары берсен-нән-берсе матур. Госман еш кына хәйран да калгалады, кемнән отып алган ул шул кадәр җырларны? Үзе чыгарамы әллә? Татарча гына түгел, Иркәтайга кушылып, казах үләңнәрен дә әйтә! Госман моңарчы ишетмәгән бик күп җырларны белә!

Ә бер кичне Сабир Госманны тәмам хәйран калдырды. Сабир учак янында бер ялгызы гына утыра иде. Башта ул бик озак янган утка карап торды-торды да, акрын сузып, йөрәк тавышы белән җыр башлады.

Йөгереп лә йөгереп җыяр идем,
Юлның буйларында юа юк.
Эзләп тә тапмаган бәхетләрне
Сатып ала торган йола юк.

Малчылар берәм-берәм учак янына тартылдылар, Лачынбай да килде, алар Сабирның җырын бүлергә курыккан төсле, аннан бераз читтәрәк, караңгылык белән яктылык очрашкан урыннарга сырыштылар. Ә Сабир беркемгә дә игътибар итмичә һаман күңелләрне тетрәтә:

Карурманның асыл киекләрен
Ау кормыйча тотып булмыйдыр.
Сәфәрләрдә йөреп саргайсаң да
Бик тиз генә кайтып булмыйдыр.

Канаты каерылган аккош каңгылдагандай җыр зарлы чайкалды да ерак, караңгы далага китеп югалды, сүнде. Бары тик учак кына чатнап-чатнап очкыннар чәчрәтә. Малчылар тып-тын калдылар. Бераздан Нәсия чал гына авыр итеп көрсенде һәм Сабирның аркасыннан какты.

— Я, балам, моңау үләңең йөрәкте телеп китте. Яшь булсаң да безнең шикелле аягына бозау басканнарның бере икәнсең, колыным.

Сабир да өлкәннәр кебек тирән итеп көрсенде.

— Авылда ике сеңелем калды бит, ата,— диде ул сагышлы тавыш белән.— Ата-анамның үлемен, ятим калуларымны сөйләгән идем шикелле. Сеңелләр кызганыч! Олысы Зифа, кечесе Миңсылу...

— Кайда соң алар? — дип сорады Госман калкынып.

— Җәләлетдин мулла: «читкә ташламам, үзем карармын», дип алып калган иде, белмим... Йөрәгем нигәдер бик өзгәләнә. Сагынам!

— И, мулла адәм үзе әйтеп алып калгач, карендәшләрең җәтимлек күрмәс... Куй, кайгырма, балам,— дип киң күңелле Нәсия чал егетне юатты, аталарча иркәләп, аркасыннан какты. Үзе китә дә башлады.— Ал, балалар, сез җатып дим алыгыз. Мин малны карап киләем.

Иркәтай Сабирдан отып алган җырны кабатлап куйды:

Сәфәрләрдә йөреп саргайсаң да
Бик тиз генә кайтып булмыйдыр!..

Нинди җырлар белә Сабир! Каян ишеткән ул аларны, кем өйрәткән?! Госман ул төнне бик озакка кадәр йокыга китә алмады. Күз алдына «сәфәрләрдә тилмереп йөреп саргайган» татар егете килде... Аның каһәрле язмышына җырчы Сабирның үз тормышы, үз кичергәннәре ялганып китте. Фәттах байны да күз алдына китерде Госман. Шулар рәтеннән үз язмышы турында да уйлады. Эх, шушы Сабир кебек җырлый белсәң иде ул, дип кызыгып уйлады егет. Бәлки ул да эч серен башкаларга сөйли алыр иде, күңелендәниләр кайнаганын юлдашларына аңлатып бирә белер иде! Юк шул! Аның әтисен «сандугач телле азанчы» дип йөртсәләр дә Госман бары тик карга шикелле каркылдый гына ала. Җыры юк, моңы пешмәгән... Сабир бер җырлады, Лачынбай да йомшап төште, Нәсия чал да егет күңелендә ниләр барын аңлады...

Монда кунган урыннары Хаҗи әфәндегә аерата хуш килде. Куйлар ярыйсы ук хәл алдылар. Куяндыга әллә ни ерак калмады, малларны бераз игә китерергә кирәк иде. Ике-өч көндә куйлар күзгә күренеп җанландылар, май койрыклар авырайдылар, хуҗаның кәефе килде. («Табыш, иншалла зарланырлык булмас!») Өстәвенә алар туктаган күл әйләнәсенә бер-бер артлы яңа кәрваннар, фаэтоннар, базарчылар туктый башлады. Яңа танышлар артты. Алыш-биреш алдыннан танышларның, хәбәрләрнең күп булуы мөһим. Алдан ук сөйләшеп, килешенеп, бәяләрне тәгъбирләп куеп була. Шуңа күрә Шаһимәрдән хаҗи моннан китәргә ашыкмады. Ә ашыкмау — малчылар өчен сөенеч. Ай чамасы алсыз-ялсыз селкенүдән газапланган әгъзалар бу арада, ниһаять, сызлану, сыкранудан тындылар. Черки талап ка́нап-кутырлап беткән бит-муеннар шомарып китте, аркадагы камчы эзләре кызарып бөреште. Атлар да мул утта туеп, йоннары елкылдый башлады. Җегәрләнделәр. Көннәр дә малчыларны җәлләгән сыман — җилсез, давылсыз.

Бәс, җыеп кына әйткәндә, Каркаралы җиренә кергәч беренче куныш малга да, җанга да хуш булды. Безнең бүз балалар өчен бигрәк тә! Кәрванчылар арасында аларның яшьтәшләре, чордашлары бик күп иде. Кичке шәфәкъ сүнеп, кичке дала өстенә беренче дымсу һава таралганда күл буендагы учаклар янында нинди сүзләр генә куермады! Арада атаклы ялганчылар да бар иде, алар җыелганнарны шаккаттырып, авызларына караттып торыр өчен ниләр генә уйлап чыгармадылар! Алар борынгыны искә алдылар, яшь чакларында күргәннәрне сөйләделәр. Хикмәт тә, гыйбрәт тә бар иде аларның сүзләрендә. Госман белән Иркәтай бераз йомыграк булсалар да, Сабир аларга караганда елдамрак булып чыкты. Бер дә тик тора белмәде ул! Һәм бер кичне...

Күл буе комы шыгырдады, җир астыннан чыккан кебек караңгыдан Сабир калыкты. Аңа тагын ике кеше ияргән иде. Әмма бу кунакларны Госман да, Иркәтай да сагаеп, хәтта бераз куркып каршыладылар. «Ник килгәннәр болар? Нигә монда йөриләр?» Сәбәп ят кешеләрнең киемнәрендә иде. Икесенең дә өстендә кара постау пиджаклар, ак күлмәк якаларын пиджак якасы өстенә каерып куйганнар. Башларында кара бәрхет кәләпүш... «Байбәтчәләр! — дип уйлады Госман,— ни пычагыма Сабир аларны монда алып килгән!»

Әле Күкчәтаудан чыкканда яраган, анда ук инде әлам-сәлам булган киемнәре теткәләнеп беткән малчылар бу егетләр алдында югалып, читенсенеп калдылар.

— Әйдәгез, егетләр, танышыгыз! — дип Сабир шул байбәтчәләр белән кул бирергә чакыра. — Егетләрнең бусы Хәмит, ә бусы Кәрим. — Егетләр көлемсерәп баш иделәр. Сабир дәвам итте: — Алар Атбасардан, Шәмсетдин байның доверенные белән ярминкәгә кызыл мал алып киләләр. Ә болары, дуслар, бая мин әйткән дус егетләр, Госман белән Иркәтай.

Бераздан тартыну бетте, яңа кешеләр яңа сүзләр алып килгәннәр, аларның тарихын ишеткәч, Госман тагын бер кат хәйран калды...

* * *

Кырыктартмачы Сәмигулла, гадәтенчә, язларның берсендә инә-төймә, кәнәфер-дарчын, камфара-борыч, аз-маз кызыл мал алып, аркалап тайгага сәүдәгә китте дә кайтмады. Әллә инде үзен бүре, аю-мазар ботарлап ташлады, әллә юлбасарлар үтерделәр. Кем белсен ялгыз юлчының ялгыз язмышын!? Хатыны Миһербану ике малае Рәхимулла һәм Шәрифулла белән чит җирдә ятим калды. Алар моннан бер ел элек кенә Кукмарадан монда — Кызылъяр каласына «бәхет эзләп» килеп чыкканнар иде. Үтереп мактагаң Себер каласында да бәхет аларны көтеп тормаган икән! Алай да ире югалгач та Миһербану зар елап урамга чыкмады, барыр кешесе дә юк иде, кеше капкасын какмады. Җәен ул түбәтәй, такыя текте, калфак чикте, кышын бүреккә тотынды. Кулда һөнәрең булуның никадәрле зур файда икәнен шунда белде! Тегә дә тегә, кайсысына сөннәтле-кырпулы бүрек, кайсысына сөннәтсез... Иң үтемлесе себер ягының күрке булган куян колак — малахай булды.

— Миһербану колагы! — дип көлеп, мактанып киделәр кызылярълылар бу малахайны. Менә шулай тырышып-тырмашып ул малайларын укудан аермады. Бары тик хәлфәдән кайткач кына малайларны вак-төяк йомышка йөгертә, җеп урарга утырта торган иде. Әмма аның да гомере кыска булган икән шул. Сәмигулланың гаип булуына биш кыш булды дигәндә, Миһербану түбән калага — Ишелгә барып бәкедә кер чайкаганда, аягы тая да боз астына төшеп китә...

Инде Рәхимулла белән Шәрифулла бөтенләй киңәксез калалар. Җанынны ачарлык туган-тумача да юк ичмасам! Алай да Рәхимулла энисе кебек үк тырыш булып чыкты, ул Шәрифулладан өч кенә яшькә олы, нибары уникедә булуына да карамастан, энисен ләхеткә куйганның икенче көнендә үк Шәвәли байга су ташырга ялланды, Шәрифулланы укудан аермады. Яз җитеп, мәдрәсә ябылгач кына, Шәрифулла да Ишелгә төште, мойкада көнлекләп йон юды.

Үлгәннәр кире кайтмый, калганнар тырышып-тырмашып үз көнен күрә!

Карлар яуды, бураннар бурады. Аннан тагын гөрләвекләр тавышы ишетелде. Җир яшәрде. Менә шулай ел артыннан ел үтеп торды. Кайчак елап, кайчак көлеп (малай чак бит, сирәк булса да көлделәр!) малайлар үсте. Рәхимулла егет булды, теше-тырнагы белән тырмашып эшләде, кеше арасына керергә тырышты. Өйләнде, башлы-күзле булды. Хатыны Бәдерниса аңа ике малай китерде. (Ике арадагы кыз үле туган иде). Мулла чакырып, азан әйтеп малайларга исем дә куштырды. Берсе Хәмит, икенчесе Кәрим аталды. Балалар дөньяга килгәч, мәшәкать бермә-бер артты, Рәхимулла элеккегә караганда да тырышыбрак эшли башлады — Кышын Моратов тире заводында тире иләде. Җәен Бәдерниса белән парлашып йон юды. (Хәмит белән Кәрим Ишел буенда көнозын «комнан аркан» иштеләр!)

— Их, энекәш! — ди торган иде ул жомга кичләрендә, кулына гармун алып моңаеп, Шәрифулланың аркасыннан кагып.— Әти-әни безне иртә ташлап киттеләр. Авыр, энекәш, мал табуы бик читен. Бичара үгез төсле көне-төне сасы йон-тире ташып... Мин укый алмадым. Инде Шәрифулла, син укы. Хәләл көчемне аямам кирәк булса Казанга хәтле барып укы!

Шулай дип гармун күрекләрен сузып-айкап гел бер жырны жырлап жибәрә торган иде:

> Биш кул буе, биш кул буе,
> Биш кул буен яратам.
> Биш кул көен бер жырласам
> Бар кайгымны таратам...

Әмма Рәхимулла үз вәгъдәсен үти алмады, чахотка авыруына дучар булып, икенче язда ук дөньядан китте. Озакламый хатыны Бәдерниса да шул ук аямас ютәл чиреннән жан тәслим кылды. Мәрхүмә, өзелере алдыннан Шәрифулланы чакырып, аңа васыятен әйтте:

— Раббым шулай язгандыр инде, абыең артыннан мин дә китәм. Ике күз нурым Хәмитжан белән Кәримжан кала. Әүвәле — хода, икенчесе — син, каенем, сиңа тапшырдым. Рәнжетмә берүк, башкалардан да рәнжеттермә күз нурларымны...

— Нигә алай дисең, жиңги?! — дип өзгәләнде Шәрифулла, шыр сөяккә калган жиңгәсенең кайнар күз карашыннан бөрешеп.— Алай димә! — Үсмер егет мендәргә куелган калын, кытыршы тышлы китапны ике куллап күтәреп алып, иелде, үпте.— Менә, жиңги, кәлям шәриф белән ант итәм. Эшһәдә энлә... үзем исән-сау вакытта Хәмит белән Кәрим энеләремне үксез итмәм...

Бәдернисаның куллары хәлсезләнеп киезгә төштеләр...

Жиңгәсен озатканда Шәрифулла, һичшиксез, чын күңеленнән ант иткән иде. Ә тормыш... Кыен икән ул, авыр икән! Бер үзеңә ике бала!.. Ашатырга кирәк аларны, эчертергә. Кеше арасына чыгарлык, урамда күренерлек кием-салым юнәтергә кирәк. Ниләр генә эшләп карамады Шәрифулла! Көн чапты, төн тырышты, йокламады, үзе ашамады, кулагага калды...

Жиңгәсен жиргә куюга ярты ел чамасы уздымы икән, Шәрифулланың тормышы көтелмәгән бер дәрәжәдә үзгәрде дә китте.

Көзге-яңгырлы көннәрнең берсе иде. Ятимнәр мондый көннәрнең аусыз шыксызлыгын аерата нык сизә! Шәрифулла көндәгечә тездән йшел суында торып йон юа иде, конторадан йөгереп-мышнап бер малай килде дә:

— Шәрифулла, Шәрифулла! Сине бай абзый чакыра. Тиз килсен диде,— дип кычкырды. Шәрифулла калтыранып, агарынып китте: нигә чакыра икән? Эштән куып чыгармаса гына ярар иде! Ятим балаларны кая куярмын?..

Икенче көнне Шәрифулла мойкага килмәде. Аның белән йон юучы иптәшләре, мөгаен, бай аны эштән кугандыр, дип пошындылар. Әмма һич көтелмәгән хәл булды. Бөтен мойка йончылары хәйран калдылар! Гажәп! Чыннан да, бу хәлгә кемнең исе-акылы китмәсен?!. Кичкырын йон юучылар конторага көнлек алырга керсәләр, шаккаттылар — өстәл артында, ниндидер бер кенәгә актарып Шәрифулла утыра. Бик күпләр: «Сөбханалла, күз буу түгелме?» — дип өстәлнең янына ук килеп, үрелеп карадылар. Көнлек алган биш тиеннәре хак булган кебек, өстәл артында кырыктартмачы Сәмигулланың угылы Шәрифулла утыра! Утыруы да бер хәл, укый-яза белгән кешегә кайда да каләм тоттыралар, ә аны бик шәп укыган, коръән хәтем кылган дип сөйлиләр иде бит! Бәс, шулай булгач, өстәл артында утырырлыгы да бар. Халыкның исе Шәрифулланың кием-салымын күргәч китте! Башында кара бәрхет такыя, өстендә юка

кара постаудан пиджак, чалбар. Ак яка. Кара галстук. Әллә Шәрифулла, әллә адвокат?! Юк, әнә, уң битендә, чебен кунган кебек кенә миң үз урынында. Сөбханалла, машалла — Шәрифулла үзе! Кара, нинди чибәр егет икән ул, мойкада йон арасында пычранып йөргәндә күзгә генә чалынмаган! Борынгылар хак әйткән шул, агач күрке яфрак, адәм күрке чүпрәк...

Икенче елны, Шәмсетдин бай Шәрифулланы урыс мәктәбенә биреп исәп-хисапка өйрәтте. Мәктәпне тәмамлагач, ул аны мойкага доверенный итеп куйды. Йон кабул итеп алу, аны яхшылап юдыру, сортын сортка бүлеп зур-зур капчыкларга тутыртып станциягә озату — барысы да Шәрифулла җилкәсенә йөкләнде. Яшь булуына карамастан, акыл да, җитезлек тә, булганлык та бар икән үзендә! Шәмсетдин юкка гына аны күзләмәгән, күзләгәч — ялгышмаган!

Булдыклылык бер хәл, өстәвенә тырышлык та кирәк бит әле. Шәрифулла тырышты. Таңнан торды, соң ятты. Шәмсетдин бай хәйләкәр, берничә тапкыр егетне сынап карады — урлап йон сатарга димләп кешеләр җибәрде, бумажнигы белән акчасын оныткан булды, акча сандыгын ачык калдыргалады... Шәрифулла димләүчеләрне кисеп кире какты, бумажнигын бер тиененә дә кагылмыйча баена кире кайтарды, акча сандыгын бикләп, ачкычын хуҗасына кайтарып тоттырды. Хыянәтсез булды. Башкача булуы мөмкинме соң? Көтмәгәндә мондый дәрәҗәгә күтәргән, шушы кадәр ышаныч белдергән кешегә хыянәт итү мөмкинме соң? Шәмсетдин бай Шәрифулла өчен дөньядагы иң изге, иң шәрәфәтле кешеләрнең берсе иде. Һәркөн биш вакыт намаздан соң, өч «Колһуалла» белән бер «Әлхәм» укый. «Я, хода, ятимнәрне ачлыктан, ялангачлыктан коткарган өчен, мине бәндәләрең арасында күрекле иткән өчен, Баһаветдин угылы Шәмсетдингә озын гомер һибә ит, Сөләйман пигамбәр байлыкларын иңдерә күр!» — дип ихлас күңеленнән дога кыла торган иде ул.

Чыннан да, Шәрифулла мойкада доверенный булып эшли башлаганнан бирле Хәмит белән Кәрим мәктәпкә йөри башладылар. Тамаклары тук, өсләре дә бөтен. Болар һәммәсе дә Шәмсетдин бай һиммәте бит! «Я, рәхимле алла, биргәнеңә мең шөкер!»

Айлар, еллар уза торды, көннәрнең берсендә, Шәмсетдин бай кичке якта исәп-хисап кенәгәсен тикшерде дә, елмаеп Шәрифулланың аркасыннан какты:

— Афәрин, энем, исәп-хисапны дөрес алып барасың. Тырышлыгың күренеп тора, бәрәкалла.

— Бай абзый, сезнең үзегезгә мең рәхмәт. Мине кеше иттегез. Мин...

— Тукта, тукта! — Бай кеткелдәп көлеп Шәрифулланы бүлде.— Син әле, энем, кеше түгел. Ярты гына кеше бит син!

— Ничек, бай абзый? — Шәрифулла аптырап калды.— Ничек инде ярты гына?

— Тукта дим, энем! — Шәмсетдин тагын рәхәтләнеп көлеп, егетнең аркасыннан сөйде.— Бөтен кеше булыр өчен егет кешегә башлы-күзле булырга кирәк. Әйе, башлы-күзле.

Шәрифулла сүзнең ишарәсен төшенеп, бит-колаклары кызарып, башын түбән иде.

— Син, кем, мулла Шәрифулла, оялма. Үз атамыз адәм галиэссәләмнән калган фарыз гамәл.

Шәрифулла каушап китте, теле бәйләнде.

— Ба... бай абзый, кайда әле миңа ул турыда уйларга?

— Нигә сиңа уйларга? — Шәмсетдин бай бик пөхтәләп, түгәрәкләп кыркылган сары сакалын сул кулы белән учлап-савып җибәрде дә дустанә кеткелдәде, яшел күзләре чаткыланып киттеләр.— Шәмсетдин абзаң әллә кайчан синең өчен уйлап куйды. Эһем, эһем... Кара әле, кем,

Шәрифулла.— Байның тавышы бик түбәнәеп, сер сөйләү җаена төште.— Миндә бит үзебезнең авылдан килгән, туган тиешле бик чибәр кыз тора. Исеме дә хур кызларының исеме — Хәдичә...

Туй искиткеч булды!

Ул аш-су! Ул шәраб, кымыз — өстәлләргә сыймады. Симез куйлар, бияләр суелды. Байның ике катлы өе, барлык бүлмәләр, келәм, тәкыямәт, киез түшәлгән ишегалды чакырылган һәм чакырылмаган кунаклар белән тулды. Кызылъярның атаклы скрипкачысы Гарифҗан, гармунчы Зариф, җырчы Әгъләм, Галимулла, сандугач Садыйк ике тәүлек бертуктамый уйнап-җырлап кунакларның күңелен ачтылар. Өченче иртәдә туй Бишкүл буена күчте. Хуҗаның фаэтонга җигелгән аргамаклары тулпар төсле очып кунакларны сахрага — далага ташыдылар. Бишкүл буена ап-ак киез өйләр тегелде, чатырлар корылды. Исәпсез күп казаннар асылды, учаклар кабынды. Скрипка, гармун, татар җырлары зәңгәр Бишкүл буенда гына түгел, хәтта Бишкүл өстендә дә чыңлады.

Никах мәҗлесендә Шәмсетдин бай үзе, муллалар белән бергә утырып, кызның атасы булып ризалыгын бирде. Кыз ягыннан килгән шаһитлар да кызның «Сәмигулла угылы Шәрифуллага хәләл җефет булып барырга риза», икәнлеген ант белән беркеттеләр. Никахны Галимҗан ахун үзе укыды.

«Бу ни бу? Өнме? Төшме?» — дип ышанырга да, ышанмаска да белмичә үз бәхетенә үзе исереп, кыз куенына керү минутларын сабырсызлык белән көтеп йөргән кияү егетен, кояш баеп, лампалар кабынгач, Шәмсетдин бай үз бүлмәсенә чакырып алды да:

— Ничек, энем, туй мәҗлесләре ошыймы? — диде гадәтенчә яңып торган алтын сакалын учлап, көлемсерәде.— Кызылъярны түбәгә күтәрәбезме?

— Ни әйтим инде, бай абзый! — Шәрифулла шатлыгыннан ни әйтергә дә белмәде, исерек кеше кебек аптырап як-ягына каранды да яшел хәтфә кәнәфидә утырган Шәмсетдиннең алдына барып тезләнде.— Сез дөньядагы иң изге кеше. Моны бөтен кала сөйли! Бөтен кеше! Әллә өнем, әллә төшем?!

— Менә, менә, бик дөрес әйттең.— Шәмсетдин аз гына калкынып алдына тезләнеп торган егетнең аркасыннан сөйде.— Афәрин! Яхшылыкның кадерен беләсең.— Бай бу урында артка чигенеп, кәнәфигә чалкайды.— Үзең уйлап кара. Шәмсетдин бай булмаса, кырыктартмачы Сәмигулла баласына бу дәрәҗә, бу туй, бу мәһәр!.. Хәдичә, мисле хур кызы, төшеңә дә кермәс иде! Атаң исән булса да, бу көннәрне күрәчәгең юк иде!

Соңгы сүзләре күңелен нык кына тырнап китсәләр дә Шәрифулла ашыгып-ашыгып аның сүзен җөпләде:

— Бик дөрес, бай абзый, бик дөрес!

— Дөрес сөйлисең, әмма колагың ишетсен! — Байның тавышы кинәт салкынайды, төсе агарып китте.— Белеп тор, хәзер пигамбәрләр заманы түгел! Могҗизалар юк, булмас та! Менә мондый, синең кебек йолкышка, хода рәхмәте дә күктән төшми. Барысында да Шәмсетдин абзаңның хәләл көче! Аның тырышлыгы! Байлыгы! Бәс, шулай икән, бәйрәм ашы кара каршы булсын инде! Якынрак кил әле! — Шәрифулланың йөрәге урыныннан купты, ул тәмам аптырап, телсез калып, баена таба тартылды.— Бер хофия сүз бар! Кил, кил, якынрак, иел! Инде тыңла!.. Капчыгың тишек булса да исең әллә ни китмәсен...— Бай кеткелдәп көлеп җибәрде.— Әһе, тишек булса да салганың коелмас әле!

— Бай абзый, аңламыйм.

— Вакыты җиткәч, төшенерсең.— Тавыш көтелмәгәнчә ачулы яңгырады.— Менә шул, бел һәм алда да онытма: Хәдичәнең кочагы уртак булыр.

— Нәрсә, нәрсә? — Шәрифулла елан чаккан төсле сискәнеп артка каерылды.— Ни дигегез, бай абзый?

— Ишәк! — Шәмсетдин, кияү егетен кулыннан умырып тотып янындагы урындыкка утыртты.— Утыр, мәхлук! Нәрсәсен төшенмисең? — Байның ачулы йөзе тимгел-тимгел кызарынды.— Пычагыма дипме мин сине тирес базыннан тартып алдым? Ни өчен укыттым? Нәрсә өчен доверенный ясадым? Инде бүләккә Кызылъяр байлары күрмәгән туй алдың! Нинди мәһәр! Крестовый өй! Җиһазы белән! Болар нәрсә? — Шәмсетдин бай авызыннан төкерекләр чәчә-чәчә җикеренде.— Болар нәрсә? Хәерче баласына сәдакамы? Тот! — Юан, алтын балдакларын ялтыратып егетнең борын төбендә йодрык уйнады.— Исңә, яхшылыкның кадерен белмәгән затсыз!

Бүлмә кинәт тып-тын булып калды. Ишек артында гармун тавышы ишетелеп китте. Шәрифулла хәлсезләнеп идәнгә чүгеп төшкән иде. Бай тычканны мәче күзәткән кебек, аннан елтыр күзләрен алмый.

— Шәрифулла! — Бай инде аяусыз, тыныч тавыш белән эндәште.— Нигә җебеп киттең? Күтәр башыңны. Итәгеңә төшкән бәхетне башсызланып түгеп җибәрмә. Аннан җыеп алалмассың. Яхшылыкның әҗерен онытма. Хәдичәң уртак булыр, аннан кырпуы коелмас, укасы уңмас.

— Я алла, бу ни дигәнегез? — Шәрифулла иңрәп-чайкалып аягына басты.— Сезнең кызыгыз Зөбәрҗәт белән кордаш бит ул, бай абзый, яшьтәш!

— Җитәр! — Шәмсетдин ачуыннан котырынып сикереп торды.— Тагын мойкага кайтасың килмәсә, авызыңны йом да кыз янына кер!

Ул арада ишек ачылып, Шәмсетдиннең хатыны Мәликә, ефәк итәкләре белән кыштырдап, күркә кебек кабарып поx-пох килеп керде:

— Бу ниегез?! Кияү керер вакыт җиткән! — диде ул.

Шәрифулла тешләрен кысып, иңрәп авызын йомды... Әгәр җиңгәсенә биргән анты булмаса, кулында ике ятимнең язмышы булмаса, ул бу хәлдән ничек котылу юлын табар иде!.. Тик, кая барасың? Ни кыласың?!

Һәр җомга көнне Шәмсетдин бай сакалын кырдырып, чәчен төзәттереп, хушбуй исләре таратып доверенныена «исәп-хисап»ка килде һәм караңгы төшкәч яшь бикәч Хәдичә белән мунча керде.

Шәрифулла күз алдындагы зинага күзен йомды... Ул йомды, дәшмәде... Берзаман Хәмит белән Кәрим үсеп җиттеләр. Калкындылар. Бала булсалар да күз-колаклары бар бит аларның! Алар сизгәннәрен абзыйларына җиткерергә тырыштылар. Башта, мөгаен, тирә-күршеләрдән тартынып, Шәрифулланың корьән үбеп ант биргәнен искә алып, көя Хәдичә балаларны артык какмады. Ә менә быел Хәмит белән Кәримнең күз карашларыннан курка башлады, аларны җен урынына күрергә тотынды, ашау-эчүдән кысты, юктан гаеп табып каргады, кирәге юк эшләрне эшләтеп теңкәләренә тиде. Кәрим өйгән утынны Хәмит җимерде, Хәмит өйгән тиресне Кәрим ишеп ташлады. Ат-арба була торып, түбән каладан Ишелдән көянтә-чиләкләп су ташытты. Мунча яктырды... Мунчаның ни өчен һәм кемгә ягылганын малайлар бик яхшы беләләр иде. Җомга көнне алар иртәдән кичкә кадәр Шәрифулла белән сөйләшергә базмыйлар иде...

Хәдичә байны учында йомарлап тота иде, теләгенә иреште, балаларны кудыртты...

Җомга көн иде, кичен, гадәтенчә, Шәмсетдин бай килде, Хәдичә белән мунча керде. Мунчадан чыгып, шәраб эчеп, бераз кызгач, бай:

— Шәрифулла! — дип җикеренде.— Иртәгә таң белән фаэтон килер. Балаларның икесен дә Атбасарга Хәйруллага озат!..

«Я, хода, нинди язмыш көтә бу сабыйларны? Үзең рәхим-шәфкатеңнән ташлама, мәүләм!» — дип иңрәде Шәрифулланың күңеле. Ләкин ул бер сүз дә өзеп әйтә һәм баеның кушканына каршы килә алмады...

Ә Хәмит белән Кәрим, йон кырка торган олы кайчыны алып чыктылар да, Шәмсетдин бай Шәрифулла агаларының хатыны Хәдичә кочагында чакта, пар атларның койрыгын төбенә кадәр кисеп ыргыттылар...

— Уй-бай, Кәримҗан,— диде Иркәтай, бот чабып көлеп.— Бу сөйләгәнеңнән дә кызыгы булмады гуй!

— Әйе,— дип баш какты Госман. Үсмер егетләрнең бай атларының койрыгын кисеп ташлаулары аңа да бик ошады.

— Иртәгә дә кил, Кәримҗан,— диде Нәсия чал...

Хәмит белән Кәрим үз куышларына таба китеп бардылар.

— Ал, җегетләр,— Лачынбай калгып-уйланып утырган җиреннән кинәт торып, учак тирәсендә уйга чумган малчыларга эндәште.— Кузгалыйк. Монау нугай баласының сүзе күңелле гуй. Чал, син Иркә белән малны, анау кура-мура ягыннан кара, орылар-караклар чыгып калмасын. Без инде, шәкерт менән, анау күл җагасындагы әрәмәгә барып җатамыз. Кем белә, төн кара, камыш калын, кашкыр, шакал дигән җот авыз салмасын! Ал, ут җансын. Кашкыр утка килмәйде. Ходайга тапшырдык. Ярминкә җомга көнне ачыласы, хаҗи абзый бик сак булырга кушты!

Лачынбай камчысын, кистәнен алып кузгалды. Башка малчылар да теләр-теләмәс кенә — инде йокы баса башлаган иде — аягүрә бастылар. Кап-караңгы төн. Кара су төбендә әкият — алтын учаклар һәм тылсымлы сарайлар. Әнә, бер йолдыз ук булып күлне төбенә кадәр тишеп үтте, әбәү! Сүнде. «Адәм баласы дөньяга килгәндә аның йолдызы кабына да, вафатында йолдызы сүнә» дип өйрәттеләр Госманны яшьтән. Менә хәзер, Госманның күз алдында йолдыз сүнде. Кем икән ул меңкен? Госман өшеп, тетрәнеп китте. Миендә чуалган куркыныч-хәтәр уйны чәчеп җибәрергә, таратырга теләгәндәй, башын чайкап-чайкап алды. Юк, юк! Ул түгел! Аның әнкәсенең йолдызы сүнмәде! Сүнмәде! Башка кешенеке иде бу йолдыз... Тик, нигә аның сүнүенә ходай Госманны шаһит итте? Нигә алай? Нигә дөньядан бик яхшы кешеләр китеп баралар да, Шәмсетдин бай, Фәттах бай кебек явызлар калалар?.. Нигә ходай аларның йолдызларын әллә кайчан күк гөмбәзеннән сыпырып төшерми?

Аяк асты йоп-йомшак. Алда Лачынбай. Ул камыт аякларын җиңел генә ташлап төлке шикелле шуып кына бара. Госман исә атлаган саен диярлек сөртенә. Уйлары авырмы, гәүдәсеме? Авыр, җәфалы юл инде, аллага мең шөкер, артта калды. Инде тиздән өйгә! Имәнтауга, әнисе, бабасы, сеңелесе янына. Ярминкә күчтәнәчләре белән кайтып керер дә... Хаҗи гына сүзендә торсын! Сүзендә торыр микән?! Байлар алар вәгъдәләрен бозарга яраталар. Вәгъдә биргәндә бер сүз сөйлиләр, үтәр вакыт җиткәч, телләре башкага күчә. Тагын бер тапкыр шундый сәфәрдә, ярминкәгә мал куып килгәндә Госман да әнә Сабир кебек, нәкъ Кәрим, Хәмит шикелле үз башыннан үткәннәрне ачы хәсрәт итеп сөйләп барырмы?! «Хаҗи абзый безнең барыбызны да алдады!» дип сүзен тәмамлармы?..

Ә төн нинди матур! Тик төннең матурлыгы да Госманның авыр уйларын матурайта алмый, җиңеләйтми!

Лачынбай барды-барды да куе челек-әрәмәлек янында туктады, үлән өстенә кулындагы тимер кистәнне — суелны ташлады да, чикмәнен җиргә җәйде. Аннан, шыпырт, мөгаен, куйлар өрекмәсен дип, акрын пышылдап кына эндәште.

— Шәкерт, мына шушында, минем җанымда җат.— Ул шунда ук утырып итекләрен салды, гадәтенчә, итек-чолгауларын баш очына җәйләп куйды.— Инде бер тынычланып алаек. Я, бисмилла...

Госман да Лачынбай янына чикмәнгә ятты. Лачынбай бик тиз йокыга китәр сыман тоелса да әллә йолдызлы күк, әллә башка нәрсә аңа тәэсир итте, ул хыялга бирелеп, Госманга серен ачып ташлады.

— Ходай биреп, ярминкә файдалы булса, хаҗи әкә безне дә рәнҗетмәйде. Мин дә бу сәфәрдән килгәннән соң үземә дигән утау тексәм кирәк[1]. Инде син дә өеңә барып, әниеңне куандырып, юлдызың ачылып, тагын бер өлкән калага укырга барырсың. Иншалла...— Өлкән малчы уйларын очлап бетерә алмады, гырлап йокыга да китте.

Ә йолдызлар тагын да түбәнрәк төшәләр, якынлашалар, асыл ташлар белән бизәлгән әкияттәге таҗ төсле күзне чагылдыралар.

Камыш арасында кемдер шапылдатып су чәчрәтте. Бераздан шул ук яктан бакылдаган тавыш ишетелде, мөгаен, ана үрдәк балаларын барлагандыр. Гырлап йоклап киткән Лачынбай капылт уянды да калкынып караңгылыкка текәлеп торды.

— Уяу бул, шәкерт,— диде ул.— Менә шундый челектә була инде кашкырның өне. Атар ягына алар шуннан чыкмаслармы?..

Өлкән малчы караңгылыкка карап тагын бераз тыңланып торды да урынына ауды, озакламый әрәмә арасында аның гырлау тавышы гына яңгырый иде. Тирә-як тып-тын. Госман хәвефле уйларын бүлә-бүлә әле сулга, әле уңга ятып карады...

Кемдер аны бик нык тарткан кебек булды. Госман сискәнеп уянып торып утырды. Кем уятты соң аны? Әле караңгы ич, таң да атмаган.

Ул, бисмилласын әйтеп, кире ятмакчы булган иде, якында гына, әрәмә куелыгында нидер шикле кыштырдады, чыбыклар чытырдап сынды. Госман йокылы-уяулы күзләрен ертып шул тавыш килгән якка карады. Каршысында гына ике яшькелт ут ялт-йолт итә. Нәрсә? Әллә инде баягы йолдызлар егылып төшкәнме?.. Тагын әнкәсе хәтеренә килеп, йөрәге сызып, сызлап алды. Әллә инде учак утымы бу? Юк, учак әллә кайда калды ич. Бу шикле ут чайкалып куйды да сүнде. Үндарак тагын кабынды. Лачынбайның «атарга бүреләр шул яктан килсә килер инде», дигән шиге кылт итеп күңелгә килде. Йөрәкне бишкә ярып ботаклар сынды. Мышнау! Сасы ис! Тир исе. Яшел күзләр! Күзләр! Госман бизгәк тоткандагы кебек дерелди башлады...

— Уй-бай, кашкыр! — Лачынбай кычкырып җибәрде.— Кузгалма!

Челек чытыр-чытыр килде, уң якта тагын ике хәвефле ут кабынды. Мышнау якынлашты. Госман җан авазы белән кычкырмакчы иде, теле аңкавына ябышты.

— Кашкыр сукмагында без! — дип пышылдады Лачынбай кармаланып.— Алар атарга бара! Уздырсак, куйларны... Эх, кистән калган!

Өлкән малчы атылып торды, аның хәрәкәтләренә буйсынып, Госман да аягына басты, иелеп кистәнне эзли башлады. Якындагы ике яшькелт ут чайкалды, һәм үткер тырнаклар Госманның җилкәсенә батып керде. Шунда ук Лачынбай бар гәүдәсе белән бүренең өстенә ауды һәм нык, каты куллары белән бүренең муенын эләктерде. Бүре ырлап авып китте, Госман ычкынды, тәненә җылы су койгандай булды. Җилкә әрнеде, әмма ул әлегә бүре тырнагыннан котылган иде. «Куйларны ботарласалар, хаҗи вәгъдәсендә тормас инде!» — дип уйлап алды Госман. Аннары, исенә килеп, бер читкә үрмәләде.

— Кистән! — дип кычкырды Лачынбай.

Әллә ул кычкырды, әллә инде Госманның кистән турындагы уйлары үз тавышы булып ишетелде. Ул кармаланып кичен Лачынбай ташлаган кистәнне эзли башлады. Мүкәләп бая яткан урыннарын кармап чыкты. Юк! Тагын иелде, тагын ике кулы белән җирне сыпырды. Менә! Госман сабы чык белән дымланган кистәнне йолдызларга тиярлек итеп күтәрде. Лачынбай һаман әле бозау хәтле зур, күк ял бүре өстендә иде...

Атар ягында чинап-дулап этләр өрә башлады. Кычкырган тавышлар яңгырады. Кемдер мылтыктан атты. Ул арада, кинәт кабынып киткән учак төсле, гөлт итеп куйлар кузгалды. Госман бар көче белән күк ялга

---

[1] Үземә өй тегеп, хатын алып, дөнья көтә башлармын мәгънәсендә.

тондырырга кизәнгән иде, нәкъ Лачынбайның артында гына тагын бер пар яшел ут кабынды. Госман бер адым атладымы-атламадымы — кизәнде, әмма шунда ук арттан кемдер сикереп аны аяктан екты, сул кул йолкынып алгандай булды, кистән кулдан ычкынды...

## 15

1904 нче елның язы Сары Арка даласына, Күкчәтау, Имәнтау кырларына гадәттәгедән соңрак, әмма дәррәү килде. Башка елларда, бу якның язы, март башындагы яңгыр белән башланып — бер җылытып, бер туңдырып, тычкан белән уйнаган мәче сыман шаяра да, май уртасындагы күз ачкысыз буран белән очлана иде. Ә бу елгы яз апрельдә генә башланды. Аңа хәтле өсте-өстенә кар түшәп, буранлатып тузынды да апрель башында капылт туктады, кояш иләмсез кыздырды, эретте.

— Бәрәкалла!

— Игелеге белән!

— Хәере белән диген, нәрәддәш! — диешteләр станичник картлар бер-берсенә, кояш кыздырган җылы эргәләргә тезелешеп утырып, Имәнтауның киң урамнарын тарайтып, шаулап-гөрләп аккан җитез гөрләвекләргә, станицаны нәкъ уртадан ярып үткән, гадәттә бик сай һәм тар инешнең хәзер кинәт тулып ташуына, шактый зур боз кисәкләрен мәтәлдереп, чумылдырып, нәкъ инде тау елгасы сыман тавышланып, ярларыннан чыгып, күлгә таба ашыгуына карап, сөенеп, сакалларын сыйпыйлар, чал мыекларын бөтергеләп «очырып» көяләр.

Сөенмәслек тә түгел иде шул, менә инде өч ел рәттән кыш соңга калып килде. Кар яңа ел башларында гына ява, анда да бик саран, арлы-бирле сибәләп кенә китә. Гөнаһ шомлыгына каршы, менә шул ала-кола кар да далада, кырларда ятып кала алмый, туктаусыз ыжгырган аждаһа җилләр, котырынып уйнаган «шайтан туйлары» даланы тап-такыр итеп себереп шәрәләндерәләр. Тума ялангач калган мескен җир зәһәр суыкларга чыдый алмыйча телем-телем яргалана, гариплләнә.

Ә быелгы кышта бөтен дала иртә көздән үк ап-ак булып күпереп, җемелдәп торды. Тигез җирләрдә дә тездән кар, уйсулыкларны, урман эчләрен әйткән дә юк. Ат-чанаң белән чумылып китәрсең.

Дәррәү килде яз, калын карны дәррәү эретеп алып китте. Алай да бу язда Имәнтау басулары суга бер туйды. Инде җирнең җылынып парлануын гына көтәргә калды. Шул өлгергән, буланган җиргә чәчәргә орлыклык бодаен да теткәзеп булса!.. Станичникларның телендә хәзер шул гына, җыелалар да шул турыда сөйләшәләр, аерылышалар да шул турыда уйлыйлар. Көнелләр бик үк тынычтан түгел, күңелләрдә хәвеф тә бар. Ничек хәвефләнмисең, каеннар әле яфрак та ярмаган. Ә урманда күке кычкыра! Бер генә тапкыр саташып кычкыруы түгел бит, бер-бер артлы өч тә, биш тә кычкыра бит ул таз баш! Ул шомлы тавышны кеше ышанмаслык малай-шалай түгел, драбанд Җәфрәтил карт үз колагы белән ишеткән. Урманга ботак-сатак җыярга барган икән — күке кычкыра!

— Нәләт төшкере! Үз башыңа! — дип каргап та караган Җәфрәтил, күкенең һич исе китмәгән икән!

Дала яз килүенә сөенә! Чөнки яз даланы аллы-гөлле чәчәкләр белән бизи, зөбәрҗәт келәмнәр җәя. Дала күлләре, елгалар зәңгәрсу күзләрен ачалар. Җир кыбырдап уяна, ул, уңган хатынның күәсендәге камыр төсле күпереп, күзәнәкләнеп кабара...

Станичниклар язгы чәчүгә әзерләнәләр. Урыс-казаклар очында ишегалларында хәрәкәт: сабан-тырмаларны барлыйлар, арбаларны рәтлиләр, атларны кояшка, иркенгә чыгарып кыргычлар белән чистарталар. Лапас асларында икмәк җилгәрәләр, анда хатын-кызлар чыр-чуы

яңгырап тора. Бөтен җирдә тереклек, туклык, яз исе! Күп кенә ишегалларында, бакчаларында, амбарларында нәрсә эшләнгәнен чит-ят күзләр күрерлек түгел, ихаталар биек, коймалар нык, барысы да нык яшерелгән.

Менә бу очта гына урыс очындагы кебек ыгы-зыгы күренми. Тегеелны, яшен сугып янганнан соң, мәчет яңадан салынган. Ул әле өр-яңа, манарасы, гөмбәзе яшел буяуга буялган. Хәзер ул, иртәнге кояш нурында зөбәрҗәт булып җемелди. Менә шунда, яңа мәчет каршында, аеруча күзгә ташланган ике өй тора. Берсе чатта, ул биек таш нигезгә салынган. Монда Имәнтау станицасының указлы мулласы Сиражетдин хәзрәт тора. Дөкәнче Кәлимулла хуҗалыгы да хәзрәтнекеннән ким түгел, киресенчә, тимер ишекле амбарлары, озын-озын складлары бу йортка тагын да баерак төс биреп тора. Бу очта башка күз тутырып карарлык йортлар да, капкалар да юк. Бөтен җирдә таркаулык, ярлылык күзгә чекрәеп кереп тора.

Күкчәтау юлының үргә күтәрелә торган төшендәге ызбаның ишегалдында агач аяклы бер карт баядан бирле иске кул арбасын төзәтеп маташа. Ул арба өстенә иске чыптадан чегән арбасыныкы кебек иттереп бөркәвеч корган. Хәзер ул абзардан карамай савыты алып чыгып, арбаның күчәрен майлый. Бераздан күчәр башын иңенә күтәреп тәгәрмәчләрне зырлатып карады. Зырлатуга гына риза булмады ахрысы, арбаны арлы-бирле йөгертеп тә тикшерде. Арба шома йөгерә, шыгырдамый да. Карт, эшеннән риза булып калды, арба тәртәләрен иплән кенә җиргә куеп, «та-ак», дип әйтеп, уйга калды, агач аяк сизелерлек булып язгы йомшак җиргә батты. Аз гына уйланып торгач карт абзардан бер кочак каен тузы күтәреп чыкты, аны иплән кенә арбаның тәртәләре яткан төшкә таратты, агач аягын сузып җибәреп бүкәнгә утырды. Чакма чагып ут кабызды, каен тузына тидереп «пофпоф» өрә үк башлады. Туз әүвәл бөтерелде, каралды, шуннан соң гына ялкынланып яна башлады. Карт янган туз кисәкләрен тәртәнең әле икенче ягына китерде һәм аеруча житди кыяфәт белән тәртәләрне көйдерә башлады. Карап торган кешегә аның кыланышлары сәер кебек тоелса да, карт үзенең ни эшләгәнен бик яхшы аңлый иде. Тәртәләр житәрлек дәрәҗәдә утта каралгач, ул маңгай тирен сөртеп тәрәзәгә карады. Карындык белән ябылган тәрәзә бүген ачык иде, аннан хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Эч, кабәм, эч инде! Тагын бер касә сөт белән ясыйм. Бибиш апаң керткән каймаклы сөт! Рәхмәт төшкере, онытмый. Менәтерәк сөткатыгын кертеп тора. Авызыннан өзә!

Госманның әнкәсе улы алдындагы буш касәгә кайнар чәй агызды да өстәл уртасындагы коймак тулы табаны аңа якынрак этте.

— Выты, кайнар килеш ашап җибәр, алтыным. Нигә ашамыйсың? Әйт әле, улым, ни булды үзеңә? Йөзең бер агара, бер күгәрә. Әллә инде чирләп тә киттеңме?

Җавап юк. Госман түгәрәк өстәл астына аякларын сузып, бөкрәеп утырганга, катып калган сыман хәрәкәтсез. Чыннан да, әнкәсе әйтмешли, йөзе бер агара, бер күгәрә. Бит сөякләре калкып чыккан, вакыт-вакыт сул күз кабагы сизелерлек тартыла, бите дерелдәп китә.

Чинап, шыгырдап ишек ачылды. Әмма өйдәгеләрнең берсе дә ул якка борылмады.

— Выты, чыгып кара, улым,— идән такталарын сыгылдырып, шакшок басып, сөйләнә-сөйләнә Җәфрәтил карт керде.— Повозкаң үзе йөри торган булды. Самакат сыман. Тәгәрмәчләре зырлап тора. Карамайны жәлләмәдем, күчәрне дә сыйладым. Рәхәтлән, улым.

Госман һаман эндәшмәде. Җәфрәтил карт ишек төбендәге ләгәндә комганнан кулын юды да, тастымалга сөртеп өстәл янына килеп утырды, «бисмилла!» дип коймакка үрелде, елмайды.

— Кызым бүген коймак белән сыйлый икән, бәрәкалла...— Берне капты, икене, өченчесен таба төбенә сыдыртты да житез генә авызга юнәлтте.— Телең йотарсың, иллә тәмле булган. Мәрфук кызыма рәхмәт инде. Үзенә кыен булса да безне онытмый, анысын-монысын китергәләп тора. Молодчина.— Карт коймагын чәйни-чәйни Әминәгә борылды.— Чәй ясап жибәрче, кызым, авызым кипте. Чәен катырак яса, бүген тагын Митри Митричкә кишергә барырмын. Үзенә тупса тапаган идем. Кишерен дә, кәбестәсен дә бирер.

Әминә атасына чәйне каты итеп ясады да үзе тагын өстәл башында өнсез утырган улына текәлде.

Картның күзләре дә бу хәлне шәйләде, ахрысы, чәен тавышлап бер-ике чөмерде дә, Госманга карады, йомшак кына эндәште:

— Улым, мин бит әле повозканың көркәсен дә рәтләдем, менә дигән чыптадан капладым. Тәртәләрен шундый төсләдем, валлаһи, чын пужардан чыккан диярсең! Сырланып-сырланып тора. Бак.— Карт улының ашка да, сүзгә дә, бу кадәр тырышлык белән юлга әзерләнгән кул арбасына да игътибарсыз калуына аптырады.— Бак. Син нигә ашамыйсың да, эчмисең дә, ә?! Инде, улым, юлга кузгалырга да бик вакыт. Выты, көн түбәгә күтәрелгән. Вын, Торналар, аталы-малайлы, повозкаларын тартып көтүдән үк киттеләр. Алар инде Кучкарбай авылына барып житеп киләнә дә башлаганнардыр. Инде алар, улым, бу язда өч подаука гәрәбә сынлы бодай киләнделәр. Өч подаука! Әйдә, улым, син дә ашык. Казахлар жәйләүгә киткәнче киләнеп калырга кирәк. Аннан аларны даладан эт белән дә эзләп таба алмассың! Чәчү вакыты да уза, кузгалырга кирәк. Әйдә, улым!

Госман көненә егерме тиен көмешкә ялланып Шаһимәрдән хажиның куйларын әйдәп ерак Куянды ярминкәсенә киткән иде бит. Каркаралы иленә барып житкәч кенә, Кара-су күле буенда, төнлә куй атарына бүре өере ябырылып, шунда Госман бүре тырнагына эләгеп, чак кына үлемнән калды. Лачынбай да, Госман да каты яраланган иделәр. Икесе дә ярминкәгә бара алмый, якындагы авылда куышта калып, карт белән кәмпердә дәваландылар.

Шаһимәрдән хажи өчен ярминкә бик уңышлы үтте. Ул, әйдәп килгән барлык куйларын күп файда белән сатып, үзе тагын, мул үләнле Күкчәтау далаларында багып симертер өчен йөз баштан артык жылкы малы сатып алып, кире үз ягына юллады. Лачынбай белән Госман, күпме имләнсәләр дә төзәлә алмадылар, бүре тырнаклары белән ертkalанган тән тиз генә бөтәшмәде һәм эрнеде, чиләнде, юлга чыгарлык хәлләре булмады. Алар шул им-томчы кәмпернең өендә калырга мәжбүр булдылар.

Шаһимәрдән хажи юлга чыгар алдыннан бу өйгә килеп, авыруларның хәлен сорашып, һәр икесенә икешәр куй, өчәр сум акча һәм кул күтәреп, дога укып, фатихасын бирде дә: «Иншалла, терелерсез. Әюб галиәссәләм моннан арырак та жәрәхәтләнгән дә савыккан. Аллаһе тәгалә сезгә дә шифасын бирер»,— дип, вәгазь әйтеп, коръәннән дә бер-ике аять укыганнан соң, аягүрә басты:

— Инде, авылның өлкәне Меңбай хажига сезне тапшырдым, мохтажыгыз булса, шуңа барырсыз,— дип, фаэтонына утырды да пар аргамагын каулап Күкчәтау ягына очты...

Кыш килде, авыл кышлауга күчте. Авыл белән бергә Лачынбай да, Госман да Меңбай хажи кышлавына килделәр. Яралары төзәлеп житмәсә дә, имче кәмпер аларга әйләнеп тә карамый иде инде. Куйлар ашалып беткән, өч тәңкә жилгә очкан, «хәере юкның име дә юк»! диде имче, кырт кисеп... Нишләсеннәр, ике байгыш аякларын көчкә сөйрәп хажиның малларын карарга чыктылар.

Кыш үтә авырлык белән узды. Язда Лачынбай Кытайдан килгән байлар белән танышып, аларның малларын Колжа шәһәренә илтергә ки-

леште, үзе белән барырга Госманны да димләде. Госманның, әлбәттә, Кытайга түгел, Имәнтауга, әнкәсе янына кайтасы килә иде! Әмма нишләмәк кирәк! Акча юк, саулык юк... Сыкрап-сыкрап ризалык бирергә булды.

Далада яшел үлән калкына башлады. Госман тагын атка менде, корык алды һәм бихисап куй малын әйдәп, Лачынбай белән бергә Кытай җиренә юл тотты.

Рәхмәт яусын инде ул Кытай табипларына! Уйламаганда, көтмәгәндә Колжа кәрван сараенда очрадылар да Лачынбай белән Госманның тәнендәге яраларны карадылар. Кып-кызыл, чи җәрәхәт иде икесенең җилкәсе! Озын чәчләрен ике толым итеп үреп ташлаган, хатын-кыз сыман нәзек тавышлы (җыерчыклы биттәге сакал-мыек билгеләре генә аларның ир затыннан икәнен белдерде!) ике табип үзара «пин-чин-мин» дип сөйләштеләр дә, аркаларыннан күн капчыкларын төшереп, аннан әллә нихәтле тамыр-томыр, яфрак, киптерелгән үлән сабакларын чыгардылар. Тамыр-томырдан бер уч йолкып, үләннән бер чеметем салып, чүлмәк савыттагы кайнар суда парладылар. Аннары, менә шул хуш исле яшел ботканы, ике егетнең җәрәхәтләренә салып, чүпрәк белән кысып бәйләделәр.

Бер атнадан соң табиплар үзләре килеп яра өстендәге чүпрәкләрне сүтеп алдылар да, тагын «пин-чин-мин» дип чыркылдап егетләрнең аркаларын кактылар.

— Шанго! Шанго!

Ходайның хикмәте, син күр дә, мин күр, күпме вакыт егетләрнең канын кайнаткан җәрәхәт бер атна дигәндә бетте! Дөрес, башта бөтәшкән урыны үтереп кычытты. Озакламый алар да тынды. Лачынбай белән Госман шунда ук турайдылар һәм тагын атка атланып Синь-зян тауларына мал багарга киттеләр.

Бак, бу якларда да Имәнтаудагы кебек таулар! Кара-кучкыл, текә таш таулар! Алар бөтен төньяк офыкны күләгәләп торалар. Ә көнчыгышта иксез-чиксез кылган даласы. Ул инде сүс чәчләрен, толымнарын тузгытып көмеш дулкын булып чайкала. Менә шушы мул азыклы, иркен далада өер-өер атлар утлап йөри. Ул Колҗаның атаклы сәүдәгәре Акчуринның җылкы көтүләре. Госман шул атларны багучы — җылкычы. Әнә, күрәсезме, бирерәк, ике үркәчле тау итәгендә кечкенә генә бер куыш — киез өй күренә! Менә шул инде Лачынбай белән Госманның торагы, кышлавы да, җәйләве дә шунда. Җылкы малы казах илендәге кебек, монда да кышын-җәен далада. Ул кура-купшыны белми.

Киез өй алдындагы учактан сыек төтен күтәрелә, анда Лачынбай. Ул сөт кайната, эремчек, сыкма әзерли. Сәгать саен бияләрне савып кымыз житештерү дә аның бурычы. Кымызларны тире капчык — сабаларга Госман коя. Акчуриннар көн саен кичкырын, махсус атчы җибәреп, кымыз алдырып торалар. Төннәрен җылкы багарга Лачынбай үзе чыга. Төн вафасыз... Соңгы вакытларда Лачынбай Госманны бәла-казалардан сакларга тырыша, аны кызгана. Юл башында егетнең сыртында камчы уйнаткан Лачынбай түгел ул хәзер! Теге чакта, хаҗи күзенә ярарга тырышып кына шулай усал кыландымы әллә? Ничек кенә булмасын, чит-ят җирләрдә ул үзен Госманның агасы кебек тотты, рәхмәт төшкере.

Көндезге каравылда Госман. Ул иярләгән атын буш җибәреп, утлатып, үзе куе кылган эчендә ауный. Тирә-якта күзгә күренмичә генә кошлар сайрый, сызгыралар, чүт-чүт, диләр. Күбәләкләр, инә караклары бер-берсен куышып очалар. Талгын җилдә, сизелер-сизелмәс кенә кылган тулгана. Җиләс, черкиләр дә аз. Ә күк зәп-зәңгәр, нәкъ Имәнтау күле сыман үтәдән-үтә күренә.

Тик Имәнтау ерак шул хәзер, бик-бик ерак! Аның кайсы якта икәнен дә чамалап булмый. Әллә унда, әллә сулда? Әллә инде әнә

тегә күгәреп торган таулар артында? Күңел иләс-миләс килә, ашкына, сыкрый, сагына! Чү, Госман күзләрен катырак йомды. Чү!..

Әнә алар! Озын сәфәрдәге ягымлы юлдашлары җылы учак янында тезелешеп утыралар. Бәхетҗан әкә, аз гына иелеп үзе белгәнчә дога укый. Аның янында Иркәтай, Нигъмәтулла, Сабир амин тоталар. Учак кинәт чытырдап, ялкынланып янып китте...

— Менә без кызыклы хәлләр сөйләргә дип килдек! — Болары калын-калын китаплар тоткан Хәмит белән Кәрим. Идел ягы моңнарын беренче тапкыр алар алып килде бит Госман аңына!..

Нәкъ борын очына кунып, үткен сөңгесен батырып өлгергән черки Госманны чынбарлыкка алып кайтты, ул черкине бәреп үтергәч, күзен йомып караса да, учак та, дуслары да юк иде инде.

— Кайда икән алар хәзер?

Үзе соравына үзе үк җавап бирә: «Өйдә алар, өйләрендә! Сез генә кайталмыйча каңгырып калдыгыз!»

Тагын ауный Госман, күз алдында һаман Имәнтау. Нигәдер елыйсы да, җырлыйсы да килә аның. Күңел ташый, ниһаять, җыр булып түгелә:

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем барсын да.
Уйлама, күңелем, барсын да,
Син уйлап шашарсың да!

Талгын гына җил исә, ул Имәнтау егетенең бу илгә таныш түгел җырын — сагышын Синь-зян тауларына алып китә.

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем төрлесен.
Уйлама, күңелем, төрлесен,
Хак язганын күрерсең.

Дөрес, Госманның тавышы әллә кем түгел, Баһау әйтмешли, күклә-яшелле, башта ярыйсы үк күтәрелә-шыңлый да, аннан очлана алмыйча, ярты юлда кинәт төшеп китеп өзелә. Ярар инде, монда, Синь-зян җирендә аны кем ишетә? Ишетсә дә...

Ә күңел чак кына тынычланып кала, хәтта тагын-тагын җырлыйсы килә. Үзен-үзе кыстатмый егет, тагын башлый:

Уйлый күңелем, уйлый күңелем
Уйның тәмлесен генә.
Тәмле уйлар арасында
Иң тәмлесе Син генә!

Кем ул Син? Әнкәсеме? Драбанд Җәфрәтил бабасымы? Имәнтау үземе! Аның таулары, күлләреме?.. Әллә туган ягын җыеп бер сүз белән «Син!» дип атап эндәштеме егет?.. Истәлекләр яңаралар, алар ачык, тере бер төсмер алалар һәм шунда хәтергә түгәрәк йөзле көлеп торган бер кыз сурәте иңә!.. Кул буенда бай малае аның чуртанын алып ыргыткач ул аның янына килеп баскан иде!.. Башка вакытларда да, очрашканда озын керфекләрен тибрәтеп көлеп карап тора иде бит ул!.. Әйе, кемне сагынганын үзеп кенә әйтеп бирә алмас иде Госман! Ул үзенә дә кызның исемен әйтми. Бары, тагын-тагын пышылдап кына кабатлап куя: «Иң тәмлесе син генә!»

— Эх, өйгә кайтасы иде, өйгә! Илгә!

Кайтырга иде! Инде Госманга тиздән наряд та җитә! Әзерләнергә кирәк. Ул — казак. Казак икәнсең — беренче өйрәнүләргә үк, лагерьга үз атыңда, үз ияр-тукымыңда, үзең тектергән себер казагы формасында — нәкъ артикул кушканча тулы обмундированиеда чыгарга тиеш. Аларны Госманга кем алып бирә? Атасы каберда, әнкәсе түшәктә — исәнме әле ул, юкмы?!

Еракта күк күкрәде. Госман сикереп торып, якында гына утлап йөргән атына атланды. Яңгыр килә! Җылкыны ышыкка таба куарга кирәк...

Уза икән еллар, уза икән...

Яшенле яңгырлар белән, буранлы, җан өшеткеч суыклар белән, сәмум җилләр белән, сагынулар белән уза икән. Һич туктап тормый икән!

Ниһаять, инде бишенче яз дигәндә, Госман белән Лачынбай, хуҗалары Әхмәтгәрәй әфәнде Акчурин белән исәп-хисапны өзеп Колҗадан Куянды ярминкәсенә бара торган кәрванга иярделәр. (Рәхмәт инде Акчуринга, рәнҗетмәде, вәгъдәләшкәнен бирде!)

Госман өстендәге чапанның эчке астары арасында карындык белән кат-кат төрелгән бер бөти ята. Догалык түгел, түгел! Биш җәй, биш кыш көне-төне җылкы артыннан йөреп, азга да канәгать булып, ачлы-туклы яшәп җыйган бар байлык анда. Исәп — строевой ат, ияр-тукым һәм казак формасы алу! Һәм... бик кысып тотсаң, бер сыерлык, һич булмаса башмак таналык та акча чыкмас микән әле! Йортка сыер кирәк, бик кирәк...

Ниһаять, күпме урау юллар узып, Госман туган йортының какшап беткән, шыңшып торган чалыш ишеген ачты. Аны, аллага шөкер, инде түшәктән күтәрелгән, әмма дөнья мәшәкате белән нык картайган авыру чырайлы анасы һәм җиз сакалы белән агач аягы бер дә үзгәрмәгән бабасы каршыладылар, дөресрәге, Госманны ишек катында күрүгә — күзләренә ышанмыйча, аптыраулы куанудан телсез калдылар. Мәрфук нигәдер күренмәде...

Бары чәй янында гына аңа телгә килде. Бертуктаусыз алъяпкыч белән эчкә баткан томанлы күзләрен сөртеп утырды да:

— Шулай инде, улым, ходайга тапшырып син югында сеңелеңне дә озатып куйдык,— диде. Госман «дерт» итеп китте. Эчәргә күтәргән чәй тулы касәсен өстәлгә куйды. Сорау белән анасына карады:

— Кемгә?

Аңа бу карашны тиз төшенде.

— Кәлимулланың улы Галимуллага никахладык. Нишләтик, улым! Житеш торалар, беләм, тел-тешләре дә бар! Үзем дә, выты, шуларның керләрен юып, сыерларын савып йөрим.— Ябык бит буйлап ике тамчы яшь тәгәрәде. Әминә, борынын тартып, читкә борылды.

— Язмыштан узмыш юк, диләр.— Кызының сүзен Җәфрәтил карт ялгап алып китте.— Может аларның чәчләре бәйләнгән булгандыр? Син, кызым, елама. Вчүтәки тамагы тук, өсте бөтен. Анда-санда безне караштырып тора.— Карт өстәлдәге коймагы кимегән майлы табага ымлады.— Кыз баланың вакытында оядан очуы хәерле.

Үз сүзләренә ышана идеме карт драбанд, әллә аптырауда калган оныгы белән кызын гына юатырга теләдеме?

«Хәерле! Хәерлеме икән? Кемгә оча бит!» — дип ачынып уйлады Госман. Галимулла белән дошман иделәр алар! Кан дошманнары, көн дошманнары! Күл буенда очрашуны әйтәсеңме? Байбәтчәнең киерелеп Бохарага укырга китеп барганда күреп калган ямьсез кызыл телен әйтәсеңме, сүзләрен! Хәзер ул «кияү»! Госман аның кодасы. Әллә язмыш һаман көлеп туймаган иде Госманнан?!

Чәйнең тәме китте, өстәл яныннан сүзсез кузгалдылар.

Госман, бүләкләрен өләшкәннән соң (Мәрфукка дигәне ятим булып сәкедә торып калды!) чапанга тегелгән акчасын сүтеп алып, күзе шар булган бабасы алдына куйды...

Алар май ярминкәсенә Күкчәтауга ат алырга киттеләр.

Яшь казакка беренче строевой ат алу — хуҗаларның гына түгел, бөтен станицаның йомышы, кайгы-шатлыгы. Шуның өчен Госманга ат

алу тантанасына, ярминкәгә Имәнтауның иң атаклы казаклары — көрәк сакаллы, көмеш медальле ветераннары, хәтта атаман Роман Михайлович үзе дә барды. Уен түгел, ятим-ялпы егет үз хисабына ат ала!

Тирә-як далаларыннан казахлар ярминкәдә сатарга өер-өер җылкы куалап китергәннәр иде. Берсеннән-берсе усал, чит кеше якынлашуга колакларын тек торгызып, күзләрен алартып күккә сикерәләр. Әмма озын походларга чыгар өчен атны сайлый белергә кирәк, мондый эш киңәш-табышсыз гына эшләнми! Атакаларга ташланыр өчен аттан аеруча тазалык, аякларының ныклыгы, күкрәкнең киңлеге, күзләрнең үткенлеге һәм гомергә дус-яр булырлык холкы кирәк! Мондый ат-иптәшне бар гомерен ат өстендә уздырган, походларда, сугышларда күп катнашкан казаклар гына сайлап ала. Көнозын Имәнтаудан килгән станичниклар йөзләгән ат арасыннан Госманга яраклысын сайладылар. Инде арып, борчылып беткәч кенә, кичкә таба, әле яңа гына бер казах бае алып килгән кара айгырга тукталдылар. Маңгайда ак йолдыз, гәүдә коеп куйган — артык калын да, артык юка да түгел. Дала аты. Үзендә дала җилләреннән йоккан кызулык, ахак күзләр ут яна, колаклар тек тора, нык-таза муенга куелган матур, һавалы баш. Аяклар озынча, нык — кырык тамырдан. Арткы ике бәкәл ак оектан.

— Выты, строевой, күзләре ут сынлы,— диде Җәфрәтил драбанд шул атны күргәч.— Минем җирән кашка да шундый иде. Севастопольдә, атакага чыкканда чокыр туры килеп, аягын сындырды...

— Драбанд дөрес әйтә, яхшы ат! — диделәр башка станичниклар да.

Ике казак авызлыгын тотып торып Госманны атландырдылар. Өстендә ят кеше булуын тою белән кара айгыр, ике казакны ике якка ыргытып, күккә ыргылды, ачы итеп кешнәде һәм ярминкәне икегә ярып, ак-караны күрмичә, далага омтылды.

Станичниклар читкә авышып, куанышып, мәгәреч эчәргә әзерләнделәр.

Госманның биш ел буена җыйган суммасы менә шушы айгыр белән ияр-тукымга такы-токы гына җитте.

Ә кием-салым?

Ә башмак?

Ходай үзе белсен! Белүен белә, бирми генә!

Нишләргә соң? Уйлый-уйлый да, озын юлларының чатына чыккан Госман, уйларының очына җитә алмый. Ахырында ул, рәнҗи-рәнҗи, кодаларына барды һәм кышын аларның җылкыларын багарга ялланып, алдан обмундирование алырга бурычка акча сорады. (Бурычка батып үз исемен дә югалткан Нәсия чалны кызганып уйлады Госман!) Галимулла бераз башын кашыгач:

— Ярар, чыбык очы булса да, туган син. Беренче килүдә йөзеңне бормыйм,— дип ризалык бирде.

Узган яз Госман үзенең кордашлары белән беренче тапкыр Күкчәтау каласы янындагы Чагалы елгасының уң ягында — җәйге лагерьда хәрби әзерлек үтте. Ике ай буенча иртәдән кичкә кадәр хәтле ат өстеннән төшмәде, стройда йөрергә, атарга, кылыч белән чабарга, киртә аша ат сикертергә өйрәнде. Солдат хезмәтенең тозлы булуын татыды! Лагерьдан алар, бөтен станица кызларының йөрәген яндырып, фуражкаларын кыңгыр салып, җырлап кайттылар... Әйтерең бармы: яшь казаклар — яшь этәчләр!

Хәзер менә шул казак, өч иманалык басуга чәчәргә орлык таба алмый. Бу ни дигән хурлык?! Бабасы аны хәер сорашырга чыгарга әзерли, арбаны рәтләп-майлап та куйган... Орлык тапмасаң, үзеңә үпкәлә: вакыт көтми, кояш кыздыра...

Әллә ничек булды бу 1904 нче елның язы!

Урыс-казаклар очында җан рәхәте! Алар инде кар китәр-китмәстә чәчүгә әзер. Аларда ат та, үгезләр дә, орлык та бар. Ындырларында

ничә еллар сугылмаган кибәннәре утыра. Станицаның татар казаклары торган ягы гына шып-шыр. Кәлимулланыкыларны, Сиражетдин мулланы, карун Каюмны алмаганда, башкаларның буралары ярты кыштан шып-шыр. Нигә алай? Татарлар ялкауракмы әллә югыйсә?! Сәбәбе бик ачык: бу очтагы татар казаклары монда әле күптән түгел генә Нижгород, Пенза, Тамбов, Сарытау ягыннан, Казан губернасыннан каңгырып, эш эзләп, җир эзләп килеп чыккан тоташы ярлы-ябагай. Алар мең чакрымнар үтеп, Урал тауларын кичеп, мең газаплар аша Күкчәтау, Имәнтау якларына килеп сырышканнар. Ярты юлда ат үлгән, арбасы ватылган, күпме җаннар арык тәннәргә сыеша алмыйча күккә очкан! Ятим-ялпы арткан. Алар күчеп килгәннәр дә җан саклап калыр өчен Себер казаклары исемлегенә язылалар. Казак булу белән нәселдән килгән юклык шунда ук юкка чыгар, күтәрелеп, туйганчы икмәк ашарбыз, дип өметләнәләр. Ни әйтсәң дә, падишаһ хәзрәтләре казакларга байтак җиңеллек бирә, җир суның, урманның яхшысы аларга, налоглар юк. Яшә генә!

Юк шул, казакларның икенче ягы — тирес ягы да бар икән, шомлыкка каршы!

Егерме яшькә җитәр-җитмәстә улыңны казаклыкка әзерли башла. Бу инде, иң әүвәл, бисмилла, дип, ат сатып ал. Андый-мондый аксактуксак алаша түгел, менә дигән, биеп торган строевой ат кирәк! Юкса, беренче смотрда ук атаман атыңны бракка чыгарып, башка ат алырга боерыр. Ә атаман — станицада патша да, алла да. Алмый хәлең юк, чөнки син — казак! Үзең теләп язылган казак! Бурычка батып булса да аласың. Аннары няр-тукым кирәк.

Аларын рәтләп куйдыңмы, инде обмундирование! Ике пар итек, пар чалбар, пар гимнастерка, шинель, фуражка, бүрек! Барысы да менә дигән — хромнан да, постаудан! Янып торган кызыл лампаслары белән! Әле болары бер улга. Әгәр, алланың рәхмәте белән, уларың ике, өч, дүрт булса?! Нишләмәк кирәк! Кем бер малай белән генә кала?! Туа малайлар. Димәк, һәммәсенә ал! Киендер! Сугышка озат! Чөнки син — казак! Димәк, гүргә кергәнче ерып чыга алмаслык тышау — бурычка батасың!

Менә шуның өчен бу оч казаклары яз җитүгә, кул арбасына көркә корып, тәртәләрен төсләп-көйдереп җигеләләр дә, якын-тирәдәге казах авылларына чыгып китәләр һәм:

— Яндык. Өйдә бер әйбер калмады. Чагалар ач. Ходай хакы өчен хәер-сәдака бирегез. Выты, тәртәләргә багыгыз. Уттан тартып алдык,— дип күренгән бер бусагада яшьләрен түгәләр. Казах халкы беркатлы, рәхимле, ышана. Кайсы — йон, кайсы — май, кайсы — хәтта куй бирә. Кыштан калган бодай булса, аны да жәлләми.

Менә шушы «көйгән тәртә сәфәрендә» кем күпме табыш алып кайта, шуның белән язга җанын саклый. Ит, май, йон сатып (билгеле инде, урыс казакларга!) чәчүлек орлык җыя. Булмаса, иманаң кысыр кала!

Үләт-чират бүген Госманнар ызбасына да килеп керде. Хәзер, менә бу өстәлдән тору белән, ул Җафрәтил бабасы төзәткән, әзерләп куйган кул арбага җигелеп келәнергә чыгып китәргә тиеш.

Егерме яшьлек тап-таза егет, атлы казак, авылдан-авылга йөреп, йөзен ертып, «яндык» дип, күрер күзгә ялганлап, тәртәләрне шаһит итеп, хәер сорашырга тиеш. Янсалар да, аңа биш былтыр узды ич инде! Ничек инде битне ертырга?! Ничек булмаганнарны әйтеп ялганларга? Ничек? Башкача яшәп булмыймы? Ә ничек «башкача?» Кайдан соң орлык табарга? Яз көтми. Ул инде басуларны киптерә, ашыктыра.

Иреннәр дерелди. Сул күз кабагы тартылып-тартылып китә. Бугазда төен. Күзләрдә... Ә бит болай караганда Госман бер дә төшеп калган егет түгел! Атасы Гомәргә тартым — эре сөякле, киң җилкәле, озын буйлы. Узып киткәч кызлар борылып-борылып карыйлар!

Ул башын күтәрмичә генә анасына карады. Елый. Елый, мескенем. Бабасы? Башын түбән игән. Кем аларның яшьләрен юар да кем башларын күтәрер? Тән чемердәп китте — өстән бозлы су койдылармыни?!

— Бабакай! — Госман тетрәнеп кычкырып җибәрде.— Бабакай! Выты, мин оялам келәнергә... валлаһи!

Җәфрәтил авызына менгән чәен кире куеп, кеткелдәп көлде.

— Һе-һе, улым, кем оялмый? Иманлы йөз оялмый буламы? Оялу, ул, улым, күркәм сыйфат. Выты, колыным, барыбыз да оялабыз. Арттан нужа әйтеп тора! Шул куа! Бак, әгәр быел чәчә алмасак, җирне кысыр калдырсак, кышын ни ашарбыз! Мин инде, аллага шөкер, сигезенче дистә белән киттем. Мине чуттан төшерсәң дә, выты, анаң бар, выты, үзең!

— Уф, алла! — Әминә тагын да тирәнрәк итеп көрсенде.

— Беләм, беләм, колыным.— Сүз өзелде. Карт нигәдер ишек ягына карады, алдында мырлап яткан песине кагып идәнгә төшерде, тамагын кырды...

— Юк!

Мондый кискен, ачулы тавышны бу ызбаның бер чакта да ишеткәне юк иде. Госман үзе дә мондый тавышы барлыгын белми иде әле. Җәфрәтил белән Әминә аптырашып, нәрсә булды, дип куркынып берберсенә карадылар. Госман сикереп торды да йөгереп ишегалдына чыгып китте. Ишек шыгырдап ябылды.

Госман ишегалдына чыгу белән, утынлыкта яткан балтаны алып, әле яңа гына бабасы төзәткән, көркә корган, тәртәләрен көйдергән арбаны аркылы-торкылы чаба, сындыра башлады.

## 16

Госман капкадан кергәндә, хәзрәт, тап-таза итеп себереп, вак ком сибелгән ишегалдының аргы кырыендагы ак мунча таһарәтханәсеннән комган тотып чыгып килә иде. Капка ачылган тавышка ул тукталып калды. Түгәрәкләп кырылган куе кара сакал белән мул кара мыек дагаланып бер-берсенә кушылып киткән калын кара кашлар күзне күләгәләп тора. Зур, карчыга борын. Буйга артык озын булмаса да, ярыйсы ук тулы бәдән аны батыр сынлы итеп күрсәтә. Зур кара күзләре рәхимле карыйлар. «Мөгаен, юлым уңар»,— дип уйлады Госман сөенеп. Хәзрәтнең өстендә бөтен төймәләре каптырылган сатин җилән, аякларында очлы башлы кәвешләр. Капкадан керүчене ул җентекләп карады да танымады. Госман ашыгып, әмма муллага ишетелерлек итеп, сәлам бирде:

— Әссәламәгаләйкем, мулла абзый!

— Вәгаләйкемәссәләм! — диде мулла иҗекләп һәм һәр иҗектән соң бераз тыныш ясап.— Әй, мулла кем, син кем угылы буласың соң? Сәламне, китап кушканча, бик һәйбәтләп бирәсең икән, афәрин.

— Мин, мулла абзый, Гомәр азанчының улы Госман булам.

— Бәрәкалла, бәрәкалла! Изге атаның баласына охшыйсың шул. Аллаһе тәгалә, иншалла, бәхетеңне ачар. Мулла кем, исемеңне Госман дидеңме әле?

— Әйе, мулла абзый, Госман булам.

Мулла Гомәр мәзин улының юкка гына йөрмәвен чамалый, ни сорасын алдан ук исәпләп куеп, җавабын да әзерләргә тырышып, сүзне егеттән алда куәтләп китте:

— Хуп, хуп. Мөбәрәк рәсүлебезнең дүрт чәһәръярларының бере Госман булган, шуның шәрәф исемен йөртәсең икән. Атаң, мәрхүм, изге җаннардан иде шул. Инде син дә, угылым, атаңның рухын рәнҗетмә, ислам диненең терәкчесе бул. Амин. Бик иртә йөрисең, берәр ашыгыч йомышың бар идеме әллә?

Госман каушап китте. «Ничек итәргә, хәзер үк әйтеп салыргамы, әллә бераз көтәргәме?» Мулла ашыктырып тамак кырды, кузгала башлады.

— Әйе, әйе, мулла абзый, йомыш белән йөрим.

— Ә? Алай булгач, бераз сабыр ит, әүвәле тәһарәт фарызны башкарыйм, аннары дөнья сүзләренә күчәрбез. Ярыймы, Госман угылым? — Хәзрәт өй ишегенә таба атлады.— Ә син, әнә, бүрәнә өстендә утырып тор. Әссабырый-рахман, биссабырый-шайтан.

Госман рәхәтләнеп, җиңеләеп тын алды. Өстеннән бер авыр йөк төшкәндәй булды. «Юлым уңар ахрысы, мулла абзыйның кәефе бик әйбәт күренә!» Һәм ул җиңеләеп, койма буена өелгән юан бүрәнәгә барып утырды. Хәзрәт тәһарәтнең һәр рәвешен җиренә җиткереп башкарды, хәтта башын артка ташлап, тамагын чайкаганда, тигезлеген югалтып, чайкалып чак кына чалкан барып төшмәде. Госман пырх итеп көлеп җибәрә язды, ярый әле, кулы белән авызын томалап өлгерде. Хәзрәт егылмады, «сөбханалла, сөбханалла!» дип комга тигән кулын чайкады да ишегалды баскычына килеп утырды, өйнең ачык ишегенә карап аваз салды:

— Әй, абыстай, сиңа әйтәм! Кара әле! Тәһарәт сөлгеләрен алып чыгып бир әле. Сиңа әйтәм, ишетәсеңме?!

Шактый вакыт узды, өйдә нидер шалтырап төште, ниһаять, идән шыгырдады. Ишеккә көчкә сыеп, бәбәйтәкле, кызыл шакмаклы күлмәк кигән, кызыл сафьян читектән алпан-тилпән абыстай килеп чыкты.

— Син дә, атасы,— тавыш ярсып, ачу белән яңгырады.— Тәһарәткә чыкканда сөлгеләреңне ала белмисең! Сандык башында, намазлыгың янында гына эленеп торалар лабаса. Казанда маем кыза, сумсаларым көеп ята. Мә, ал җәтрәк! — Сөлгеләрне мулланың кулына ташлаганда аның усал күзләре Госманга төште.— Бәй! Бусы тагын нинди йолкыш? Таң тишегеннән кукыраеп утыра!

— Тик, анасы, тик! — Мулла абзый уңайсызланган кебек булды.— Алай әйтмә, бик инсафлы егет күренә. Сәламне дә китапча, мәкам белән бирде, бәрәкалла. Танымый калдыңмы әллә, бу бит теге, ходаның язмышы... Изге җаннардан булсын! Иртәнге азанны әйткәндә яшен суккан Гомәр азанчының угылы Госман була бит.

— Ярый, бик әйбәт! — Абыстай җилтерәп алга атлаганда чак кына баскычтан төшеп китмәде, култыксага тотынып калды.— Бик әйбәт. Үзе килгән икән! Юкса үзем барырга дип йөри идем.

Мулла, абыстайга карап, аяк корытырга кирәген дә онытты.

— Ни, абыстай, сәдака-нәзерең бар идеме әллә?

— Бар! — Абыстай гасаби бер әче тавыш белән кычкырып та җибәрде.— Тотсыннар капчыгымны! Ул денсезләргә ни дигән фытыр!? Алган карызларын да түләмиләр, биш ел була бит инде.

Мулла яланаяк баскычка торып басты, иңендәге сөлгеләр шуышып төшеп киттеләр.

— Нинди карыз? Ни булды алай, сөбханалла, машалла! Нигә бу кадәр чәпчисең?

Госман да бүрәнә өстеннән купты, аптырады: бу ни хәл?!

Абыстай хәзрәткә карап кул гына селкеде:

— Син дә шул, махау, хуҗа насыр. Үз кулың белән биргәнне үзең онытасың. Үләсе язын, нәкъ шушы вакытта Гомәр азанчы килеп, өч подаука гәрәбә сынлы бодай алып киткәне кайда, көзен бирермен дип? Менә бирде. Үзе җан тәслим кылды, бурычы муенында калды лабаса.

Хәзрәт бер агарып, бер күгәреп торган Госманга карады да тамагын кырды:

— Әйе, әйе! Абыстай бик дөрес әйтә. Түләнмәгән бурыч, ди, каләм шәриф, ходай үзе сакласын, теге дөньяда утлы муенчак булып карыз алган бәндәнең муенын буып торыр, ди. Әльгаязы билләһи... Калган варисларга мәрхүмнең бурычын кайтару мотлак фарыз!

— Кайтарырлар, көтеп тор! — Абыстай көеп барган сумсасын онытып, тагын да кыза төште. — Выты, биш ел инде анасы да, бабасы да йортка аяк басмыйлар. Карызны оныттылар. Ураза, намаз, муллага фытыр сәдакасы бирү уйларына да кереп чыкмый. Фәсихләр! Хәзер дә бу йолкышы, оялмыйча, келәнергә килгәндер әле!

Хәзрәт тиз үк абыстай җаена күчте:

— Син, мулла кем, хәзер менә өеңә кайт та, анаңа әйт, атайның мулла абзыйларга өч подаука орлык бирәсе бар икән... Ул бурыч утлы муенчак булып атайның муенын буып тора икән... Атайны коткарыйк, диген!

— Ай, алла! Беттем! Шул йолкышның кәсафәте белән сумсамны көйдердем бу имансызлар белән булышып актык өеңне яндырырсың. Бәдбәхетләр, үтердегез!

Абыстай, егыла язып, ишеккә ташланды, яланаягына кәвешләрен эләктергән мулла аның артыннан керә-керә һаман Госманны үгетләде:

— Бар, кит. Анаңа әйт, карызны иртәгә үк китереп тапшырсын. Гөнаһасына калмасын, ишеттеңме?

Ишектән кергәндә, ул борылып карады, бүрәнә янында беркем дә юк иде инде.

Урам буена озын-озынга сузылган таш койма. Биек. Ике кеше буе булыр. Менә шушы крепость коймага якынлаша башлау белән үк теге яктан эт өрә башлады. Госман кибеткә якынлашты. Гадәттә, көтүдән үк ачыла торган тимер ишекләр бүген нигәдер ябык. Тимер бастырыкларда йозаклар. Госман сабырсызланып уйлап алды: «Кәлимулла коданы да күреп булмыймы? Кукчәтауга товарга киткәннәрме әллә?»

Мулладан өмет өзеп чыккач та ул озак уйлап тормады, башкача барыр җире дә, кагар капкасы да юк иде. Бөтен өмет аларда... «Хәзрәтнең дә, абыстайның да иманы юк! Атай үзләренә күпме эшләде, бушка малларын бакты. Ә алар, үлгәч тә, аннан карыз сорыйлар. Ә мин, дурак, выты, орлык бирмәсләрме, дип, сорарга барган идем! Выты, алдың!»

Беркатлы Госман атасының муллага бернинди бурычы юклыгын, иртә-таңнан бүрәнә өстендә утырган егетнең, бары тик чәчү орлыгы гына сорарга килү ихтималын абыстай бер караудa төшенеп алган иде! Ул, хәзрәттән алга чыгып, егетнең авызын томалап куйды! Абыстай белән хәзрәт көйгән сумсаларны майга манып-манып ашаганда Госманнан рәхәтләнеп бер көлделәр!

— Кем анда? — Госман капка келәсенә дә тотынырга өлгермәде, эчтән хатын-кыз тавышы килде.— Кем кирәк?

Госман, тавышны танып, куанып китте:

— Бу мин, Мәрфук, ач.

— Кит, Дүрткүз, кит, дим, явыз! Капка ачарга бир!

Зур, калын капканың калиткасы теләр-теләмәс кенә ачылды.

— Нишләп йөрисең, Госман?

«Артык ябыккан, сулган. Бал белән майда торып, шулай буламы? Әллә балы ачы, мае зәһәрме?» Госман сеңлесенә карап, җәлләп, әйтер сүзен дә онытты.

— Бак, сиңа ни булды, Мәрфук?

— Әйтмә инде, Госман!

— Ни булды соң? Нигә әйтмисең?

— И, алла! — Мәрфуга, нигәдер ялт борылып, ишек ягына күз ташлап алды.— Атакай эчсә, Галимуллага: «Хәерче кызын алып килеп, битебезгә көя яктың!» — дип тынычлык бирми. Ә ул аннары изаланып мине кыйный. Выты, кичә атай әйтә: «Вын, бабаң Җәфрәтил, улы Халюкны нарядка озатканда, ат-сбруй алам, бер елда түләрмен, дип

алтмыш сум көмеш алган иде. Инде ничәнче елы бара, Халюкның службадан кайтыр чагы җитә, ә үндүрт сум көмеш әле түләнмәгән. Имәнтау хәерчеләренең бетмәс тишекләрен ямый торган әндри казнасы миндә юк. Иртәгә үк өенә бар да аксак хрычка әйт, карызны китерсен. Булмаса, теләнчеләреңнән кайтма, шунда кал,— ди.

— Үзе өйдәме соң?

— Таңнан Күкчәтауга, Баязитовларга товарга киткән иде.

Ул арада, ялгана гына башланган сүзне бүлеп, олы өйнең тәрәзәсеннән шыңлап гармун аккордлары ишетелде, аннан скрипка кыллары чинап-сызлап колакны кисеп узды. Госман аңына да килеп өлгермәде, гармун белән скрипка бергә кушылып, ярсып, чәчрәп «Баламишкин» көен сыздыра башлады.

— Әллә инде туй сездә? — диде аптырап Госман.

— Эчәләр шунда! Атакай өченче көн Күкчәтаудан ике музыкант алып кайткан иде, ике көн керфек какмыйча эчәләр. Бирәннәре ярылгыры! Ашарга әзерләп өлгертеп булмый, бүген ике тапкыр казан астым инде. Атай киткәч, Галимулла бигрәк азынды...

Җыр яңгырады.

Баламишкин агып киткән
Чиләбенең суына.
Без уйныйбыз да җырлыйбыз
Галимулла туенда.
Әйт шуны, Майтапны!
Без дә күрдек байтакны.

Госман аерманы бик тиз сизде: анда ике тәүлек туктамыйча эчәләр... көн тугайга әле күпме генә, ә Мәрфуга ике тапкыр казан асарга өлгергән... Ашыйлар, тыгыналар, ә аларның өендә карга чукырлык та ризык юк... Чәчүлек турында әйтеп тә торасы түгел!.. Чөнки алар бай, ә ул — йолкыш! Абыстай бик туры әйтте, «йолкыш», диде.

— Әй, келәнче кызы! — Уйны раслагандай ишек ягыннан исерек тавыш ишетелде.— Кай җәһәннәмгә төшеп югалдың? Куырдык кайда?! Бәбәкләреңне...

— Әнә, убыр эзләп тә чыккан,— диде Мәрфуга дер калтырап.— Син, бар, кит инде...

Ачык тәрәзәдән тагын гармун, скрипка тавышы яңгырады һәм аңа җилбәзәк-куштан җыр кушылды...

Госман ничек чыгып киткәнен дә, капканы ничек шапылдатканын да сизми калды. Ул тизрәк бу исерекләрдән, аларның кабих тавышларыннан читкәрәк китәргә ашыкты. Кемнән кача? Кая? Кем янына чаба? Ник? Бу турыда хәзер Госман уйлый да алмый, уйларга да теләми иде. Баш чатный, сызлый, мена-мена ярылып китәр сыман. Тын кысыла: сулыш җитми. Качарга! Шушы пычрак моңнан ераккарак качарга! Ул тыкрыктан урамга, урамнан тыкрыкларга йөгереп күчә-күчә станицаны әйләнеп тә чыкты бугай. Аяклары талып, көчсезләнеп мәйдан читендә туктап калды.

— Усман-ка!

Кемдер арттан кычкырды, әллә шулай ишетелде генәме? Кемгә кирәге бар йолкыш Госманның?! Җирең булып та, орлыгың булмасын! Орлыгын тапсаң, үгезең булмасын... Киявең типтереп, аракы чөмереп, каладан музыкантлар чакыртып яшәсен... Ә син... Йөр инде төсләнгән тәртә арасына кереп келәнеп! Келәнмәсәң кая бара аласың? Кем син?!

— Ус-ман-ка!

Җир дөп-дөп итә. Ат тоягы тавышы. Госман чиркәү ягына турылап чыкты, аннан бабаларына юл кыскарак.

— Әй, Усманка!

Бу тавыш колакны телеп үтте, нәзек тавыш, хатын-кыз кычкыруы. Госман нидер сизеп, сискәнеп туктады, артына борылды. Инеш ягыннан тузан уйнатып чабып ике атлы килә. Алда күк ат. Аңа кызыл күл-

мәкле кыз атланган. Җирән чәчләре ял төсле тузып, якын килә. Аны бастырып менә-менә узам, дип, кара ат чаба. Аның өстендә ак күлмәкле егет. Шулар «Усманка!» дип кычкырды, күрәсең. Ул арада кара айгыр алга чыкты да Госман атменәрне таныды: дьякон Григорий Яковлевичның улы Петька ич бу! Ә кыз? Кызны танымады Госман, алай да йөрәк тирәсендә нидер сулкылдап алды. Кыз, ярсып-ачуланып тезгенне тартты да, күк ат ыргылып алга чыкты. Кызыл күлмәк җилдә кабынып дөрләде.

— Маша!

Госман үзе дә сизмәстән, кычкырып җибәрде. Чыннан да, атта станица атаманының кызы Маша иде. Атлар бастырып туп-туры аның өстенә килделәр дә җитәр-җитмәс шып туктадылар.

— Кычкырам, кычкырам, һаман туктамыйсың, Усманка,— диде кыз, таралган чәчләрен бер якка сыпырып.— Ә мин сине әллә кайдан таныдым. Петька әйтә, ул түгел, ди. Күрдеңме, Петька, кем хаклы булган?

Петька иелеп Госманга кулын бирде. Кулы анда булса да, күзе кызда: ничек үзгәргән ул, ничек үскән!..

Госманның Машаны Куянды ярминкәсенә киткәннән бирле күргәне юк иде. Былтыр җәй лагерьга чыкканда аны утырмага кунакка туганнарына киткән, дип сөйләделәр. Аннан кайткач та Госманда кыз кайгысы булмады, дөнья мәшәкатьләре басып китте... Үскән, күз тимәсен, сылу кыз булып җиткән. Элек Маша олырак авызлы, салпы колаклы, шыксыз гына «озын сыйрак, кыска тун» иде, аны «торна» дип үчеклиләр иде. Ә хәзер?!. Яшьлеге, тулылыгы бөтен яктан күзгә чәчрәп кереп тора. Түгәрәк, тулы битләрендә аз гына сипкел дә бар ахрысы, әмма алар кызны ямьсезләмиләр, киресенчә, аерата бер сөйкемлелек өстәп торалар. Борыны әүвәлгечә аз гына почык! Каян алып аны зур авызлы дип уйлаган икән Госман? Таман гына! Иреннәре тулып, кызарып торалар, әле генә чия ашап чыккан диярсең. Өстәге иренгә нәни генә «чебен» кунган — миң! Кара, кара, күзләрен! Ут көйдереп карый бит, имансыз... Чәчләрен тотып, сыйпап карыйсы килә...

Күзләр гыйшык белән караганда уйлар йөгерек була, шушы бер минут эчендә Госман Петька белән бер-ике сүз алышырга да, Машаны баштанаяк карап тикшерергә дә өлгерде. Карады, карап туймады, выты, шайтан, нинди сылу кыз булган ич, ә?!

— Әллә Маша Волкованы танымыйсың инде? — диде Петька, төрттереп.

— Оныткан, икмәктер, оныткан! — дип көмеш тәңкәләр чәчте Маша.

— Онытмадым,— дип мөгрәде Госман. Атменәрләр икесе дә көлеп җибәрделәр. Петька атын чак тыеп тора иде, иелеп аның муенын сыйпады да:

— Нигә монда торабыз әле? Әйдә, Усманка, безгә. Уха ашарга. Әни замат арасында пешерә,— диде.

— Юк, мин бит...— дип нидер ялганламакчы иде Госман, Маша иелә төшеп, аның күлмәк якасыннан тартты, күлмәкнең кай төшедер шыртлап китте.

— Әйдә, атлан минем атка!

— Без икәү! — диде Петька.— Әйдә, Усманка!

Госман ике ат арасында калды, Петька белән Маша аны ике яктан култыклап алдылар, «һоп!» дип чөеп җибәрделәр, яшь казак ат өстенә сикереп менгәнен абайламый да калды. Петьканың кара айгыры эре адымнар белән юырта башлады, Машаның күк биясе дә калышмады, алар «ә» дигәнче дьякон йортына кайтып та җиттеләр.

— О, Усманка! — Шау-шуга капка алдына чыккан Анастасия Васильевна — Петьканың әнкәсе, әле кызларча зифа-озын буйлы, тыгыз

гәүдәле мөлаем хатын, Госманны күрүгә куанып китте.— Исәнме, казачок?!

Ул кунак көтеп алгандай елмайды, кулын бирде, әмма кулын тиз генә ычкындырмады.

— Әйдә, әйдә, Усман Умарович, өйгә кер, күптәннән күренмисең. Берәр яры иденме әллә?

— Юк ла, өйдә ятам.— Госман оялып кулын тартты, киреләнергә уйлаган иде, Петьканың әнисе кычкырып көлде дә, Госманны аттан тартып төшереп, күтәреп алды, капкадан алып кереп тә китте. Петька белән Маша кычкырып көлештеләр, Госман оятыннан кая керер тишек тапмады.

— Өйләнмәдеңме әле? — дип шаяртты хатын, һаман Госман белән булышып.

— Нинди өйләнү ди әле?

Анастасия Васильевна аз гына «төшергән» иде ахрысы, ачык тәрәзәдән стакан чыңлаган тавышлар да ишетелеп китте, Госман «тагын килеп каптым!» дип уйлап капкага таба тартылды. Маша белән Петька атларын урнаштырып маташа иделәр.

— Юк, юк! Жибәрәмме соң?! — диде Анастасия Васильевна тагын Госманның кулыннан эләктереп. Ул аны сөйрәп диярлек тәрәзәгә якын китерде һәм:

— Әй, господа станичниклар, менә сезгә тагын бер кунак! Ә бәлки, Роман Михайлович, сиңа кияү дә булыр әле! — Хужа хатын тәрәзәдән башын алды һәм чыбыкка тезелгән балыкларны тотып өйгә кереп барган Машага күз кысты.— Шулаймы, чибәрем?

Өйдә шаулатып көлештеләр. Госман коелып төште. Маша да кинәт абынып туктады, күз керфекләре жиргә кадалды.

— Ой, тетя Настя, оят бит! Әти янына керерлегемне калдырмадыгыз!

— Ничего, ничего,— диде хужа хатын.— Каушама. Син бит атаман кызы! Ә Усманка казак түгелме? Ул кемнән ким! Тиздән аңа наряд та житә, шулаймы, казак Абдрашитов? — Егетнең колаклары ут булып яна иде. «Вәт, тел бистәсе! Вәт килеп каптым!»

Ә Анастасия Васильевна һаман күңелле сөйләнә-сөйләнә егетне баскычка кадәр китерде.

— Бар, кереп атаманга сәлам бир. Ә син, чибәр кыз,— ул Машага карап күз кысты, нидер ишарәләде,— балыкларны тиз генә чистарт та уха пешер, ашка киявең дә килеп өлгерде.

— Тетя Настя! — Кыз еларга житешеп ялварды, чөнки хужа хатын шул кадәр кычкырып сөйләшә, өйдәгеләр һәммәсен ишетеп торалар иде.

Петя белән Маша балыкчылар янына барганнар икән, кунакларның бик кинәт кенә «уха ашыйсылары килгән!»

Нишлисең, ничарадан бичара, йорт эченә үк узды Госман һәм кунакларны күргәч, ишек катында туктап калды.

Түрдә бөтен өстәлне алып-каплап атаман Роман Михайлович Волков утыра. Мәһабәт гәүдә, билгә кадәр төшкән куе, кара сакал. Чәч таптакыр итеп кыркылган. Ул өр-яңа, хаки төсендәге постау костюмнан, күкрәктә ялт-йолт иткән өч Георгий тәресе. Иңнәрендә көмеш погоннар. Аның артында стенада уңып-таушалып беткән эреле-ваклы фоторәсемнәр. Атлы-атсыз, коралы-коралсыз казаклар... Сул як стенага терәлеп жирән, куе мыеклы яшь казак — станица писере Петруша утыра. Озын, ябык, яңак сөякләре калкып тора. Әмма артикул буенча — формадан киенгән. Унда йорт хужасы Григорий Яковлевич Беляев. Ул аягүрә басып кунакларны сыйлый. Өстәлдә самогон чиреге. Кунаклар байтактан утыра ахрысы, ул инде яртыланган. Чирек янында буш стаканнар. Аларга кәбестә кисәкләре, суган кыяклары ябышкан. Ташбалчык та-

бакларда мичкә тәгәрәткән кабыклы бәрәңге, гөмбә ише әйберләр тутырылган. Шунда ук озын чүлмәк белән каймак та куелган.

«Бу нинди көн? Татарлар аяк тибеп эчә, руслар кочаклашып эчә!» Шулай дип уйлап рәнҗеп-аптырап Госман кире борылды.

— Стой! — Роман Михайловичның калын тавышы өйне тыгызлап тутырды.— Ул нинди отходной?! Господа станичникларга сәламне как следует бирергә кирәк! Син, нәрсә, казак түгелме? Кер монда.

Госман, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранды, бәхетсезлеккә каршы, Петя да, Маша да якында күренмәде, Анастасия Васильевна да күрмәгән иде, мөгаен, алар өчәүләшеп балык чистарта торгандыр.

Госман ирексездән кире борылып, бусагадан узуга ук «смирно» басты.

— Исәнлек телим сезгә, господа станичниклар!

— Вот и молодец! Форма буенча! — Роман Михайлович, өстәл уртасында горур басып торган «чирек»не үзенә табарак тартты, тамагын кырды.— Инде, казачок, өстәл янына кил.

— Мин эчмим, господин атаман!

— Дурак! — Атаман гөрелдәп, Кәлимулла байның амбарына эленгән йозак хәтле йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.

— Господин атаман,— диде ярыйсы ук сәрхүшләнгән Петруша, яшелле-мөшелле тавыш белән.— Беләсезме, Усманка нигә эчми?

— Ну әйт, Петруша! Яшь казак Абдрашитов нигә самогон эчми? — Атаман хуҗа китереп биргән стакан белән өстәлгә шап иттереп берне сукты.— Я!

— Роман Михайлович, ул курка!

— Кемнән? — Атаман, стаканын кулыннан ычкындырмыйча, бераз аптырап туктап калды.— Кемнән курка?

— Кемнән булсын — мулладан!

— Ха-ха-ха!

— Хи-хи-хи!

Хуҗа да, кунаклар да ярылганчы көлделәр, атаман стаканга эчемлек салам дип өстәл өстен диңгез ясады.

— Ха-ха-ха, вот Петруша, мәзәк таптың! Ничек инде алай! Атаманы сыйлый, ә ул мулласыннан куркып эчми! Этого не может быть! Атаман зурмы, мулламы?! Үтердең, Петруша, үтердең!

Ул арада өй хуҗасы, ындыр табагы хәтле чуен табаны ике куллап көчкә-көчкә тотып, өстәл уртасына китереп куйды. Таба баскач «диңгез суы» өстәл читеннән чырылдап ага башлады, борынга куе, сасы самогон исе аңкыды.

— Кунаклар,— диде хуҗа эре генә.— Бу беленнәрне сезнең өчен Анастасия Васильевна махсус койды! Әйдә, Усманка, утыр! — Ул атаман кулыннан стаканны алып кыяр-кыймас кына өстәлгә якынлашкан Госманга таба шудырды.— Утыр, сыйлан, аша. Син казак! Син Петьканың дусты! Курыкма, без муллага әйтмибез!

— Ну да! — диде аны җүпләп атаман.— Без муллага ни гу-гу! Ну, ходайга тапшырып күтәрдек, за царя, за отечество!

— Юк!— диде Госман бөтен көчен җыеп. «Нишләп әле шушы кадәр җебеп төштем?! Куянды юлларын үткән, Кытайга барып җиткән казак ич мин!»

— Как так юк!

— Господа станичниклар, әгәр мине хөрмәт итәсегез икән, сыйламагыз мине, сез миңа булышыгыз!

— А? — диде Роман Михайлович, авызына тыгызлап тутырган беленнәрен көчкә йотып җибәреп.— Булышыргамы? Була. Нигә булачак кияүгә булышмаска, ә, господа станичники?!

Атаман авызын киң ерып елмайды, үрелеп, чирекне аударып җибәрә язды, Петруша гаҗәп бер житезлек белән бутыльны тотып калды. Менә син аны йокымсыраган дип уйла!

— Вот атаман синең ярты грузыңны ала! — Роман Михайлович Госман стаканының яртысын эчеп тә җибәрде, тагын беленгә үрелде.

— Юк! Миңа самогон түгел, чәчүлек бирегез сез, господа станичниклар. Басуны сукаларга үгез бирегез. Вот миңа нинди булышлык кирәк бүген.

— А? — Атаман авызына алып барып житкергән мөлдерәмә тулы стаканын кире өстәлгә куйды да кыюланып, ярсып сүз әйткән Госманга карады.— Вот сиңа Усманка!

— Менә шулай,— диде Госман олыларча.

Хуҗа дьяконның май баскан күзләрендә шаян утлар җемелдәде.

— Нигә бирмәскә? — диде ул кинәт.— Бирәбез! Бирәбезме, Роман Михайлович?

Дьяконның мондый мәсьәләләрдә хәйләкәр икәнлеген дә, төрле мәзәкләр оештырырга сәләтле булуын да белә иде атаман, тик бу юлы аның кая таба бөккәнен аңлап житкермәде, саңгырау гына:

— Бирергә дә була! — дип куйды. Аның ризамы, түгелме икәнен дә белерлек түгел иде.

— Менә шушы самогонны рәттән өч стакан эчсәң орлык та бирәбез, үгезләр дә синеке! Килештекме?! — диде Григорий Яковлевич. Атаман хихылдап аның симез җилкәсен төя башлады, яшь казак писер Петруша бертуктаусыз, яшь коя-коя тәгәрәп көлә иде.

— Ризалаш, Усманка! — диде ул, Госманга күз кысып.— Ризалашып кал. Господа станичниклар сиңа хөрмәт күрсәтә!

Бүген иртә таңнан күңелгә жыелып килгән гарьлек егетнең бугазына килеп тыгылды. Бабасының теләнче арбасы тәкъдим итүе, мулла белән абыстайның парлашып аннан көлүләре, «йолкыш» дип атаулары, Мәрфуганың йончыган йөзе, куркынган күзләре, ниһаять, менә монда исерекләр... Бу соңгы чик. Чикнең азагы. Моннан ары Госманның барыр кешесе юк. Ул бу читен сорау белән атаманга мөрәҗәгать иткәндә аз-маз бабасы турында да уйлады. Госманга орлык бирмәсә дә Полный кавалер драбандка аз булса да хөрмәте бардыр ич казачий атаманның?! Тик алар да әнә... «өч стакан!» Иртән юньләп ашамаган көйгә...

Аның икеләнүләре озак бармады, ул көлгән булып авызын чалшайтты, атаманга ошатырга тырышып шап иттереп өстәлгә китереп сукты һәм беренче стаканны күз дә йоммыйча эчеп җибәрде.

Анастасия Васильевна кереп житеп: «Нишләтәсез егетне? Адәм көлкесенә калдырырга телисезме?!» — дип чәпчеп караган иде, мәзәк ясау белән мавыккан ирләр, хихылдап, аны бер читкә генә кагып җибәрделәр. Икенче стаканны эчкәнен дә хәтерли әле Госман, хуҗа хатын аның авызына көчләп диярлек гөмбә кисәкләре, кайнар майлы белен каптырып азапланды... Аннан соңгысын эчтеме-юкмы — хәтерләми Госман, аны Петя белән Маша өйгә кадәр илтеп куйдылар. Петя көлә, Маша исә кызганып ниндидер ягымлы, якын сүзләр әйтә. Тик сүзләрен хәтерли алмады Госман, ягымлы, йомшак тавышы гына күңелгә уелып калды.

Эчеп бетергән булырга тиеш, атаман белән дьякон, яртышар-яртышар өлешкә кереп Җәфрәтил драбандка гәрәбәдәй бодай да җибәрделәр, жирен сукаларга үгезләр дә биреп тордылар.

## 17

Күкчәтау каласының үзендә татарлар шактый күп булса да, өяздә татар авыллары икәү генә — Күкчәтаудан 90 чакрым ераклыктагы Имәнтау станицасы (күргәнегезчә, руслар белән кара-катыш авыл), икенчесе каладан утыз биш чакрымда гына Җилтау авылы. Бу авыл

да, Имәнтау авылы шикелле үк, узган гасырның соңгы дистәләрендә Идел буеннан ачлыктан-юклыктан качып килгән ярлы-ябагадан оешкан. Тик алар имәнтаулылар сыман «казак»лыкка язылмаганнар, шуның өчен өяз земствосы аларны иң түбән сорт кешеләр санап, иң котсыз җирләргә утырта. Сулары тозлы, якындагы тау да күп хәсрәтләр күргәнгәме, тоташтан пеләш, урмансыз-куаксыз җирләр, көне-төне җил уйнап тора. Шуңамы, авылга Җилтау исеме биргәннәр.

Туган җирләрдән ерак китсә дә халык үз йоласын ташламаган, гореф-гадәтләрен онытмаган. Татарлар булган бар җирләрдәге кебек үк, монда да иң зур, иң тантаналы бәйрәм — сабан туе. Имәнтауда сабан туе — татарның да, урыс-казакларның да уртак бәйрәме. Урман аланына барысы да җыела: башларына кара бәрхет такыя, өсләренә хәл-җаена карап — кайсы өр-яңадан, кайсы юып, бәләкләнгән ак киндер күлмәк, кара камзул, кара чалбар, аякларына итек, читек, кәвеш кигән, кырынган, юынган, олылы-кечеле такырбаш татар агай-энеләр, станичниклар; башларына төрле төстәге яулыклар бөркәнгән, аратирә чиккән калфак кадаган, төрле төстәге чуар, бәбәйтәкле күлмәкләрен чиккән алъяпкычлар белән кысып куйган, озын толымнарына көмеш чулпылар таккан татар апалары, аларның ыбыр-чыбыр балачагалары; артикул буенча нәкъ урыс казаклары киенгәнчә кызыл лампасларын балкытып, кыңгыр салган фуражкаларының ялтыр козырекларын кояшта балкытып япь-яшь егетләр, сабыр акыллы морзалар, аксакаллар, атлы шук кызлар — һәммәсе дә бар Имәнтау сабан туенда. Атаман да шунда, аны дәрәҗәле, күкрәкләренә бар булган медальләрен, тәреләрен тезгән абруйлы казаклар урап алган, арада Җәфрәтил карт та бар...

Госман егетләр арасында. Быелгы яз башта бик куркытып торды-торды да, ахырга таба, эшләр чак кына җайланып китте. Язгы чәчү бетүгә кодалар Госманнарны барлык өй эче белән, кунакка чакырып сыйладылар да, бирнә бирделәр драбанд картка күлмәк, ыштан, чапан, анакайга күлмәк, яулык, ә Госманга — бердәнбер яшь кодага — бүләкнең мулы эләкте. Аны баштанаяк киендерделәр. Күк сатин күлмәк, постау чалбар, кара бәрхет такыя өстенә шыгырдап торган хром итекләр эләкте. Бу көтелмәгән баю иде. Ни булды бу Кәлимулла кодаларга? Ничек болай тиктомалдан ачылып, юмартланып киттеләр әле? Әллә инде атаман булып атаман үзе Госманнарга капчыклап чәчүлек орлык, дьякон үгезләрен биргәч, «кытыкландыларммы»?! Атаман алдында яхшы атланырга теләделәрме? Озын колаклар һәм озын телләр «атаман кызы Маша Җәфрәтилләрнең Госманы белән чиртерә икән!» дигән хәбәрне бик теләп таратып өлгергәннәр иде инде! Әллә шуны чамаладылармы кәлимуллаңыкылар? Ни булса булды, уйламаганда-көтмәгәндә, Госманнарның җиргә сеңеп барган өйләренә нур иңде. Госманның өс-башына күзе төшкән саен елап йөргән Әминә дә, «инде бу дөньяда алыш-бирешем бетеп бара», дип сагышка баткан Җәфрәтил дә йөгереп кенә йөри башладылар. Һавалар да утырып китеп, яңгырлар да вакытында яуды, чәчкән игеннәре дә тигез булып калкынып китте, ходайга шөкер, димәк, алда да өмет бар, алда да якты көннәр көтә!

Шуның өчен сабан туен сабырсызланып көтеп алды Госман. Бала чагында ул гел көрәшкә чыга, шуның өчен түземсезләнеп-ярсып каршылый иде бәйрәмне. Быел ул башкачарак көтте, бүтәнчәрәк дулкынланды. Өс киемнәре дә ару гына булгач, аның бәйрәмне тизрәк китереп җиткерәсе килде.

Кайнап торган халык арасыннан ул аны әллә кайдан күреп алды. Ияк астыннан чалып куйган җете чия төсендәге кәшимир яулык, калкып торган күкрәк өстенә, гаруз белән ике роза чәчәге чигелгән, бөрмә җиңле шикәр ак кофта, киң, озын зәңгәр сатин юбка һәм биек

үкчәле, озын кунычлы кызыл сафьян ботинкалар. Кунычлары сары тасма белән шнурланып, очлары бантлап бәйләнгән. Әллә ашыгып килгәнгә, әллә көн эссегә, ул бераз тирләгән, кызарган. Сызылып, кыйгачланып кына торган саргылт кашлар шаян сикерәләр, күзләр зур ачылып дөньяга һәм Госманга шук карыйлар. Ә теге, өске ирендәге нәни генә миң-чебен, елмайган саен очып китәргә тора!

Баһау, Госманның дус егете, әллә ни арада озын колга башына менеп, кызыл «кучатны» һәм бүләккә бер уч чуклы кәнфит алган. Хәзер ул, Госманны чак кына көнләштереп, Машаны сыйлый. Иптәш кызлары тырышып-тырышып кызны чакырсалар да, ул Госманнар яныннан китмәде. Аңлаган кешегә аз-маз аңларлык иде бу нәрсә!

Иң башта көрәш. Бала-чагалардан башланып киткән көрәш тора-бара мәйданга олыракларны чакырды. Көлешә-көлешә, кемне хурлап, кемгә көч биреп озак кына көрәшне тамаша иттеләр. Аннан чокыр аша ат сикертүләр булды. Кып-кызыл чырайлы, купшы чәчле егетләр кылыч айкый-айкый «лоза чаптылар».

Кинәт халык тагын чайкалып, көрәшне, ат сикертүләрне, лоза чабуларны ташлап, Госманнар торган якка, үргә таба авышты, шаулап, ярсып кычкырып җибәрде.

— Уй-бай, килә җатыр! Килә җатыр!

— Киләләр, киләләр!

— Едут, едут!

Менә беренче чуар дулкын — бала-чага, хатын-кыз, егетләр берберсен этә-төртә үргә үрелде. Һәм ишелеп килеп Госманнарга сукты. Машаны артыннан килеп төртеп ектылар.

— Нишлисез, таптыйсыз бит!

Госман, кулындагы чачаклы кәнфитне ыргытып бәреп, ачулы тавышы белән дулкынны туктатырга тырышып, Машага ташланды, аны җирдән күтәреп алды. Әмма кызны аягына бастырырга һич әмәл юк иде, дулкын үзенең агымы-басымы белән аларны сөйрәп тауга алып менеп китте. Әлерәк кенә такылдап, шырык-шырык көлеп торган Маша, күзләрен йомып, тавышсыз-өнсез Госманның кочагында бара. Госманның куллары аның биленнән кысып кочкан. Кызның йөрәк тибеше дә, сулышы да сизелә. Халык аларны ирексездән кочаклашкан килеш бераз өстерәп барды да, кинәт таралып китте. Алар шул килеш яшел чирәм өстенә аудылар.

Әле иртәнге салкында ук утыздан артык чабышкы моннан егерме чакрымдагы Ак Болак кизләвенә озатылган иде. Ат хуҗалары дерелдәп, сөенеп, көенеп, бер кызып, бер туңып, Ак Болак юлыннан күтәрелгән тузанга карыйлар. Алар гынамы?! Бәхет кайсы атның маңгаенда яна?

Кем бәхете?

Кем йолдызы?

Кем даны?

Карт драбанд — «сабантуй атаманы» Җәфрәтил карт та үр астында калмады, яшь-җилкенчәк аны, ай-ваена карамыйча җилтерәтеп, күтәреп алып, үрнең нәкъ түбәсенә мендереп куйташ өстенә утыртты.

— Бак, выты, инде бак, бабакай, бар дөнья синең пүлән астында ята! — дип, көлә-көлә, хәле беткән картны җилкендереп тә куйдылар. Җәфрәтил карт бәйгене күзәтеп, үзеннән ерак та түгел, бер-берсенә кысылышып басып торган Госманны да, Машаны да күрми калды.

Мәйдан уртасындагы колга төбендә аяклары бәйләнгән, мөгезләре калач кебек уралган, бозау хәтле кушкар — сабан туйның иң зур бүләге бәйгедә алдынгы килүче чабышкы хуҗасын көтә!

Ак Болак кизләве ягыннан, очып килгән торналар сыман, сузылып, бәйге атлары күренде. Ел тәүлегенә әзерләнеп, өметләнеп, сөенеп көткән хәлиткеч минутлар якынлашты. Тузан тагын да куера төште.

Әнә шул соры тузан болытын куптарып, бер-берсен таптап-узып, тулпар атлар килә! Ат өстендә малайлар ял өстенә иелеп камчыларын селтиләр.

— Һайт! Һайт!

— Акбуз юлга чыкты.

— Әйдә, әйдә, Карагер!

Нәкъ менә шушы тантаналы мизгелдә үр өстеннән ачы бер тавыш яңгырап колакларны кисте.

— Карагыз, карагыз! Күкчәтаудан ярчы килә!

— Ярчы?!

— Гонец!

Бөтен кешегә дә ишетелерлек булып күк күкрәде. Әле генә сөенечле чайкалып торган халык диңгезе тып-тын булып калды. Бәйге онытылды. Атлар сабан туй колгалары янынннан агылып уздылар. Халык тетрәнеп, тынсыз калган Күкчәтау юлындагы ялгыз атлыга төбәлде. Анда карагер атка атланган казак чабып килә, аның кулында баш өстеннән биек күтәрелгән колга — сөңге! Сөңгедә кызыл әләм! Тояклары белән җир селкетеп узган чабыш атларын халык күрмәде дә бугай, бөтен игътибар башка якта — Күкчәтау юлында. Кызыл әләмле казак якынлашканнан-якынлаша, аның әләме ут булып яна, һәм һәрбер казакның йөрәгенә ук булып кадала. Чөнки һәрбер казак бала чактан ук белеп үсә — сөңге очындагы кызыл әләм — ил өстенә килгән бәла турында хәбәр-яр! Әле узган кыш кына беренче разрядларны озаткannar иде, тагын нинди афәт килә икән?!.

— Сугыш!

— Гомуми мобилизация!..

*Ахыры бар.*

## Зәки Нури

# ЯРАТАМ, ЯРАТМЫЙМ...

(Төрле еллар дәфтәрләреннән)

## Давыл купкач

Кичә күктә йолдыз бик күп иде.
Шулар мәллә бар да ташланды
Безнең өскә? Юк, юк... Давыл килде...
Ут сулыйсы көннәр башланды...

Җир һәм күкне болыт булып каплап
Ят танклар гүли, ят кошлар.
Окобымны иште мина шартлап...
Җан тетрәткеч авыр чак... Дошман.

Чигенә халык — ут кысрыклый дулап.
Ул куркак та түгел, качкын да —
Фашист белән бергә һава сулап
Кала алмый бер күк астында.

«Күченергә! Әмәл табарга!» дип
Уйлый төсле хәтта урманнар.
Көнчыгышка бары агарга дип
Ярдан ташып сулар тулганнар...

«Кызган безне, кызган, нәни хуҗа,
Ал безне дә — сыйдыр кочакка!»
Шулай диеп гүя кулын суза
һәм ялвара елап курчак та.

...Туп бик кызды. Бераз сулыш алсын,
Күләгәңә яшер, тал-тирәк.
Ал син, каләм, әйдә син ал сүзне,
Әйтереңне җырга сал, йөрәк.

Икегез дә әле исән-имин,
Рәхмәт яусын — әле төзекләр.
Керсен, Җиңү, олы Поэмаңа
Утта туган нәни өзекләр!

...Юк, онытылмас болар — әкияттәге
Тәмуг ялкынына тиң утлар.
Төпкелендә булып шул упкынның
Телсез-өнсез калган минутлар.

*1941, 22 июнь.*
*Валилы урманы (элекке Белосток өлкәсе).*

## Бер шигырь белән гәпләшү

...Тудың син тып-тын окопта
Тупларга аваз биреп.
Кайнар тир түктең походта
Утлардан утка кереп.
Мең бәхеткә тиендек без
Бер юлдан бергә йөреп.

Син ул, син мине юаттың
Иң-иң авыр чакларда.
Әгәр кирәксә, өйрәттең
Бомба булып шартларга,
Яки тын да чыгармыйча
Тешне кысып атларга.

Ә курку-шүрләүне гүя
Җәһәннәмнәргә кудың.
Бәлки мин булмас та идем,
Ярый әле син тудың.
Рәхмәт сиңа, җырым-бәгырем —
Угым минем һәм тубым!

*1942.*

## Кыз хаты

Киттең, иркәм, ерак-еракка,
Илебезнең чиген сакларга.
Шәүләң синең һаман йөрәктә,
Йөрсәң дә син кайсы якларда!

Сурәтеңә карап туялмыйм —
Теркөмештәй тере күзеңә.
Сүзләремнең агышын тыялмыйм,
Җырлар булып алар тезелә.

Рәхәт була сине уйласам,—
Хезмәтемдә армам-талмам мин.
Юлларымда давыл уйнаса,
Аптырап һәм куркып калмам мин.

Илем имин. Чөнки син сакчы! —
Һәр минутта шуны белермен.
Булырсыңмы минем илһамчым —
Сәлам-хатың көн дә килерме?!

*1946.*

## Соклану

Күзләре зәңгәр күл кебек,
Керфекләре — яшел яр.
Әйтерсең, алар төбендә
Сүнмәс утлы яшен бар.

Шул уттан бозлар эрер дә
Сулар кибәрдер кебек...
Булсын иде барча күздә
Шундый чибәрлек күреп!

*1985.*

## Бәхет йолдызы

Борынгының зирәк бер сүзе
Күптән таныш җирдә күпләргә:
Кеше туса — аның йолдызы
Калка, диләр, балкып күкләрдә.

Яна, диләр, һаман яктырып,
Бер балкыса — сүнми вакытсыз.
Кабынмаса шундый яктылык,
Кеше, диләр, була бәхетсез...

Безнең өчен шундый йолдызның
Октябрьдә туды балкышы.
Бәхетебез, диеп, мул безнең,
Шул йолдызга карый бар кеше.

Нурын сибеп ерак-еракка,
Яктырта ул барыр юлларны.
Дәрт сала ул безнең йөрәккә,
Талмас итә эштә кулларны.

Күңелләрдә балкый ул безнең,
Балкый күктә, балкый ааләмдә.
Без үзебез ясап йолдызны
Җибәрәбез хәзер галәмгә.

*1976*

## Шулай кирәк

«Айны бир дә, кояшны ал» диеп,
Кемдер әйтсә — ничек карарсың?
Шундый комсыз була белсәң әгәр,
Дөньяда син кемгә ярарсың?!.

Ишеткәндә берәү елаганны,
Юат аны якты елмаеп.
Кемдер шашып, чиктән ашып көлсә —
Бүлдер аны үзең моңаеп.

Төсең итеп, кайнар хисең итеп
Кешегә син җылы бүләк ит,
Нурың белән яктырт аның юлын,
Шатлыкларын аның күбрәк ит.

Күбрәк күтәр юлда заман йөген,
Бүтәннәргә шуны гыйбрәт ит.
Үзең соңгар, дустың алга узсын —
Тик шундый бул! Шулай кирәк бит...

*1976*

## Бөре ачылганны күреп

Куанып котларга
Тиешсең син, күңел,
Нәп-нәни, йом-йомшак
Бу бөре эчендә
Яфраклар шавын да,
Чәчәкләр ямен дә,
Күзнең мул сыен да,
Күкрәүләр көчен дә.

Ул — бәбкә, Мамыклы.
Ул — елтыр соры күз.
Карашын юнәлтә
Гел кояш ягына.
Ул — тере: тылсымлы
Көйләрен тын көйли,
Җир көчле булсын дип
Күкләргә табына.

Әйт, күңел, бөрегә:
— Кодрәтең кадерен бел,
Һәрвакыт бул кыю,
Һәркайчан — мул, эре!..

Җырыңа исә әйт:
— Бул син дә бөредәй —
Көч тудыр, нур балкыт...
Ил буйлап юл йөре!

*1978.*

## Бер басканда биш адым

Әйтте үзенә: «Изүне
Чиш, җиңне сызган да! — дип,—
Заман авыр эшкә җигә,
Үзеңне кызганма!» — дип.

Яу юлын кара төндә дә
Якты дип күзаллады,—
Абынган-сөртенгән чакта
Үзен һич кызганмады...

Шундыйдыр алар — бер басып
Биш адым атлаучылар,
Уттан чыгып суга кергән
Юлда сынатмаучылар.

*1981.*

## Тезләнүләр

Тезләндем мин, дуслар, бик-бик сирәк,
Изге антым санап барсын да:
Сәфәрләргә киткән-кайткан чакта —
Башым иеп әнкәм каршында.

Бер тезләндем, кысып үбәр өчен
Байрак читен учка алдым да,—
Ватаныма тугры булырмын дип
Вәгъдә бирдем полкым алдында.

Ә бер чакны тәүге гыйшкым төшкән
Гүзәл кызга чәчәк өзәргә
Кайнар сулап янә бер тезләндем
Тормыш юлын, димәк, бизәргә.

Тезләндем мин һәм тезләнәм һаман
Саф чишмәләр суын эчәргә —
Туры килсә юлда арып-талып
Ерак араларны кичәргә.

... Тезләнү ул — чүгеп алу түгел
Чуккан сыман бию остасы.
Тезләнү ул — кыйбла сайлый белү
Адашмаулар өчен, кыскасы.

*1983.*

## Тыйнаклыкның төсе

Син — бөре: чәчәк туганчы
Яшел яфрак ярасың.
Бер күргә җанга якын
Булып истә каласың.

«Мин» дип тә син лаф ормыйсың,
Гүя бар да, юк та син.

Ап-ак карда, без походта
Яккан алсу утта син.

Очратты төрле юлларда
Сине күңел-эзтабар...
Бер салават күпереннән
Синдә барча төс тә бар!

*1981.*

## Яратам, яратмыйм...

Ялкаулана башлыйм икән
Үземне үзем яратмыйм.
Тик шәрә түшәмгә карап
Язган җыр сүзен яратмыйм.

Таң сүзендә зур якты бар,
Булмый караңгы, кара таң.
Күңелләрне балку итеп
Яктырган таңны яратам.

Дуслар куанычын яшен
Тизлеге белән таратам:
Шулай кирәклеген беләм,
Шулай яшәүне яратам.

Ләйсән яудырмаса әгәр
Язгы яшенне яратмыйм.
Моннан биш ел элек булган
Алтмыш яшемне яратмыйм.

Урманда: — Саумы, иманнәр?!
Саумы, яшь буын нарат?! — дим.
Урманны тыңлый белмәгән
Туң йөрәкләрне яратмыйм.

Күпләр белән юл йөрермен,
Атлармын юлны яратып:
Күңел компасым куелган
Кояшлы якка каратып!

*1985.*

## Галимҗан Латыйп

### Бик кадерле бит ул туган туфрак

Туган җирдән аерылса кеше,
Өч-дүрт адым саен бер абынган;
Эчкән суым, туган туфрагым дип,
Төшләрендә күреп гел сагынган.
Бик кадерле бит ул туган туфрак!

Ил-көннәрнең бәйсезлеге өчен
Күпме күз яшь, кайнар каннар тамган.
Батырлар һич аямаган җанны,
Үзе утта дөрләп янса янган.
Зәңгәр ялкын булып балкып калган...

Кошлар кайта диңгез артларыннан,
Оя корып, бала очырырга.
Күзләр җитсә, килми китәселәр:
Нәсел-нәсәбәнең очы монда.
Бик кадерле бит ул туган туфрак!

Галәм киңлегенә очты кеше,
Очты җирдән бер уч туфрак алып,
Йолдызларга кадәр күтәрде ул,
Чыра яккан Россиянең данын.
Бик кадерле бит ул туган туфрак!

Әткәм, әнкәм изге туфрагын
(Киткән чакта дөнья сагыннан),
Баш астына ястык итеп салган,
Юрган итеп өстенә ябынган.
Бик кадерле бит ул туган туфрак!

### Әйләнәбез бер боҗрада

Туктале дим, ерак юлдан кайтып кергәч,
Бер сафланыйм, рәхәтләнеп мунча керим.
Аннан минем әнкәемнең кулы тигән
Әйберләрне тотып-тотып карап йөрим.

Алар минем шатлыкларым, кайгыларым,
Гомерем буе онытылмас сагышларым.
Шушы җирдә яши минем ярты җаным,
Кире кайтмас югалтулар, табышларым.

Бабам безгә кат-кат тукып әйтә иде:
— Сез бу җирне онытмагыз, оныкларым.
Әйтеп куям: ни барлыгы, ни юклыгы
Эчкән суын — Туган җирен онытканның...

Кайтам да мин, ата-баба эзләренә,
Истәлекләр белән балкып, басып йөрим.
Моңа кадәр ачылмаган ишекләрне
Яңа дөнья ачкан кебек ачып йөрим.

Сораштырам, югалганны эзлим, табам,
Хәтеремне терелтәм дә, гел яңарам.

Исән әле сукмаклары малай чакның,
Офыклары балкып тора, һаман якты.
Учак яктым ат ашаткан үзәнемдә,
Һаман да Ай бер ялгызы йөзә монда.
Урады да кайтты кинәт малай чагым,
Тик ишетмим күрше авылның чиркәү чаңын...

Үзгәрешләр шактый монда, зурдан монда,
Әйләнгәннәр хыялларым җитди җырга.

Ата-баба кайтып күрсә бу тирәне,
Канатланып, исе китеп сөйләр иде...

Бер карасаң, дөнья — олы сабан туе,
Әйләнәбез бер бождрада гомер буе.

❁

Кош булып та очалмаса,
Кошмыни ул?
Эшең булып эшләнмәсә,
Эшмени ул?

Теләгең эшкә ашмаса,
Теләкме ул?
Киләткә ашлык кермәсә,
Киләтме ул?

Иелгәнне кылыч кисми,—
Кол язмышы.
Горур башка кылыч үтми,—
Ил язмышы.

Батырларга халык мәрмәр
Һәйкәл куя.
Исемнәрен алтын белән
Язып уя.

Озак яшәп, яшьнәмәсәң,—
Гомерсезлек...
Аз яшәп тә янып калсаң,—
Үлемсезлек!

## Бәхетле кеше

Китабын кочаклап йоклый ул,
Китабын кочаклап уяна.
Җанына кагылса яктылык,
Мөкиббән китә ул дөньяга.

Син аның кулына китап бир,
Тик булсын китапның яхшысы.
Калганын ул үзе хәл итәр,
Бар аның тылсымлы ачкычы:

Һәр эшне эшли ул үз итеп,
Бирелеп,
яратып,
нурланып,
Ни тотса,
ул шуны булдыра,
Һичшиксез сәләте зур аның.

Дәртне дә, көчне дә ала ул
Тормыштан,
белемнән,
кояштан.
Чөнки ул үзенең җанына
Сөремсез, ахактай ут яккан.

Күңеле диңгездәй киң аның,
Ә диңгез ул ләмле буламы?
Бары тик яктылык чәчәргә
Тиеш бит бәхетле ир җаны.

Бәхет ул — зур байлык кемгә дә,
Бәхет ул — яктылык, җан җыры.
«Мин» дигән кояшка табынмый,
Белә тик нурланып януны!

## Иярле ак атын уйнатып

Агачтан яфраклар коелган,
Кырлардан җыясы җыелган.
Түбәсен күкләргә тидереп,
Кышка дип эскертләр куелган.

Кара пар өстендә яшь уҗым,
Чәүкәләр төштеме, күмелә...
Яреннең көшеле өстенә
Әбиләр чуагы түгелә.

Сөенә күңелләр, сөенә,
Ялкынлы хисләрне уятып...
Шатлыгым тәгәри кырлардан
Иярле ак атын уйнатып.

## Чәчәкләр таратам

Гөлләргә су сибәм,
Үстерәм.
Аларга җан җылым
Күчерәм.

Ансыз бит ышыксыз
Таш кала.—
Матурлык төсләрдән
Башлана.

Дөньяга бәбиләр
Туса да,
Туйлар һәм бәйрәмнәр
Булса да,

Һаман да чәчәкләр
Таратам...
Кешеләр, мин сезне
Яратам,
Яратам,
Яратам!

## Җыялар

Юкә чәчәге җыялар
Әбиләр.
Таудан мәтрүшкә җыялар
Әниләр.

Гомер чәчәге җыялар
Бәбиләр,
Сөте тулы күкрәкләргә
Ябышып...

Картлыгында кемдер җыя,
Яшьлектәге
Ялгышын.

**Илдар Юзеев**

# ОНЫТЫЛМАС БӘЕТ

ИКЕ БҮЛЕКЛЕ ДРАМА

**КАТНАШАЛАР:**

Хәтимә — тегермәнче кызы.
Шаһинур — пенсионер, 70 яшьтә; 2-5 нче күренешләрдә 30 яшьтә.
Вәдүт — 70 яшьтә; 2-5 нче күренешләрдә 30 яшьтә.
Мөнирә — сатучы, 34 яшьтә.
Энҗе — Мөнирәнең кызы, 16 яшьтә.
Алмаз — студент, 18 яшьтә.
Ак бабай.
Ак әби.
Кара карчык.
Авыл халкы.

Вакыйга — 2-5 нче күренешләрдә 1945—1946 елларда, башка күренешләрдә безнең көннәрдә бара.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Беренче күренеш

**Бер якта иске тегермән, икенче якта — яңа өй. Өй янында карт карама. Янәшәдә — каен үсеп утыра. Яр буенда — басма. Еракта, олы юлга алып чыгулы юл, елга күренә. Карт карама янында Ак бабай, Ак әби басканнар. Ял итәргә җыелган яшьләр җыры ишетелә.**

Онытылган җыр шикелле
Тынып калган тегермән.
Сөймәсәң — бик исем китми,—
Артларыңнан йөгермәм.
Карамалы, Карамалы,
Каенлы, карамалы.
Тегермәннәрен узгач та,
Әйләнеп карамалы.

Ак бабай. Безнең авылның исеме — Карамалы. Картлар тикмәгә генә шундый исем бирмәгәннәр... Һай, заманалар, яшь чакта, тар урамнарны киңәйтеп, җырлап уза торган иек... Ничек әле?... *(Ак әби белән бергә.)*

Исеме генә түгел, аның
Җисеме — Карамалы.
Бөгелмәде, кемнәр генә
Тырышып карамады. Их!..

Ак әби. Нигә тынып калган иске тегермән янына килдегез дисезме?

Ак бабай. Борын-борыннан калган җыелу урыны инде бу.

Ак әби. Һәр авылдашның тормышы шушы тегермән белән бәйләнгән.

Ак бабай. Элек-электән җыен-сабантуйлар монда уза. Их, яшь чаклар!

Ак әби. Карты-яше дә, бала-чагасы — бөтен авыл, дәррәү кубып монда җыйнала торган ие. Әй, заманалар!

Ак бабай. Изге ниятлеләрне без һәрчак якты чырай...

Ак әби. ...такта чәй белән каршы алабыз.

Ак бабай. Карамалының ташка басылмаган үз кануннары бар. Кайгы яисә шатлык туганда — бер җанга, нәфрәт туганда — бер

йодрыкка әйләнә торган холкы бар безнекеләрнең.

Ак әби. Яхшыга — күк кояшы, яманга — тегермән ташы безнекеләр!

Ак бабай. Тегермән хәзер тынып калган...

Ак әби. Ничәмә еллар әйләнгән-әйләнгән дә туктаган. Халык өчен көрәшеп егылган баһадир сыман...

Ак бабай. Сүттермичә саклыйбыз. Картларга — ядкарь, яшьләргә — гыйбрәт!

Ак әби. Күпме вакыйгаларның телсез шаһите... Карамалы тегермәне бәеткә дә кереп калган.

Ак бабай. Тсс... Шаулама. Без ул бәетне телгә алмаска дип карар кылдык.

Ак әби. Әмма авылыбызда булган бер вакыйга аны гел искә төшереп тора.

**Кара карчык керә.**

Кара карчык. Ишеттегезме?.. Теге кыңгыр эшне тикшерергә килӛләр, ди.

Ак бабай. Туктале син, ашыкма... Узган елларга кайтыйк... *(Бәет әйтә.)*

Карамалы буйларының
Язы — шаулы, җәе — тын.
Без әйтәбез, сез тыңлагыз
Хәтимәнең бәетен...

## Икенче күренеш

**Тегермән. Көз. Кич. Яшьләр җыры. Өенә керешли Хәтимә җырлап уза.**

Киң болында колын сыман
Чапкан чагым, хуш инде.
Уйный-уйный куанычлар
Тапкан чагым, хуш инде.
Йөгереп тә җитәлмәгән
Хыялларым, хуш инде.
Башкаемны хыялыма
Куялмадым, хуш инде.
Беләм, йөрәкне яндырып
Калачагын, хуш инде.
Моңсуланып озата барган
Балачагым, хуш инде.

*(Хәрби кием кигән Шаһинур кереп, җырны тыңлап тора.)*

Шаһинур. Хәтимә... Синең моңлы тавышыңны ерактан ишетү дә минем өчен зур бәхет. Кайтып барышлый, бәлки, гәүдәңне булса да күреп калырмын дигән өмет белән килдем. *(Тәрәзәгә бара. Чигенә.)* Ярамый... Соңладың, Шаһинур! Мәңгегә йолкып ат Хәтимәне йөрәгеңнән... Кит! Югал!.. Оныт!.. *(Китәргә кузгалганда Хәтимә чыга.)*

Хәтимә. Кем бар анда? Вәдүт абый, синме?

Шаһинур. Хәтимә? *(Борылып.)* Исәнме, Хәтимә?

Хәтимә. Шаһинур абый?! Сезне бит...

Шаһинур. Исән, Хәтимә! Ватан сугышы инвалиды... Хәтимә, нигә минем хатларга җавап язмадың?

Хәтимә. Ачуланмагыз инде, Шаһинур абый...

Шаһинур. Әмма шулай да, Хәтимә, сугышта, тәмуг утлары эчендә, өскә аждаһадай фашист танкы сытам дип килгәндә, мин синең йөзеңне алдымда күрә идем. Госпитальдә яраларым сызлаганда сине уйласам, җиңел булып китә иде...

Хәтимә. Шаһинур абый...

Шаһинур. Бер сүз дә дәшмә... Узган язлар искә төште... Мәктәптә укыганда, Карамалыдан килеп, сезнең өйдә яшәгән онытылмас көннәр... Язгы юл төшү белән ялан-аяк йөргән тегермән буасы... Урманнан иң беренче умырзаяларны җыеп кайткан Хәтимә... Без су чәчрәтеп уйнаган буа... Их, Хәтимә... Йөрәктәгене әйттем... Инде китәм...

Хәтимә. Туктагыз... Эти-әниләр янына кермисезмени?

Шаһинур. Ашыгам, Хәтимә, төн булганчы Казилегә кайтып җитәргә кирәк. Әни карчык көтәдер... Сау бул, Хәтимә! *(Үзенең һич тә китәсе килми.)* Хәтимә, нигә җырың бик кайгылы?

Хәтимә. Юк... Болай гына... Кинәт кенә яшьлегем узган кебек булып китте...

Шаһинур. Һич тә үзгәрмәгәнсең. Һаман шулай каеннар арасыннан авылга таба, башың артка ташлап чабасыңдыр...

Хәтимә. Юк инде... Минем яшьлегемнең хуҗасы бар...

Шаһинур. Беләм. Вәдүт.

Хәтимә. Әйе. Барысы да хәл ителгән.

Шаһинур. Ни әйтим, Хәтимә... Бәхетле бул... Хуш!.. *(Үзе китми.)* Шулай да, үтеп барганда гына булса да, күрергә рөхсәт ит, Хәтимә?

Хәтимә. Килә күрмәгез, Шаһинур абый... Хушыгыз...

Шаһинур. Хуш, Хәтимә... *(Кузгала.)*

Хәтимә. Туктагыз...

Шаһинур. Хәтимә...

Хәтимә. Шаһинур абый... Инде китегез... *(Шаһинур чыга. Гармунда уйнап-җырлап ярым хәрби киемнән Вәдүт керә.)*

Вәдүт. Яндырасың, көйдерәсең,
Сөю учакларында.
Янып үлсәм дә үкенмим
Синең кочакларыңда.

Хәтимә! Киттек уенга!

Хәтимә. Әй лә, кәефем юк бүген...

Вәдүт. Булыр, Хәтимә! Минем бүген бөтен дөньяга кычкырасы, бөтен җирләрне селкетеп биисе, барлык халыкны шаккатырып җырлыйсы килә! Тәк, димәк, дүрт ел сугышта йөреп, бозлы окопларда ятып, ут елгасында агып, мин исән калдым! «Атка менсән, сикереп мен, бөдрә чәчең селкенсен», — дип рәхәтләнеп җырлап булмый анда, Хәтимә, сугышта. Утыр әле...

Хәтимә. Күп авырлыклар күргәнсеңдер, Вәдүт абый, кара бөдрә чәчләрегез аксыллана, сирәгәя төшкән...

Вәдүт *(Хәтимәне эскәмиягә утырта)*. Утыр әле яныма... Искә төшерсәң, коелган чәчләрем үрә тора! Дүрт ел коноюх булып, ат тизәгенә батып йөрдем... *(Үзен кызган-*

*дырырга тырышып).* Мена шулай, Хәтимә... Бу чәчләремнән мине беркем дә иркәләмәде. Үтенәм: бер генә сыйпа шушы нужалар күргән башкаемны...

Хәтимә *(иркәләп).* Бичара... *(Күзеннән яшьләрен сөртә.)*

Вәдүт. Рәхмәт, җаным. Анда мине кызганучы шәфкатьле җан булмады... *(Сикереп торып.)* И шуны белдем, Хәтимә, мин үземне синең өчен саклаганмын икән. Үлемнең күзенә карап торганда, нәзер әйткән идем, тәк, димәк, мәнә шушындый: әгәренки шушы тәмуглардан исән-сау кайтсаммы, калган гомеремнең кадерен белеп, дөньяның рәхәтен күреп яшәр идем. И шуның өстенә авылның иң мировой кызын алыр идем, дип. И шулай булды: син — минеке!

Хәтимә. Вәдүт абый...

Вәдүт. Сугыш бетте! Авырлыклар-газаплар шуның белән вәссәләм! Яхшы бел, Хәтимә, и ышан: моны бывший фронтовик, сельпо председателе Сөләйманов әйтә! Мәнә бирегә каен төбенә бас әле... Шәп! Мин күрдем ярты дөньяның чибәрләрен, тәк, димәк, үзебез җиңгән немкаларны да, алар асыл кием белән күзнең явын алалар иде, ләкин бит без җиңдек! Мә, матурым, бәйли тор бу бүләк яулыкны! *(Кыр сумкасыннан яулык ала.)* Бәйлә!

Хәтимә. Кирәкми, Вәдүт абый, кирәкми...

Вәдүт. Бары сиңа гына килешә! Ал! *(Бәйли.)* Киттек уенга! Синең өчен мин таң атканчы уйныйм, җырлыйм, биим, Хәтимә!

Хәтимә. Мин бүген баралмыйм, ачуланма...

Вәдүт. Туктале, тукта... Нигә төсең киткән? Әле генә монда кем булды? Аксый-аксый киткәнен күреп калдым.

Хәтимә. Шаһинур абый...

Вәдүт. Шаһинур? Кызык... Нигә миңа сельпога кермәгән икән?..

Хәтимә. Госпитальдән чыккан. Шундый ябыккан...

Вәдүт. Кызганасың? Мәнә ни өчен кәефең киткән икән... *(Үпкәләп.)* Мин сине аңламыйм, Хәтимә!

Хәтимә. Бер дә аңа түгел... Вәдүт абый... Әйтсәм әйтим инде... үзем дә белмим... сөенергәме...

Вәдүт. Әйт!

Хәтимә. Әйтергә дә оялам... Син әти булырсың кебек...

Вәдүт. Ә? Ничек?

Хәтимә. Сизәм...

Вәдүт. Мин алай тиз булыр дип уйламаган идем...

Хәтимә. Вәдүт абый?..

Вәдүт. Чын булса, бер дә борчылма, асылым, син — мәңге минеке!

Хәтимә. Язылышыйк, Вәдүт абый...

Вәдүт. Язылышу качмый, яшьлек качар, Хәтимә! Әйдә, яшьлек белән исәнләшеп, туйганчы бер җырлап-биеп килик әле! *(Уйнап-җырлап чыга. Хәтимә ияра. Караңгылана. Кара карчык белән Ак әби узалар.)*

Кара карчык. Ишеттегезме, ишеттегезме? Шаһинур бүлнистән кайтышлый Хәтимәдә кунып чыккан, ди. Вәдүт сизми калган, ди, имеш... Хәерлегә түгел бу, ходаем, үзең сакла!

Ак әби. Үз күзең белән күрмәгәнне чын булса да сөйләмә, ди. Кара гайбәт чәчеп йөрмә!

Кара карчык. Ишеттегезме, ишеттегезме?! *(Чыгалар.)*

## Өченче күренеш

**Ак бабай тавышы ишетелә.**

Күз дә җитте, кыш та үтте, -
Хәтимәкәй, ашкынма.
Гамьсез шашкан яшьлегең дә
Күмеләдер ташкынга.

Чәчләреңне җилфердәтеп
Йөрерсең дә эзеннән.
Җитәлмәссең яшьлегеңә
Барасы юл өзелгән...

Хәтимә *(авыл ягына, юлга карый).* Атка атланган кемдер килә! Һай! Батасың! Кызыл тау буеннан әйләнеп кил! Вәдүт абый түгелме соң бу? Вәдүт абый? Атын агачка бәйләде... Вәдүт абый! *(Каршысына йөгерә.)*

Вәдүт *(ашыгып керә, кулында — кыр сумкасы, чыбыркы).* Хәтимә... кычкырма... акрын...

Хәтимә. Ни булды, Вәдүт абый? Төсең киткән.

Вәдүт. Тсс... Әти-әниләрең өйдәме?

Хәтимә. Юк, кичтән үк күрше авылга кунакка киттеләр. Юл өзелеп кайталмаганнардыр. Әйдә, өйгә керик!

Вәдүт. Вакыт юк, Хәтимә, ашыгам!

Хәтимә. Караңгылы-яктылы, иртә таңнан кая барасың?

Вәдүт. Хәтәр юлга чыгам, Хәтимә...

Хәтимә. Кая?

Вәдүт. Районга.

Хәтимә. Районга? Юллар өзелгән бит, Вәдүт абый...

Вәдүт. Бәлки әле барып та җитәрмен.

Хәтимә. Юк, беркая да җибәрмим... Күңелем нидер сизеп, төне буе йокламадым.

Вәдүт. Минем дә күңелем нәрсәдер сизгән сыман... Уйлама, Хәтимә, мине ташкыннан курка дип, син мине беләсең... бүреләрдән дә курыкмыйм...

Хәтимә. Кемнән куркасың?

Вәдүт. Кешеләрдән! Юл басулары ихтимал! Серемне ачыйм инде сиңа гына *(кыр сумкасын күрсәтеп).* Миңа шушыны, тәк, димәк, бүген үк районга илтеп тапшырырга кирәк...

Хәтимә. Ташу вакытында, төнгә каршы... Юк, җибәрмим!

Вәдүт. Онытма шуны: мин кавалерист! Югалмады Вәдүт и югалмас! Суга батса да калкып чыгар! Син шуны бел: исән-сау калсам, бездән дә бәхетлеләр булмас... Мин сине калага алдыртырмын. Күп интектек, җитәр, әле сугыш, әле ачлык... Кешеләрчә яшәргә вакыт — и вәссәлам! Ә инде кайталмасам...

Хәтимә. Кайталмасам?.. Ә мине... безне... шул килеш ташлап китәсеңмени?

Вәдүт. Кем әйтте әле мин ташлап китәм дип... Кайтам, җаным. Ышанмасаң, менә балдак... *(Бирә.)* Әйдә, киттек! Ни күрсәк тә бергә күрербез. Атлан ияргә!

Хәтимә. Кая? Нигә? Мин беркая да китмим!

Вәдүт. Ах, булмый шул... Юл куркыныч... Кайгырма, Хәтимә, насыйп булса, бергә булырбыз...

Хәтимә. Насыйп булмаса?

Вәдүт. Насыйп булмасамы?.. Бер генә юл кала: бәхил бул, Хәтимә! И шуны сорыйм синнән: кем генә сорап килсә дә, минем монда булганны әйтмә! Төшендеңме? *(Кочаклый.)* Сау бул! *(Чыга.)* Сау бул!

Хәтимә *(хәлсезләнеп, ул киткән якка ташланып).* Вәдүт абый!.. *(Эскәмиягә барып егыла, шәле иңнәренә шуып төшә.)* Китте! Китте...

**Ак бабай тавышы ишетелә:**

Вәдүтнең киткән юлларын
Сулар юган — эзе юк.
Телләре юк аңлатырга,
Аты кайткан, үзе — юк.

*(Шул ук сәхнә. Эскәмиядә — Хәтимә.)*

Шаһинур *(керә. Хәтимәне күреп).* Хәтимә? Синме бу? *(Янына барып.)* Нишләдең син? *(Шәле белән башын ябa.)* Әйдә өеңә... Ни булды сиңа?

Хәтимә *(сиздермичә).* Әллә нигә башым әйләнеп китте... Шаһинур абый...

Шаһинур. Сиңа ни булды?

Хәтимә *(кинәт хәле авыраеп).* Ой! *(Һуштан язып егылганда, Шаһинур тотып кала.)* Шаһинур абый... Миңа авыр... Ярдәм итегез...

Шаһинур *(аңлап ала, башта югалып кала).* Әйдә, Хәтимә, кереп ят... *(Җитәкләп өйгә алып керә. Аннан Хәтимәнең үзәк өзгеч тавыш белән кычкырганы ишетелә. Шаһинур атылып чыга. Узып баручы Кара карчыкка.)* Әби, зинһар өчен ярдәм ит... анда Хәтимә... бала таба!

Кара карчык. Алла сакласын! Шаһит булып судка йөрер хәлем юк! Юлымда булам, мин күрмәдем, ишетмәдем... Бозылды дөнья, ахыр заман якынлаша... Алла сакласын! *(Чыга.)*

Шаһинур. Тфү! *(Ерактан бер әбине күреп.)* Әби! Кил әле монда! *(Ак әби белән Ак бабай керәләр.)*

Ак бабай. Ни булды, улым Шаһинур?

Ак әби. Мине дәштеңме, балам?

Шаһинур. Кендек әби, ярдәм ит!

Ак әби *(Хәтимәнең кычкырганын ишетеп).* Хәзер, балам, бер дә борчылма... Бәхете белән дөньяга килсен... *(Кереп китә.)*

Ак бабай *(бәет әйтә):*

Хәтимәнең мамык шәле
Муенына уралган.
Хәтимә бала тапканда,
Вәдүт китеп югалган.

Хәтимәнең чәч толымын
Үрдереп озайтканнар.
Хәтимәне авыр хәлдә
Булнискә озатканнар.

## Дүртенче күренеш

**Яктырганда — башта Хәтимәнең, аннан Шаһинурның йөзләре күренә.**

Шаһинур. Хәтимә... Бу мин — Шаһинур.

Хәтимә. Шаһинур абый... кил... якынрак...

Шаһинур. Килдем. Хәлең ничек, Хәтимә?

Хәтимә. Больницага син китердеңме?

Шаһинур. Әйе.

Хәтимә. Вәдүт абый турында нинди хәбәрләр бар?

Шаһинур *(әйтмәскә тырышып).* Борчылма, Хәтимә, әлегә әллә ни юк...

Хәтимә. Үтенәм... дөресен әйтегез... Мин белеп китәргә тиеш...

Шаһинур. Ревизия тәмамланган. Материаллар тикшерү органнарына тапшырылган.

Хәтимә. Тикшерү?

Шаһинур. Әйе. Югаласы көнне Вәдүт, халыктан җыелган зур суманы алып, банкка тапшырырга дип киткән. Ул кичне сезгә килгәндә мин дә аны күреп калдым. Шул китүдән юкка чыккан. Сөендек авылы янында буш сумкасы гына табылган...

Хәтимә *(өмет-курку белән).* Димәк, аны бандитлар талаганнар?..

Шаһинур. Башкача булуы да ихтимал.

Хәтимә. Шаһинур абый... Вәдүт абый турында яман хәбәр кайтса, кызыма әйтмә... Күңелендә әйбәт булып калсын... Талаганнар дигәне дөрескә чыга күрсен... Кызыма да шулай диярсең. Якынрак кил...

Шаһинур. Тыңлыйм.

Хәтимә. Күңелем тоя. Мин ялгыштым...
Ялгышырга өлгерсәм дә,
Яшәргә өлгермәдем,
Умырзаядан да кыска
Булды шул гомерләрем.

Шаһинур. Минә терелерсең. Бергәләп каен җиләге җыярбыз...

Хәтимә. Мин инде баралмам шул, Шаһинур абый... Мин китәм.

Шаһинур. Кая китәсең, Хәтимә?

Хәтимә. Мәңге кайтмыйм торган җиргә.

Шаһинур. Юк, китмисең, Хәтимә, китмисең!

Хәтимә. Тагын да якынрак кил, абыем...

*(Шаһинур иелә.)* Хәтимәдән ятимә кала. Ата бул кызыма. Минә аңа миннән ядкарь итеп тапшырырсың... *(Балдагын салып бирә.)*

Шаһинур. Китмә, йомма күзләреңне, Хәтимә!..

Ак бабай.
Сабыр холыклы Шаһинур
Сабырлыкларын җуйган,
Шәймәрдән абзый, Мәслихәттәй
Кайгыдан дөнья куйган.
Хәтимә сөйгән каенның
Тамыры корып калган,
Тегермәнченең өендә
Шаһинур торып калган.

## Бишенче күренеш

**Тегермән. Халык буа буарга өмәгә җыелган. Җыр ишетелә.**

Карамалы малаена
Чана карамаларга
Әйткән идем, әйткән идем
Чана карамаларга, һай, кара малай!
Карамалап чыгып киткән
Карама чаналарда
Чыгып киткән, чыгып киткән
Карама чаналарда, һай, кара малай!
Кара буран котырганда,
Карыйм карамаларга,
Юкка чыкты, юкка чыкты
Карама чаналарда, һай, кара малай!
Ап-ак бураннар эченнән
Карама чаналарда
Ап-ак хәбәр килер сыман
Бик якын араларда, һай, кара малай!

Ак әби. Карасана, әй халык! Буа буарга бөтен Карамалы чыккан. Тамак ач дип тормыйлар, җимертеп эшлиләр, уйныйлар, көләләр, җырлыйлар...

Ак бабай. Юлга күз салыйк әле. Яхшы хәбәр белән килүче-кайтучы юкмы?

Ак әби. Һай, Вәдүт, Вәдүт... Суга төшкән кебек югалды бит... Үтереп кенә ташлаганнардыр инде мескенкәйне...

Ак бабай. Төрле имеш-мимешләр йөри. Исән икән, качып йөри икән, фәлән-фәсмәтән, алла сакласын.

Кара карчык *(керә)*. Ишеттегезме?! Шаһинурны милиция алып киткән, ди, стенага мылтык белән терәп, сорау алалар, ди, башы Себер китәчәк, ди... Я алла, ахыр заман якынлаша, иманлы кеше калмады, дөньяны залим адәмнәр басты. Вәдүте дә шул, Шаһинуры да шул, берсе — бата, икенчесе — калка.

Ак әби. Өмет өзмә изгелектән, дөреслек калкып чыгар беркөнне...

Ак бабай. Шаһитлар да килеп чыгар әле, боерса...

Кара карчык. Я хода, үзең сакла, шаһитларның күзен капла. Әллә ниләр ишетерсең... Ишеттегезме әле?.. *(Такмаклап.)*
Куласалар әйләндерә
Тегермәннең ташларын,
Шаһинур гына ашады
Шул Вәдүтнең башларын...

Ак бабай. Үз күзең белән күрмәгәнне чын булса да сөйләмә...

Кара карчык. Бу бәетне җырласам да, чыгаручы мин түгел... Ишеттегезме әле, ишеттегезме?!

Ак әби *(юлга карап)*. Сөбханалла, үзе кайтып килә түгелме?

Ак бабай. Шул! *(Кычкырып.)* Карагыз, Шаһинур кайта! Шаһинур!

Халык тавышы:
— Шаһинур кайтты!
— Нинди хәбәр алып кайткан?
— Вәдүт кайда?
— Кайда ул үзе?

*(Йончыган, арыган кыяфәттә Шаһинур керә.)*

Шаһинур. Саумысыз, авылдашлар?
*(Тынлык.)*
Өмәләр котлы булсын!
*(Дәшмиләр.)*
Нигә дәшмисез?..

Халык тавышы:
— Вәдүт кайда?!
— Үлеме, тереме?
— Кибеттә тоз юк!
— Шырпы, керосин юк!

Шаһинур. Туганнар, тыңлагыз әле!

Халык:
— Син җавап бир халыкка!
— Җыйган акча кайда?!
— Үз авызыбыздан өзеп сельпога сөт, йомырка тапшырдык...
— Ул сумага ятимнәр өчен балалар йорты салырга килешенгән иде...
— Кем керде ятимнәр өлешенә?

*(Тавышлар тынган арада, өй эченнән бала елаган тавыш ишетелә, Шаһинур өйгә ташлана. Ак әби аңа биләүдәге баланы бирә.)*

Ак бабай.
Озата барасы микән,
Әллә каласы микән?
Тегермәндә бала елый,
Кемнең баласы икән?

Шаһинур *(кычкырып елаган баланы күкрәгенә кысып, халык алдына чыга)*. Елама, Мөнирә! Әттәң кайтты! Китмәскә кайтты! *(Халыкка.)* Вәдүт хакында әлегә беркем берни әйтә алмый. Җыйган акча да юк. Тикшерү дәвам итә. Сезгә билгеләнгән сельпо председателе буларак, мин шуны әйтәм: кибеттә тоз, керосин, шырпы булыр! *(Халык тын гына тыңлый.)*

Әмма сездән бер генә нәрсәне үтенеп сорыйм! Җырламагыз Хәтимә бәетен!.. Онытыгыз... Шушы гөнаһсыз сабый хакына... *(Тынлык.)*

## Алтынчы күренеш

Ак бабай. Утыз елдан артык вакыт узды...

Ак әби. Авылыбыз танымаслык булып үзгәрде.

Ак бабай. Җырлар да, биюләр дә башка... *(Яшьләр җырлый.)*

Онытылган җыр шикелле
Бер кайтырмын әйләнеп.
Артыңнан калмый йөрермен
Йөрәгеңә бәйләнеп.
Карамалы, Карамалы,
Каенлы, карамалы.
Тегермәннәрен узгач та
Әйләнеп карамалы.

Ак бабай. Хәтимә бәетен без инде бөтенләй оныта язган идек...

Ак әби. Авылыбызда булган бер вакыйга аны искә төшерергә мәҗбүр итте...

Кара карчык *(керә)*. Ишеттегезме, ишеттегезме? Теге кыңгыр эшне тикшерергә киләләр икән, ди, энәсенән җебенә тикле сорашалар икән, ди, бөтен тирә-як авыллардан тикшереп киләләр, ди, ходаем, үзең сакла, кыңгыр эш кырык елдан соң да калкып чыгар, ди. Дошманы кулыннан шаһит киткәннәр, кыямәт көнне күтәрелеп, сорау алырга тотынырлар, ди. Ходаем, үзең сакла, шаһитларның күзен капла...

Ак бабай. Коткы таратып йөрмә монда, Кара карчык! Күздән югал!

Кара карчык. Ишеттегезме, ишеттегезме? *(Югала.)*

Ак әби. Чын булып куя күрмәсен тагын...

Ак бабай. Күпме әйттем үзеңә: тишек капчыкка һәм Кара карчыкка ышанма, дип...

Ак әби. Кара, автобус килеп туктады!

Ак бабай. Бер егет туп-туры монда килә! *(Иңнәренә сумка, фотоаппарат, магнитофон аскан Алмаз керә.)*

Алмаз. Сәлам, Карамалы! *(Тегеләр бер-берсенә карашалар.)*

Ак бабай. Хәерле хәбәрләр алып киләсеңме, юлчы?

Алмаз. Бары тик! *(Фотоаппаратын алып, төшерә башлый.)* Һоп!

Ак әби. Хуш киләсең, балам! Әйдә безгә, чәй эчәрбез!..

Ак бабай. Ашыкма. *(Алмазга.)* Йола! Берничә сорауга җавап бирмичә, Карамалыга — капка ябык!

Алмаз. Сорагыз!

Ак бабай. Кем син, атың кем синең?

Алмаз. Студент. Алмаз. Экспедиция. Халык авыз иҗатын җыям. *(Тегеләр җиңел сулыш алып куялар.)*

Ак бабай. Максат?

Алмаз. Җыю.

Ак бабай. Нәрсә җыю?

Алмаз. Мәкаль, җыр, табышмак...

Ак әби. Шулаймыни, балам... Изге ният белән йөрисең икән, рәхмәт төшкере.

Ак бабай. Афәрин! Алай булса, сынап карыйк! Ачыдан ачы ни ачы?

Алмаз. Лимон... түгел. Кайгы.

Ак бабай. Без дә «кайгы» дияр идек.

Ак әби. Татлыдан татлы ни татлы?

Алмаз. Мороженое... түгел... Туган җир.

Ак әби. Без дә «туган җир» дияр идек.

Ак бабай. Нәрсәне сатып алып булмый?

Алмаз. Самолетны... түгел. Яшьлекне.

Ак бабай. Без дә «яшьлекне» дияр идек. Соңгы сөаль. «Сандык төбеннән төенчек алдым, чишеп карап, яңадан салдым» ни булыр?

Алмаз. Саклык кассасы... түгел. Үткәнне хәтерләү.

Ак бабай. Без дә «үткәнне хәтерләү» дияр идек.

Алмаз. Беттеме?

Ак бабай. Киңәш корыйк! Кабул кылабызмы?

Ак әби. Нияте саф баланың.

Ак бабай. Уе йөгерек. Тагын бер генә сорау. Син нишләп нәкъ менә Карамалыны сайладың?

Алмаз. Бәет...

Ак бабай *(сагаеп)*. Бәет?..

Алмаз. Бәет.

Ак бабай. Нинди бәет?

Алмаз. Хәтимә бәете.

Ак бабай. Кем әйтте?

Алмаз. Күршеләрегез.

Ак бабай. Юк сүз! Бездә бәет юк!

Ак әби. Тузга язмаганны сөйлиләр...

Алмаз. Бар. Язылмаган. Язам. *(Магнитофонын көйләп, Ак бабайга.)* Бабай, рәхим итеп җырлагыз...

Ак бабай. Булмаганны җырларга — башыма тай типмәгән!

Алмаз. Әби, җырлагыз, Хәтимә...

Ак әби *(куркып)*. Әстәгыфирулла! Берниндн Хәтимәне дә белмим!

Ак бабай. Студент! Ялгыш килгәнсең — бездә андый бәет юк!

Алмаз. Бар! *(Кызга.)* Әйтегез?

Ак бабай. Бәет юк! Кит!

Ак әби. Барыбер табалмассың!

Ак бабай. Безнекеләр — бер сүздә... файдасыз...

Алмаз. Китмим! Әзлим! Табам! Карамалы... һе! *(Кыю адымнар белән авыл ягына китә.)*

Ак бабай. Ай-яй-яй!..

Ак әби. Тикшерүче-фәлән була күрмәсен...

Кыз. Прокурордан да яман бу...

Ак әби. Хәерле генә булсын, бәла-казага юлыкмыйк!..

## Җиденче күренеш

**Тегермән буе. Уртада таган. Өстәл. Җитмеш яшьлек Шаһинур балык шулпасы пешерә. Тозын татып карый.**

Шаһинур *(көйли)*.

Карамалы, Карамалы,
Каенлы, карамалы,
Яшьлегем узды да китте,
Әйләнеп карамады.

Мөнирә *(кайтып керә)*. Сөенче, Шаһинур эти!

Шаһинур. Ни булды?

Мөнирә. Сәлимов этинең исемен телгә алды.

Шаһинур. Соң?

Мөнирә. Халык мәнфәгате өчен көрәшеп корбан булган Вәдүт Сөләйманов кебек каһарманнарны онытырга ярамый, диде. *(Шаһинурны кочаклап.)* Шаһинур эти... мин бу көнне... бу сүзләрне күпме көттем... *(Шаһинур дәшми.)* Тик ни өчендер Сәлимов синең исемеңне әйтми калдырды...

Шаһинур. Ул... әйтмәс... Менә балыктан авыз ит. Карп. *(Тәлинкәгә салып, алдына куя.)*

Мөнирә *(өстәл янына утырып)*. Иске авызга яңа аш... *(Авыз итеп.)* Телне йотарлык!

Шаһинур *(кәефсез)*. Бүген тагын председатель янына бардым: «Күпме акчаны суга салдың — уттай кызу урак өстендә ачу китереп йөрмә әле!»— ди.

Мөнирә. Дөрес әйтә! Пенсиягә чыккач, рәхәтләнеп ял итәсе урында...

Шаһинур. Карамалы халкына затлы балык ашатасым килә... Нык торгач, барыбер ризалашты тагын. Бернечә көннән өмә ясап буа буарга булдык әле. *(Уйчан.)* Шундый да күңелле өмәләр ясый идек Карамалыда...

Мөнирә. Балыгың тәмле, рәхмәт... *(Кузгала.)*

Шаһинур. Шулпасыннан да авыз ит.

Мөнирә. Ашыгам. Сөенечемне әйтергә генә кайттым. Кәефеңне төшермә, Шаһинур эти, җыелышта мин чәчрәп чыктым! Туктагыз, мин әйтәм, нишләп әле күпме еллар сәүдә идарәсе председателе булып эшләгән Шаһинур этинең дә исемен телгә алмадыгыз, дим.

Шаһинур *(савыт-саба юып)*. Юкка яклагансың...

Мөнирә. Колхоз председателе дә кушылды сине яклап... Сәлимов миннән курка ул! Усал бит мин, Шаһинур эти, әйеме?

Шаһинур. «Мөнирәнең усаллыгы да сөйкемле» ди торган иде Сәгыйть мәрхүм...

Мөнирә. Сәгыйтемә кайчак авыр сүз әйтүләремне уйлап, үкенеп бетә алмыйм. Кешеләр өчен дә, минем өчен дә үлеп торган асыл зат иде Сәгыйтем...

Шаһинур. Кешеләр өчен җанын бирде дә...

Мөнирә. Янып үлгән җирендә «Бу урында тракторчы Сәгыйть Сәлмәнов колхоз ашлыгын янудан коткарып калганда һәлак булды» дип язып чардуган куярга уйлыйлар.

Шаһинур. Бездән ераклашкан саен кадере арта бара егетнең.

Мөнирә. Күзем йомсам, күз алларымда — Сәгыйть, кырларга чыксам — кояштай елмаеп ул басып тора... Кочып-кочып елардай булам... Белмәдем мәхәббәтнең кадерләрен!

Шаһинур. Аңлыйм, кызым... Мәхәббәтеңнең бәхетен күрә алмадың...

Мөнирә. Туп-тулы бәхет юктыр инде ул... Ярый әле кызым Энҗе бар. Сиңа рәхмәт, Шаһинур эти, без ятимнәрне кеше иттең.

Шаһинур. Рәхмәт әйтергә ашыкма. Безгә яшисе дә яшисе әле...

Мөнирә. Синең кебек кешеләр барда — яшибез, Шаһинур эти! Ярый мин эшкә киттем! *(Китәргә уйлый.)*

Шаһинур. Мөнирә, туктале...

Мөнирә. Нәрсә, Шаһинур эти?

Шаһинур. Сүзем бар.

Мөнирә. Әйт тизрәк!

Шаһинур. Халыкта төрле сүзләр йөри...

Мөнирә. Ни әйтергә телисең?..

Шаһинур. Тәртип йомшарды сельпода.

Мөнирә. «Мин пенсиягә киткәч» дисеңме?

Шаһинур. Әйе. Сәлимов ни теләсә шуны эшли. *(Усал.)* Идарәгә, кибетләргә туган-тумачаларын җыя.

Мөнирә. Юкка каныгасың... Эш бара. План үтәлә.

Шаһинур. «Эш бара! План үтәлә». Аракы хисабына! Кирәк товарлар таныш-белеш, дус-ишкә — итәк астыннан! Карамалыда мондый хәлнең булганы юк иде!

Мөнирә. Син Сәлимовны гомер буе яратмадың инде. Синең урынга килгәч — бигрәк тә... Райкомга барганыңны Сәлимовлар белә.

Шаһинур. Мин беркемнән дә яшермәдем.

Мөнирә. Алар гафу итә торганнардан түгел!..

Шаһинур. Андыйларны күп күргән. Кара аны, Сәлимовлар башыңны ашамасын!

Мөнирә. Болай да инде мин аның күзен ачырмыйм. Бирешмәм.

Шаһинур. Итәгеңне җыеп йөр!

Мөнирә. Борчылма! Киттем! *(Чыга.)*

Шаһинур *(чәй кайнатырга әзерләнә, җырлый)*.

Карамалы, Карамалы,
Каенлы, карамалы.
Яшьлегем узды да китте —
Әйләнеп карамады.

Алмаз *(керә)*. Исәнмесез, бабай?

Шаһинур. Исән.

Алмаз. Карамалы?

Шаһинур. Үзе.

Алмаз. Иске тегермән?

Шаһинур. Әйе.

Алмаз. Шаһинур? Сафин?

Шаһинур. Әйе.

Алмаз *(өстәл янына утырып, магнитофонын куя, блокнотын актарып)*. Фронт. Дүрт ел. Карамалы авылында сәүдә идарәсе председателе. Утыз ел. Пенсия. Ике ел... Дөресме?

Шаһинур. Дөрес. Ни кирәк?

Алмаз. Хәтимә бәете кирәк.

Шаһинур *(сагаеп)*. Нинди Хәтимә? Нинди бәет?

Алмаз. Сораштым. Һәр кешедән. Дәшмиләр. Өмет — сездә! Бабай, әйтегез...

Шаһинур. Ни әйтергә?

Алмаз. Хәтимә бәетен! *(Авторучка, кәгазь ала.)*

Шаһинур. Нинди Хәтимә? Нинди бәет?

Алмаз. Әйттеләр, сез беләсез дип.

Шаһинур. Кем әйтте?

Алмаз. Күрше авыллар.

Шаһинур. Күршеләр ни сөйләмәс...

Алмаз *(йөреп)*. Карамалы буе. Тегермән. Бәет — монда! Бабай, әйтегез!

Шаһинур. Мин берниндн дә бәет белмим.

Алмаз. Беләсез. Куркасызмы? Мине кем дип беләсез?

Шаһинур. Кем булса да барыбер.

Алмаз. Шикләнмәгез. Мин студент. Халык авыз иҗатын җыючы.

Шаһинур. Булса соң...

Алмаз. Аңлагыз! Хәтимә бәете — тарих. Карамалы даны. Эгоизмнан өстен булыйк. Җырлагыз бәетне!

Шаһинур. Белмим! Юлыңда бул!

Алмаз. Әһә! Бер абзый сүзләре: «Әчмичә җырлыйлармыни?» *(Сумкасыннан шәраб ала.)* Бабай, утырыгыз, бер нитик әле... Стакан... *(Шаһинур сүзсез генә өстәл янына килә.)* Рәхмәт... *(Шаһинур вино шешәсен ала да атып бәрә.)* Нишлисез? Их... *(Башын тотып уйга кала. Сикереп торып, куркытмакчы була.)* Җырлатырбыз! Мәҗбүр итәрбез! Казанга чакыртып! Җырлыйсызмы, юкмы? *(Шаһинур дәшми. Алмаз утыра. Бераздан.)* Абзыкаем... Җаным, зинһар, ялынып сорыйм... Алларыңа тезләнимме? Кызлар алдында да, дошманым алдында да баш игәнем юк! Бүген горур башымны иям! Ярый, җырламагыз... сүзләрен генә әйтегез... *(Берниндн чара да тәэсир итмәгәч, сикереп тора.)* Карамалылар — таш бәгырьлеләр... дәшмиләр... Таш булып таш дәшәр иде... *(Бик моңлы итеп җырлап җибәрә.)*

Карамалы буйларының
Язы шаулы, җәе — тын.
Без әйтәбез, сез тыңлагыз
Хәтимәнең бәетен.

Шаһинур *(сорамый түзә алмый)*. Каян ишеттең?

Алмаз *(Шаһинур янына бара, өмет белән)*. Күршеләрегездән. Калганын белмиләр... Сезнекеләр дәшми... Хәзер әйтәсезме?

Шаһинур. Ал магнитофоныңны...

Алмаз *(сөенеп, җырлап, магнитофон әзерли)*. Мин әзер!

Шаһинур. Ал магнитофоныңны да ычкын!

Алмаз. Ничек?

Шаһинур. Бездә берниндн дә бәет юк! Төшендеңме?

Алмаз. Төшенмәдем...

Шаһинур. Төшенсәң дә, төшенмәсәң дә... бар... кит!..

Алмаз. Китмим! Таш булып ятам! Трактор белән тарттырсагыз да! Бәетсез китү юк!

*(Шаһинур аңа усал караш ташлый да өенә кереп китә. Алмаз сумкасыннан кармак ала, салынган басмадан балык тотарга керешә. Энҗе керә. Алмазны күреп, аны кызыксынып күзәтә.)*

Алмаз. Тфү-тфү, балык, кап, яр башында ялтырап ят! *(Сала.)* Монда халык та, балык та бер сүздә икән... *(Кармагын алып, тагын сала.)* Тфү-тфү, балык, кап... *(Чиртә.)* Ой, чиртте! *(Зур гына карпны каптырып, ярга ыргыта. Аны Энҗе эләктереп ала да шундук суга җибәрә.)* Харап иттең! Нишлисең, ә? Мин тоткан балыкны... Их син...

Энҗе. Браконьер!

Алмаз. Гомеремдә бер тапкыр шундый зур балык эләктердем... аны да...

Энҗе. Ярый әле Шаһинур дәү әти күрмәде.

Алмаз. Күрсә?..

Энҗе. Колагыңнан колак кага идең...

Алмаз *(Энҗегә якын килеп)*. Ул синең дәү әтиеңмени?

Энҗе. Әһә.

Алмаз. Нигә шундый ул?

Энҗе. Нинди?

Алмаз. Әллә кинди...

Энҗе. Син үзең әллә нинди!

Алмаз. Кызык... Үзе дәү эти... Үзе Шаһинур. Нишләп?

Энҗе. Ә ул минем чын дәү эти түгел.

Алмаз. Ә чыны?

Энҗе. Вәдүт. Сельпо председателе булган. Язгы ташу вакытында районга барганда, бандитлар үтергәннәр. Безнең отряд пионерлары сельпога каһарманнар стенды төзергә алынды. Дәү әтинең фотосы кирәк. Хәзер әни дә килә... Туктале, нишләп йөрисең монда, кем син?

Алмаз. Университет студенты. Алмаз.

Энҗе. Студент? Гафу итегез...

Алмаз *(сызганган балакларын төшерә).* Ә сез?

Энҗе. Мин — Энҗе. Монда торам.

Алмаз. Энҗе сеңелем, халык авыз иҗаты җыю экспедициясе синең ярдәмгә мохтаҗ.

Энҗе. Минем ярдәмгә?

Алмаз. Әйе. Без Хәтимә бәетен эзлибез.

Энҗе. Хәтимә бәетен? Ул минем дәү әни булган.

Алмаз. Шулаймыни? Бәеткә әверелгәч, аның яшьлеге давыллы да, фаҗигале дә булгандыр.

Энҗе. Мин аның турында берни дә белмим шул.

Алмаз. Эзлик. Табыйк. Бәет барысын да сөйләп бирер. Әмма беркем дә аның сүзләрен әйтергә теләми. Авылның барлык өлкән кешеләреннән сорашып чыктым.

Энҗе. Шаһинур дәү эти?..

Алмаз. Сөйләшергә дә теләми.

Энҗе. Күпме генә сорасам да, ул миңа да берни сөйләми шул... Ниндидер сер бар, мөгаен... Кара карчыкны күрмәдегезме?

Алмаз. Юк. Кем ул?

Энҗе. Хәзер барырбыз. Эшне генә бетерәм дә... Шаһинур эти!

Шаһинур *(керә).* Ни бар? *(Алмазга.)* Әле син китмәдеңмени?

Энҗе. Кунак кеше...

Шаһинур. ...тыйнак була ул!

Энҗе. Шаһинур эти, фотоальбомыңны алып чык әле!

Шаһинур. Хәзер. *(Чыга.)*

Энҗе. Сезгә дә күрсәтәм хәзер дәү этине...

Мөнирә *(кайтып керә).* Энҗе, таптыңмы? Кунак бар икән... Исәнмесез?

Алмаз. Исәнмесез? Алмаз.

Энҗе. Студент. Халык авыз иҗаты җыя.

Мөнирә. Фотоны таптыңмы, кызым?

Энҗе. Әнә... Шаһинур дәү этидә... *(Шаһинур фотоальбомны сүзсез генә Энҗегә бирә.)*

Мөнирә. Каяле... табып бирим... Пионерларың да миңа килгәннәр, ашыктыралар... *(Актара.)* Юк ул монда... Әтинең бердәнбер төсе. Аның башка рәсеме юк. Кайда ул? Сугышка кадәр үк авыл яшьләре концерттан соң төшкән рәсем... Эти гармун белән уртада... Кайда ул, ә? Шаһинур эти, нигә син дәшмисең?

Шаһинур *(теләмичә генә).* Югалгандыр...

Мөнирә. Югала торган истәлек түгел ул. Димәк, син аны юк иткәнсең? Шулаймы? *(Шаһинур дәшми.)*

Кара карчык *(керә).* Ишеттегезме, ишеттегезме?! Суга баткан Вәдүт эшен тикшерергә килгәннәр икән, ди, өйдән өйгә сорашып йөриләр икән, ди... Я алла, мәрхүмә Хәтимә турында да сорашалар икән, ди Ходай үзең сакла, шаһитларның күзен капла... Мин гөнаһсыз бәндәдән килеп сорыйнитә калсалар, шуны гына әйтә алам... *(Көйләп.)*

Куласалар әйләндерә
Тегермәннең ташларын.
Шаһинур гына ашады
Шул Вәдүтнең башларын...

Алмаз *(магнитофонын көйләп).* Әби, тагын кабатлагыз! Тагын! Тагын! *(Энҗегә.)* Энҗе, таптым! *(Энҗе куркып, әнисенә сыена.)*

Мөнирә. Җитте! Кабатлама! Чыгып кит моннан, Кара карчык! Кит!

Кара карчык. Ишеттегезме, ишеттегезме!.. *(Чыга.)*

Мөнирә. Шаһинур эти... Аңлат безгә. газаплама гомер буе... Бу хакта мин күптән ишетеп килəм. Моңа кадәр кара гайбәт дип йөрдем. Бүген... килеп... Кызым Энҗе белән ялварып сорыйбыз: әйт, гайбәтме, чынмы бу? *(Шаһинур дәшми.)* Димәк, чын?! *(Битен куллары белән каплый.)*

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### Сигезенче күренеш

**Берничә көн узган. Иске тегермән буе. Иртә. Күчмә кибет сатучысы Мөнирә товарларын тәртипкә китерә. Шунда ук әйрән салынган бидон. Сәхнәдә — Ак бабай, Ак әби. Якында гына яшьләр җыры ишетелә.**

Ак бабай. Әйттерәләр бит, ә?

Ак әби. Иртә таңнан уянганнар.

Ак бабай. Кичтән килгәннәр алар, таң сандугачлары, йокламаганнар. Каладан ялга кайткан үзебезнең яшьләр. Өмәгә атлыгып торалар.

Ак әби. Һай тынгысыз җан, Шаһинурны әйтәм, картаюны белмәде... Өмә оештырып йөри, рәхмәт төшкере, яшь чакларны искә төшереп...

Ак бабай. Шаһинур ул сүзен җилгә ташламас, өмәсен дә ясар, балыгын да үрчетер! *(Мөнирәне күреп.)* Кара, Мөнирә, син түгелме соң, исәнме, кызым?

Ак әби. Күрми дә торабыз. Исәнме, кызым? Әллә инде өмәгә әзерләнәсең?

Мөнирә. Әйе. Бик иртәләгәнсез...

Ак әби. Өмә дигәч без дә сикереп торган булдык әле.

Ак бабай. Яшь чакларны искә төшерик дигән булабыз инде.

Ак әби. Бигрәкләр дә күңелгә якын шушы тегермән буйкайлары!

Ак бабай. Кайтмый калган әллә кемнәр кайтып керер кебек шушы яктан...

Ак әби. Һәммәсе кайтсын! Карамалының күңеле киң!

Ак бабай. Әнә автобус кайтты!

Ак әби. Кемдер туп-туры монда килә. *(Мөнирә үз эше белән мәшгуль, әмма барысын да ишетеп тора.)*

Ак бабай. Кем булыр бу, бер дә күргән-белгәнгә охшамаган.

Ак әби. Безнеке булмады бу...

Ак бабай. Иплəп кенә сорашыйк...

*(Картайган, таушалган, зонтикка таянган Вәдүт килеп керә. Өстенә бик ук ятышмый торган яңа костюм, башына салам эшләпә, аягына ялтыравыклы ботинкалар кигән. Күрәсең, ул аларны яңа гына сатып алган. Вәдүт картларны күрми, тегермән буйларын йотлыгып карый.)*

Ак бабай. Әссәламәгаләйкем!

Ак әби. Исәнме, кордаш!

Вәдүт *(сискәнеп китә)*. Исәннәрмесез?

Ак бабай. Каян киләсең?

Ак әби. Кая юл тоттың?

Вәдүт. Яшьлеккә.

Ак әби. Ниятең изгеме?

Вәдүт. Якаңнан үлем китереп тотканда, нинди ният булсын...

Ак бабай. Карамалының йоласы инде, юлаучыга берничә сөаль бирәбез. Әйт әле, юлаучы, тәмледән тәмле ни тәмле?

Вәдүт. Бу дөньяны онытып төш күрү.

Ак әби. Ачыдан ачы ни ачы?

Вәдүт. Авызыңнан тәм китсә, һәммәсе ачы: чишмә суы да, кура җиләге дә, хатынкыз да...

Ак бабай. Авырдан авыр ни авыр?

Вәдүт. Алган бурычыңны кайтарып бирү.

Ак әби. Нәрсәне сатып алып булмый?

Вәдүт. Акчаң булса, һәммә нәрсәне сатып алып була, тәк димәк, сәламәтлекне — булмый.

Ак бабай. Соңгы сөаль? «Сандык төбеннән төенчек алдым, чишеп карап яңадан салдым» ни булыр?

Вәдүт. Алтын. *(Картлар бер-берсенә карашалар.)*

Ак бабай. Юл кешесенең юлда булуы хәерле...

Ак әби. Юлың уң булсын!

Вәдүт *(кулын каш өстенә куеп)*. Карамалымы соң бу?

Ак бабай. Син аны барып кара. *(Чыгалар.)*

Вәдүт. Барып та карарбыз... тәк димәк... *(Чыга.)*

Мөнирә *(җырлый)*:

Туган якның карамасы
Серләрен ачмый гына,
Моңаядыр күз яшьләрен
Җилләргә чәчми генә.
Туган якның карамасы
Тирәнгә тамырланган,
Тамырланган карамадай
Булмадым сабырлардан.

*(Тәрәзәгә килеп.)* Энҗе! Кызым! Тор әле! Тор!

Энҗе *(өй эченнән чыга, кәефсез)*. Йоклап кына киттем... уяттың да...

Мөнирә. Кил әле монда!

Энҗе. Кибетне өйгә күчердеңме әллә?

Мөнирә. Буа буарга өмә җыела. Сатарга миңа куштылар. Кәефең ничек, кызым?

Энҗе. Үзегез дә төне буе йокламыйсыз, мине дә йоклатмыйсыз...

Мөнирә. Кызым, сиңа әйтәсе сүзем бар.

Энҗе. Әйт соң...

Мөнирә. Шаһинур этинең өендә без инде бик күп еллар торабыз.

Энҗе. Ничек... аның өендә?

Мөнирә. Ул безне җылы канаты астына алды. Безне кеше итү өчен үз бәхетеннән баш тартты. Мөгаен, «үги ана боларны кыерсытыр», дип, өйләнмәгәндер ул... Барысы өчен дә рәхмәт аңа! Хәзер безгә үз тормышыбызны үзебез күрергә вакыт. Син инде буй җиткән кыз. Безнең хәлләрне үзең күреп тордың. Шуның өстенә — кибеттә ревизия. Шаһинур бабай башлаган эш! Курыкма, кыек эшләрем юк... Сәлимов кызган табага баскандай бии. Чын-чынлап кабахәт икән: кичә ялган актка кул куйдырырга маташты, янәсе, ул товарларны без бергә списать иткәнбез! «Кул куймасаң, үзеңне дә батырам»,— ди. Бер генә сүз әйттем!

Энҗе. Бирешмә, әни!

Мөнирә. Сизәм: алар миңа барыбер көн күрсәтмәячәкләр...

Энҗе. Әйтеп бетер!

Мөнирә. Китик Карамалыдан...

Энҗе. Кая?

Мөнирә. Кая гына булса да... Мөнә КамАЗга чакырып торалар.

Энҗе. Әни, син нишләдең?

Мөнирә. Риза түгелсеңме әллә?

Энҗе. Синме бу, әни?

Мөнирә. Китәбез!

Энҗе. Әткәй күмелгән изге туфракны калдырыпмы?

Мөнирә. Үзем дә авыр, кызым... Нишлим соң...

Энҗе. Шаһинур дәү этине картайгач кына ташлап калдырабызмы? Япа-ялгызын?

Мөнирә. Аның белән булган хәлләрне үзең беләсең... Гомер буе шикләнеп бер өйдә ничек яшәмәк кирәк?

Энҗе. Ышанмыйм! Шаһинур дәү әти андый түгел!

Мөнирә. Сиңа бик ерак шул Вәдүт дигән кеше: дәү әти генә, ә миңа — әти, беләсеңме, әти... Атамның язмышында аның кулы уйнаган, диләр... Я, китәбезме?

Энҗе. Син китәсең икән, рәхим ит, мин калам!

Мөнирә. Кемнәргә генә охшап шундый үзсүзле булдың син, кыребеткән кызый?! *(Елый.)* Ачуланма, Энҗекәем, үземне кая куярга белми йөрим. Бәхетем син генә бит минем, кызым-бәгырем. Синең өчен тырышам ич, бирдәнберем өчен... Сине шәфкатьсезлектән, хаксызлыктан саклыйсым килә.

Энҗе. Елама, әни. *(Әнисенең башын күкрәгенә кыса, үзе дә елап җибәрә.)* Елаганыңны беренче күрәм, әни... Мин сиңа каршы килмим... Шулай да икебез дә тагын уйлап карыйк әле...

Мөнирә. Менә рәхмәт, кызым, аңладың...

Э н җ е. Йомшаклыгыңны башка беркемгә дә күрсәтмә, әни, яме, сиңа килешми. Әниемне мескен итеп күрәсем килми!

М ө н и р ә. Ярый, оныттык. *(Элекке халәтенә кайтып.)* Син монда калып тор. Мин тагын товарлар алып төшәм.

Энҗе. Ярый.

Мөнирә. Киттем! Гаризага да язып кайтам! *(Китә.)*

Энҗе. Ашыкма! *(Бидон артына баса. Шәһәр барларындагы барменнарга охшатып.)* Бары тик безнең фирмада, безнең марка! *(Бозып әйтә.)* Ойрән! Коктейль — чүп! Пепси-кола — саз суы! Кока-кола — диңгез суы! Безнең ойрән! О, шәп, ол райт! *(Бидоннан стаканга салып, җирдән салам ала. Алмаз керер, Энҗенең кыланганын карап тора.)*

Алмаз. О, әйрән!?

Энҗе *(уенын дәвам итеп)*. Әйрән? Плизми! *(Өстәлгә бер стакан әйрән һәм салам китереп куя.)* Гут бай?

Алмаз *(Энҗенең үзен дә чакырып)*. Сит даун!

Энҗе. Сөйнк ю! *(Үзенә дә әйрән салып, саламнан эчә башлыйлар.)* Алмаз абый, кайда йокладыгыз?

Алмаз. Йокламадым.

Энҗе. Чынлапмы? Белгән булсам...

Алмаз. Нишләр идең?

Энҗе. Мин дә чыгар идем. Ә нигә йокламадыгыз?

Алмаз. Нинди йокы?.. Җәйге төн. Күктә — йолдызлар. Таллыкта — сандугач. Суда балык йөзәдер... Авылыбызда бер чибәр бар, үзәгемне өзәдер...

Энҗе. Кем ул?

Алмаз. Юк, болай, җыр гына...

Энҗе *(күңелсез)*. Мин әллә тагын...

Алмаз. Төне буе учак янында авыл яшьләре белән утырдым. Аннан ялгызым таң атканны күзәттем. Кызганыч, мин сезнең авылда тумаганмын...

Энҗе. Тусагыз?

Алмаз. Шушында яшәп, шушында үләр идем.

Энҗе. Нигә?

Алмаз. Мин гашыйк...

Энҗе *(сөенеп, оялып)*. Чынлапмы?

Алмаз. Беренче күрүдә үк. Их, Энҗе...

Энҗе. Кемгә?

Алмаз. Табигатькә.

Энҗе. Ә... шулаймыни...

Алмаз. Мондагыдай уйчан агымсулар, моңлы сандугачлар, җырчы камышлар башка беркайда да юктыр!..

Энҗе. Ә мине әни моннан алып китмәкче була... Бөтенләйгә!

Алмаз. Китәсеңме... шушыннанмы?

Энҗе. Китәсем килеп китмимен...

Алмаз *(җыр белән дәвам итеп)*. Туган җирдән кем туйган. Син, шушы җирнең нәни генә сандугачы, саргаеп үләрсең читтә...

Энҗе. Онытылыр әле... кайтасы да килмәс.

Алмаз. Картайгач сагынырсың...

Энҗе. Нәрсә соң ул сагыну?

Алмаз. Сагынумы? Сагыну ул... *(Уйланып.)* Туган яктан китәсең... Берничә елдан төш күрәсең: авылның яшел чирәменнән яланаяк чабасың... Билдән ашкан печән эчендә ятасың, зәңгәр күккә карыйсың... Челтерәп аккан чишмә тавышын ишетәсең. Уянасың: шәһәрдә таш диварлар эчендә ятасың... Моңсу булып китә... Йөрәкне сагыну, сагыш кисә... *(Музыка, яшьләр җыры.)*

Энҗе. Син карт түгел — каян беләсең?

Алмаз. Беләм. Җырлар аша.

Энҗе. Республика газетасында бик кызык белдерү бар. Укыдыңмы?

Алмаз. Юк.

Энҗе. Менә...

Алмаз *(укый)*. «Фәлән номерлы картлар йортыннан җитмеш яшьлек Фәтхулла бабай чыгып югалды. Зонтикка таянып йөри. «Яшьлеккә кайтам» дип чыгып киткән. Сүзләрендә мәгънә бәйләнеше юк. Кызымны эзлим, ди. «Эзбиркнижкә» дип саташа. Исемен төрлечә әйтә. Үзе кайтып керә белми. Күрүчеләр булса, хәбәр итүегезне сорыйбыз».

Энҗе. Мескен...

Алмаз. Күңелендә булса, кеше үзенең туган җиренә нинди хәлдә дә кайтып җитә ала.

*(Музыка. Яшьләр җыры ишетелә.)* Ишетәсеңме...

Кайтыр юлда өсләремә
Ташкыннар урләсә дә,
Яраланып, хәлсезләнеп,
Аяклар йөрмәсә дә,
Карамалым, Карамалым,
Барыбер кайтып җитәрмен,
Бернигә карамамын.

Бу җырны мин бүген генә язып алдым. Кем чыгарган җыр бу?

Энҗе. Белмим.

Алмаз. Сезнекеләр.

Энҗе. Авторы?

Алмаз. Ул инде халык авыз иҗатына әверелгән, авторы — билгесез. Минемчә, бу җырны синең дәү әтиләреңнең берсе: я Вәдүт, я Шаһинур җырлап кайткандыр...

Энҗе. Кайсысы? Минем дәү әти бик матур җырлаган, диләр.

Алмаз. Икесе дә җырлаган дип уйлыйк... Энҗе, мин бәетнең тагын башка җырларын таптым. *(Дәфтәр алып.)* Хәтимә бәете — кара урман, эченә кергән саен серлерәк, шомлырак була бара.

Кем ул төнне юлда булган,
Шул күреп калган диләр.
Вәдүт гәүдәсен Шаһинур
Ташкынга салган, диләр.

Энҗе. Алмаз абый... булмас!

Алмаз. Булуы да ихтимал.

Энҗе. Ничек? Ни өчен?

Алмаз. Егерме яшьлек Хәтимә
Тегерманче кызыдыр,
Ярсу башлар гына түгел,
Яткан ташлар кызыгыр.

Әйтик, яшь чибәр Хәтимәгә ике егет гашыйк: берсе — Вәдүт, икенчесе — Шаһинур. Сельпо Вәдүт, синең дәү әтиең, язгы ташу вакытында ат менеп районга юнәлә. Каршыга — көндәше Шаһинур килә. Болар кызып китәләр... һәм... Шаһинур... Вәдүтне...

Энҗе. Әйтмәгез!.. Шаһинур Хәтимәне, дәү әнине яраткан мы?

Алмаз. Монысы — бәхәссез!

Энҗе. Йөрәгендә мәхәббәт йөрткән кеше җинаять эшли алмый.

Алмаз. Ә Отелло?.. Көнләшеп, үзенең сөйгәне Дездемонаны буып үтерә.

Энҗе. Шулай да...

Алмаз. Бәеттә икенче версия дә бар...

Энҗе. Нинди?

Алмаз. Иртә-кичен көткән халык,
Шикләнеп, уйга калып.
Сельпо Вәдүт юкка чыккан
Бик зур суманы алып.
Озата да бармадым,
Хәбәрләр дә алмадым.
Йөрәккәйләремне кысып,
Калды, Вәдүт, балдагың.

Энҗе. Балдак? *(Бармагыннан балдагын салып.)* Менә ул балдак!

Алмаз. Каян алдың син аны?

Энҗе. Әни бирде. Дәү әнинең бердәнбер ядкаре...

Алмаз *(кире биреп)*. Димәк: шул балдак! Әмма бу вариант дөрескә чыкса, Вәдүт акчаны алып юкка чыга, ягъни авылны, Хәтимәне авыр хәлдә калдырып, ташлап кача...

Энҗе. Юк, аны бандитлар үтереп суга ташлаганнар!

Алмаз. Бәеттә ул хакта бер сүз дә юк... *(Укый.)*

Ялгышырга өлгерсәм дә,
Яшәргә өлгермәдем.
Умырзаядан да кыска
Булды шул гомерләрем.

Хәтимә үлем алдыннан үзенең ялгышуын сиздерә. Нинди ялгыш? Каен белән карама... Менә алар... Вакыйгаларның урыны — шушы. *(Энҗе — каенга, Алмаз — карамага сөяләләр.)*

Энҗе. Каен белән карама. Дәшмиләр...

Алмаз. Сезнекеләрнең холкы!

Энҗе. Нишләргә, Алмаз абый?

Алмаз. Эзләнүне дәвам итәргә! Киттек! *(Чыгарга баралар. Каршыларына Вәдүт килә. Ул аларны күрми, әкрен генә тәрәзә чиртә.)*

Вәдүт. Һәй! Хуҗалар өйдәме? Һәй! *(Тагын чиртә.)*

Энҗе. Сез кем?

Вәдүт *(сискәнеп, куркып)*. Үзем дә белмим кем икәнемне!

Энҗе. Кая барасың, бабай?

Вәдүт. Белмим, белмим...

Алмаз. Юл йөреп аргансыздыр?

Вәдүт. Яшәп ардым.

Алмаз. Озак яшәдегезмени, бабай?

Вәдүт. Мең ел кебек.

Алмаз. Үзегезгә ничә яшь?

Вәдүт. Җитмеш.

Алмаз. Шул кадәр яшәп, нинди нәтиҗәгә килдегез?

Вәдүт. Тормыш — дәрья, берләр — бата, берләр — калка. *(Кесәсеннән портмонет ала, акча чыгара.)* Кызым, су бир әле. *(Акча суза.)*

Энҗе *(әйрән салып бирә)*. Бушлай.

Вәдүт *(эчә, маңгаеннан тирен сыпыра, як-ягына карап)*. Тегермән ташы әйләнә...

Алмаз *(магнитофонны әзерләп)*. «Тегермән ташы әйләнә»... Аннан ничек? Исегезгә төшерегез, бабакай...

Вәдүт. Нәрсәне?

Алмаз. Хәтимә бәетен... беләсезме?..

Вәдүт *(сизелерлек каушап, сөенеп куя)*. Хәтимә... Хәтимә дидегезме? Хәтимәнең... бәете бармыни?..

Алмаз. Бар.

Вәдүт. Ничек?

Алмаз. Энҗе, җырла...

Энҗе *(җырлый)*.

Суларга да батмаган ул,
Өйгә дә кайтмаган ул,
Хәтимәнең—бичараның
Ишеген какмаган ул.

Вәдүт *(җырны тыныч тыңлый алмый, урсаләнеп, әле сикереп тора, әле утыра. Җыр тәмамлангач)*. Бу өйдә кемнәр тора?

Энҗе. Без.

Вәдүт. Шәймәрдән абзый... Мөслихәттәйләр исәнме?.. Әллә...

Энҗе *(аптырап кала, картны саташа дип уйлап, Алмазга ишарә ясый)*. Ялгыш килгәнсең, бабай...

Вәдүт *(ни өчендер зонтикны җәеп, баш очына күтәрә)*. Хәтимә исәнме?

Алмаз. Бәете исән. Очына чыгалмыйбыз. *(Зонтикка ымлап.)* Бабай, яңгыр яумый...

Вәдүт *(зонтикны җыя, таяна).* Хәтимә... кайда? *(Яшьләр бер-берсенә карашалар.)*

Энҗе *(һаман аңламыйча, кулы белән күрсәтә).* Ә-ә-әнә, тегендә.

Вәдүт *(кузгалып).* Алып барыгыз аның янына. Сүзем бар.

Энҗе *(шаярып).* Бабай, әллә син Фәтхулла хәзрәтме?

Вәдүт *(игътибар итмичә).* Әйе... һәммә нәрсә үзгәрә... Үзгәрә... буалар, ташлар, тегермәннәр, адәмнәр. Язмыш адәм баласын мең кыяфәткә кертә... Мең кыяфәткә!

Алмаз *(Вәдүтнең колагына).* Бабай, Энҗе әйтә, әллә син Фәтхулла исемлеме, ди.

Вәдүт. Ишетәм... әнә... дөп-дөп-дөп тегермән тәгәрмәче әйләнгәнне дә ишетәм... Бу өйнең хуҗасы кем?

Энҗе. Шаһинур.

Вәдүт. Шулаймыни? Димәк, тәк... Исән?..

Энҗе. Тиздән кайтыр.

Вәдүт. Хәтимә кайда?

Энҗе. Зиратта дидем бит...

Вәдүт. Хәтимә вафатмыни? Тәк, димәк, Хәтимә юк дөньяда...

Алмаз *(җырлый).*

Карамалы буйларында
Кем йөзәр суларында,
Хәтимәкәй җан бирәдер
Шаһинур кулларында...

Бабай, әллә сез бу бәетне беләсезме?

Вәдүт. Бәет? Ишеткән юк.

Энҗе *(Алмазга «бу карт ычкынган» дигән хәрәкәт ясый).* Киттек, Алмаз абый!

Вәдүт. Хәтимәнең токымы бармы?

Энҗе. Нинди токым?

Вәдүт. Тәк, димәк, балалары.

Энҗе *(шаярып кына).* Бар, бабай, бар.

Вәдүт. Малайларымы, кызларымы?

Энҗе. Кыз.

Вәдүт. Исеме ничек?

Энҗе. Мөнирә.

Вәдүт. Мөнирә. Атасының исеме?

Энҗе. Нигә кирәк ул сиңа, бабай?

Алмаз *(нәрсәдер сизенгән төсле).* Әйт, Энҗе...

Энҗе. Вәдүт булсын, ди...

Вәдүт *(сөенеп).* Вәдүт? Чынлап Вәдүтме?

Энҗе. Чынлап.

Алмаз. Ә менә Энҗе — Мөнирә апаның кызы.

Вәдүт. Энҗе... Тәк, димәк, син минем оныгым буласың! Энҗе...

Энҗе. Кит аннан!.. *(Газетага ымлап.)* Белдерүдәге карт бу! Нишләтәбез, Алмаз абый?

Алмаз. Мин тиз генә авылга... Телефонга... *(Чыга.)*

Вәдүт. Энҗе... кызым... бар, әниеңне алып кил...

Энҗе. Әнә үзе кайта!

Мөнирә *(керә).* Энҗе кызым, әтинең фотосын укытучылар китерде. Сәгыйть белән бергә истәлек тактасында тора! Бар, барып кара!

Энҗе *(шаярып).* Барасы юк... менә... үзе!

Вәдүт *(Мөнирәгә озак кына карап торганнан соң, аңа омтылып).* Кызым... *(Елап җибәрә.)* Мин бу... әтиең... Әйе, әйе... Димәк ки, син Хәтимәнең кызы? Тәк, димәк, мин карт көнемдә Хәтимәне алырга кайттым. Вафат икән, мәрхүмә, бәхете булмаган икән. Димәк, син калгансың токымның очы булып... Төшләремә дә керәмде... кызым...

Мөнирә *(каушап, агарып).* Ни сөйлисең син, бабай, булмаганны...

Вәдүт. Булганны сөйлим. Гөнаһ шомлыгына каршы, үлмәдем гомерем булгач, димәк, мин нәселемне эзлим. Корымаган, димәк, токым...

Мөнирә. Исемең ничек синең, бабай?

Вәдүт. Синең атаңның ничек иде исеме?

Мөнирә. Вәдүт.

Вәдүт. Менә... Вәдүт — мин инде, димәк ки. Үз атаң!..

Мөнирә. Минем үз атам үлде.

Энҗе. Бандитлар үтереп суга ташлаганнар аны, бабай.

Вәдүт. Үлмәде атагыз Вәдүт. Сезнең бәхеттән исән калды.

Мөнирә. Ничек... исән калды?

Вәдүт. Шулай... тәк, димәк, ул үзен сезнең өчен саклады. Ул гомере буе сезнең өчен газап чикте, сезгә мөлкәт калдырам дип, гомер бакый эт күрмәгәннәрне күрде, кайтып күренә алмады, түбәнлекләргә төште, пычракларга батты, исән калды, әмма бөтен җыйганын алып кайтып, сезнең алга килде. Кызым, оныгым...

Мөнирә. Юк, ышанмыйм... Саташу бу.

Вәдүт. Курыкмагыз атагыздан. Шундыйшундый хәлләргә төшсәм дә, мин сезнең түшәккә егылырга яки алимент түләтергә кайтмадым, мин бөтен барлыгымны сезгә васыять итәргә кайттым. И әйтәм сезгә, балакайлар, атагызның торган җирендә зираты сайланган, эше беткән. Әтиегезне шунда барып хөрмәтләп җиргә тапшырасыз да, теләсәгез аның өен сатасыз, теләсәгез — шунда яшәп каласыз. И менә сезгә калдырасы васыять! *(Кесәсеннән саклык кенәгәсе чыгарып.)* Илле мең!

Энҗе. Илле мең?

Вәдүт. И әйтәм: яңа акча белән илле мең! Шул суммага тагын, дөньяда яшәүнең кайбер хәйләләрен өйрәнгән адәм буларак, атагыз сезгә файдалы киңәшләр дә калдыра: тормыш — язгы ташкын, яшәү хәйләсен белмәсәң — батасың, булыгыз атагыздай: теләсә ничек булса да, өскә калкып чыгыгыз, кемнедер батырам, кимсетәм, рәнҗетәм дип уйласаң — үзең өлешсез калырсың! Үзегезгә кирәкне, әгәренки бирмәсә — умырып, суырып, каерып, йолкып алыгыз, кешедән дә, табигатьтән дә! И дә җитте дип туктап калмагыз, үзегездән артканы — балаларыгызга и оныкларыгызга калыр — алар да шулай булсын: бабалары кебек!

Илле мең! Менә нинди атагыз килеп чыкты сезнең бәхеттән! Сөенегез, сикерегез, биегез, балакайлар!.. Атагыз, Вәдүт кайтты!

Мөнирә *(башын куллары белән тотып)*. Кинәт кенә күз алларым караңгыланып китте...

Энҗе. Әни, борчылма, утыр...

Мөнирә. Әллә инде... Ни уйларга да белмим... Энҗе?

Энҗе *(газетаны биреп)*. Менә моны укысаң, шундук тынычланырсың...

Мөнирә *(укый. Бер Вәдүткә, бер газетага карап)*. Бабай, сез ялгыш килгәнсез безгә... *(Утыра.)*

Вәдүт. Ялгыш? Юк... Ялгыш түгел... Куркасыз?.. Димәк ки, сез мине атагыз дип танымыйсыз? И дөрес эшлисез! Сез мине күрмәгән бөтенләй! Һәммәсе дә законно булсын... Башта исбатларга кирәк, кайсыдыр ки мин — Вәдүт?

Мөнирә *(Энҗегә)*. Шаһинур эти кайда?

Энҗе. Әнә... өмә буласы урында печән чаба.

Мөнирә. Чакыр.

Энҗе. Шаһинур эти! Шаһинур эти!

Вәдүт. Шаһинур?! И дөрес! Ул мине танырга тиеш.

Шаһинур *(чалгы тотып керә)*. Ни бар? Халык җыеламы?

Мөнирә. Шаһинур эти... Син бу кешене таныйсыңмы? *(Шаһинур белән Вәдүт берберсенә озак кына карашып торалар.)* Танысыңмы?

Вәдүт. Яшьтәш, исәнме? *(Шаһинур дәшми.)* Шаһинур! *(Шаһинур игътибар итми.)* Дөнья картайткан сине дә, малай... Илләә мәгәр танырлык... Әллә минем танырлык җирем калмаган?.. Димәк ки кыяфәт үзгәргән... әмма син танырга тиеш. Тагын да күзләреңне ачыбрак кара, яшьтәш... Или синең күзләр начарландымы? Бөтенләй дә танымыйсың?

Шаһинур. Юк. Танымыйм.

Вәдүт. Вәдүт мин.

Шаһинур. Вәдүт? Кайсы Вәдүт?

Вәдүт. Малай чакта бергә уйнап үскән Вәдүт бу.

Шаһинур. Юк, хәтерләмим. Безнең авыл малайларын кыйнап кайтара торган Вәдүтме әллә?

Вәдүт. Тач өстенә бастың. Авылдашларыңны яклап минем белән сугышканың да истәме? Иллә мәгәр өеңә елап кайтмыйдырыең. Исеңә төштеме? Без икебез дә ыштансыз үскән ярлы балалары бит, икебез дә колхозга кердек... Ә истәме колхозга трактор алырга өй борынча талир тәңкәләр җыйган чаклар?

Шаһинур. Талир тәңкәләрнең бер өлешен үзенә алган Вәдүтме әллә?

Вәдүт. Шул Вәдүт. Соңыннан ул тәңкәләрне Хәтимә толымнарына таккан Вәдүт. Хәтереңдәме театр уйнаган? Мин — Хәлил. Тавыш шәп бит. Гармунны да үзем сыздырам. Син — кулак малае Исмәгыйль... Әллә ни уйный алмадың бугай... Шул кичне Хәтимә миңа игътибар итте. Исеңдәме? Китерсә дә китерә икән язмыш: сугышта да бер дивизиядә... Син ач йөргәндә миндә сохарила була торган ие, шул Вәдүтне беләсеңме?

Шаһинур. Җыйган сохариларын качып үзе генә кимерә торган Вәдүтме әллә?

Вәдүт. Аннан килеп, хәтерлисеңдер, сугыштан кайткач, сельпода эшләгән Вәдүтне? Синең инде сугышырлык хәлең калмаган. Хәтимә минеке булды. Миңа каршы килеп, син аны нык яраттың, бу нәрсә миңа шөбһә салды. Син дөнья йөзендә яшәгәндә миңа рәхәт яшәү юк — шуны аңладым мин. Һәм дә, Хәтиманең и үземнең эзләрне синең күзләрдән югалту өчен, Хәтимәне Карамалыдан алып качмак булдым. Шуның өстенә — ревизор! Була инде сельпода эшләгән кешенең гөнаһлары! И мин китеп югалдым, беткән баш беткән дип, бөтен акчаларны алып... Янәсе дә башта үзем барып урнашам, аннан Хәтимәне алып качам! Шашкынлыктан айныгач аңладым: Карамалыга юл өзелгән, Хәтимәгә юл ябык!.. Менә инде утыз елдан соң кайттым Хәтимәне алырга... Васыятьне калдырырга һәм аның кулларында тынычлап үләргә!.. Хәтимәдән җилләр искән. Күптән гүрдә икән, мәрхүмә. Әле ярый бәхеттин кызым, оныгым исән икән. Таныдыңмы инде, Шаһинур, исеңә төштеме?

Шаһинур. Син әйткән Вәдүтне хәтерлим мин. Ә менә син — ул Вәдүт түгел! Минем өчен — Вәдүт юк!

Вәдүт. Әгәренки йөрәгеңдә шәфкать булса, син танырга тиеш мине, Шаһинур. Икебез дә карт, кабер авызында торабыз, сугышырлык хәлләр калмаган. Таны син мине, яшьтәш, менә бу кызларымның бәхетле булуларын теләсәң... Әгәренки син минем Вәдүт икәнемне расласаң, мин аларга бөтен гомерем буена җыйган акчаны калдырам. Таны, Шаһинур! Кызларым, әйтегез, ул сезне тыңлар... Мөнирә кызым, Энҗе...

Мөнирә *(шикләнү, шөбһә, икеләнү белән)*. Шаһинур эти?..

Энҗе *(бу адәмнең дәү этисе булып чыгуыннан куркып)*. Шаһинур дәү эти?.. *(Аңа сыена.)*

Шаһинур *(башта кызларга, аннан Вәдүткә карап тора да)*. Бу адәм Вәдүт түгел!

Вәдүт. Димәк ки, танырга теләмисең?.. Кызларым, җан кисәкләрем, курыкмагыз, мине Карамалыда танучылар булыр... *(Халыкның җырлап өмәгә җыелганы ишетелә.)* Инде килеп, соңгы үтенечемне тыңла... Чакыр монда халыкны! Сөйләшәсем килә авылдашлар белән...

Шаһинур. Һәй! Монда килегез! Бирегә! *(Әкренләп, җырлый-җырлый, халык җыела. Алда — Ак бабай, Ак әби, Кара карчык. Вәдүткә беркем дә игътибар итми, ул бераз читтә басып тора.)*

Халык.

— Исәнме, Шаһинур!

— Нигә чакырдың, Шаһинур абый?

— Без әзер!

— Өмәне башлыйбызмы?

Шаһинур. Авылдашлар! Рәхмәт сезгә: барыгыз да бердәм булып килгәнсез. Карамалылар борын-борыннан бердәм халык. Картрак кешеләр хәтерлиләрдер, менә шушы урында бөтен тирә-як өчен бердәнбер тегермән бар иде. Ак бабай, Ак әби, шулаймы?

Ак бабай. Бик хәтерлибез, Шаһинур энем. Тегермәнче Шәймәрдән гаять тә ихтирамлы, инсафлы кеше иде...

Ак әби. Карчыгы Мөслимә мәрхүмә дә дөнья бәясе кеше иде.

Ак бабай. Бигрәкләр дә ак күңеллеләр иде.

Кара карчык. Таптыгыз искә алырлык адәмнәр, я алла, ишеттегезме...

Шаһинур. Шушы җирдә ак күңелле Карамалы яшьләре очрашканнар, яратышканнар, балаларын, аталарын, сөйгәннәрен дошманга каршы яуга озатып калганнар, шушы җирдә исән кайтканнарны каршы алганнар. Үзегез дә беләсез, авылдашлар, мин күрше Казиле авылыннан. Шулай да мин шушы җиргә кече яшьтән гашыйк булдым. Фин сугышында, Ватан сугышында катнашып, миңа дөньяның бик күп почмакларын күрергә туры килде. Минем өчен шушыннан да ягымлы, шушыннан да кадерле, шушыннан да мәхәббәтле җир юк! Менә бу карама сыман, шушы җиргә тамырланып калуга, бәлки, сез гаҗәпләнгәнсездер дә. Кайберәүләргә минем аз сүзле, йомык кеше булуым да сәер тоелгандыр. Минем беренче мәхәббәтем шушы җирдә туды, шушы җирдә күмелде, кадерле авылдашлар. Бу җир — минем соңгы мәхәббәтем дә булыр... Хуҗалар белән киңәштек тә, бу урынга сезне буа буарга өмәгә чакырдык. Игелекле, изге бу җир киләчәктә дә халыкка хезмәт итсен!

Халык:

— Хак әйттең, Шаһинур!

— Дөрес!

— Эшлибез аны!

Шаһинур. Тагын бер генә минут, иптәшләр! Сезнең белән киңәшәсе сүз бар!

Халык:

— Әйт, Шаһинур!

— Нинди сүз ул?

— Тыңлыйбыз.

Шаһинур. Безнең авылга ниндидер бер сәер карт килгән. Ул үзен Вәдүт дип таныткачы була.

Халык:

— Вәдүт?

— Нинди Вәдүт?

— Кайсы Вәдүт?

Шаһинур. Өлкәннәр, бәлки, хәтерлиләрдер... 1946 елның язгы ташу вакытында сельпо председателе Вәдүт юкка чыккан иде. Ул үзен менә шул Вәдүт димәкче була.

Халык:

— Үзе әйтсен!

— Үзенә сүз бир!

— Үзен тыңлыйк!

Вәдүт *(халык алдына чыга, көч-хәл белән).* Авылдашлар... исәнлектәме?.. Ышансагыз, ышанмасагыз да мин шул Вәдүт!

Халык:

— Шул Вәдүт диме?

— Кит аннан, булмаганны?

— Тузга язмаганны...

— Тукта, булыр да...

— Вәдүт булсаң, аңлат, кайда югалдың?

Вәдүт. Сез инде беләсез, ревизор килү хәбәрен ишеткәч, димәк ки, җыйган акчаларны алып чыгып киткәнне...

Халык:

— Булдымы шундый хәл?

— Ишеткән бар!

— Булды андый хәл.

— Калганын сөйлә.

Вәдүт. Хәзер, димәк, сөйләсәң дә ярый. Факт: алдыгызда басып торам.

Халык:

— Нәрсә сөйли бу?

— Әллә чынлап та шул Вәдүт инде?

— Кит аннан, булмаганны...

— Кем соң ул Вәдүт?

— Вәдүт булсаң әйт — нигә шул вакытта кайтмадың?

Вәдүт. Инде килеп сөйләсәң дә ярый. Хөкем ителүнең срогы узган. Булган хәл онытылган, мине хәзер беркем эзләми. Хәзер закон минем якта!

Узган эш узган — закон мине гафу итте. Сез дә үлем алдыннан бәхилләшергә кайткан картка мәрхәмәтле булырсыз дип ышанам.

Халык:

— Нигә кайттың, карт?

— Ни кирәк сиңа Карамалыда?

Вәдүт. Һәркемнең үлеме җиткәч калдыра торган аманәте-васыяте була... И минем дә токымым, мөгаен, бардыр дип Карамалыга кайттым. Хәтимә вафат, ләкин безнең икебезнең кызыбыз исән икән әле, шөкер.

Халык:

— Нинди кыз?

— Кем ул?

— Исемен ата?

Вәдүт. Әнә ул, Мөнирә! *(Халык аптырап, Мөнирәгә карый.)*

Мөнирә. Авылдашлар... Сез тагын ышанып куймагыз... Юкны сөйли ул. *(Газетаны бирә, ул кулдан-кулга күчә.)* Менә... укыгыз... Саташу бу...

Вәдүт. Аннан кызымның кызы... Энҗе! *(Төртеп күрсәтә. Халык Энҗегә карый.)*

Энҗе. Кит аннан! Минем мондый дәү әтием булса...

Вәдүт. Мин аларга илле мең акчамны мирас итеп калдырам!

Халык:

— Илле мең!

— Кызларга калдырам диме?

— Тәмам ычкынган бу мескен...

Вәдүт. Ләкин моның өчен сез мине, авылдашларым, Вәдүт итеп танырга тиешсез. Я, нигә эндәшмисез?

Ак бабай. Башта минә мөхтәрәм авылдашыбыз Шаһинур әйтеп карасын. Без аңа бик тә ышанабыз. Утыз елдан артык сельпода эшләп, ник бер кыңгыр эш кылсын...

Халык:

— Таныса, сине Шаһинур таный инде.

— Шаһинур абый танысын!

Шаһинур. Бу юлы бөтен халык алдында әйтәм: Карамалы өчен, минем өчен Вәдүт — юк! Бу адәм Вәдүт түгел!

Халык:

— Шаһинур әйтсә, хак әйтә!

— Сүз бетте!

— Тукта, ни әйтер икән үзе?

— Карт, сүзең бармы?

Вәдүт. Шаһинур мине таный, ләкин әйтми: гомер буе миңа үчле булды Хәтимә аркасында... Белегез, валлаһи, билләһи, җир йотсын алдасам, мин — шул Вәдүт!

Халык:

— Ышанмыйбыз!

— Исбат ит!

— Ничек исбат итсен ул Вәдүт булмагач?

Вәдүт. Менә син, Ак бабай, беләсең минем Вәдүт икәнне. Әйт!

Халык:

— Ак бабай!

— Кара әле ныклабрак!

— Әллә Шаһинур ялгышамы?

— Якынрак барып кара!

Ак бабай *(Вәдүт янына бара, аны алдан да, арттан да игътибар белән карый)*. Юк туганнар... Мин белгән Вәдүт түгел бу!

Вәдүт. Хәтерлә, бабай, ничек мин сезнең өйдә кәефләнгәч биедем?

Ак бабай. Хәтерләмим... Хәтерләмим...

Вәдүт *(баян тоткан егеткә)*. Уйна бию көен! *(Егет уйный. Вәдүт соңгы көчен җыеп бии башлый, аннан йөрәген тотып, егыла.)* Ак бабай,танысыңмы? Таныдыңмы инде?...

Ак бабай. Вәдүт мәрхүмнең биегәне бик истә. Ләкин син алай ук бии алмыйсың.

Вәдүт *(соңгы өмет белән)*. Ак әби, исеңдәме, сугыштан кайткан көнне мин биегәндә син яулыгың белән күзеңне сөртеп утырдың... Син бит танйысың, бу мин — Вәдүт?.. Кара карчык!.. Син дә, син дә белмисеңме Вәдүтне? «Шаһинурның күңелен Хәтимәдән биздерәм» дип, миннән немецки яулык алганыңны оныттыңмы, ә, әйт, Кара карчык? Мин Вәдүт!

Кара карчык *(егылып яткан карт янына барып, кире кита)*. Алла сакласын, алла сакласын!.. Каян килеп бу кыяфәтсез Вәдүт булсын! Вәдүтнең үлгәненә биш былтыр... Үз күзләрем белән күреп тордым ничек итеп Шаһинурның боз өстендә Вәдүт белән сугышканын, Вәдүтнең су төбенә киткәнен. Я алла, үзең сакла!

Халык:

— Ни сөйли бу карчык?

— Аңа ышансаң!

— Юкны сөйли ул!

— Куып җибәрегез үзен! *(Кара карчыкны куалар.)*

Вәдүт *(үз кайгысы кайгы)*. Димәк ки, танымадыгыз?! Танымагыз! Белдем: авылдашыгыз баеп кайткан, күпсенәсез, көнләшәсез! Шаһинур, син элек тә ярлы булдың, һаман да шулай!.. Кызларым, китмәсен исегез, миңа аларның тануы — кирәк түгел! Минем сезне балаларым итеп тану җиткән! Закон — минем якта! Акчаны кемгә телим — шуңа калдырам! Мөнирә кызым, Энҗе оныгым, култыклагыз атагызны... Киттек кассага, акчаны сезгә яздырам...

Мөнирә. Бабай, миңа сезнең акчаларыгызның кирәге юк...

Вәдүт *(тәмам аптырап, каушап)*. Син... нәрсә... Илле меңнән баш тартасың, башсыз кыз! *(Соңгы өмет, талпыну белән.)* Энҗе, син аның кебек акылсызлык эшләмәссең... Дәү әтиең сиңа ышана... Илле мең синеке, Энҗе кызым, синеке!

Энҗе. Үзеңә булсын, бабай!

Вәдүт *(соңгы өмете сүнеп)*. Димәк ки, барыгыз да бер сүздә! Ләкин шуны да белегез: мин исән, үләргә җыенмыйм әле, мирасны ышанып калдырырлык кеше табарбыз и танытырбыз Вәдүт икәнне! *(Саклык кенәгәсен югары күтәреп.)* Танытырбыз кем икәнне! *(Акрын гына чыга.)*

Халык:

— Шул карт инде бу алайса!

— Тәмам саташкан!

— Илтеп куегыз!

— Килеп алырлар әле!

Алмаз *(керә)*. Шаһинур абый, Мөнирә апа, Энҗе! Картлар йорты белән телефоннан сөйләштем. Чыгып киткән Фәтхулла бабай кичә үк табылган...

Мөнирә *(аңлап алып, авыр адымнар белән Вәдүт киткән якка кита)*. Туктагыз... туктагыз...

Энҗе *(аның артыннан барып тота)*. Әни... бармa!

Алмаз. Картлар миңа Хәтимә бәетенең тагын бер җырын әйттеләр:

Йомшак җилдә җилфердидер
Шаһинурның шинеле.
Шикләнмәгез, чишмәдәй саф
Шаһинурның күңеле.

Мин аңладым: бәетнең ике варианты бар. Берсен кара ниятле явыз адәмнәр чыгарган. Икенчесе — саф күңелле, хакыйкать яклы олы җанлы кешеләр иҗаты.

Мөнирә *(бөтен йөрәк җылысы белән)*. Әти...

Энҗе *(Шаһинурны кочаклап)*. Дәү әти...

Алмаз *(Шаһинур янына килеп, яратып)*. Шаһинур ага... Бәет аркылы аңладым: гомерегез олы юлдан, хаклык юлыннан узган. Бер генә сорау: Хәтимә бәетен ни өчен сер итеп сакладыгыз?

Шаһинур. Кызларымның күңелен яралаудан курыктым, улым... Карамалының яман атын да чыгарасым килмәде. Шуның өстенә үземнең дә *(йөрәген тотып)* менә бу урында төзәлмәс яралар бар бит әле. Кузгатасы килмәгәндер... Аннан соң мин синең кебек егетнең килеп чыгасына һәм бәетне карадан аерып бирәсенә ышанып яшәдем.

Мөнирә. Эти... Халык сине яңадан үз урыныңа кайтуны сорый. Нишләргә уйлыйсың?

Шаһинур. Минем эшем, балалар, менә моннан... буа буарлык! Ә син нишләргә уйлыйсың, Мөнирә?

Мөнирә. Мин синеңчә яшәргә уйлыйм, эти!

Энҗе *(сөенеп)*. Әни! Карамалыдан китмибез! *(Кочаклый.)*

Шаһинур *(яшьләрне кочагына җыеп)*. Рәхмәт, балакайларым... Гомерем заяга узмаган икән... Киттек, өмәгә!

**Барысы да дәртле җыр иштелгән якка китәләр.**

*1980.*

**Пәрдә.**

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

**— Соңгы елларда Сез аеруча мөһим һәм кызыклы булган нинди яңа табылдыкларга юлыктыгыз?**

**МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты:**

**— Соңгы еллардагы кызыклы археографик табышлар арасыннан татар әдәбияты, фольклоры һәм гомумән культурасы өчен зур кыйммәткә ия булган билгесез әсәрләрнең табылуын күрсәтеп үтәр идем.**

**Аларның беренчесе XVIII гасыр азакларында Бәрәскә авылындагы Ибраһим бине Бикчәнтәй мәдрәсәсе шәкерте тарафыннан күчерелгән «Таһир белән Зөһрә» дастаны. Әдәбиятыбыз тарихында аңа кадәр бу сюжетка язылган Кылыч бине Саядның «Бабахан дастаны» гына билгеле иде, ә соңгы табыш әсәрнең халыклашкан, халык дастаны булып әверелгән үрнәге барлыгын да ачты. Арча районы Яңа Мәнгәр авылында табылган бу нөсхәнең әһәмияте шунда: ул татар халкында электән үк дастан жанрының яшәп килүен тагын бер кат раслый.**

**Икенче мөһим табышыбыз XVIII йөз ахырларында Казан җирлегендә язылган зур күләмле «Каһарман китабы» (542 бит) исемле романның кульъязмасы булды. Аны безгә Казанда яшәүче Р. Заманова һәм С. Кәримова апалар тапшырды. Романда геройларның Идел буйларыннан, «Дәшти-Кыпчак» тан башланып, Туран, Иран һәм Һиндстан җирләрендә дәвам иткән мажаралары, сугышлары хакында языла. Бу романның табылуы да XVIII гасыр татар прозасының үсеш дәрәҗәсен билгеләүче мөһим бер күрсәткеч булып тора.**

**Истәлекләрнең өченчесе XIX гасыр башларында Казанда төзелгән татарча фантастик һәм гыйбрәтле хикәяләр җыентыгы. «Хикәятнамә» дип аталган бу җыентыкта барлыгы 40 хикәя бирелгән.**

## Зөфәр Фәтхетдинов

# КЕМ — КЕМНЕ...

ПОВЕСТЬ

13

Лагерьга кайтып җитү белән, Нурмыев отряд командирына Непоновода булган хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Журкинның канәгатьләнүе йөзенә чыкты. Сөенечле хәбәр бит: дошман радисты кулга алынган, никадәр зыян китергән агент үтерелгән.

— Уңышларыгыз белән чын күңелдән котлыйм, Зәки Шәрипович. Рәхмәт яусын сезгә. Дөресен әйткәндә, ул кабахәтләрне тота алуыбызга шикләнә башлаган идем инде. Менә хәзер эшләр җайланыр.

Әмма Зәки шатланырга ашыкмады. Агентның отрядта берүзе генә булмавы ихтимал иде. Бәлки тагын берәрсе посып кына явызлыклар кылып ятадыр? Бу очракта Непоноводагы уңышларның нәтиҗәсе сизелерлек булмаячак. Нурмыев шик-шөбһәләрен шунда ук отряд җитәкчеләренә сөйләп бирергә ниятләде.

Антип Опешевтан сорау алдылар.

Сугыш башланганда төрмәдә утырган икән. Дәүләт милкенә кул сузган өчен хөкем ителгән. Немецлар аны шуннан туп-туры агентлар әзерләп торган курсларга озатканнар. Курсларны тәмамлауга, 1942 елның мартында Непоновога китереп урнаштырганнар. Авылдан өч чакрым чамасы ераклыкта юл буенда бер карт имән бар, мәгълүматларны Глеб кушаматлы агент, шул имән төбендәге яшерен урында калдыра торган булган. Бик ашыгыч хәбәр булганда Глеб өйгә дә килгәләгән. Антип имән янына көн саен гадәттә төнлә барып йөргән. Алынган мәгълүматларны шунда ук шифрлап район үзәгенә — гауптштурмфюрер Дремельгә тапшырган.

— Яшерен урынга тәүлегенә ничә тапкыр бара идегез? — дип кабатлап сорады тикшерүче.

— Бер тапкыр гына. Авыл кешеләре күрмәсен өчен, таң алдыннан. Кузгалак җыярга барган көннәрдә көндез дә күз сала идем.

— Нинди эш белән шөгыльләнгәнегезне хуҗа хатын белә идеме? — дип сорады майор Журкин.

— Юк, әлбәттә. Хатын-кыз белгәнне бөтен дөнья белә, диләр... Мин өйалдында йоклый идем, кереп-чыгып йөргәнемне беркем сизми.

---

Ахыры. Башы 10 нчы санда.

— Алдашмыйсызмы, Опешев? Дөресен сөйләү генә хәлегезне җиңеләйтәчәген аңлыйсыздыр бит?

— Теләсәгез нишләтегез, мин тәүлеккә бер генә тапкыр бара идем. Боерык шундый, аны үтәргә кирәк иде. Урманда банди... партизаннар да еш очрыйлар бит, югыйсә бик тиз эләктергән булырлар иде.

Куыштагылар бер-беренә карашып алдылар. Ничек инде болай? Радист яшерен урынга бер сәгать чамасы барырга тиеш, өйгә кире кайту өчен дә шулкадәр үк вакыт кирәк. Рацияне яшергән урыннан алып көйләү, мәгълүматларны тапшыру — кимендә тагын бер сәгать сорый. Яңалыкларны лагерьдан имән төбенә илтеп җиткерү өчен дә вакыт кирәк бит әле. Димәк, мәгълүматларны лагерьдан район үзәгенә тапшыру өчен кимендә өч-дүрт сәгать киткән. Ә моңа кадәрге тикшерүләр отрядтагы бөтен яңалыкларны дошманның ике сәгать эчендә белүен күрсәтә.

Юк, радист һәм Глеб төп элемтә каналы түгелдер. Гестапога хәбәр башка юл белән тапшырыладыр. Ә бу — отрядта тагын бер шымчы бар дигән сүз.

Радист элемтәгә кергән көннәрне, сәгатьләрне, ул тапшырган радиограммаларның эчтәлеген фаҗигале тәмамланган операцияләр көндәлеге белән чагыштыру да шундыйрак нәтиҗәләр бирде. Элемтәче Глебның «хат ташучы» вазифасын үтәвендә шик юк, отрядта тагын кемдер эш итүе турында Опешевка беркайчан да сөйләмәгән сөйләвен, хәбәрләрне дә үз исеменнән генә тапшырып барган. Глеб кыяфәтен, килеш-килбәтен үзгәртергә чын артист кебек бик оста булган.

Радисттан сорау алу озакка сузылды. Нурмыев соңгы сорау биргәндә кичке аш вакыты җиткән иде инде.

— Күршеләр печәнлегендә куна калган партизаннар белән нигә алай саксыз кыландыгыз? Аларның сезгә зыяны тимәгәндер ич?

— Минем төнлә рация эшләтүемне сезделәр кебек тоелды. Теге дөньяга олактырмасам, янам бит, мәйтәм. Җае да чыкты: иртән авылга немецлар килеп җиттеләр. Файдаланып калырга уйлаган идем, барып чыкмады, сыздылар банд... гафу итегез, партизаннар. Мин шунда ук хуҗаларыма: «Янам, алыгыз моннан»,— дидем. Тик кенә утыр, бернәрсә дә булмас, дип тынычландырдылар. Сизде күңелем, сизде...— Опешев маңгаендагы тирне сөртеп алды.— Бу хәлгә төшүемнең сәбәбе нәкъ шул партизаннардыр инде.

— Әйе, шулар.

— Әй, ходаем, нигә шул вакытта акыллы киңәшләреңне бирмәдең? Төнлә, тавыш-тынсыз гына үзем дә...

Аңламассың бу агентны — әллә инде акылдан шаша башлаган, әллә чыгырыннан чыккан бер бәдбәхет шунда.

Кичке сәгать унда Нурмыев үзәк белән элемтәгә керде.

Шифрорадиограмма

Левчукка

Шымчы-радист Антип Опешев кулга алынды. Гестапога партизаннар турында мәгълүматлар тапшырып яткан. Кулга алганда «Глеб» кушаматлы дошман агенты үтерелде. Бу — элемтәнең өстәмә каналы, дип уйлыйм. Отрядта аз дигәндә тагын бер агент булырга тиеш. Әлегә эзенә төшә алмадым.

Андрей

Шифрорадиограмма

Михайловка

Соңгы ике тәүлек эчендә без урнашкан район аша Урта Идел юнәлешендә унике хәрби эшелон узды. Шуларның сигезенә танклар төялгән, дүртесенә — туплар. Үзйөрешле туплар да күренде.

Журкин

Шифрорадиограмма

Журкинга

Бүген төнлә сәгать икедән дүрткә кадәр самолет каршылагыз. Урын билгеләре элеккечә булсын.

Михайлов

Ишек ачык булса да, куышта инде караңгы иде. Сукыр лампаны кабызырга дип кулына шырпы алуга, ишек шакыдылар.

— Ишек ачык, рәхим итегез,— диде Зәки. Борылып караса, Вера басып тора икән. Куыш кинәт яктырып киткәндәй булды. Зәки шатлыгыннан бер мәлгә сүзсез калды. Ә Вера исәнләште дә, елмаюын яшермичә, шелтәләргә керешге:

— Иптәш авыру, сезне эзләп табу торган саен кыенлаша бара. Ниндидер Непоново авылына командировкаларга йөрисез. Дәвалану кирәклеген онытгыгыз ахры?

— Минем бик барасым килде... Бер дә исемнән чыгармадым...

— Әйдәгез әле, ярагызны карыйк.

Вера саклык белән генә бинтларны сүтә башлады. Күзләрен кыздан ала алмый утырган Зәки, җаен туры китереп, аның кулын үбеп алды. Вераның шелтәле карашы да кәефен боза алмады аның. Соңрак, яраны бәйләп бетергәч, Зәки Вераның кулларын инде кыюрак үпте, гаҗәпләнү чагылдырган күзләренә карап:

— Сезне һәрвакыт күрәсем килә минем,— дип пышылдады. — Әйе, әйе, һәрвакыт... Әллә нәрсә булды. Беркемне дә шулай сагынып көткәнем юк иде...

— Вакытлыча бу, Зәки, узар.

— Юк, Вера, узмас. Мин үземне үзем яхшы беләм.

...Вера куыштан чыгып киткәч тә әллә никадәр бәхет дулкыннарында йөзде Зәки. Әйтелмичә калган сүзләре күңелен алгысытты. Шундый авыр заманда, мәрхәмәтсез сугыш барган көннәрдә туган бу кайнар хис аны бераз аптыраштта да калдырды. Ничек тиз — бер күрүдә сиздә йөрәк үз бәхетен. Сәбәбе нәрсәдә икән?

Бәлки моңа вакыт үзе «гаепледер?»

Сугышта кеше гомере дә еллар белән түгел, көннәр, хәтта сәгатьләр белән исәпләнә бит. Кеше күңеле дә сизгеррәк була. Ә тойгылар, хисләр һәрвакыт табигать законнарына гына буйсыналар.

## 14

Моторларын үкертеп немец самолеты узып киткәндә күктә йолдызлар җемелди иде инде. Бер янып, бер сүнеп барган самолет утларына карап, вакытны төгәл билгеләргә мөмкин. Чыннан да, уникенче ярты иде хәзер. Зәки штабка юнәлде. Повзневтан сорау аласы бар иде.

Көчле дәлилләргә каршы тора алмады Повзнев — гаебен танырга мәҗбүр булды. Яралы Валетовны ташлап калдыруының сәбәбен дә әйтеп бирде: дошман солдатлары килеп чыккач, ут ачмыйча, минерларга хәбәр итмичә качып китүе турында сөйләп бирүеннән курыккан икән.

Партизаннар суды куркак җанга тиешле җәза бирү турында карар чыгарды: Повзнев атарга хөкем ителде. Төнлә Зур җирдән самолет килде. Яңа радист җибәргәннәр икән. Инде күнегелгән «оясын» шул яшь кызга калдырып, Зәки үзе штаб өенә күчте.

Менә тагын йоклый алмый ята әле ул. Алга таба нәрсә эшләргә, ничек табарга шымчыны?

Ракеталар чөю очраклары белән партизан операцияләре арасында бернинди бәйләнеш булмавы расланды. Көн саен дип әйтерлек бернчә төркем юлга чыга, ә ракеталар күренми. Юк, ракеталарны төп элемтә чарасы дип уйлау нигезле булмас. Башка юл белән элемтәгә керә шымчы. Шул даими элемтә чарасын эзләргә кирәк иде.

Иртән лейтенант урыныннан бик авырлык белән генә торды. Башы авырта, авызы кипкән. «Әллә авырып киттем инде? Температура юк бит. Арыганлык сиздерәдер ахры?»

Бүгенге көнне Скишовка багышларга туры килер. Бу вакыйгада

ачыклыйсы урыннар житәрлек, ашыгырга кирәк. Иртәгәгә калдырылган эшне башкару өчен ике тапкыр артык көч түгеләчәгенә Зәки студент чагында ук төшенгән иде. Иртәнге аштан соң, үз карамагына бирелгән разведчиклар белән Скишовны да алып, отряд элек яшәгән урынга киттеләр. Арык атларны никадәр кусаң да файда юк шул: барып житкәнче өч сәгатьтән артык вакыт узды.

Скишов юлда үзен-үзе бик тыныч тотты. Кайда, нәрсә, ничек булганын сөйләп бирү мөмкинлеге аны шатландырды гына кебек.

Тикшерүче тотынган эш башкалар өчен гаҗәбрәк тоелгандыр. Бер карасаң, лагерь уртасындагы бомба чокырыннан Скишов качып яткан тирән чокырга кадәрге араны йөгереп үтү вакыты нәрсәгә хаҗәт инде? Ул гынамы әле. Лейтенант элек отряд яшәгән урынның һәр агачын, һәр бомба чокырын исәпкә алып, рәсемгә күчерә барды. Чүлдәге ком тауларын санау кебек файдасыз эш түгелме соң бу?

Тик Нурмыев башкачарак фикер йөртте. Беренче чокырда качып яту гына немец самолетлары яудырган бомбалардан исән-сау котылу дигән сүз түгел бит әле. Партизан лагере планына карап озак утыргач кына, Нурмыев төпле бер фикергә килде. Бомбага тотылырга тиеш урынның төгәл координатларын очучылар белгән очракта, шымчыга лагерьдан читтәрәк тору файдалырак түгелме?

Сержант Скишов качып яткан лагерь кырыенда лазарет тора. Әмма Скишов монда очраклы гына килеп чыккан, ул хезмәт иткән сакчылар взводы нәкъ лагерь уртасында булган. Шулай итеп, Скишов — дошман шымчысы дип әйтергә урын юк кебек. Кичә үзәктән алынган хәбәр дә аның сөйләгәннәрен раслый.

Скишов кайдан кая йөгергәнен күрсәтте. Ике минут эчендә ярты чакрым ара узган. Ул сикереп төшкәндә чокырда кемдер яткан булган инде.

Нурмыев, лазареттан чокырга кадәр араны чамалап:

— Юлда берәрсе узып китмәдеме?

— Ю-ук. Мин йөгерү буенча хәрби округ чемпионы идем, уздыраммы соң. Миннән соң ул чокырга беркем дә төшмәде. Ивлиев бездән ерак түгел иде түгелен, ләкин нигәдер безгә таба килмәде.

— Яраланган булган, йөгерә алмаган.

Лейтенант чокыр төбенә төшеп як-ягына күз салды.

Скишов кая таба ракеталар чөюен, юнкерсларның бомбаларын кайсы урынга ташлауларын сөйләп бирде.

Чыннан да, лагерьдан ике чакрым чамасы киткәч аеруча күп бомба яудырылган урын табылды.

Яралы Ивлиев ракеталарның нинди юнәлештә очуын тәгаен белә алмый инде. Ә Скишов янында яткан кеше нигә ярдәм итәргә теләми? Димәк, куркырга сәбәбе бар, димәк, ул — дошман. Табарга кирәк аны, табарга! Без эзләгән кеше шул булырга тиеш. Бу чокырга лазареттан гына йөгереп килә алалар. Дошман лазаретта яткан булып чыга!

Нурмыев житәкчесе әйткән сүзләрне хәтеренә төшерде: дөрес фикер йөрткән кеше дөрес җавап табачак!

— Карап карыйк,— диде ул үзалдына.

Скишов аптырап калды:

— Нәрсә дидегез, иптәш лейтенант?

— Юк, болай гына.— Нурмыев кесәсеннән пистолет чыгарып Скишовка бирде.— Алыгыз, кирәге тияр әле.

Дулкынланудан Скишовның күзләре дымланды. Саклык белән генә пистолетны кулына алып, калтыранган иреннәре белән генә:

— Рәхмәт сезгә, иптәш Андрей, ышануыгыз өчен рәхмәт! — дип пышылдады.

## 15

Көннең икенче яртысында отрядка кайтырга чыктылар. Бормалы тар юл анда-монда үскән агачлар арасыннан бераз баргач, гитлерчылар тарафыннан тулысынча яндырылган авылга килеп чыга. Авылны узгач, юл киңәя, тигезләнә, сугышка кадәр олы юл төзү өчен өелгән дамба аша үтеп, карурманга кереп югала. Урман авызы тозак кору өчен бик җайлы урын. Шунлыктан ике партизанны күзәтеп килергә җибәрделәр. Дошман юклыгын белдереп кул болгагач кына инеш буена төшеп атларга су эчерергә булдылар.

Эссе көндә хәйран юл үткән арык атлар сусауларын баскач, юлны дәвам иттеләр. Яндырылган авыл, шул авылның бөтен кешесе бергә күмелгән зур чокыр янынннан узу партизаннарда авыр тәэсир калдырды.

Куе урманның салкынча саф һавасы, кошларның салмак җырлары гына бүлде кайгылы уйларны. Лагерьга ерак калмаганын сизгәндәй атлар да адымнарын тизләттеләр. Кипкән нарат энәләре һәм күркәләре, вак ботаклар түшәлгән юл тирән чокыр ярына барып чыкканда партизаннар инде барысы бер төркем булып баралар иде. Чокыр төбендә вак усаклык, ә ике ярда мәһабәт наратлар.

Кинәт автомат һәм пулеметлардан аткан тавыш урманны яңгыратты. Һәлакәт якынлыгын хәбәр итүче бу тавыш кайтаваз булып бөтен урманга таралды. Аңа яралы атларның ярсып кешнәве, кешеләрнең ачынып кычкыруы өстәлде.

Нурмыев атланган ат гөрселдәп җиргә ауды. Җайдак та берничә метр читкә очты. Алдагы атта баручы сакаллы партизан иярдән шуып төшкәнче үк һәлак булган иде инде. Бер атлы туры чокырга сикергән иде, аннан да ату тавышлары ишетелде. Димәк, анда да тозак куелган! Кичекмәстән кире борылырга кирәк! Артына борылып караса — анда да соры шинельләр тезмәсе күренде.

Нурмыев шмайссердан [1] ут ачты. Янәшәдә генә тагын кемдер исән икән, автоматтан ата башлауга, берничә фашистны дөмектерде. Башкалары агач артларына посып атарга керештеләр.

Кая карама — немец солдатлары. «Божраны кысалар!» — дип уйлап алды Нурмыев. Юл буендагыларның берсе, граната ыргытырга теләп, нарат кәүсәсе артыннан күренүгә билгесез мәргән автоматы телгә килде. Немец солдаты гранатасын кулыннан төшереп җибәрде, көчле шартлау аның гәүдәсен читкә алып ыргытты. Дошманнар тагын да котырыныбрак ата башладылар.

Нурмыев та тешләрен кысып атуын дәвам итте.

Якында гына кемнеңдер:

— Иптәш командир! — дип эндәшкәнен ишетте. Борылып караса, Арон белән Скишов аңа таба шуышалар икән.

Арон ашыгып сүз башлады.

— Чокырга таба шуышырга кирәк, иптәш командир, башка чара юк.

Зәки анда да тозак корылган булуын аңлатып:

— Көтәләр анда безне, Арон. Тереләй кулга төшерергә уйлыйлар,— диде.

— Тотсыннар...— Арон ачы итеп сүгенеп куйды. Бил каешыннан «лимонка» алып учына кысты.— Мин аларны үзем белән теге дөньяга алып китәм. Әле минем алар белән исәп-хисап өзелмәгән!

Нурмыев Скишовка күз салды. Ул да ахырга кадәр сугышачак, үлемгә барырга да риза күренә иде.

Тиздән патроннар бетте. Ауган нарат артыннан берәү:

— Steẻt auf! Hende hoch! [2] — дип боерды.

Икенчесе русча сукалады.

---

[1] Шмайссер — гитлерчылар коралланган автомат.

[2] Торыгыз! Кулларыгызны күтәрегез!

— Стафайтесь! Просте автомат! Ходи суда! Рукки фферх! [1]

Хәлләре бик мөшкел иде партизаннарның. Өчесенә биш граната һәм Скишов пистолетындагы берданбер патрон: ул соңгы укны үзенә дип калдырган иде.

— Менә нәрсә, егетләр,— дип башлады сүзен Нурмыев.— Соңгы мөмкинлектән файдаланып карарга кирәк. Алар безне чокырда көтәләр. Я булмаса кире борылырлар дип уйлыйлар. Турыга, бертуктаусыз атып торган пулеметка таба барырлар дип башларына да китермиләр. Ә без нәкъ шулай эшлибез. Я, ничек, сез ризамы?

— Башка чара юк,— дип җавап бирде Скишов.

— Андрей, алдан мин барыйм. Сугышка кадәр мин фокусчы һөнәренә өйрәнгән идем, кулларым җитез. Ун-унбиш адымнан кулымдагы лимонканы күрә алмаслар.

— Әйдә, Арон, башлап җибәр «чыгышыңны».

Егет башта чекалары алынган ике гранатаны чәнчә бармаклары белән кысып учларына яшерде. Аннан автомат каешын имән бармакларына элеп, кулларын күтәрде дә:

— Nicht schliessen [2].— дип кычкырганнан соң, биреләчәген аңлатып автоматын читкә ыргытты.

Арон артыннан, кулларын күтәреп, Нурмыев белән Скишов атладылар.

Ун-унбиш адым ара узгач кына агачлар арасыннан офицер житәкчелегендә унлап автоматчы күренде. Офицер белер-белмәс рус телендә туктарга боерык бирде. Әмма партизаннар, аңламаган кебек, атлый бирделәр. „Halt" [3] дип кычкырган ачы тавыш һәм автоматларның атарга әзерләнүе генә партизаннарны туктата алды.

Шул ук мизгелдә Арон, яшен тизлегендә агач артына сикереп, бер-бер артлы ике гранатасын да пулеметка таба томырды. Ә Нурмыев гранаталары офицер һәм солдатлар өстенә очтылар.

Алдан сөйләшү буенча, Скишов әлегә резервта: ул соңгы граната белән исән калган фашистларны дөмектерергә тиеш иде. Ә инде уйланган эш барып чыкмаган очракта граната белән иптәшләрен шартлатырга, соңгы укны — үзенә...

Гранаталар берсе артыннан берсе шартладылар. Аптырашта калган дошман солдатлары җиргә ташланырга да өлгермәделәр, шартлау дулкыны, бихисап күп ярчыклар аларны кырып ташлады. Шуннан файдаланып, партизаннар бөтен көчләренә алга омтылдылар. Немецлар аңнарына килгәнче өлгерергә кирәк.

Аронның бөтен теләге пулеметны кулга төшерү иде. Ауган агач аша сикерүгә ул теләгенә иреште дә.

Шартлаудан контузия алган бер солдат тезләнгән дә уңга-сулга башын боргалый. Офицер да исән икән, аягүрә басмакчы булган иде, хәле җитмәде инде яткан килеш кенә пистолетын капмалап маташа иде.

Җирдә аунап яткан немецларга таба йөгерүче Нурмыев боларның берсен дә сизмәде, күрмәде. Тезләнгән солдатның кулыннан автоматын тартып алды да Арон янына, ауган агач артына ташланды.

Скишов унбиш-егерме метрга арткарак калган иде. Ул офицерның Нурмыевка атарга теләвен күреп, юлбарыстай аның өстенә сикерде. Пуля һавага очты. Ату тавышына әйләнеп караган лейтенант гомерен Скишов кына саклап калуын аңлады.

Сержант хәйран җитез, булган егет икән. Тиз генә офицерның пистолетын кулына алды да як-ягына күз ташлады. Яр читендәге куаклар

---

[1] Бирелегез! Коралларыгызны ташлагыз! Монда килегез! Кулларыгызны күтәрегез!

[2] Атмагыз!

[3] Тукта!

аша дошман солдатлары аларга таба йөгерәләр. Соңгы гранатаның да файдасы тиде — немецлар кире яр астына коелдылар.

Арон пулеметны җайлап куюга ярга таба пуля яудырырга тотынды. Бәхеткә каршы патроннары да җитәрлек. Ул арада Скишов та килеп җитте.

— Чигенәбез! — дип кычкырды лейтенант.

— Командир! Ярда тагын немецлар! — Скишов аунап яткан автоматны эләктереп озын чират бирде. Аңа Арон пулеметы да кушылгач немецлар тагын яшеренергә мәҗбүр булдылар.

Партизаннар өчесе дә, артларына борылып ата-ата, яр буйлап йөгерделәр. Чокыр төбеннән немецлар чаба, юлны кисәргә телиләр иде ахры. Чыннан да, акырып-бакырып, куе куаклар аша юлга чыгалар түгелме? Моны күргә, Нурмыевның планнары үзгәрде, ул куе куаклар, йөзьеллык наратлар каплаган биеклекне күрсәтеп:

— Әйдәгез тизрәк шунда! — дип боерды. Ул үр артында куе урман башлана, дошманнан качып котылу җиңелрәк булачак иде. Тик шунысы бар: үргә менгәндә дошман аларны ачыграк күрәчәк. Берничә минуттан ату шулкадәр көчәйде ки, партизаннарга чыннан да җиргә сыенырга туры килде. Ерак та калмады югыйсә, бары илле метр чамасы, тик юк шул, ук яңгыры баш күтәрергә дә ирек бирми иде.

Немецлар, берничә төркемгә бүленеп, тагын аларга таба йөгерә башлаган иде, Арон пулеметы бик тиз таратты үзләрен. Әмма дошман уты туктамады. Инде куаклыкта да дошман солдатлары күренә башлады. Бөтенләй чолганышта калу куркынычы партизаннарны урыннарыннан кузгатты. Агач араларына яшеренә-яшеренә тагын йөгерделәр. Үргә менеп җиттек дигәндә генә ук Скишовны аяктан екты.

— Калдырыгыз мине... Барыбер исән калмыйм...— диюенә карамастан, иптәшләре аны күтәреп түбән таба йөгерделәр. Хәл алырга туктауга, Скишов, күзләрен ачып, ике генә сүз әйтә алды:

— Рәхмәт... дуслар...

Нурмыев үле Скишовның башын күкрәгенә кысты:

— Хуш, дустым... Бәхил бул!..

Арон яңадан — пулеметына ябышып, соңгы патронга кадәр атты да, инде кирәге беткән пулеметны читкә ыргытты.

— Бәйрәм тәмам, командир,— диде ул карлыккан тавыш белән.

...Бераздан алар куе урманга килеп керделәр. Хәзер инде дошман аларны күрми, бары чамалап кына ата. Әмма уклары әле һаман хәйран ачы сызгыра иде.

Иңкүлеккә төшеп, болганчык су итекләргә кунган тузанны юа башлауга, Арон нечкә усакка ябышты да туктап калды.

— Аякка эләктерделәр, кабахәтләр,— диде ул ыңгырашып.

Калган дошман солдатлары да үргә менеп җиттеләр ахры, ату тагын көчәйде. Немецлар якын, менә-менә куаклар арасыннан килеп чыгарлар кебек иде.

Лейтенант автоматны муенына асты да, Аронны җилкәсенә күтәреп, юлын дәвам итте.

— Командир... икебез дә кача алмыйбыз бит... Бир автоматыңны, мин аларны тоткарлармын...— Арон кипкән иреннәрен ялап тагын кабатлады.— Андрей... Бир дим автоматыңны, бир, мин тоткарлармын...

Хәлдән тайган лейтенант Арон әйткәннәрне әллә ишетмәде, әллә аңламады. Дөресен әйткәндә, башы шаулый башлау бернәрсәне дә ишетерми иде. Күз аллары караңгылангач, аяклары атламас булгач кына туктады ул. Инде кечкенә сазлыкны узып, коры җиргә чыкканнар икән. Аронны яшь усаклар төбенә яткырды. Күп кан югалту нәтиҗәседерме, Арон аңын югалткан иде. Нурмыев бил каешын салып, ярадан өстәрәк аның аягын буып куйды. Инде тирә-якка күз салырга да була. Ату тавышлары сирәгәйде, берән-сәрән генә ишетелә. Кайдадыр читтәрәк

немецча сөйләшәләр. Инде нишләргә? Тукта әле, әллә кайчангы тәгәрмәч эзе шәйләнә түгелме соң? Котылу өчен башка чара юк кебек. Лейтенант тәгәрмәч эзенә башта Аронны салды, аннан үзе дә ятып, өсләренә чыбык-чабык таратты. «Этләре юк бугай, үзләре күрмәскә тиеш. Арон гына ыңгырашмасын иде инде».

Берничә минут вакыт узуга, гитлерчылар килеп чыкты. Алар артыннан — полицайлар. Икесе үзара кычкырып русча сөйләшә:

— Бәхет бар икән, малай. Ярый әле чокырда калдык, юкса баш беткән иде бит.— Туктап тәмәке кабыздылар.— Уктан котылган очракта да исән калу чамалы иде. Гауптштурмфюрер Дремель агач ботагына «элеп» куйган булыр иде. Бу «урман җеннәрен» кайда эләктерергә икәнен безнең хуҗаларга ул үзе әйткән ди бит. «Берсе дә ычкына алмасын»,— дигән.

Полицай йөткереп алды.

— Әйдә,— диде икенчесе.— Я унтершарфюрер Шетцель килеп җитәр. Куркак җаннар исемлегенә кертер үзебезне.

Бераздан аяк тавышлары тынды. Инде ату тавышлары да ишетелми башлады.

Зәки кинәт кошлар җырын, салмак җилдә яфраклар кыштырдавын ишетте. Биек нарат башлары кояш нурларында коена. «Рәхәт бу наратларга, сугышмы, түгелме — барыбер,— дип уйлап алды ул.— Юк, алай түгелдер. Агачларга да хәйран эләгә бу сугышта. Сугыш бит кешеләрне дә, табигатьне дә аямый».

— Беркемне дә аямый,— дип өстәде ул үзалдына.— Сугыш һәрвакыт — үлем туе. Ул кешеләрне ачлык-ялангачлыкка дучар итә, башка күп кайгы-хәсрәтләр алып килә.

Кинәт Арон ыңгырашып куйды. «Нигә әле ул дөньясын онытып ята?»

— Хәзер, дускай, хәзер, аз гына түз, яраңны бәйлибез дә юлга чыгарбыз.

Алар лагерьга икенче көнне кичен генә кайтып җиттеләр. Разведчиклар аларны бертуктаусыз эзләгәннәр, ләкин таба алмаганнар икән.

## 16

Лейтенантның озак сөйләшеп утырырлык хәле калмаган иде. Кайда, ничек засадага очрауларын, Скишовның батырларча һәлак булуы турында кыскача әйтеп бирүгә, үзе дә сизмәстән, утырган килеш йокыга китте. Уятырга базмадылар, күтәреп алып, командир ятагына яткырдылар. Артык талчыккан кешенең йокысы да тынгысыз була — лейтенант йокы аралаш партизаннар ни сөйләшкәнен ишетеп ятты.

Отряд командиры Скишовның үлеме турында туганнарына хәбәр итәргә кушты.

...Лейтенант йокыдан бик авырлык белән торды. Буыннар сызлый, баш авырта, әйтерсең, кичтән хәйран гына хәмер чөмереп йоклаган иде. Теләр-теләмәс ике бәрәңге генә ашады да, лазаретка, яралы дустының хәлен белешергә китте. Кояш инде көндәлек юлының яртысын диярлек үткән, күләгәләрнең иң кыска вакыты. Кошлар җыры, чикерткәләр чиратлашып башка вакытта яхшы концерт кебек яратып тыңлый иде, ә бүген бу тавышлар лейтенантка фикер тупларга комачаулады.

Тозакка очраулары очраклы хәл генәме, әллә махсус куелган капкынмы? Юк, махсус безне көтеп торулары мөмкин түгел! Минем элекке лагерьга китүемне гауптштурмфюрер Дремель кайдан белсен ди? Бу турыда элек тә берничә кеше генә белә иде, хәзер исә аларның өчесе генә исән: отряд командиры, штаб башлыгы, һәм Арон. Берсе дә шикләнерлек кеше түгел. Әмма тозакның, вакытын белеп, алдан әзерләнгән булуы шик тудыра. Полицайлар сөйләвенә караганда, тозакны гестапо башлыгы Дремель үзе корган. Шулай булгач, безне көткәннәр дияргә дә нигез бар.

Бу күңелсез нәтиҗә лейтенантка бик авыр тәэсир итте. Дремельнең юк-бар эшләр белән шөгыльләнмәвен ул яхшы белә иде. «Капкын безнең өчен куелган дисәң, кайсы юлдан үтәчәгебезне алар ничек белгәннәр? Хәер, кая баруыбызны белгән очракта, иң кыска юлны эзләп табу кыен эш түгел инде. Гаҗәп бит, гестапо минем һәр адымымны чамалап тора».

Нурмыев кинәт баскан җирендә катып калды. Әй, ахмак! Шымчы кая барачагыңны син лагерьдан чыгып киткәнче үк белгән, ләбаса. Ул, Скишовның сак астында утыруын белеп, аны күздән ычкындырмаска тырышкандыр. Ә инде унлап партизан белән алып китүләрен күргәч, кая юл тотулары ачык ич инде, әлбәттә, иске лагерьга. Скишов сөйләгәннәрнең дөреслеген ачыкларга! Шымчыны табарга мөмкинлек бирәчәк җеп очы да шунда бит.

Шымчы ничегрәк фикер йөртте икән?

Скишовның бомбага тоту вакытында тирән чокырда үзе генә булмавын әйтүе шиксез. Тикшерүче таныш булмаган партизанны эзли башлаячак һәм ике-өч көн эчендә агентның эзенә төшәчәк. Шымчы моны яхшы аңлагандыр.

Нурмыев картлар кебек авыр сулап торды. Нигәдер һава җитми кебек. «Ул шуннан курыккан да инде. Уңайлы шартлардан файдаланып, куркыныч шаһиттан, аның белән бергә миннән дә котылырга ниятләгән. Башка чара юк бит. Отрядтан качса гына инде».

Бөтенесе туры килә, иптәш тикшерүче, диде Зәки үз-үзенә. Әлегә син вакыйгаларга бәя биреп кенә утырасың. Алдан күрә белсәң, мондый хәлдә калмас идең!

Лейтенант янәшәдәге чыршыга барып сөялде. Үзең эләккән капкынны, партизан отрядының «авыр чүкече» белән суккалып-каккалап, файдалы эштә кулланып булыр иде. Башкача әйткәндә, сиңа дип казылган чокырга дошманның үзен төртеп төшерергә мөмкин иде. Скишов та исән калыр иде. Эх, шайтан алгыры!

Зәки хәлсезләнеп, якында гына җирдән калкып торган агач тамырына барып утырды. Үзенең көчсезлегенә, еш ялгышуына ачуы килә иде аның.

Шактый шулай үзен-үзе сүгеп, уйга бирелеп утырды ул. Башын күтәреп як-ягына караса, кояш инде агачлар артына кереп югала язган. Юк, болай хискә бирелеп озак утыру ярап бетмәс, үз-үзеңне кулга ал, иптәш тикшерүче, җавап табасы сорауларың хәйран бит. Беренчесе, иң катлаулысы: шымчы хуҗалары белән ничек шулай тиз арада элемтәгә кергән икән соң?

«Без иске лагерьга кадәр өч сәгать чамасы бардык. Анда бер сәгать чамасы булдык. Тагын ике сәгать ярымнан тозакка очрадык. Димәк, без лагерьдан чыгып киткәнгә биш сәгать ярым вакыт үткән булган. Гестапо җитәкчеләренә тозак кору өчен көч тупларга, тиешле күрсәтмәләр бирергә, гаскәрне кайда урнаштыру турында уйларга кирәк иде. Район үзәгеннән урман юлына килеп җиткәнче дә шактый вакыт уза. Бөтенесен исәпкә алсаң, лагерьдагы шымчының гестапо башлыгы Дремельгә хәбәр итү өчен ике, ике сәгать ярым вакыты калуы беленә. Тагын «ике сәгать — ике сәгать ярым». Башка очракларда да шулай иде.

Бик югарыда көнчыгышка таба очып үткән самолет гөрелтесе Зәкинең уйларын бүлде. Ул утырган урыныннан торып партизан шифаханәсенә юл тотты.

Лагерь өстеннән немец самолетләры очуы да шикләндерә. Бу очышлар белән шымчы эшчәнлеге арасында нинди дә булса бәйләнеш бар микән? Бу турыда тикшерүченең әллә ничә тапкыр уйлаганы бар инде. Игътибар итмәслек тә түгел бит: көн саен кичләрен сәгать ярым саен бер очып үтәләр. Ә бүген ул бәйләнеш барлыгына нык ышанды. Әйе, әйе, бөтен эш шул самолетларда. Самолетлар сәгать ярымга бер очалар, ә гестапо яңалыкларны ике сәгатьтән генә белә, дип аптыраган идем. Очучыларга алынган хәбәрләрне эшкәртеп гестапога җиткерү өчен дә вакыт кирәк бит

әле. Гестапо гарнизоннарга хәбәр иткәнче дә вакыт үтә. Менә сиңа ике сәгать — ике сәгать ярым! Әй, ахмак, шуңа да башым җитмәгән бит!

Ә самолетларга ничек хәбәр итеңә? Бу сорауга да җавап табарга кирәк әле. Нурмыевның хәтерендә: болытлы көннәрне самолетлар агач башларына тияр-тимәс очып үтәләр, ә аяз булса — мең метр чамасы биеклектә. Димәк, радио турында сүз дә булуы мөмкин түгел, бары оптик җайланмалар, күз күреме турында гына. Агентның радиотапшыргычы булса, самолетларның нигә кирәге бар ди. Бер генә юл кала — яктылык сигналлары! Яктырткыч ракеталар да эзлекле рәвештә күренми. Бу очракта иң җайлысы — көзгеле кайтарткычы, төсле пыялалары булган кесә фонаре. Отрядта кемнәрдә бар икән андый «уенчыклар»? Мәгълүматлар кесә фонаре ярдәмендә тапшырылса, нигә моңа кадәр беркем дә күрмәгән? Бер уйлаганда, ничек күрсеннәр инде. Чормадан яки түбәдәге тишек аша эш итсәң, яктылык сибелүе җирдәгеләргә күренми бит. Нурмыев лагерьдагы куышларны күңелдән барлап чыкты: ачык түбәлеләре юк. Өстәвенә аларда берничә кеше бергә яши, яшерен эшләр белән даими шөгыльләнү һич тә мөмкин түгел. Шул чак шифаханә түбәсенә күзе төште Зәкиненң. Карале, дускай, бу «гиппократ йорты» чормасыннан сигналлар тапшыру бик җайлы түгелме соң? Түбәне агач башлары каплап тормый, тирә-якта биек-биек агачлар үсә. Чыннан да яктылык сигналларыннан файдалануга бик ышанып кына бетә алмый үзе. Әмма башка элемтә чаралары да башка килми.

Бомбага тоту вакытында Скишов белән бергә чокырда утырган билгесез кеше дә лазареттан чыккан булырга тиеш. Моны берәнче шик. Ә икенчесе — чорма аша яктылык сигналлары тапшыру мөмкинлеге.

Гаепсез кешегә күләгә төшермичә, ә гаеплеләрне, әгәр андыйлар лазаретта чыннан да бар икән, куркытмыйча гына тикшерү үткәрәсе иде.

Бераз уйланып торганнан соң Нурмыев болдырга таба атлады. Лазарет янында бер төркем яралылар кайсы төпкә, кайсы махсус ясалган утыргычларга утырган иде. Җирән чәчле, сипкелле яшь егетнең сөйләвен тыңлыйлар. Бер күзен хәйләле кысып, тегесе шундый кызыклы хәлләр сөйли, ә яралылар шундый бирелеп тыңлыйлар, кергән-чыккан кешегә игътибар итү дә юк. Зәкиненң күңелен бер-берсе белән килешә алмаслык ике хис билəп алды. Беренчедән, монда аның сөйгәне Вера эшли, шунлыктан шифаханә аңа туган йорты кебек якын. Икенчедән, бу бина шикләндерә, борчый.

Вераны күрәсе килүдән йөрәге ашкыныбрак тибә башлады. Кайда икән аның кадерлесе?

Бер заман баскыч төбендәгеләрнең шаркылдап көлүе ишетелде. Ә җирән егет сөйли дә сөйли:

— Бервакыт тагын да кызыклырак вакыйгага юлыктым ич әле мин. Абыйны халык утырышчысы итеп сайлаган иделәр. Ул мине үзе катнашкан беренче утырышка чакырды. Бер сүз белән әйткәндә, бер мәзәк ир-атны хөкем итәләр икән. Судья моңа сүз биргән иде, әй китте бу сөйләп! «Бу кешене, ягъни Прорехинны тукмавым хак. Кабыргаларын санадым мин аның. Сәбәбен белергә телисезме? Оятсыз кеше ул, искиткеч оятсыз. Үзегез уйлап карагыз. Мин аның ике кабыргасын, балконыма икенче каттан өченче катка үрмәләп менгән өчен сындырмадым (Альпинист имеш!). Балкондагы чәчәкләрне таптавы өчен дә түгел (Ботаникмыни ул?!). Хәтта минем хатын белән рояль өстендә оятсыз рәвештә зина кылуы өчен дә түгел. Фатирымнан чыгып барганда: «Мин әле тагын киләм», дигән сүзләре ярсытты мине, шуның өчен кыйнадым. Карале син аны, хуҗа булган имеш!»

Яралылар тагын дәррәү көлештеләр. Көлүдән туктагач, өлкән яшьләрдәге берсе:

— Әйт әле, Митюшка, ул альпинист син үзең түгел идеңме? — дип сорады. — Шундыйга бик охшаган бит син, ә?

Жирән егет үпкәләде булса кирәк, тәмәкесен ташлап бер тәкерде дә, лазаретка кереп китте.

Ишекне япкач өйалдында караңгы икән, кайда нәрсә барлыгын күрү кыен иде. Капмалана торгач, бер почмакта яшь чыршы кәүсәсеннән ясалган баскыч табылды. Зәки саклык белән генә чормага үрмәләде. Кояш хәйран кыздырганлыктан, һава бик бөркү иде.

Шифаханәдәгеләр сизмәсен өчен, итекләрне салып, ялanaяк йөрергә туры килде. Һәр тактаны үз кулларың белән капшап карарга туры килә, бәлки берәрсе кадакланмагандыр? Сигнал бирерлек тишекне табарга кирәк иде. Берничә минуттан тикшерүченең кәефе тәмам кырылды: тишек тә, кадакланмаган такта да күренмәде. Вакыт-вакыт аста кемнәрнеңдер сөйләшүе ишетелеп ала. Сакланунын зыяны тимәс. Белмәссең, бәлки шымчы үзе монда менәр? Көтелмәгән эшләр эшләп ташлый бит ул. Чыннан да, шул минутта баскыч шыгырдаган кебек булды. Нурмыев, пистолетын әзер тотып, морҗа артына яшеренде.

Ничек озак үтә вакыт. Дулкынланудан аркасыннан, маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. Юк, менмәскә уйлады ахры, авыр адымнар белән кире чыгып китте. Тикшерүче, аяк очларына гына басып, стена буена килде. Өйалдында беркем юк, тышкы якта гына сөйләшү ишетелә иде. Ә баскыч инде башка урында. Димәк, кемдер менәргә теләгән! Әллә үзе куркыттымы? Бәлки болай гына алып куйгандыр? Алай дисәң, кемгә комачаулаган икән соң ул баскыч?

Аннан соң ул озак кына фонарь эзләде, ләкин таба алмады. Өмете өзелә кебек тоелды аңа. Инде төшәм дигәндә генә чорма бәпкәләренә корым саруына игътибар итте. «Кызык, нигә монда төтен чыга икән? Морҗасы яхшы эшләнгән кебек бит. Гаҗәп». Лейтенант яңадан морҗа янына килде. Бер метр чамасы өлеше кирпечтән эшләнгән, яхшы гына сыланган. Өске өлеше — телеграф баганасы юанлыгында тимер торба. Морҗа тирәли түшәмгә ком җәелгән. Тикшерүче, кесәсеннән зажигалка алып, түшәмгә тезләнде. Менә сиңа мә! Комда циркуль белән сызган кебек түгәрәк эзләр. Тимер торба эзе бит бу! Димәк, аны кирпечләр өстеннән алып, комга куеп торганнар. Ә торбаны алгач, түбәдә сигнал бирү өчен бик уңайлы тишек кала!

Торба чыннан да бик җиңел алына икән. Диаметры да комдагы түгәрәкләрнекенә туры килә. Әгәр кирпеч өеменә бассаң, тишек аша тирә-якны да күзәтеп була. Иң әһәмиятлесе шунда — тишек түбәнең самолетлар очып үтә торган ягында, яктылык сигналларын бирергә бик җайлы.

...Никадәр игътибар белән караса да, комда аяк эзләре табылмады. Торбаны урынына куеп, үзе калдырган эзләрне себергәләгәч, Нурмыев чормадан төшеп китте.

## 17

Лазарет бусагасын атлап кергәндә Нурмыев үзен имтиханга килүче студент кебек хис итте. Ул җавап табарга тиеш сораулар чыннан да гаять катлаулы бит: беренче чиратта шикләнүләренең урынлы икәнлеген расларлык дәлилләр табып, шымчының лазаретта булуына башкаларны гына түгел, үз-үзеңне дә ышандырырга кирәк. Лазареттагыларның кайсысы агент: хезмәткәрләрнең берәрсеме? Әллә авыруга салышып ятучымы? Бу очракта аны фаш итү авыр булачак, чөнки тикшерү өчен отрядта уңайлы шартлар да, тәҗрибәле белгечләр дә юк.

Әйе, баштагы уйларның, шикләрнең чиге күренми. Бер генә жылы хис — Вераны сөюе генә йөрәген ашкындыра да, тынычландыра да.

Вера да, врач Губин да каядыр чыгып киткәннәр иде. Нурмыевны санитар Никифоров каршы алды. Кырыс йөзле, авызыннан сүзе чыкмас бу ир уртасы кеше Зәкине авыр яралылар яткан эчке бүлмәгә озатты.

«Бу санитарның аяк атлаулары теге көнне өйалдында йөргән бәндәнеке кебек. Бәлки, баскыч янында ул маташкандыр?»

Арон берничә көн эчендә шулкадәр үзгәргән иде ки, Зәки аны чак таныды.

Операцияне Губин ясаганын белә иде ул. Әмма сугышчан дусты белән сөйләшеп утырырга туры килмәде — Арон йоклый иде.

Штабка килүгә, лейтенант отряд командирына үз фикерен кыскача сөйләп бирде: немец самолетларына сигналлар лагерьдан, дөресрәге, госпиталь чормасыннан тапшырылган булырга тиеш.

Бөтен нәрсәгә тыныч караучы Ковригин урыныннан сикереп торды.

— Мин моңа ышанмыйм. Бу эшне шулай ансат эшләп буламыни?

Лейтенант өчен командир җавап бирде:

— Була, була. Шымчы лагерь эчендә рациядән файдалана алмый. Шулай да ике сәгать эчендә аның хәбәре хуҗаларына барып җитә. Димәк, шушы чара гына кала. Бу беренчесе. Икенчесе: кул астында берничә төсле пыяла һәм ике фонарь булганда, алдан килешенгән шартларга туры китереп, самолетларга күп нәрсә хәбәр итәргә мөмкин. Әйтик, кызыл фонарь яна икән — отряд җитди операциягә тотынды, дигән сүз. Яшел ут — шартлатучылар төркеме юлга чыгуын аңлатырга мөмкин. Самолетлар сәгать ярымга бер очып үтәләр. Шуның буенча теге яки бу эшнең кайчан башлануы беленә, каршы торырга әзерлек чаралары күрергә дә өлгерәләр. Ә инде берничә төс, мөгаен, тагын нindидер мәгънәләр аңлатадыр. Шулай бит, иптәш тикшерүче?

— Бик дөрес, иптәш командир.

— Кемнән шикләнәсез? — дип сорады Ковригин кыюсыз гына. Әйтерсең, аның үзенә ышанып бетмиләр.

Нурмыев ачык кына җавап бирергә ашыкмады.

— Медицина хезмәткәрләрен, лазаретта озак ятучы авыруларны күздә тотарга кирәк,— диде ул.— Миңа аларның чын исем-фамилияләре, автобиографияләреннән кайбер мәгълүматлар кирәк булыр. Һәрберсе турында берничә сүз әйтеп китүегезне үтенәм.

— Ярый, эшләрбез,— диде Ковригин тонык тавыш белән. Ул нәрсә турындадыр бик нык уйлый иде.— Фонарьларны табарга кирәк, Зәки Шәрипович. Шунсыз сез әйткәннәргә ышану кыен.

— Нәрсәгә ышанмыйсыз? — дип сорады Зәки тыныч кына.

— Яктылык сигналлары турында да... Комда калган торба эзе генә факт була алмый бит әле. Бәлки ул эзләр морҗа башын эшләгәндә калгандыр...

— Эзләр бик ачык, әйтерсең торбаны берничә сәгать элек кенә комга куеп торганнар. Эзгә ком бөртекләре дә бик аз коелган. Нәтиҗә ясау өчен...— Дулкынланудан Нурмыевның бугаз төене хәрәкәткә килде.

— Зинһар тынычланыгыз, Зәки Шәрипович,— диде майор Журкин.— Сүзләрегезнең хаклыгына башкаларны ышандыру җиңел эш түгел, моның өчен аерым бер осталык кирәк. Кайвакыт кешеләрне ышандыру берәр эшне тормышка ашыру кебек авыр була. Кайберәүләр үз куллары белән тотып карамыйча ышанмыйлар. Бүгенге сөйләшүне иҗади бәхәс дип кабул итик.

Отряд командиры, урыныннан торып, ишекле-түрле йөргән уңайга тәмәке кабызды. Берничә тапкыр суыргач, сүзен дәвам итте:

— Менә нәрсә, дусларым. Сезгә гомуми хәлне яхшы белү дә кирәк. Бигрәк тә безнең шартларда. Район үзәгендә эшләүче иптәшләребез хәбәр иттеләр: ике көннән бу тирәгә фронттан хәрби частьлар күчереләчәк. Яңадан оештыру, тулыландыру өчен, янәсе. Инде торак урыннарны да әзерләп куйганнар. Бу гаскәрләрне безгә каршы җибәрүләре мөмкин. Күрше отрядтан рация буенча хәбәр иттеләр: бүген иртән аларны камап алганнар. Район үзәгендә тукталыш ясап тормыйча, килеп җитүгә, безгә ташланулары мөмкин.

— Димәк, күп дигәндә өч-дүрт көннән безгә яңа урынга күчәргә туры киләчәк. Үзебез белән шымчыны ияртеп йөрү яхшылыкка алып бармас. Әгәр аны шушы көннәрдә табып, дөмектерергә өлгермәсәк, соңрак авыр булачак.

Отряд командиры тәмәке төпчеген сүндереп почмакка ташлады да бүкәнгә барып утырды. Бераз тынлыктан соң Ковригинга күрсәтмәләр бирде:

— Взводларны лагерьдан читкәрәк: һөҗүмгә каршы тору өчен дә, бомбалаудан саклап калу өчен дә уңайлырак җиргә урнаштырыгыз. Һөҗүм алдыннан козгыннар кебек ябырыла торган гадәтләре бар... Отрядны ерак постлар тирәсенә урнаштырыйк, дозорларны тагын да читкәрәк. Берәр хәл булган очракта хәрәкәт итү җиңелрәк булыр. Яңа окоплар, ут оялары казырга кирәк.

Ковригин урыныннан торып бил каешын, гимнастеркасын рәтләде.

— Китәргә рөхсәт итегез?

— Барыгыз, Михаил Анемподистович. Тик башта лейтенантка кирәкле мәгълүматларны әзерләп бирегез.

Ковригин ризалык белдереп башын селкеде дә, сумкасыннан кәгазьләр алып, эшкә тотынды.

— Әйе, катлаулы эзләнү алып барасыз, Зәки Шәрипович. Сезнең хезмәттә иң әһәмиятлесе — кешеләрне танып белү.

Ковригин башын күтәреп озак кына командирга карап торды. Нәрсә булган безнең командирга? Моңа кадәр фәлсәфә сатканы юк иде кебек. Аның бу карашын Журкин сизеп алды да җавап биргәнне көтеп тормыйча, сүзен дәвам итте.

— Нәрсә? Әллә дөрес түгелмени? Боерыклар гына ишетергә күнегеп беттек инде. Бәхәсләшү, фикер йөртү кебек нәрсәләрне бөтенләй оныттык.

Журкин тагын тәмәке кабызды.

— Кешеләрне аңлау өчен күп басмалы баскычтан менәргә кирәк,— диде ул аннары.— Иң әһәмиятлесе беренче өч басма: күреп белү, кешенең сүзләре, аның эшләгән эше. Тышкы кыяфәте белән сокландырса, тәмле теле белән исертә ала. Ә инде өченче басмада кешенең эшен күргәч асылын да аңлыйсың, ул кеше турында дөрес фикер туа: я күзләрең киң ачылып айныйсың (бу хәл ешрак була), я элеккечә сокланып карыйсың һәм тагын да ныграк ярата башлыйсың.

Куышка радист кыз йөгереп керде.

— Иптәш майор, сезгә ашыгыч радиограмма.

Отряд командиры кәгазьгә күз салды.

— Бүген төнлә Зур җирдән «күчтәнәч» алып киләчәкләр. Хәзерләнеп торырга кирәк. Әйдәгез, иптәшләр, эшкә тотыныйк.

Ковригин әйтүе буенча лазаретта дүрт хезмәткәр эшли иде: ике ир кеше, ике хатын-кыз. Врач Губин белән санитар Никошев элекке Пахомов отрядыннан килгәннәр. Тикшерүче хатын-кызларны шикләләр исәбеннән башта ук төшереп калдырды. Алар икесе дә отрядка оештырылган көннәрдә үк кушылганнар.

Төшке аштан соң лейтенант лазаретка барып килде. Арон белән озак кына сөйләшеп утырдылар.

— Сиңа һәм врач Губинга рәхмәтем чиксез,— диде дусты.

Аронны саклап калу өчен Губин бераз үз канын биргән икән. Штаб начальнигы Ковригин да исән калуы өчен Губинга бурычлы бит.

Нурмыев лазаретта Вераны да очратты. Озак авырып ятучылар турында сорашты. Вераның әйтүенчә, лазаретта озак вакыт бер Досомов кына ята. Гаҗәп, ул да Пахомов отрядыннан ич!

Нурмыев врач Губиннан Аронның хәлен сорашты. Башка авырулар, шул исәптән Досомов белән дә кызыксынды.

Губин таза гәүдәле, ачык йөзле кеше. Яше утызлар тирәсендә. Аның ягымлы елмаюы, үз-үзен тотышы кешеләрдә яхшы тәэсир калдыра иде.

Тикшерүче үзе врачны тыңлый, үзенең башында әллә ниткән уйлар: Гестапо шымчысы. Аронның тормышын саклап калу өчен, үз канын бирә алыр идеме? Штаб начальнигы Ковригинның исән калуы аңа нигә кирәк? Үзен үлемнән алып калган кешедән шикләнүләрен Ковригин да ошатмады.

Ярты сәгатьтән тикшерүче радист куышында иде инде. Губинны бөтен кеше хөрмәт итсә дә, тикшермичә булмый. Хәвефле заман, кемнең кем булуына карамастан, аның турында да белешергә туры килә.

Радиограмма

Левчукка Ашыгыч

Губин Валентин Владимирович турында мәгълүматлар җибәрүегезне үтенәм. Аны күреп белгән кешеләр фикере дә кызыксындыра. Губин 1913 елда Пенза шәһәрендә туган. 1891 елда Кострома шәһәрендә туган Никошев Николай Пантелеймонович һәм 1900 елда Чита шәһәрендә туган Досомов Павел Константинович турында да хәбәр итегез.

Андрей

Кайсысы шымчы? Фонарьлар кайда яшерелгән? Бүген көне буе тикшерүчене менә шушы сораулар борчыды.

Көнозын аяк өсте йөреп бик арыган икән, яту белән йокыга китте. Төнге икеләр тирәсендә генә уянды. Куышта шулкадәр бөркү, саф һавага чыгарга мәҗбүр булды. Караңгы болытлар арасында йөзгән тонык ай менә-менә урман артына кереп югалачак. Бөтен күк йөзендә бердәнбер Казык йолдыз яна. Сихри тынлык. Кинәт шул тынлыкта аяк тавышлары ишетелде. Кемдер Нурмыевка таба йөгерә.

Нәрсә булды икән? Тикмәгә генә төн уртасында йөгереп килмәсләр. Йөгерүче килеп җитәр-җитмәс ашыгып сүзен башлады. Озак йөгерүдән сулышы кысылган, тотлыга да шикелле:

— Иптәш Андрей, бу сезме? Лазаретта бер авыру югалган — Павел Досомов.

Каравыл взводыннан лазаретны күзәтергә куелган яшь партизанны Нурмыев тиз таныды. Кушаматы Евгений. Бер иптәше белән күзәтү алып барырга, ул-бу булса, кичекмәстән тикшерүчегә хәбәр итәргә тиеш иделәр.

— Кайчан югалган?

— Егерме минутлап бардыр. Бәдрәфкә кергән иде. Бик озак торгач, барып карарга булдым...

— Тизрәк сөйлә,— дип ашыктырды Нурмыев түземлеген җуеп.

— Мин ишектән күземне алмадым. Ә ул арт такталарны шудырган да сызган...

Евгений кесәсеннән тимер портсигар чыгарып тикшерүчегә сузды.

— Бәдрәф яныннан таптык. Тишектән чыкканда төшереп калдыргандыр ахры...

— Взвод командирына әйтегез, кичекмәстән бөтен постларга хәбәр итсен. Лагерьдан чыгып китәргә теләгән һәр кешене кулга алырга. Каравылда торучылардан башка бөтен партизаннарны тирә-як юлларга урнаштырырга кирәк. Әйдә, йөгер!

Авыр итекләре белән лап-лап басып, партизан кире чапты.

Нурмыев пиджагын гына эләктерде дә, караңгыда абына-сөртенә, лазаретка йөгерде. Берничә тапкыр егылып та алды.

Менә ул каһәр суккан будка. Тикмәгә генә качмагандыр инде. Досомов шымчы булып чыгадыр.

Чыннан да арттакталар аскы якта кадакланмаганнар икән. Аларны ике якка этеп җибәрсәң, бик ансат кына чыгып була. Качкан, качкан, бәдбәхет...

Нурмыев аптырап як-ягына каранды. Тирә-якны караңгылык чолгаган иде.

Лейтенант кесә фонаре яктысында аяк астын караштырып лазаретка юнәлде. Өйалдында Губин очрады. Исәнләшкәннән соң Досомов яткан палатага керделәр.

Губин сул яктан икенче ятакка күрсәтте:

— Менә шушында аның урыны.

— Алай икән. Барыгыз, Валентин Владимирович, үз эшләрегезне карагыз.

Губин күзлеген җайлап киде дә ашыкмый гына палатадан чыгып китте.

Тикшерүче бөтен урын-җирне җентекләп карап чыкты. Аннан ятак астыннан таушалган солдат капчыгы тартып чыгарды. Иң өстә яшел сырма. Ә капчык төбендә... төрле төстәге түгәрәк пыялалар. Андый пыялалар урам чатларында светофорларга куела. Зәки хәлсезләнеп ятакка утырды да, башын учлап, уйга калды. Вакыт-вакыт ыңгырашып та алды. Ахмак! Көндез, чормадан төшүгә, тентү ясарга кирәк иде бит. Бөтен мәсьәләләр хәл ителеп, дошман инде ярты тәүлек элек үк кулда булыр иде!

Лейтенант ярсып урыныннан торды да биш минутлап ишекле-түрле йөрде. Бераз үз-үзен тынычландырганнан соң тагын эшкә тотынды. Капчыктагы бар нәрсәне идәнгә бушатты. Тозлы тир сеңеп уңган гимнастерка, табаннары ашалып кыйшайган бер пар солдат ботинкалары — башка һич нәрсә юк иде. Гимнастерканың эчке кесәсендә уч төбе кадәрле генә куен дәфтәре һәм бер фоторәсем: яшь кенә бер ир-ат хатыны һәм кызы белән төшкән. Артында язуы да бар: «Чита шәһәре. 1941 ел, май».

Досомов семьясыдыр ахры. Димәк, ул профессионал разведчик түгел. Тукта әле, тукта...— Кинәт туган шик лейтенантның уйларын бүлде. Ул куен дәфтәре битләренә күз салып, фикер йөртүен дәвам итте:— Профессионал булмагач, каян килә шундый тәҗрибәлелек, җитезлек, осталык? Шундый дошман семьясы белән төшкән фоторәсемен, үзенең һәм танышларының адресларын саксыз калдырып качармы? Башын бетерерлек дәлилләрне үз ятагы астында саклар идеме? Шикле бит бу, бик шикле. Ә бәлки...»

Нурмыев бар әйберне кире тутырып, капчыкны үз урынына куйды да зур бүлмәгә чыкты. Почмакта, сукыр лампа яктысында Губин яшь партизанның ярасын карап утыра. Санитар Никошев үзенең гадәттәге урынында йоклап ята. Врач үз эше белән шулкадәр мавыккан, керүчегә игътибар да итмәде. Зәки сак кына атлап түргә узды. Арон да тыныч кына йоклый иде.

Нурмыев яңа туган шикләрен тикшерергә ашыкмады. Тагын ялгышуы бар бит. Болай да инде... Ә тикшерү өчен бик зур әзерлек һәм кискен чаралар күрергә кирәк. Тагын бер кат авыруларны күңелдән барлап чыкты. Юк, башкалары шымчы булырлык түгел. Я Досомов, я лазарет хезмәткәрләренең берсе булса гына.

Бәлки Журкин белән Ковригинның аэродромнан кайтып җитүен көтәргәдер? Самолет инде кире Мәскәүгә дә очкандыр. Лейтенант сәгатенә күз салды — өч тулырга унбиш минут икән. Алар белән киңәшләшсәң, әйбәт булыр иде инде. Әгәр иртән генә кайтсалар? Юк, озакка сузарга ярамый.

Тагын бераз уйланып торганнан соң, Нурмыев ишеккә таба атлады. Инде чыгып китәм дигәндә генә туктап врачка эндәште:

— Валентин Владимирович...

Врач теләр-теләмәс кенә башын борды.

— Сез миңа эндәшәсезме?

— Әйе.

Губин тарау кешеләрдәй салмак адымнар белән ишек янына килде.

— Яралыларның берәрсе эндәшкәндер дип уйладым. Ни әйтергә теләгән идегез?

Тикшерүче бераз вакыт Губинның йөзенә текәлеп карап торды, әмма бернинди үзгәреш сизмәде.

— Сез бу йортта берәр сәер хәлгә игътибар итмәдегезме?

Врач башта кесәсеннән яулыгын чыгарып күзлеген сөртте, шуннан соң гына сорауга сорау белән җавап бирде:

— Нинди сәер хәлләр булырга тиеш?

— Гомумән әйтәм. Ә Досомовның үз-үзен тотышы?

— Бу очракта сезнең игътибарга лаек бернәрсә дә күргәнем булмады. Авырулар турында да начар сүз әйтә алмыйм. Бернинди дә. Вак-төяк булса гына инде...

— Әйтеп бетерсәгез иде.

— Досомов бер шешә йод белән бөтен елан агуын әләктереп качкан. Радикулит белән авыручыларга бик кирәк нәрсәләр. Бөтен югалтуларыбыз шул.

Лейтенант, врачка рәхмәт әйтеп, кайтырга чыкты. Урманда әле дә тынлык. Якында гына пост булырга тиеш. Нурмыев эндәшүгә Евгений килеп тә житте. Әйтерсең, авызына абагә чәчәге кабып, янәшәдә генә басып торган.

— Тиз генә взвод командиры Павловны эзләп табыгыз. Лазаретка килсен.

Евгений тагын караңгылыкка кереп югалды. Лейтенант, саклык белән өйалдына кереп, кесә фонарен яндырды. Беркем дә юк. Бераздан взвод командиры да килеп житте. Утыз биш яшьләр тирәсендәге сержант белән Зәки әлектән таныш иде.

— Иптәш лейтенант, өлкән сержант Павлов, сезнең боерык буенча...

— Мин әйткәннәрнең барысы да үтәлдеме?

— Барысы да, иптәш лейтенант. Хәзер генә өстәмә постларны урнаштырып бетердек. Үзем дә сезнең янга килергә җыенган идем.

— Нинди яңалыклар бар, берәрсен әләктермәгәннәрме?

— Юк.

Павлов сугышка кадәр НКВД гаскәрләрендә хезмәт иткән, ышанычлы кеше. Лейтенант иң җаваплы бурычны аңа йөкләргә булды.

— Менә нәрсә, иптәш өлкән сержант. Тагын дүрт кеше алыгыз да лазаретка керегез. Евгений да сезнең белән булсын. Санитар Никошевны һәм врач Губинны күздән ычкындырмагыз.

Павлов гаҗәпләнүдән телсез калды. Бераз хәл алгач кына:

— Врач Губин турында сез чынлап әйттегезме? — дип сорады.

— Әйе, врач Губин турында да. Коралларыгыз һәрвакыт әзер булсын. Берәр шикләнерлек нәрсә булса, нишләргә икәнен үзегез беләсез.

— Әгәр дә кемдер чыгып китәргә теләсә?

— Авырулар һәм яралыларга чыгып йөрергә була, тик сезнең кешеләр озата чыксыннар. Лагерьга дошман ялчылары үтеп кергән, безгә лазаретны саклау бурычы куелды, дип аңлатырсыз.

— Үтәлер, иптәш лейтенант.

— Ә санитар һәм врач өчен башыгыз белән җавап бирәсез.— Лейтенантның тавышында гадәттән тыш кырыслык сизелә иде.

Сержант, пистолетын кобурадан алып чалбар кесәсенә тыккач, устав кагыйдәләрендә күрсәтелмәгәнчә җавап бирде:

— Аңладым, тырышырбыз.

Ун минут вакыт узгандырмы-юкмы, Павлов үзенең кешеләре белән лазаретка кереп урнашкан иде инде. Хәзер тикшерүчегә дә тынычланып, башка эшләр белән шөгыльләнергә мөмкин иде.

Нурмыев якын-тирәдәге агач араларын, куак төпләрен карап чыкты. Әмма эзләгәнен таба алмады. Досомовның үле гәүдәсен эзли иде ул. Врач Губин әйткән сүзләр аның шиген көчәйтте генә: әгәр Досомов шымчы икән, аңа дарулар нигә хаҗәт?

Тәҗрибәле дошман өчен фоторәсем, куен дәфтәрен алып китү яхшырак булыр иде. Әгәр ул чынлап та авырган булса, шымчы була алыр идеме? Бәлки капчыкны ятак астына кем дә булса махсус яшергәндер дә, «качу» спектаклен оештыргандыр? Тикшерүне ялгыш юлга җибәрү өчен яхшы сәбәп бит. Тик бу очрак та кайдадыр мәет булырга тиеш. Ә кайда?

Тикшерүче яңадан куаклар янына әйләнеп килде. Бәдрәфкә кадәр утыз метр чамасы. Ишеген аермачык күреп булмый булуын. Ә бәдрәф артында нәрсә эшләнгәне бөтенләй күренми. Шымчының шуннан файдаланган булуы мөмкин. Караңгыда әкрен генә бәдрәф янына килеп такталарны читкә шудыра да, корбанының башына суга. Мәетне тишектән генә сөйрәп чыгара да, иңенә салып кайдадыр илтеп яшерә. Портсигар юлда төшеп кала.

Тукта әле. Ә нигә портсигар төшеп калган, дип кенә уйларга? — Кинәт килгән уй тикшерүчене сискәндереп куйды.— Аны махсус ташлаулары да бар бит. Ташламаган булсалар — нинди максат белән? Качу — эзенә төшүләрен сизгән дигән сүз. Өстәвенә гаебен исбатларлык көчле дәлилләр дә бар. Досомовның дошман икәнлеге болай да көн кебек ачык. Димәк, портсигарны махсус ташлауның кирәге юк?

Нурмыев тагын бер тапкыр лазарет тирәли әйләнеп чыкты. Уйла, иптәш тикшерүче, ныклап уйла. Бәлки, портсигар табылу башка нәрсә турында сөйлидер. Чыннан да, портсигар бәдрәфтән читтәрәк табылгач, Досомов качкан дигән сүз. Әгәр качмаган булса? Үтереп, гәүдәсен бәдрәф чокырына батырган булсалар? Ул вакытта озын колгадан файдаланырга тиешләр. Эзләргә кирәк, эзләргә.

Нурмыев колганы ярты сәгатьтән соң гына таба алды. Бер очы пычранган. Димәк, үтергәннәр! Шымчы, эзенә төшүләрен сизгән ахры, тик ни сәбәптәндер лагерьдан кача алмагач, мескен Досомовны корбан итеп, котылырга уйлаган. Эзенә төшүебезне ничек сизде икән ул? Тагын кайдадыр ялгышканмын ахры.

Кайсысы шымчы — Никошевмы, әллә Губинмы? Яңадан шул ук сорауга җавап эзләргә туры килә.

Хәзер инде Досомов югалган вакытта һәрберсенең кайда булуын ачыкларга кирәк. Үзләрен акларлык дәлилләр, шаһитлар таба алырлармы? Алырлар кебек. Шундый тәҗрибәле дошман алдын-артын уйлаган булырга тиеш. Хәйран тапкыр эш итә. Бүген генә мине алдармын дип уйлап ялгышты. Үзем дә ышана яздым бит. Шымчы артыграк тырышкан бу юлы. Шуңысы шикләндерде дә.

Евгений сөйләгәннәрне тыңлагач, тикшерүче тагын аптырашта калды. Досомов юкка чыкканда Губин белән Никошев икесе дә лазаретта булганнар.

Әллә тагын ялгыша инде? Юк, башка шымчы булуы мөмкин түгел! Әгәр лазареттагыларның берсе дошман булмаса, ул Досомовның кайчан чыгачагын ничек белә алыр иде? Көтеп торган дисәң, бик озак вакыт кирәк. Ул кадәр вакыт югалып торуыңны шунда ук сизәчәкләр. Көтеп торганда күреп алулары да мөмкин. Димәк, шымчының лазаретта булуында шик юк. Нурмыев тагын лазаретны әйләнеп чыкты: партизан постыннан күренми торган караңгы якта бер тәрәзә бар. Кечкенә генә кухня тәрәзәсе бу. Аның каршында карга миләше үсә. Кесә фонаре яктысында игътибар белән карагач, рамда яңа тырналган эзләр дә табылды. Тәрәзә күптән түгел генә ачылган булып чыга! Лейтенант тәрәзә капкачларын үзенә тартып караган иде, бик җиңел ачылдылар. Хәзер инде эш җиңеләйде. Шымчы сизәр дип сакланып йөрергә кирәкми. Лазаретка коралны партизаннар урнаштыру үзе кулга алу белән бер. Эшеңне эшлә, әмма беркая да китәргә рөхсәт юк дигән сүз. Алдау барып чыкмаганлыгы да дошманга көн кебек ачык.

Лейтенант тәрәзәдән кереп, кухня аша партизаннар урнашкан зур бүлмәгә узды. Врач Губин яралы партизан белән мәшгуль. Санитар Никошев әле һаман йокыдан тормаган иде.

Нурмыевны күргәч, Павлов аптырашта калды:

— Әллә күземә күренәсез инде? Ишектән күземне дә алганым юк, әмма кергәнегезне күрми калдым.

— Тәрәзә аша да кереп булганда, нигә ишектән йөрергә?— диде Нурмыев елмаеп. Үзе Губинга таба борылды.— Шулай бит, Валентин Владимирович?

Әмма Губин җавап бирмәде, башын күтәреп бер генә елмайды да, эшен дәвам итте.

Врачның үз-үзен тыныч тотуы, ягымлы карашы лейтенантның ышанычын киметә төште. Ул түгелдер ахры. Әйе, ул түгелдер. Гаепле, шикле кеше үз-үзен шулай кулда тота алмас иде. Никошевтыр инде. Карале син аны, рәхәтләнеп йоклап ята. Әллә йоклаганга салышып ятамы? Кичекмәстән тентү уткәрергә кирәк. Бик тиз йокың качар, урлап тотылган мәче кебек үрле-кырлы сикерерсең!

Тикшерүче Павловка тиешле күрсәтмәләр бирүгә, эшкә тотындылар. Башта чоланны карап чыктылар. Инде палаталарга чират житте. Иңбашына кагылуга Никошев сикереп торды.

— Нәрсә булды? Кемгә ярдәм кирәк?

— Әлегә кирәк түгел,— диде Нурмыев.— Шәхси мөлкәтегезне генә күрсәтегез.

Никошевның йөзендә сырлар, күзләрен чак-чак ачып тора. Чынлап йоклаган булган бит. Нервлары хәйран нык икән.

— Нинди әйберләрне?— Санитар күзләрен челт-челт йомып аңламый торды.

— Шәхси әйберләрегезне.

— Ә...— Ул мендәр урынына баш астына салынган киндер капчыкка кулын сузган иде, нигәдер туктап калды:

— Ә нигә? Анда аяк чолгаулары...

— Карап карыйк.— Нурмыев коры гына санитарның сүзен бүлеп капчыкны үз кулына алды.— Хәтерегездә тотыгыз: тентү — бик житди һәм күңелсез эш. Тентү барганда сүзләргә ышану юк, бары тик үзең күргәнгә һәм кулыңа тотып караганга гына ышанасың.

— Тентү?— Никошев аптыравыннан ятагына барып утырды.

Капчыкта дөрестән дә аяк чолгауларыннан башка бер нәрсә дә юк иде. Инде урын-жирне карарга кирәк.

Агач сәкегә пружиналы матрас калынлыгында кипкән каен ботаклары җәелгән. Җәймә урынына — ертык шинель, стена буенда — яхшылап төрелгән яшел сырма. Лейтенант башта шинельне игътибар белән карап чыкты. Бернәрсә дә юк. Сырма гына бик авыр, әллә кесәләренә таш тутырганнар инде. Таш түгел, сырлы тимер. Гранаталар. Тикшерүче ян кесәләрдән дүрт лимонка, куен кесәсеннән «ТТ» системалы пистолет алып сәкегә куйды.

— Сезнекеме болар?

Никошев бөтенләй югалып калды. «Юк» дип әйтерлек тә хәле калмаган иде инде. Авызын бер ачып, бер ябып озак торгач кына тотлыгып сорап куйды:

— Нн-ә-р-р-сә өчен? Кке-еммгә?


— Димәк, корал сезнеке түгел?— Тикшерүченең ачулы тавышы һәркемне сискәндерде.— Ә сырма сезнекедер бит?

— Әйе-е.

— Кемдер яшергән дип әйтәсегез киләме? Бәлки «уенчыклар» турында онытkансыз гынадыр?

Куркудан Никошевның йөзе тартыша башлады.

— Бүген... йокларга ятканда гына... шунда куйдым... Бернәрсә дә юк иде...



*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

Тикшерүче аның кайчан йокларга ятуын сорашты. Инде бераз аңына килгән Никошев яралылар йоклап бетмичә ятмавын әйтте.

— Төнге уникеләрдән соң гына ятам мин. Бүген дә шулай...

Нурмыев санитар белән шөгыльләнгән арада Губин, эшен бетереп, ишеккә таба юнәлде. Әмма өлкән яшьләрдәге партизан бусагада аңа каршы төште. Беркемне дә чыгармаска дип алдан ук әйтеп куелган иде.

— Тикшерүчедән рөхсәт сорагыз.

Губин теләр-теләмәс кенә Нурмыевка таба атлады.

— Сезне борчырга туры килә.

— Тыңлыйм,— диде лейтенант, Никошевны күздән ычкындырмый гына.

— Минерларның яраларын карыйсы иде. Алар үз куышларында яталар. Монда күчерер идек, үзегез күреп торасыз, урын юк. Берсенең аягында гангрена башлану куркынычы бар.

Лейтенант башта «Барыгыз» дип кул селтәргә теләгән иде дә, нигәдер бу уеннан кире кайтты.

— Хәзер, хәзер... Күрәсез бит, эш бетмәгән...

Губин аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламады, күрәсең, баскан урынында торып калды.

Никошевны тентеп, сораштырып бетергәнче тагын берничә минут вакыт үтте.

Губин яңадан сүз башлады:

— Үз эшегезне үзегез яхшырак беләсез инде, иптәш лейтенант, әмма мин дә врач буларак үз бурычымны үтәргә тиеш...

Врачның бу сүзләре тикшерүчегә бер дә ошамады. Бәлки, мөрәҗәгать итү өчен ул нәкъ менә шундый вакыт җиткәнен көткәндер? Бик мавыгып эшләп утырган кешедән ни генә сорасаң да ул риза булачак, тик комачауламасыннар гына. Шуңа өметләнәме? Врач вазифаларын да үтәргә кирәк инде. Әмма сакчыга бер сүз дә әйтмәде Нурмыев. Губин түзмәде, эчке бүлмәгә — авыр яралылар янына кереп китте.

Тентү тәрәзәләргә иртәнге нурлар төшкәч кенә тәмамланды. Өйалдындагы идән такталарын күтәреп карагач, тагын бер табышка ия булдылар — ике чагылдыргыч куеп эшләнгән кесә фонаре иде бу. Алдан табылган пыялалар фонарьга бик җиңел куелалар икән. Эх, бармак эзләрен чагыштыру өчен тиешле шартлар булса икән! Бөтен табышмакка җавап табылыр иде.

— Сезнекеме бу?— дип сорады Нурмыев врачтан.

— Гафу итегез, беренче тапкыр күрәм. Әгәр бүләк итсәгез, рәхмәт әйтеп кабул итәр идем. Төнлә операцияләр ясаганда бик кирәк нәрсә.

Никошев та фонарьны танымады.

Лазареттан китәр вакыт җиткәч, Нурмыев врачтан:

— Валентин Владимирович, сез корал йөртәсезме?— дип сорады.

— Әлбәттә.— Губинның йөзендә елмаю, кәефе яхшы ахры.

— Бик матур револьвер, хатын-кызлар өчен эшләнгән. Кая куйганымны гына хәтерләмим. Әй, халат кесәсендә бит әле.— Губин кесәсеннән биш патронлы никельләнгән браунинг чыгарып лейтенантка сузды.— Менә, карагыз... Майор Ковригин бүләге...

Нурмыевны бер нәрсә гаҗәпләндерә: Губин белән сөйләшә башлауга аңа карата булган бөтен шикләрең әллә кая югала. Бигрәк үз-үзен табигый тыныч тота шул, ышанмаслык та түгел. Алай гына да түгел. Йомшак тавышы, ачык йөзе, туры ягымлы карашы белән бөтенләй кеше күңелен яулап ала.

Менә хәзер дә җитди сөйләшү өчен Нурмыевка бөтен көчен тупларга туры килде:

— Валентин Владимирович, алдан ук гафу үтенәм. Миңа йөкләнгән эш гаять зур әһәмияткә ия булганга, кайбер мәсьәләләрне ачыклаганчы беркая да чыгып йөрмәвегезне үтенәм. Бу башка иптәшләргә дә кагыла.—

Губин пистолетын лейтенант үз кесәсенә салды.— Ачыктан-ачык әйтәм: сезгә карата булган шикләр урынсыз булып чыгар, дип уйлыйм. Минем сезне ничек хөрмәт итүемне үзегез беләсез.— Губин иңбашларын сикертеп алды.

— Эшегез шундый булгач... Тик яралы минерларны гына монда күчерсеннәр иде. Вакыт уза...

— Борчылмагыз, эшләнер.

Ай-һай тыныч кеше дә инде. Үлем упкыны шулкадәр якын булганда болай оста уйнау мөмкинме? Бу спектакльдә аның катнашы юк ахры.— Лейтенант үзе дә сизмичә тагын икеләнә башлады.— Әйдә, радиограмма килгәнче, сак астында утырып торсын әле.

## 18

Отряд җитәкчеләре аэродромнан иртәнге якта гына кайтып җитте. Фронт сызыгы аша үткәндә зенит снаряды кыйпылчыгы тиеп шассилары ватылу сәбәпле, самолет җиргә төшә алмаган, йөкне парашютлар белән ташлаганнар. Берничәсе сазлыкка төшкән. Бу турыда Нурмыевка штабта сөйләделәр. Үткән төнне булган хәлләр белән таныштырганнан соң тикшерүче шундый нәтиҗә ясады:

— Никошев белән Губинның икесенең берсе агент.

— Ә бәлки икесе дәдер? Алар бит Пахомов отрядында да бергә эшләгәннәр. Минемчә икесе дә.— Журкин үз фикеренең дөреслегенә ышана төшеп сүзен дәвам итте.— Әгәр шулай булмаса, бу вакыт эчендә берсе икенчесенең шикле эшләрен сизми калмас иде. Сез ничек уйлыйсыз?

— Мин бу турыда уйлаган идем, иптәш майор,— диде тикшерүче күңелсез генә.— Әмма бу очракта бер нәрсә бар.

— Табылган корал Никошевныкы дип санасак, ул — шымчы. Әгәр инде аның корал минеке түгел, дигәненә ышансак, башка кешедән — врач Губиннан шикләнергә мәҗбүр булабыз. Димәк, кемдер гранаталарны һәм пистолетны башка кешене батырып, үзеннән шик төшерү өчен махсус яшергән. Ә бу — икесе дә шик астында калалар, дигән сүз. Бер отрядта ике шымчы булса, килешебрәк эшләрләр иде.

— Мин Губинның шымчы булуына барыбер ышанмыйм.— Штаб башлыгы сүзен әнә шулай катгый башлады.— Әгәр ул дошман булса, шулкадәр тырышып, күңел биреп эшләр идеме? Нигә катлаулы операцияләр ясап, кирәк булган очракларда үз канын биреп, партизаннарны коткарып калырга? Аннан-моннан гына да эшләп була бит. Алай да берничнди артык сүз булмас иде. Отрядта дарулар белән эш итә белүче ул үзе генә. Димәк, врач лазаретта алла да, патша да, хәрби башлык та. Кемнеңдер үлеменә сәбәп булган яраның ни дәрәҗәдә катлаулы булуын беркем тикшерә алмый. Ул бит мине дә теге дөньядан кире кайтарды. Мине генәме соң, бик күпләрне! Көннәр буе дару үләннәре җыярга да мәҗбүр итүче юк. Ә ул миннән өстәмә кешеләр дә сорап ала. Йогышлы ашказаны-эчәк авырулары таралмау да шул үләннәр аркасында бит. Үзегез беләсез, андый авыру бер башланса...

Бераз тынлыктан соң Ковригин сүзен дәвам итте:

— Валентин Владимирович интеллигент кеше, винтовканы автоматтан аера белмидер кебек. Мин аңа браунинг бүләк иткән идем бит, аны ничек корырга икәнен дә миннән сорады. Ә сез аның турында әллә ниләр сөйлисез...

— Авыр яралангач, сезне үлемнән алып калуын, аңа бурычлы икәнлегезне мин аңлыйм, Михаил Анемподистович,— диде Журкин кырыс кына.— Тик бу очракта ашыгыч нәтиҗә ясарга ярамый. Тикшерү кирәк икән, тикшерербез. Минемчә, без үзәктән көткән радиограмма күп нәрсәне ачыклаячак. Аз гына түзик, Зәки Шәрипович, ничек уйлыйсыз?

— Бик дөрес әйтәсез, иптәш майор. Мин дә ул радиограммага зур өмет баглыйм. Әгәр тикшерү Губин файдасына бетә икән, бик шат булыр идем, ул миңа да бик ошый. Ә хәзергә ул лазаретта сак астында эшләп торсын. Бу күңелсез хәл өчен мин үзем аның алдында гафу үтенермен.

Инде таралышабыз дигәндә генә взвод командиры Петров килеп керде. Озак йөгерүдән сулышы кысылган, тирләп чыккан.

— Иптәш лейтенант!..

— Нәрсә булды?..— дип сорады тикшерүче шикләнеп.— Әллә качтымы?

— Юк ла. Анда тәртип. Мин тәрәзә саен да сакчылар куйдым. Сакланганны язмыш саклый.— Петров кулындагы биш тиенлек акча зурлыгында кәгазьне Нурмыевка сузды.

— Менә, сөяк эченнән таптык.

— Нинди сөяк эченнән?

— Гап-гади сөяк инде. Төн уртасында посттан ерак түгел кыштырдау сизгәннәр. Безнекеләр автоматтан тырылдаталар, эт чинаган тавыш ишетелә. Иртән барып карасалар, сөяк ята, бер ук аны эт авызыннан «коткарган». Яхшылап карагач, сөяк эченнән менә шушы кәгазь табылган.

— Кай тирәдә булды бу хәл?

— Моннан ике километр ераклыкта, район үзәгенә таба. Посттан бер километр чамасы киткәч, авылара юл уза. Юл белән пост арасында, тирән ерым ярында искереп беткән урманчы өе бар. Урманчы үзе дә бик карт. Аның нәселле овчаркасы бар, шул булмадымы икән?

Кечкенә генә папирос кәгазе кисәгенә карандаш белән багана-багана цифрлар язылган. Укырга тырышып карарргамы? Юк, вакыт әрәм үтәр,— дип уйлап алды тикшерүче.— Булдыра алуым да шикле. Башкача эш итәргә кирәк...

— Иптәш Петров, беркая да китми торыгыз. Мин хәзер.— Лейтенант штаб куышына ашыкты. Майор Журкинга хәлне аңлатканнан соң, разведка взводы сугышчыларын үз карамагына бирүен сорады. Тиз генә старшина Назаренконы чакырып китерделәр.

— Менә нәрсә, старшина. Кешеләреңне ал да, урманчы өенә ашык. Эшнең нәрсәдә икәнлеген Нурмыев юлда барганда аңлатыр. Сораулар бармы?

— Юк, иптәш командир.

— Алай булса — юлга...

Кыш буе ярым ач торган атлар әле дә хәл җыярга өлгермәгәннәр — күптән йөрелмәгән тар урман юлыннан салмак кына юырталар.

— Ун минуттан барып җитәбез,— диде взвод командиры Петров.

— Без бу юлдан еш йөрибез, таныш урыннар.

— Ул этне әлеграк лагерьда күргәнегез бар идеме?— дип сорады тикшерүче.

— Әйе. Биш көн чамасы элек урманчы лагерь янында кузгалак җыеп йөри иде, ашарга юк бит. Эте дә янында иде.

— Ниндирәк кеше үзе?

— Бер аягы гүрдә инде.— Старшина Назаренко сүзгә кушылды.— Без аның өенә сугылгалыйбыз. Гражданнар сугышы инвалиды, кызылармияче булган. Ә яше инде сиксәннән арткан.

— Үзе генә яшиме?

— Абыйсы белән. Анысының бер аягы юк.

Урманчы өенә берничә йөз метр кала атларны калдырырга булдылар. Нурмыев алда торган бурычны аңлатты.

Алдан урманчыны яхшы белгән разведчиклар китте. Башкалар йортны чолгап алдылар.

Ишек тышкы яктан бикләнгән булып чыкты. Күгәрә башлаган зур йозак хуҗалар өйдә юклыгын күрсәтеп тора иде.

Лейтенант өй тирәли әйләнеп чыкты, кыйшайган такта келәт эченә күз салды. Бераз уйланып торганнан соң, Назаренкога эндәште:

— Иптәш старшина, тикшереп карагыз әле, чормадан чоланга үтеп буламы икән?

Назаренко җитез генә югарыга үрмәләп, шыгырдап ачылган чорма ишегеннән кереп югалды. Озак та үтмәде, аның җете җирән чәчле башы яңадан ишектә күренде:

— Юк, булмый, иптәш лейтенант.— Үзе сикереп төшәргә теләп аякларын салындырып утырды.— Степанов! Син пыялачы бит әле, ач тәрәзәне, тәрәзәдән керәбез.

Өлкән яшьләрдәге тәбәнәк буйлы партизан тәрәзә пыяласын алды. Рамын ачарга теләп кулын сузуы булды, өй эченнән ярсып автомат ата башлады. Гаҗәпләнүе йөзенә чыккан Степанов җиргә ауды. Шул минутта тәрәзәдән граната ыргыттылар. Көчле шартлау өйне генә түгел, сарайны да дер селкетте.

Ыңгырашуларны басып, партизан автоматлары бердәнбер тәрәзәгә ут ачтылар.

Тәрәзәдән тагын бер граната ыргыттылар — бу юлы болдырга таба. Янәшәдә басып торган разведчиклар кайсы кая аудылар. Әгәр Петров кеше ышанмаслык кыюлык күрсәтмәгән булса, исән калучылар булыр идеме икән: ул гранатаны җиргә тиеп өлгергәнче тотып алды да кире ыргытты. Граната тәрәзәгә түгел, өске яңагына эләгеп шартлады. Якында гына шарсыман яшен сукты диярсең, бөтен дөнья яктырып китте, бүрәнә араларыннан чыгып торган сүскә ут капты.

Петров яңгыравык тавыш белән:

— Бирелегез, өй чолгап алынган,— дип кычкырды.

Әмма өй эченнән автомат кына җавап бирде. Бер генә кеше ата кебек, әмма бертуктаусыз пуля яудыра. Магазиннарын ничек алыштырып өлгерәдер, анысы билгесез.

Атышу берничә минут кына дәвам итә әле. Шул арада ялкын бөтен өйне чолгап алды. Шырпы тартмасы кебек тиз яна, инде чормада да ялкын бии. Болай булса өй эчендәгеләр янып үләчәкләр, эз тагын югалачак, эт ташыган хатларның кемгә адресланган булуын мәңге белә алмаячаксың. Димәк, ашыгырга кирәк. Старшина Назаренко ике сикерүдә тәрәзә янына барып җитеп, өй эченә автоматтан тырылдатты һәм секунд эчендә үзе дә бүлмә эченә сикерде. Стена буенда сыңар аяклы бер ир кеше бугазын тотып идәнгә ауды. Мич янында карт урманчы ята, иреннәре селкенә, дога укый иде, ахры. Ул арада такталары черегән ишекне ватып, берничә кеше чоланга керә алдылар.

— Монда керегез!— дип кычкырды старшина.

Өй эче төтен белән тулган, күз ачарлык, сулыш алырлык түгел. Тиз генә урманчыны күтәреп, урамга ашыктылар. Ул һаман хәлсез тавыш белән сөйләнә иде:

— Каһәр суккан явыз... Аяксыз иблис... Өемне басып алды... Туганым түгел ул минем... Алдадылар, этләр... Энем дип әйтергә куштылар... Партизан, янәсе...

— Кем әйтергә кушты? Кем?— Картка бирелгән соңгы сораулар икәнен белгәндәй, дулкынланып һәм ашыгып кычкырды Нурмыев.

— ...Командир иде бугай...

— Нинди командир? Кайдан?

— Үзе әйтте... Партизаннар командиры, диде.

— Кыяфәте нинди иде? Йөзе-бите?

— ...Карарак, кырыс йөзле. Күзләре кечкенә, елтыр, каракларныкы кебек...

— Кайчан булды бу хәл? Аяксыз кайчаннан монда?

— ...Бер атна.

Юл ягыннан партизаннарның кайсыдыр кычкырды:

— Немецлар!!! Машиналар һәм мотоциклларда киләләр!

Дошман килеп чыгу мөмкинлеген алдан сизеп, дозорлар куюның файдасы шунда сизелде.

— Атлар янына! Барыгыз да! — Нурмыев җитәкчелекне үз кулына алды.

— Барыгыз да елганың аръягына!

Партизаннар, урманчы картны күтәреп, елга аша йөгерделәр.

Мотоцикл моторлары тавышы тиз якынайды.

— Петров! Үз кешеләрең белән, без елга аша чыкканчы, дошманны тоткарлап тор. Аннан үзегез кузгалырсыз, без каплап торырбыз,— дип боерды лейтенант.

Борылышта башта берничә мотоцикл, алар артыннан брезент белән капланган дүрт авыр йөк машинасы күренде.

Тоткарлау төркеме сугышчылары яр буена ук тезелеп яттылар. Соңыннан елга буйлап урманга таба качарга мөмкин булачак. Ә анда атлар көтә...

Петров «Дегтяр» артында яткан пулеметчыга команда бирде:

— Прицел өч йөз! Ут!

Пулеметка өч автомат та кушылды.

Алдан килүче мотоцикл җиргә капланды, башкалары кайсы кая таралдылар. Йөк машиналарыннан саранчалар кебек солдатлар коелдылар.

Партизан автоматлары һәм пулеметлары яудырган кургаш яңгыры немецларны туктап җиргә сыенырга мәҗбүр итте. Әмма алар шунда ук котырынып атарга тотындылар. Уклар сызгыруы колакларны тондырды.

Нурмыев белән янәшә йөгерүче партизан абынган кешедәй берничә адым атлады да тавыш-тынсыз җиргә ауды. Иптәшләре аны шунда ук күтәреп алдылар. Каршы як ярга менеп җиткәндә урманчы тагын бер тапкыр яраланды. Һәм аңын югалтты. Бу аяныч хәлне күрүгә лейтенантның күз аллары караңгыланды, үзе яраланганнан да авыррак тоелды. Нигә инде язмыш шундый мәрхәмәтсез икән? Бөтен планнар, бөтен әзерлек тагын юкка чыгармы? Бу уйлар лейтенантка шулкадәр ачу, ярсу, тәвәккәллек уятты ки, ул хәтта үзенең отрядка нинди эш белән җибәрелгәнлеген дә онытты.

— Старшина Назаренко! — Боерык та катырак яңгырады.— Яралы урманчыны мөмкин кадәр тизрәк лагерьга, лазаретка озатсыннар. Аны озатучыларга әйт, булышырга бер-ике взвод җибәрсеннәр. Ә ярдәм килгәнче бу хәшәрәтләр белән без пулеметлар телендә сөйләшә торырбыз.

Бер минут чамасы вакыт узуга, Назаренко, оборона тотучылар белән янәшә ятып, автоматтан ата башлаган иде инде. Бераздан Петров җитәкчелегендәге тоткарлау төркеме дә елга аркылы чыга алды.

Никадәр тыгыз сафлар белән һөҗүм итсәләр дә, «Дегтярев» пулеметы ата башлагач, немецларга туктап җиргә сыенырга туры килде. Дошман тагын ике тапкыр турыдан һөҗүм итеп карады, ике яктан чолгап алырга тырышты, әмма көчле ут астында яралы һәм үле солдатларын калдырып чигенергә мәҗбүр булды. Партизаннарның да патроннары һәм гранаталары да бетте диярлек.

Кинәт дошман тылында ату тавышлары ишетелде, берничә граната шартлады. Немец солдатлары арасында паника башланды: алар алныартны карамый машиналарга таба йөгерделәр.

Нурмыев сәгатенә күз салды. Бәрелеш башлануга бары чирек сәгать вакыт узган, чама буенча ярдәм килеп җитәргә иртәрәк иде әле.

Урманчы өе янында гранаталар шартлый башлауга отрядта тревога күтәрүләрен лейтенант белми иде шул. Нурмыев төркеме тозакка очрады дип уйладылар. Ковригин шунда ук йөзгә якын партизан белән ярдәмгә ашыкты. Юлда урманчыны алып кайтучы партизан очрап, хәлне кыскача сөйләп бирде.

Ярдәмгә килүчеләр немецларга тылдан һөҗүм иттеләр. Көтелмәгән бу һөҗүм дошманны таралырга, машиналарына төялеп качарга мәҗбүр итте. Дошман ташлап калдырган коралларны җыеп, лагерьга таба кузгалдылар. Аяксыз шымчыны урманчы өенә кем урнаштырган? Юл буе Нурмыевны шул сорау борчыды.

Бу очракта да отрядтагы дошманның кулы уйнавында шик юк, тик ни дәрәҗәдә? «Аяксыз» Антип Опешевны алыштырган булырга тиеш. Яшерен шымчыга өстәмә элемтә юлы бик кирәк бит. Урманчы сөйләгәннәр исенә төште: «Карарак, кырыс йөзле, күзләре кечкенә, елтыр, каракларныкы кебек...»

Яралы карт үлмәсә генә ярар иде инде. Ул исән калса, кайбер нәрсәләрне ачыкларга мөмкин булачак. Урманчы карт тасвирлаган кеше Никошевка охшаган бит. Корал да аңарда табылды. Әллә чынлап та шулмы?

## 19

Лагерьга кайтуга, лейтенантка күңелсез хәбәр тапшырдылар: урманчы операция вакытында үлгән. Тәмам кәефе кырылган Нурмыев лазареттан бик тиз чыгып китте. Баскыч янында гаять зур көнчыгыш Европа овчаркасы чинанып тора. Каян килгән бу эт? Кемнеке икән?.. И аллам, бу бит урманчы эте! Ләкин ул монда ничек килеп эләккән?

Лейтенантның хәтерендә: эт, яна башлаган өйдән чабып чыгып, елгага таба качкан иде. Димәк, хуҗасы эзеннән килгән. Дөресрәге, хуҗасын алып килгән ат эзеннән. Менә сиңа мә! Этләр тугрылыгы һичшиксез иң зур хөрмәткә лаек. Башка җан ияләрендә андый хәл сирәк очрый. Әмма кешеләр бу сыйфатка никтер тиешенчә бәя генә бирә белмиләр. Кайвакытта әле этләргә карата бик начар фикерләр дә ычкындыралар: эткә эт үлеме, имеш. Эт тугрылыгына тиешле бәя бирә алмауның тагын бер җитди сәбәбе бар: кешеләрдә бу сыйфат я тиешле дәрәҗәдә түгел, я инде бөтенләй юк. Андыйлар бу сыйфатны аңламыйлар, дүрт аяклы гаҗәеп җанварларга мыскыл итеп кенә карыйлар.

Нурмыев баскычка утырды да җайлап кына эткә эндәште:

— Кемне көтәсең син, дускаем? Хуҗаңнымы? Үлде бит ул, үлде... Аңлыйсыңмы шуны?

Эт койрыгын болгап Зәкигә якынрак килде. Кесәсеннән сохари алып эткә ташлаган иде, маэмай иснәп карады, ялап алды, тик ашамады. Эһе, дустым, бик яхшы өйрәтелгәнсең икән. Кем кулыннан гына аласың соң син разыкны? Кемдер сөякләр биргәндер бит сиңа!

Кинәт тикшерүченең башына бер уй килде: язулы кәгазь тыгылган сөякне эткә кем биргән булса, шул кеше кулыннан ризык та алачак! Йөрәге дә ешрак тибә башлады. Безнең шартларда бу бит иң көчле дәлил! Урманчы шымчыны эт белән элегрәк таныштырган булырга тиеш. Урманчының эт белән лагерьда йөргәнен күргәннәр бит. Дошман тарафыннан алданган карт этне кем кулыннандыр сөяк алырга өйрәткән. Ул кеше — шымчы.

Нурмыев бил каешын салып саклык белән генә этнең муенына бәйләде. Дошманны эт ярдәмендә табып карарга уйлады ул. Вакыт-вакыт чинап алса да, овчарка карышмады, Зәки артыннан штабка таба атлады.

Штаб янында аны радист кыз көтеп тора иде:

— Иптәш Андрей! Сезгә үзәктән хәбәр бар.

Никошев һәм Губин турында хәбәр итүләрен сораган иде бит. Шуңа җавап килгәндер. Нурмыевның баш түбәсенә кадәр тир бәреп чыкты: хәзер бу төен чишеләчәк.

Текст язылган кәгазьне кулына алгач, Зәки башта этне агачка бәйләп куйды. Дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәген, бар байлыгын соңгы карта хөкеменә тапшырган уенчы кебек, саклык белән ачты ул.

«...Никошев Николай Пантелеймонович. 1891 елда Кострома шәһәрендә туган. Чәче кара төстә, уртача буйлы, озынча йөзле, күзләре кара, кечкенә, тирән урнашкан. 1941 елның июненә кадәр Ленин исемендәге җитен комбинатында токарь булып эшләгән. 1941 елның июлендә үзе теләп фронтка киткән. Ундүртенче аерым артиллерия бригадасы составында Мәскәү тирәсен саклауда катнашкан. 1942 елның февраль аенда Тула янындагы сугышларда хәбәрсез югалган».

Нурмыев, радиограммадан авырлык белән генә аерылып, Никошевны күз алдына китерде, аның турында кайбер мәгълүматларны искә төшерде. Юк, һичшиксез, ул түгел. Гаепсез Никошев. Ламброзо уйлап тапкан җинаятьче портретына туры килә, имеш...

«Валентин Владимирович Губин. 1933 елда Пенза шәһәрендә туган. Аксыл чәчле, озын гәүдәле, түгәрәк йөзле, күзләре соры, ерактан күрми. 1939 елда Мәскәү медицина институтын тәмамлаган. Шул ук елның сентябрь аенда хәрби хезмәткә алынган. Белоруссия хәрби округының үзәк госпиталендә хезмәт иткән. 1942 елның гыйнвар аеннан 289 укчы дивизия составында хәрәкәттәге армиядә. 1942 елның 26 гыйнварендә камалыштан чыкканда хәбәрсез югалган...»

Ничек болай була инде?! Губин да гаепсезме? «Аксыл чәчле, озын гәүдәле...»

Лейтенант аерым билгеләрен күңеленнән кабатлады. Барысы да туры килә иде.

Нурмыевның хәзер үк барып ятасы килде. Мендәргә капланып ятарга, беркемне дә күрмәскә, ишетмәскә. Бу теләкнең сәбәбе дә бар, тез буыннары кинәт йомшарды. Кайда гына ятып торырга икән?

Киеренкелектән иснәнә-иснәнә, үләнгә барып ятты.

Юкны эзләү дип атала бу, диде ул үзалдына. Юк, юк. Дөрес урында эзләдем, тик башкалар арасыннан эзләргә кирәк булган. Бөтен ялгышым шунда. Тар алымлы ургыч кебек булганмын, тикшерергә тиешле зур кырның бер өлешен генә эшкәрткәнмен.

Бөтен кешеләрне дә тикшереп чыгарга кирәк иде бит, берничәсен генә түгел. Ике-өч атна дәвамында лазаретта булган барлык партизаннарны күздән ычкындырмаска иде. Верадан башкаларын, әлбәттә.

Кинәт искән җил, җылы бәхет җиле күңел күген каплаган караңгы болытларны куып таратты диярсең, күңелсез уйлар кайдадыр юкка чыктылар. Ай-һай, көчле дә соң бу мәхәббәт. Нинди авыр вакытларда да кешегә өстәмә көч бирә. Бераз ятып торганнан соң Нурмыев торып утырды. Ник соң әле мин балтам суга төшкән кебек утырам? Шымчы табылганчы тикшерүне дәвам итәргә кирәк. Ул, һичшиксез, лазаретта.

Досомовны үтерүләре дә шуны күрсәтә. Аны чокырдан табып алып күмделәр. Баш сөяген сугып ярганнар. Өстәвенә — теге фонарьлар табылу. Никошевта табылган корал турында да онытырга ярамас.

Лазаретта кешеләр шул ук. Беркем беркая китмәде. Бухгалтерлар теле белән әйткәндә, активта калырлык әйбер бар — ул да булса шымчының элемтәсез калуы. Фонарьлары табылды, аяксыз элемтәче «янды» яки янып үлде. Дошман хәзер берни эшли алмый. Ә бу шымчы юк дигән сүз. Алга таба нишләр икән ул? Ничек элемтәгә керер? Әллә качарга тырышырмы? Хәле мөшкел икәнен, божраның тараюын сизә бит ул. Бауда биюче артист кебек, әз генә чайкалдыңмы, беттең дигән сүз. Димәк, ул башта качып котылырга тырышачак.

— Я, хәлләр ничек, безнең Шерлок Холмс?

Башын күтәреп караса, янында отряд командиры белән штаб башлыгы килеп басканнар икән.

— Урманчы өенә барып кайтканнан соң бераз хәл кердеме инде? — Ковригин көнчыгыш халыкларына охшатып, аякларын бөкләп җиргә утырды.— Юкка гына бәрелештә катнаштыгыз, сезнең бурыч немецлар белән атышу түгел бит. Шулай да, дөресен әйтергә кирәк, егет икәнсез.

— Ярый әле сез килеп җиттегез, Михаил Анемподистович. Ни белән беткән булыр иде бу очрашу — билгесез. Ачуым чыкты. Нигә дип әле без куркак куян кебек гел качып кына йөрергә тиеш? Әллә мин кайбер нәрсәләрне уйлап бетермәгәнлектән, гестапочы Дремель чаралар күреп өлгерә, әллә инде бу очраклы хәлләр.— Зәки авыр сулап куйды.— Ә бәлки икесе бергәдер.

Ул радиограмма язылган кәгазьне Журкинга сузды. Хәбәрне укыган да командирның кашлары җыерылды:

— Димәк, белмичәрәк табынганбыз бу аллаларга.

Ә Ковригин, киресенчә, сөенде генә:

— Әйттем ич мин сезгә, Губин дошман түгел дип. Гафу үтенергә дә ирекка чыгарырга кирәк.

Тикшерүченең җавабы катгый иде:

— Гафу үтенергә иртәрәк әле, соңгарак калсак та,зур зыян булмас. Бүген, хәзер үк әһәмиятле бер тикшерү үткәрәсе бар. Шуннан соң гафу үтенергә дә мөмкин булыр.

— Хәрби кеше икәнлегегез әллә каян күренә. Үгезне мөгезеннән эләктерергә яратасыз.

Нурмыев кыскача гына булачак тикшерү шартлары турында сөйләп бирде.

— Гитлерчы шымчының моңа кадәрге эшчәнлеге аның разведка мәктәпләрендә махсус әзерлек, озак һәм яхшы әзерлек үтүен күрсәтә. Агент — сатлык җан гына түгел. Ул безнең арага ашыгыч рәвештә җибәрелмәгән, аның һәр адымы алдан уйланылган.

— Никошев белән Губиннан шикләнмәскә мөмкин, дип әйтергә нигез юк дисез инде?

— Әйе, шулай. Бездә булган һәм үзәктән алынган мәгълүматларның бик үк төгәл булмавы да бар бит әле. Әсирлеккә төшкән берәр кешене күздә тотып шымчы әзерләргә була, я киресенчә, агентка охшаган кешене әсирләр арасыннан эзләргә. Әсирнең биографиясен шымчы үзенә ала. Бу очракта аның ялганын тоту бик авыр. Берәр ялгыш җибәрсә, яки җинаять эшләгәндә тотылса гына чын йөзе ачыла. Отрядтагы шымчының берничә ялгыш адымы аның лазаретта икәнлеген белергә мөмкинлек бирде. Инде хәзер бөтен ышаныч эттә, ул дошманны танырга тиеш.

— Күпме вакыт ач торган эт, никадәр өйрәтелгән булса да,чит кеше кулыннан ризык алмас дип уйлыйсызмы?— Ковригин моңа ышанып бетми иде, күрәсең.— Этләр яңа хуҗаларына да ничектер ияләнәләр бит. Димәк, ризык та алалар.

— Шулаен шулай. Эт таныш булмаган кеше кулыннан да ризык ала, тик, барыбер, бераз күнеккәч кенә. Ике-өч көннән соң. Теләсә нинди эт түгел, өйрәтелгән нәселле эт турында гына сүз бара. Игътибар белән карагыз әле, бу җанвар гади эт түгел бит.

— Хәзер тикшереп карыйбыз,— диде Ковригин.

— Кабыргалары күренеп тора бит, ул ризыкны гына түгел, ризык бирүчене дә чәйнәп йотарга әзер. Әйеме?— Штаб башлыгы командирның хуплавын көткән иде, тегесе эндәшмәде.

Ковригин тиз генә куыштан консерва банкасына салып ат ите кисәге алып чыкты.

— Кич белән ашармын дип калдырган идем. Кирәге чыкты тагын.

Ул, якынрак килеп, итне эткә ташлады. Овчарка башта сагаеп карап торды, аннан итне иснәде дә читкә китеп басты. Яңа кешедән яхшылык көтми иде ул.

Ковригинның югалып калуын күргән командир көлеп җибәрде:

— Нәрсәгә кәефең кырылды әле? Тешләмәгән өченме?.. Я, ярый, борчылма ул кадәр. Хәзер синнән шикләнмәскә була, тикшерү үттең инде.

Ул Нурмыевка таба борылып:

— Миңа да шундый «ренгент» узаргамы?— диде.

Тикшерүченең йөзенә кызыллык йөгерде:

— Сез нәрсә инде. Безнең башка «авырулар» да бар. Күптән чират көтәләр дияргә була. Савыгып килүчеләрне дә онытырга ярамас. Санитар Никошевтан башларбыз.

Отряд командиры Никошевны алып килергә кушты. Лейтенант ит кисәген җирдән алды да, чүпләрен каккалап кире банкага салды.

## 20

Санитар Никошев узган тәүлек эчендә күзгә күренеп картайган: йөзе суырылып, күзләре эчкә баткан, битен чал сакал-мыек баскан, гәүдәсе кечерәеп, бөкрәеп калган. Сорау алу Нурмыев куышында барды. Качарга тырышып караган очракта шымчыны корал кулланмый гына тотарлык итеп, тикшерү алдыннан тирә-якка каравыл взводы урнаштырылды. Дошман исән килеш кирәк — аннан күп нәрсә белергә мөмкин булачак иде.

Башта бераз сөйләшеп утырдылар. Журкин белән Нурмыев Никошевка берничә сорау бирделәр. Берәрсеннән шикләнмиме, аның әйберләре арасына коралны кем тыгып куярга мөмкин? Әмма санитар бер дә төпле җавап бирә алмады. Бер нәрсә белми, беркемнән шикләнми иде ул.

— Ярый алай булгач, Николай Пантелеймонович,— диде Журкин.— Бар, минем землянкада утырып тор. Авырсынмасаң, юл уңаенда менә бу сөякне эткә бирә кит әле, минем вакыт юк.— Журкин санитарга сөяк салынган банканы сузды.

Никошев эт янына сак кына килде дә банканы аның борын төбенә диярлек куйды. Эт сөякне иснәп тә карамады. Аптырашта калган санитар командир куышына юнәлде.

— Николай Пантелеймонович, сорарга онытканмын,— диде лейтенант, Никошевны куып җитеп.— Авыруларга һәм яралыларга ризыкны кем алып килә, кем өләшә?

— Миннән башка кем эшләсен инде бу эшне.

— Калдык-постыкны кая куясыз?

— Әй, аллам, хәзер ризык каламыни, вакыты шундый бит, үзегез күреп торасыз.

— Бернәрсә дә калмыймы?

— Юк...

— Ә сөякләр? Әллә аларны да ашап бетерәләрме?

— Анысы бар, иптәш тикшерүче, сөякләр кала. Бәлки калмас иде, тешләр нык түгел.

— Сөякләрне кая ташлыйсыз?

— Соң, чүплеккә инде, урманда урын күп бит.

— Бәлки берәрсенең сөяклерәк ит сораганы булгандыр?

Никошев бер урында таптанып уйга калды.

— Туктагыз әле, булды бит андый хәл, кемдер сөякле ит яратам, дип сөйләнде. Итне атнага бер генә ашыйбыз бит, сөяккә игътибар итүче сирәк...

— Бәлки сөяк яратучы исегезгә төшәр әле. Миңа әйтерсез. Килештекме?

— Соңрак искә төшәр, төшми калмас. Командир белән дә, сезнең белән дә шундый сөйләшүдән соң әлегә баш бик эшләми бит.

...Куышка килеп кергәндә, врач Губинның күңеле күтәренке иде.

Нурмыев аны ачык йөз белән каршы алды.

— Узыгыз, Валентин Владимирович.

Ковригинның да йөзендә елмаю:

— Менә монда, сәкегә,— диде ул.

Алдан сөйләшенгән буенча, отряд командиры әлегә үз куышында утырырга тиеш.

Йөзенә караганда, Губинның кәефе яхшы гына кебек. Тик күз төпләре генә бераз шешенгән.

Нурмыев күкрәк кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды.

— Сезне сөендерергә ашыктык, үзәктән хәбәр килде.

— Безнең өчен дә сөенечле хәбәр,— диде Ковригин.— Борчылган идек.

Врач ашыкмыйча гына укып чыкты.

Канәгатьләнүдән йөзе яктырып киткәндәй булды:

— Өстәп бер нәрсә дә әйтеп булмый...

Отрядны яңа урынга күчерү турында киңәшләштеләр. Штаб начальнигы Губиннан яралыларны күчерү өчен нинчә олау кирәк булачагын белеште.

Әңгәмәне Нурмыев йомгаклады:

— Житеп торыр, иптәшләр, әйдәгез, эшкә тотыныйк...— Врачка кулын сузды.— Гафу итегез инде мине, Валентин Владимирович, бик нык борчыдым. Эшем шундый бит.

— Борчылмагыз, мин үпкәләмәдем. Чынлап та, бер сүзем дә юк.

— Алай булса бик яхшы.— Лейтенант каравыл взводы командирына эндәште:

— Менә нәрсә, иптәш өлкән сержант. Врач Губин шушы минуттан азат. Аңлашылдымы?

— Нәкъ шулай. Моннан да аңлаешлырак булалмый.

Штаб башлыгы белән Петров чыгып киттеләр. Нурмыев башы авыртудан зарланып алды. Врач инде төзәлеп килгән яраны караганнан соң:

— Барысы да тәртиптә, узар,— диде.

Тагын бер тапкыр аның кулын кысканнан соң, итле сөяк салынган консерва банкасын тотып врач артыннан Нурмыев та куыштан чыкты. Аларга таба килүче отряд командиры ординарецы ерактан:

— Иптәш лейтенант, сезне майор Журкин үзе янына чакыра,— дип эндәште.— Бик ашыгыч килергә кушты.

Нурмыев зарлангандай итте:

— Иртәдән кичкә кадәр тынгы юк. Эткә ашарга да бирмәгән әле, ачтан үләдер инде, мескен.— Ул банканы ишек янында калдырырга теләгән иде, кире сүтелде дә Губинга тоттырды.— Я тагын онытырмын. Сез генә бирегез инде эткә шушы ризыкны.

Берничә адым киткәч, борылып куышка таба күрсәтте:

— Эт шунда, наратка бәйләп куелган...

Ялгызы калгач, Губин як-ягына каранды. Беркем дә күренми иде. Ул, эт янына килеп, алдына банканы куйды. Койрыгын болгый-болгый овчарка башта иснәнде, аннары сөякне эләктереп качарга теләде. Аны бәйләгән каеш бау җәя кереше кебек тартылды. Эт, ычкынырга теләп, башын бора-бора артка чигенде, бераздан муенчагын салып, агачлар арасына кереп югалды.

Бу күренешне онытылып карап торган Губин Нурмыев белән Ковригинның һәм ике автоматчының үзе янына килеп басуларын сизми дә калды. Күргәч тә бераз аптырап торды: нигә бик тиз әйләнеп килде соң әле Нурмыев һәм автоматларын әзер тоткан ике партизан? Лейтенант кулындагы сөяк эченнән кәгазь кисәге тартып чыгаргач, Губинның йөзеннән кан качты. Бөтенесе аңлашынды: тозакка эләкте, эләктерделәр!

— Бу шифровканы эт кемгә алып килгәнен эзли-эзли хәлдән тайган идек инде. Сез дә бер сүз дә әйтмисез. Ярдәм итәргә кирәк иде бит. Димәк, гауптштурмфюрер Дремель аяксыз агент аша сезгә сәлам җибәрә икән. Сез бит, Валентин Владимирович, гафу итегез, немецча исемегезне белмим, гестапо башлыгының...

Врачның йөзенә игътибар белән карап торган лейтенант өчен көтелмәгән хәл булды: тыштан мыштырдык күренгән бу кеше яшен тизлегендә аның башына китереп сукты. Бермәлгә Нурмыевның күз аллары карангыланды. Шул ук мизгелдә Губин, башын иеп, алга ыргылды, каршында торган автоматчыны сөзеп екты да, итек кунычыннан кечкенә браунинг тартып чыгарып, куакларга таба йөгерде. Йөгергән шәпкә төзәп тә тормыйча атып җибәрде. Ковригин күкрәгеннән тотып җиргә ауды. Куаклар артында яшеренеп торган өлкән сержант Петров, юлына аркылы төшеп, врач кулындагы коралны бәреп төшерде. Дошман аны да бер сугуда егып качарга теләгән иде дә, икенче автоматчы белән Нурмыев килеп өлгерделәр һәм докторның кулларын бәйләделәр.

Лейтенант җиргә ауган Ковригин янына килде. Гимнастеркасындагы кан табын күргәч, штаб башлыгының авыр яралануын аңлап алды. Ковригин инде аңын югалткан иде. Нурмыев читтәрәк басып торган Никошевка эндәште:

— Сез азат, лазаретка чабыгыз. Медфельдшер Бунакова тиз генә монда килсен. Ковригинның тормышы хәзер аның кулында.

Азат ителүенә сөенгән санитар лазаретка йөгерде.

Лейтенант шуннан соң җирдә яткан дошман янына килде. Губинның күзлеге югалган, күзләре йомык иде.

— Ачыктан-ачык сөйләшер вакыт җитте кебек, Валентин Владимирович.

Губин эндәшмәде.

— Хөрмәтле доктор, рус телендә сөйләшәсегез килмәсә, бәлки туган телегездә — немец телендә сөйләшербез? Ничек? Ризамы?

Губин күзләрен ачмый гына баш чайкады:

— Сөйләшергә теләмим.

— Ихтыярыгыз, Валентин Владимирович. Тик шуны исегездә тотыгыз: иртәгә отряд яңа урынга күчә, без сезне өстерәп йөрмәячәкбез. Артык йөк кирәк түгел. Сезне шушы урында күмеп калдырачакбыз.

Сүзгә Журкин кушылды:

— Кич белән партизан суды хөкем чыгарыр. Сезнең белән мәшәкатьләнергә вакыт юк — хәлне үзегез дә яхшы беләсез. Нинди хөкем көткәне дә билгеле. Уйлап карагыз.

— Уйлаудан ни файда, барыбер эш беткән,— диде Губин чит, өметсез тавыш белән.

— Белеп булмый. Сез — кадровый агент. Әгәр үзегезнең эшчәнлегегез, беренче чиратта безнең илдә ниләр эшләвегез турында сөйләсәгез, сезне тылга озатачакбыз. Кайда кемнәр белән укыгыз, башка илләрдә нәрсә белән шөгыльләнүегез безнең контрразведканы кызыксындырыр дип уйлыйм.

Шымчы күзләрен ачып зәңгәр күккә карады. Бераздан сорау алучыларга таба борылып ятты:

— Уйлау өчен бер сәгать вакыт бирегез.

Тикшерүче белән Журкин күзгә-күз карашып алдылар.

— Яхшы. Ләкин белеп торыгыз: әгәр бер сәгатьтән соң да кирелләнәсез икән,— Нурмыв сәгатенә карады,— суд башланачак. Димәк, кичкә сәгать сигездә. Шунда бүген үк бөтен эшне төгәлләрбез.

Ковригинны плащ-палаткага салып госпитальгә илттеләр. Авырлык белән булса да медфельдшер Бунакова пуляны ала алды. Бу инде Ковригинны коткарып калуга өмет бар дигән сүз иде. Боксчылар теле белән әйткәндә, партизан рингындагы күп раундлы бу көрәштә Нурмыевка хәйран каты эләккәләде. Әмма соңгы сугуны һәм штаб башлыгының яралануын ул бигрәк тә авыр кичерде. Әгәр Губинны вакытында тентегән булсалар... Әйе, шикләнде шул, шикләнде, гаепсез кешене рәнҗетүен бар бит. Дошманның тәмам фаш ителүе генә бераз күңелне тынычландыра. Әйе, чын көрәштә һәрвакыт авырлыклар да, югалтулар да була:

кемгәдер кимрәк, кемгәдер күбрәк эләгә — аерма бары шунда гына. Борынгыдан калган бу законны Зәки менә үзе өчен хәзер яңадан ачты, аның асылын бөтен җаны-тәне белән сизде.

— Иптәш лейтенант,— отряд командиры ординарецы тавышы иде бу.— Сезне майор Журкин чакыра.

Лейтенант ялгышмаган: шымчы сөйләү файдалырак икәнен, әгәр чын йөзен ачмаса, сатлыкҗан буларак бүген үк хөкем итеп атачакларын аңлаган иде.

Бәлки самолет килгәнче, я Мәскәүгә алып кайтканда качарга өметләнәдер? Тагын шунысын да аңлый шымчы: берьюлы бөтенесен сөйләп бетерергә ярамый, гомерен саклап калу, озайту өчен мәгълүматларны, ларектагы товар кебек, аз-азлап кына, бик кызыксынган кешегә генә сатарга кирәк. Шулай итеп, дошман озак сатулашырга өметләнде.

Командир куышында бөкрәеп, почмакка сеңеп утырган шымчының йөзе иңнәренә авыр йөк салынган атлант йөзе кебек: интегүле караш, кайгылы йөз. Агент сораулар биргәнне дә көтеп тормады, лейтенант бүлмә уртасындагы бүкәнгә килеп утыругач, сөйли башлады. Чын исеме — Курт Шредер. Хәрби дәрәҗәсе — оберштурмфюрер. Берлинда разведка мәктәбен тәмамлаган. Аңа кадәр хәрби госпитальдә хирург булып эшләгән. Шунда эшләгәндә башта СС сафларына алынган, соңрак гестапода хезмәт итәргә чакырылган. Гауптштурмфюрер Дремель белән бергә төрле эшләр башкарганнар. Аеруча осталык күрсәткәннәре өчен икесе дә тимер тәре белән бүләкләнгәннәр. Партизаннар хәрәкәте киң җәелгәч, монда җибәргәннәр. «Отрядка үтеп керүгә бик озак — өч ай әзерләндек: әсирләр арасыннан миңа охшаган врач эзләдек. Таптык. Тегенең күзләре начар күрә, ә минем күзләр тәртиптә. Күзлек ясарга туры килде. Кырыен калынрак эшләткәч, гади пыяла да кабарынкы линзага охшап кала. Күзлек кигәч күз төсләрендәге аермалык та күренмәс булды...»

— Пахомов отрядына ничек үтеп керә алдыгыз?— дип сорады тикшерүче.

— Гадәттәгечә: мине Губин исеме белән якындагы концлагерьга китерделәр, аннан өчәү качтык: качар өчен шартлар булдырылган иде. Юлдашларымда бернинди дә шик тумады. Ике төрле юл белән элемтәгә керә идем. Ашыгыч хәбәрләрне төрле төстәге пыялалар ярдәмендә самолетларга тапшырдым. Тулыландырып, гестапоны кызыксындырган дәлилләрне өстәп — элемтәче Глеб аша. Ул партизаннар базасы белән радист арасында йөрде. Ул тотылганнан соң вазифасын яңа агент — «аяксыз» башкарырга тиеш иде. Бәхете кыска булды...— Гестапо агенты салмак кына боек тавыш белән сөйли, әледән-әле киеренкелек белән башын күтәрә, тагын ия. Мина кыры янында булган вакыйга серләрен дә ачты: «төн кошлары» отряд җитәкчеләрен юк итәргә теләгәннәр. Мина кыры схемасы турында очраклы рәвештә, минерлар сөйләшкәндә ишеткән. Врач буларак аның эшчәнлегенең төп мәгънәсе: күпләп юк итү өчен кайберәүләрнең тормышын саклап калу да исеменә «тап» төшермәүдә» булган. Дару үләннәре җыю, үзе дә анда катнашу партизан постларын урнаштыру тәртибен өйрәнергә мөмкинлек биргән.

Оберштурмфюрер Шредер, тикшерүче сержант Скишов белән бергә иске партизан базасына киткәч, беренче тапкыр чын-чынлап курыккан.

— Иске базага барып кайткач, Скишовның акланачагы билгеле иде,— диде шымчы.— Тикшерүченең аннан соңгы адымы да минем өчен сер булмады: кайтуга отрядтагы бөтен кешене күздән кичерәчәкләр һәм эш пешті дигән сүз. Бу төркемнең әйләнеп кайтмавы минем өчен бик әһәмиятле иде. Шуңа күрә тиз генә Дремельгә хәбәр иттем...

Әллә үз хәленә күнекте, әллә язмышына кул селтәде, дошман эшлекле кыяфәттә сөйләшә башлады. Әйтерсең, партнеры белән әле генә тамамланган шахмат уенын тикшереп утыралар.

— Лейтенант, Сезгә тиешле бәя бирә алмавым минем иң зур, хәлиткеч ялгышым булды.— Досомовның «качуын» оештырганнан соң, Сез бик тиз

блицтурнирдагыча эш итә башладыгыз, һәр йөрешегез төгәл, дөрес иде. Чынын әйтим, Досомов гәүдәсен соңрак, мин отрядтан качканнан соң гына таба алырсыз, дип уйлаган идем. Шуңа кадәр мин сезгә карагaнда алданрак күрә, тизрәк йөри идем. Кызганычка каршы, артык тынычландым, уяулыгымны киметтем. Качып өлгерермен кебек тоелды. Өстәвенә Никошевны «яшен уздыргыч» ясаган идем. Ул гына да түгел...

Тикшерүче аның сүзен бүлде:

— Аяксыз агентны урнаштырганда файдаланылган ялган партизан командирын санитар Никошевка охшатып сайлавыгызны әйтәсезме, Шредер? Элемтәче «янган» очракта, без аңа «абынган» булыр идек. Шулаймы?

Гестапочы гаҗәпләнүен яшерә алмады:

— Әйе... Сезне болай уктыр дип уйламаган идем...

Шымчы, кулъяулыгын чыгарып, маңгаендагы тирен сөртте.

— Әйтегез әле, Шредер, аяксыз агентны кем урнаштырды? Дремель һәрхәлдә үзе түгелдер ич?

— Юк, түгел. Ул — уйлап табучы. Бик үзенчәлекле, төпле фикер йөртә белә. Аңа әле егерме биш кенә яшь, инде чираттагы хәрби дәрәҗәгә — штурмбанфюрер чинына тәкъдим ителгән.

Шымчы бик каты тирләп чыкты. Кечкенә яулыгы белән әле маңгаен, әле муенын сөртеп карады — файдасы күренмәде.

— ...Бу эшне безнең тәрҗемәчебез башкарды. Ул бераз Никошевка охшаган. Дремель шуннан файдаланырга булды. Урманчы үзе элемтә өчен файдаланырлык кеше түгел, ышаныч аз иде. Шуңа күрә гестапо шефы гади генә, әмма өметле операция тәкъдим итте. Урманчыны үтерергә ярамый, шик тудырачак. Дремель үз кешеләрен партизаннар итеп киендереп урманчы янына җибәрә. Тегеләр урманчыны бер ай «аяксыз» белән торырга ризалаштыралар. «Ашарга бирәбез, тик бөтен кешегә дә энекәш килде дип әйтерсең». Янәсе, партизаннарның бик яшерен эше.

Шымчыдан сорау алу ярты төн узгач кына тәмамланды.

Иртән лазаретка барганда, Вера очрады. Туктап, моңсу гына сүз башлады:

— Губинны сез фаш иттегезме?

Зәки җавап бирмәде.

— Ә мин тагын сезне өйрәткән булдым. Үземнең борын төбендә дошман эш иткәнен сизмәгәнмен, авыз ачып карап торганмын... Миңа оят, Зәки, гафу итегез...— Вера башын югары күтәреп агач башларына карады. Әйтерсең, аның кичерешләренә дәва шунда гына иде.

Кояш нуры кызның битенә төшкән. Күзләре дә яшькелт түгел, күк кебек зәңгәрсу булып тоелалар. Шул күзләрне үбә-үбә, Зәки кызга үзенең яңа бер шигырен укыды.

— Мин сезне яратам, Вера...

Ул аның күкрәгенә сыенып, моңсу гына пышылдады:

— Тиздән безне ташлап китәсез ич инде: монда эшегез бетте кебек. Ә мин...— Кызның тавышы тәмам ишетелмәс булды.— Мөмкин булса, калыгыз сез монда...

— Калам, Вера. Әлбәттә, калам.

— Чынлап әйтәсезме? Әллә мине тынычландыру өчен генәме?

— Чын дөресен әйтәм, Вера. Миңа отрядта разведка житәкчесе булып калырга тәкъдим иттеләр. Ә отряд тиздән бригада итеп оештырылачак. Миңа монда да эш җитәрлек булыр. Менә хәзер отряд командиры янына барам да ризалыгымны белдерәм. Ул шуны өмет итә бугай.

— Бар, Зәки. Мин сине шушында көтәрмен!

Русчадан **Ринат ВАХИТОВ** тәрҗемәсе.

## Гәрәй Рәхим

### Оча күңлем

Оча күңлем...
        Оча күңлем...
                Оча күңлем
                Киңлекләргә.
Кошларгамы,
        Икаргамы —
Тиң икәнмен соң кемнәргә?!.

Мин йолдызмы,
                космонавтмы,
Әллә гади Биктимерме?!.
Белмим...
        Белмим...
                Әмма күңлем
Җир тарту көчен җимерде!..

Оча күңлем...
        Оча күңлем...
Аста кала диңгезләр дә.
Җирдән өстә...
        Айдан өстә...
Орбитасы кай җирләрдә?!.

Сфералар бик тар аңа —
Чиксезлекне коча күңлем.
Исемсез К ү к,
                атсыз К о я ш.
Ят Айларга оча күңлем!..
Яңа Г а л ә м,
                Яңа Җ и һ а н,
                        яңа Д ө н ь я ача күңлем!..

Оча күңлем...
        Оча күңлем...
                Оча күңлем...

❁

Ничәнче гасырын яши Җир,
Кояштан яктылык сирпелә.
Тик гөлләр һаман да җырлыйлар:
Үсәргә нур кирәк,
                нур кирәк,
                        нур кирәк!..

Галәм ул серләргә бай дөнья —
Мәхәббәт галәмнән серлерәк.
Шулай да гашыйклар җырлыйлар:
— Сөйләргә сер кирәк,
сер кирәк,
сер кирәк!..

Тарихта тантана күп булды —
Бүгенге тантана көчлерәк.
Бит бүген мәйданнар җырлыйлар:
— Мәйданга җыр кирәк,
җыр кирәк,
җыр кирәк!..

Ничәнче гасырын яши Җир,
Әйләнә һаман бер көй көйләп:
— Мин яшим, тик миңа яшәргә
Нур кирәк,
сер кирәк,
җыр кирәк!..

## Синдә генә

Идеал-хыялда түгел,
Түгел сурәт-рәсемдә —
Безнең гап-гади бөеклек,
Табигать, синдә генә.

Урманнар юмартлыгыннан
Үрнәкләр ала-ала,
Идеалда, хыялында
Кеше дә юмартлана.

Далалар киңлеген күргәч,
Киңәя безнең җаннар.
Яктырып китә күңелләр
Атканда аяз таңнар.

Чишмәләр сафлыгын тыңлап
Чистара кеше үзе.
Якты кояш, тулган айдан
Елмая бара йөзе.

Күкләрнең биеклегеннән
Омтылыш, өлге алып,
Үтәсе килә галәмне
Комета кебек ярып.

Җирем, тик син бай булганда
Бай була ала кеше.

Тик сине,
сине ярату
Аның иң төпле эше...

...Идеал-хыялда түгел,
Түгел сурәт-рәсемдә —
Безнең гап-гади кешелек,
Табигать, синдә генә.

## Сөйлә

Замана ваклыкларыннан
Ваклана күрмә, шигырь!
Тарихның бер табына да
Таплана күрмә, шигырь!

Ракеталар әле кешенең
Иң көчле көче түгел —
Ракеталар түбәнлегенә
Төшә күрмә син, күңел!

Ялчылык — хурлык!
Кемгә дә
Яллана күрмә, тәнем!

Заман алдавычларына
Алдана күрмә, тәнем!

Сәнгатьләр биеклегенә
Күтәрел, көйрә, рухым!
Тормыш дигән чор арбасын
Туктатма, сөйрә, рухым!

Тереклеккә, яшәешкә
Дан көен көйлә, шигырь!
Мәңгелеккә мактау сүзен
Туктаусыз сөйлә, шигырь!

## Бәйрәм

Урамнарда бәйрәм тавышлары,
Без котлыйбыз бөтен танышларны:
— Бәйрәм белән!
Бәйрәм белән!..
Бүген кояш җиргә яз өләште,
Бүген таңда сандугачлар дәште:
— Бәйрәм белән!..
Бәйрәм белән!..

Күңелләрдән куып сагышларны,
Тыңлыйк әле язгы тавышларны:
— Яшәү рәхәт!..
Яшәү рәхәт!..
Бүген күктән җиргә бәхет иңде,
Бәйрәм булып безгә шат яз килде —
Кояш, рәхмәт!.. Кояш, рәхмәт!..

## *Сафа Сабировка 70 яшь*



*Сафа Сабиров әдәбият сөючеләргә иң элек үзенең Идел һәм елгачылар тормышына багышланган повестьлары, хикәяләре, күп санлы очерклары белән билгеле. Профессиональ елгачы буларак, ул Иделне, аның кабатланмас табигатен, бай тарихын, анда эшләүче кешеләрнең хезмәтен, уй-хисләрен тирәнтен белеп, ышандырырлык итеп яза. Язучының әсәрләрендә гражданнар сугышы вакыйгалары («Утлы фарватердан» повесте), Бөек Ватан сугышы вакытында елгачыларның Бөек Җиңүне якынайтуга керткән өлеше («Хатлар язам сагынып» повесте) чагылыш тапты. Автор повесть, хикәя, очеркларында шулай ук сугыштан соңгы тормышны да сурәтли, Идел киңлекләрендә барган зур эшләрне, үзгәрешләрне күрсәтә, замандашларыбызның якты омтылышларын, тыныч хезмәттәге уңышларын тасвирлый.*


*С. Сабиров байтак еллар Татарстан китап нәшриятында да эшләде, республикабызның иҗат көчләре белән тыгыз элемтәдә торды. Язучы әле дә актив эшләп килә, иҗади эзләнүләрен дәвам итә. Әдәбият сөючеләр исеменнән без аны кайнар котлыйбыз һәм киләчәктә дә иҗат уңышлары телибез.*

# Сафа Сабиров

# СЫЕРЧЫКЛАР НИ ДИП САЙРЫЙ?

ХИКӘЯ

I



Карлы-буранлы кышкы салкыннардан соң нурлы яз кергән, елгачылар кышкы квартиралардан теплоходларга, баржаларга күченгән мәшәкатьле чак. Кояш көннән-көч ягымлырак елмая, тау битләреннән йөгерек гөрләвекләр шаулап ага, елгада су арта. Яр өстендәге өянкеләрдә күптән түгел генә җылы яклардан кайткан кара каргалар шау-гөр килеп оя тибә.

Кечерәк кенә сары чемодан тоткан повар кыз Назифә, соңга калмагаем дигән сыман, җиңел адымнар белән затонга ашыга һәм барган шәпкә әледән-әле үзалдына елмаеп куя. Әйләнә-тирәдәге ыгы-зыгылы җанлылыктан, кояшлы язгы һавадан аның йөрәге җилкенә: үзен җиңелчә башы әйләнгәндәй хис итә, тизрәк Иделгә чыгарга, хыял кебек чиксез зәңгәр киңлеккә ашкына ул.

Түбәндә причалда, кояш нурына балкып былтыр җәй эшләгән биек корпуслы мәһабәт «Владивосток» теплоходы тора. Назифә аны туган үскән йорты кебек үз итеп, яратып өлгергән иде. Причалга якыная барган

саен аның йөрәге ешрак тибә, күңелендә шатлык дулкыны күтәрелә.

Әнә, алгы палубада зәңгәр куртка кигән базык гәүдәле бер егет, рулевой Госман Хәйруллин, судан коткару бөятләренә кызыл буяу белән теплоход исемен язып маташа. Такта траптан менеп килгән Назифәне күрү белән, аның шатлыгы йөзенә бәреп чыкты.

— Әһә, менә туйдыручыбыз да килеп җитте. Әйдә, рәхим ит,— диде ул, елмаеп. Һәм шундук эшеннән туктап, Назифәнең кулыннан чемоданын алды.

Алар исәнләшеп хәл-әхвәл белешкән арада кайдадыр якында гына кош-корт чыр-чу килгәне ишетелде. Башларын күтәреп карасалар, рубка өстендә бер пар сыерчык кайнаша, кемдер ясап куйган ояга яр буеннан коры салам, яфрак кисәкләре ташып, ашыга-ашыга торак әмәллиләр.

— Карале, рубка өстенә сыерчык оялаган ич...— диде Назифә.— Сыерчык иләшкән йортка шатлык килә, диләр. Шулай булсын, безгә дә шатлык китерсеннәр.

— Күрче, чынлап та сыерчыклар иләшкән бит,— диде Хәйруллин гаҗәпләнеп.— Чү, бу ояны капитанның онытына мин ясап биргән идем бит. Өенә алып китәсе урында ул малай актыгы аны рубка өстенә менгереп куйган. Кай арада аңа сыерчык иләшкән?

Күренеп тора, хәзер сыерчыкларның туйлашу вакыты: түш һәм муен каурыйлары кояшта утлы-яшелле җемелди, хәрәкәтләре ашкынулы; эштән туктап ял иткән арада, бер-берсенә мәдхия җырлагандай, чут-чут сайрап та алалар.

— Госман абый, син ничек уйлыйсың,— диде Назифә,— бу сыерчыклар ни дип сайрый икән? Гомумән, берәр нәрсә тоеп, белеп сайрый микән алар?

— Әлбәттә, белеп сайрыйлардыр... Минемчә, алар нәкъ син уйлаган нәрсә турында сайрый бугай.

— Бигрәк инде син...— Назифә уңайсызланып калды; битенә җиңелчә кызыллык йөгерде.

— Ярар, үпкәләмә... Әйдә, каютаң ачкычын бирим. Әйберләреңне урнаштыр да, азык-төлек алырга барырбыз. Склад ябылганчы өлгерергә кирәк, иртәгә иртүк рейска чыгасы.

Теплоходта көндезге ял вакыты, әлерәк кенә завод ашханәсеннән кайткан бер төркем команда членнары урта люк капкачы өстендә кояшта тәмәке көйрәтә-көйрәтә гәп сатып утыралар. Барысы да былтыр бергә эшләгән таныш-белешләр. Арада купшы гына киенгән җирән мыеклы таныш түгел берәү бар. Быел яңа штурман килгән дип әйткәннәр иде, бу мыек шул булса кирәк. Назифә сәлам биреп уйнак адымнар белән яннарыннан үткәндә егетләр дусларча елмаеп исәнләштеләр һәм повар кызның зифа буена сокланып карап калдылар. Арадан бер озын теллесе үзенчә мәзәк итеп булса кирәк:

— Менә бу фигура... Моңа якорь салып карасаң да ярый,— дип реплика ташлады һәм тамак кырып куйды.

Моны ул акрын гына, янында утырган егетләр ишетелерлек итеп кенә әйткән шикелле иде. Әмма аны Назифә дә ишетте һәм ялт борылып:

— Якорь салып карарга исәбең?! Я, күрик, кем ул шундый кайнар йөрәкле?..— диде.

Кинәт уңайсыз тынлык урнашты. Теге пычрак телле бәндә үзен белгертергә батырчылык итмәде, бүтәнчә сүз уйнатмады, куркакларча кеше артына посты. Башкалар исә аны уңайсыз хәлгә куярга теләмәделәр, күрәсең, берни дә ишетмәгән-күрмәгәндәй, сүзсез утыра бирделәр. Назифә берничә адым китеп барганнан соң да әле тынычлана алмыйча, эчке чиркану белән:

— Былтыр бездә мондый затсызлану юк иде, кайсы булды икән бу,— дип үзалдына әйтеп куйды.

## II

Поселок клубы гөр килә, яше-карты шунда җыелган.

Бүген анда зур тантана — навигация ачылу алдыннан затон белән саубуллашу кичәсе. Кышкы ремонт алдынгыларына Мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр бирделәр. Завод җитәкчеләре, хезмәт ветераннары — карт капитаннар, механиклар — иртәгә Иделгә чыгасы командаларга хәерле юл теләделәр, үгет-нәсихәтләрен әйттеләр.

Тәнәфестән соң кичәнең икенче бүлеге башлана. Бәйрәмчә киенгән яшь штурманнар, рулевойлар, матрослар, хәрәкәтчән кыз һәм киленнәр вальс көенә бөтереләләр. Кышлау вакытында табышкан парлар ташлашмаска вәгъдәләшә, хат язарга сүз куеша. Рулевой Хәйруллин гына, бәйсез буйдаклыгы белән горурланган сыман, авыз эченнән һаман бер җырны кабатлап йөри:

Башкаема хәсрәт алып
Яр сөясем калмаган...

«Владивосток» егетләре — үзләре бер артель — Назифәгә туктап тын алырга да бирмиләр, әле берсе, әле икенчесе биюгә чакырып кына тора. Яңа штурман Борһанов иң оста биюче булып чыкты. Аның эрсез шаянлыгы, берсеннән-берсе көлдергеч мәзәкләре бушка китми бугай, Назифә аңа ягымлырак елмая, аның белән теләбрәк бии. Дөрес, моны ул үзенчә башкаларга бик сиздермәскә тырыша, егетләрнең берсенә дә өстенлек күрсәтмәгән сыман, һәркайсы белән эчкерсез ачык йөзле, дусларча шаяра-көлә.

Кичә беткәннән соң теплоходка кайтканда да шаян штурман һаман Назифә тирәсендә булды, бетмәс-төкәнмәс мәзәкләрен, күңелле шаяртуларын туктаусыз сиптерә торды. Яр буена җитәрәк караңгыда тайгак урыннан үткәндә, ярдәм иткәндәй, култыклап алды да, төркемнән арттарак калырга теләп, адымын акрынайта төште. Әмма Назифә аның бу ниятен әдәп белән генә кире какты:

— Иртәгә камбуз эшли башлый, иртүк торасым бар,— дип, теплоходка башкалар белән бергә кайтуны мәгъкуль күрде.

Бу кичне ул җыйнак итеп җыештырылган кечерәк кенә каютасында канатлы уйларга чумган хәлдә йоклап китә алмыйча озак ятты. Клубтагы күңелле кичә, җилкенеп биюләр, гашыйк егетләрнең берсеннән-берсе уздырып аның тирәсендә бөтерелүләре күз алдыннан кабат үтте. Өйдән киткәндә артык бала җанлы әнисе аның өчен борчылу белән: «Елгачылар шома телле, җилбәзәк халык, берүк алдыңны-артыңны карап йөр, сак бул»,— дип кисәтеп калган иде.

Юкка борчыла әнисе. Назифә моны үзе дә күреп тора. Һәркайда җиңел аралашканга һәм үзләрен артык иркен тотканга гына бераз җилбәзәк күренәләр алар... Шунда ул, үзе дә көтмәстән, көндез палубада кайсыныңдыр «менә моңа якорь салып карарга ярый» дип әйткән затсыз сүзләрен хәтерләп, уйга калды. Кайсы мәнсезе булган икән, бүген клубка барды микән ул?

Шулай да көнозын аяк өсте йөрү үзенекен итә. Назифәне акрынлап татлы талыгу баса, керфекләре авыраеп, күзләре үзеннән-үзе йомыла башлый. Кайдадыр баш очында сыерчык сайрый, колакка ятышлы вальс моңнары яңгырый һәм, өн белән төш катнаш дулкыннар кочагында тирбәлеп, ул татлы йокыга китә.

## III

Кар кебек ак калфак, кыска ак халат кигән Назифә иртән каютасыннан чыкканда кояш инде шактый югары күтәрелгән, теплоход затонның боздан ачык өлешендә салмак кына борылып, хушлашу

гудоклары кычкырта-кычкырта юлга чыгып бара иде. Өске палубада җыелган команда членнары яр буенда озатып калучы туганнары белән кул болгап саубуллашалар; бүген алар, кичәге кебек, уенчак-шаян түгел, барысы да уйчан, йөзләре ямансу.

Сыерчыклар исә, киресенчә, ифрат тынгысыз, рубка өстендә ут чыккан кебек тыз-быз киләләр, оя эченә әле кереп, әле чыгып борчылалар. Ул да түгел, берсе, затоннан аерылырга теләмәгәндәй, теплоход кышлаган причалга таба очып китте, икенчесе оя түбәсендә канатларын җилпи-җилпи аның артыннан карап калды.

— Ай, иркәге бугай, оясын ташлап китте...— диде Назифә, камбуз ишегеннән карап торган җиреннән.— Кара син, ә... Ул кайтмаса, аның артыннан монысының да китүе ихтимал бит.

Бу хәл палубадагы егетләргә дә сәер тоелды, әле берсе, әле икенчесе әткә сыерчык очып киткән тарафка борчылулы караш ташлый иде. Рулевой Хәйруллин гына исе китмичә:

— Сыерчык үз оясын, тормыш юлдашын ташлап китә торган җилбәзәк кош түгел,— диде.— Ул болай гына, иявәшкән яр буйлары, күршедәш сыерчыклар белән хушлашырга киткән булса кирәк. Менә күрерсез, күп тә үтмәс, һичшиксез, очып кайтып җитәр.

— Һи, әйткән сүз, җилбәзәк кош түгел, имеш,— диде штурман Борһанов, үртәүле көлеп.— Кайтты ди, тот капчыгыңны...

Ул тагын нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, шунда әткә сыерчыкның очып кайтып төшкәнен күреп, ярты сүздә шым булды. Әле һаман борчылып карап торган Назифә шат тавыш белән:

— Кайтты ич, акыллым, әнә кайтты...— дип кычкырып җибәрде.

— Әйе, әйе, кайтты, молодец!..— дип, егетләр дә моны хуп күрделәр.

— Сыерчык ул күке ише зимагур түгел, оя җанлы кош.

— Болай булгач, боларны команда составына алырга туры килә инде... Әй, Назифә, ишет: бүгеннән ашны ике җанга күбрәк пешерә башларсың.

Тиздән затон тамагыннан Идел киңлегенә чыктылар, теплоход бар куәтенә эшләп китте. Сыерчыклар бу хәрәкәткә, гел алмашынып торган ярларга аптыраулы каранып бардылар да, бераздан янә сузып-сузып сайрый башладылар.

Һәм шуннан бирле алар, тулы хокуклы команда членнары кебек, гел теплоходта йөри, коры җирдә яшәүче тугандашларыдай нык төпләнеп, йөзмә ояда көн итә торган булып киттеләр. Дөрес, баштарак алар бераз сагая, кинәт гудок кычкыртулардан сискәнеп куялар иде. Тора-бара тынычландылар, тынгысыз ыгы-зыгылы тормышка тәмам ияләштеләр. Тагын шунысы кызык: кешеләрне бер-берсеннән аера-таный беләләр, палубада еш ишетелә торган кайбер сүзләрне үзләренчә кабатлыйлар да икән.

Юлда барганда алар күбрәк ояда үз эшләре белән мәшгуль яки, йорт кошлары кебек, аяк астында, камбуз тирәсендә чүпләнделәр. Пристаньнарда туктап торган вакытларны әле берсе, әле икенчесе бөҗәк эзләп яр буена чыга һәм кузгалып китү алдыннан гудок кычкыртуга шундук очып кайтып керә иде.

Канатлы җырчыларны команда членнары да үз күрәләр, кул астында булган ризык валчыклары белән сыйлыйлар. Кичке моңсу сәгатьләрдә аларның мачта очында чут-чут өздереп, сузып-сузып сайраулары һәркемнең күңеленә хуш килә.

Тиздән сыерчыкларның туй каурыйлары утлы-яшелле җемелдәвен югалтты, алар икесе дә, басынкыланып калды. Ана сыерчык инде беркая чыкмый, хәзер ул гел оя эчендә йомыркада утыра. Кайгыртучан ата сыерчык аңа җимне үзе ташып ашата. Ә эштән буш араларда оя каршындагы мачта очына куна да, назлы сайрап бикәсенең күңелен күтәрә.

## IV

«Владивосток» һәрвакыт диярлек хәрәкәттә, үткен борыны белән елганы урталай ярып һаман алга бара. Вахта артыннан вахта алышына, һәркем үз эше белән мәшгуль.

Башкалар кебек вахтада тормаса да, Назифә дә иртәдән кичкә тикле үз постында: камбузда аш-су пешереп, көненә өч мәртәбә команданы ашата-эчертә, савыт-сабасын юа, пристаньнарда туктап торганда артельче Хәйруллин белән магазиннан азык-төлек ала, кичләрен кызыл почмакта мөдирлек итә, егетләр белән стена газетасы чыгарыша.

Назифәдән тыш, теплоходта тагын берничә хатын-кыз бар. Алар — ирләре янында булыр өчен кайсы матрос, кайсы моторчы булып эшлиләр, беришләре җәйге ялларын якыннары янында үткәрәләр, үзара гына әйткәндә, Назифәдән бераз көнләшәләр дә. Чөнки мондагы буйдак егетҗилән генә түгел, семьялы ирләр дә киң күңелле, ачык йөзле, эшкә уңган повар кызны үз итәләр, кирәк чакта эшендә теләп булышалар.

Назифә инсафлы кызларга хас сизгерлек белән үзен һәрвакыт әдәпле тота, чытлыкланып, кемгә дә булса артык ягымлылык күрсәтеп, имешмимеш сүз йөртүләргә азык бирми.

Ләкин бу тыштан гына шулай, дөресрәге, баштарак шулай иде. Чынлыкта исә аның йөрәгенә берәү ут салды инде. Хәзергә әле телдән сөйләшкәннәре, ачыктан-ачык аңлашканнары булмаса да, Назифә гел аның турында уйлап йөри, ашханәгә ул килеп кергәндә, аның өчен дөнья кояш чыккандай яктырып китә, йөрәге ешрак тибә башлый, йөзенә кызыллык йөгерә. Йөрәгендә беренче мәхәббәт ялкыны кабынганнан бирле ул төскә-биткә дә чибәрләнеп, тагын да мөлаемланып китте. Хәзер ул һәр иртәне елмаеп, якты өмет белән уяна, һәр яңа туган көн аңа менә-менә зур сөенеч алып килер кебек.

## V

Назифәнең бүгенге көне дә матур башланып китте. Иртәнге аштан соң кызыл почмакта айлык эш йомгакларын тикшерүгә багышланган җыелышта алдынгылар арасында профорг аның исемен дә телгә алды һәм Мактау тактасына теркәргә тәкъдим кертте.

Гадәттәгечә тыныч кына башланган бу җыелыш бик тиз кызып китте. Һәркемне энә күзеннән үткәргән кебек, җентекле тикшергәннән соң гына тавышка куеп расладылар.

Назифәгә чират җиткәч, шау-шулы җыелыш кинәт тын калды. Повар профессиональ елгачы булмагангамы, кешеләр бер-берсенә сораулы карашып алдылар. Бераздан, түр тәрәзә янында моңарчы тын гына утырган капитан Федор Петрович сүз сорагач, Назифәгә эсселе-суыклы булып китте, эштә эленке-салынкылыкны, һәртөрле җыйнаксызлыкны җене сөймәгән таләпчән карт елгачы менә хәзер бөтен команда алдында тиргәп оятлы итәр кебек тоелды.

Капитан исә утырган җиреннән кузгалмыйча, гадәтенчә сабыр гына:

— Ник әле сез, Надяны күрмәгән-белмәгән кебек, ләммим сүзсез калдыгыз? — диде.— Диңгезчеләрдә бер әйтем бар: корабта яхшы кок врачка тиң, диләр. Әйтегез әле, безнең кок та шундый түгелмени?! Һәр көн ул пешергән тәмле ашны рәхәтләнеп ашыйсыз. Туган көн бәйрәмнәрегездә һәркайсыгызны бизәкле торт, баллы чәк-чәк белән кадерләп сыйлый... Берүк күз тимәсен, бик тырыш, бик уңган кыз, кирәк булганда юк кына азык-төлекне дә оста төрләндереп, менә дигән аш әзерләп бирә бит. Шуның өстенә китапханәче, кызыл почмакны плакатлар, рәсемнәр белән бизәде. Минемчә, Мактау тактасына һичшиксез лаеклы безнең кок.

Капитан сүзенә кушылып, барысы да дәррәү кул күтәрделәр, Назифәгә эшендә яңа уңышлар теләделәр. Аның белән янәшә утырган штурман Борһанов, сүзсез генә тәбрик иткәндәй, терсәгенә җиңелчә кагылып алды.

Ә кичен, кызыл почмакта бар кеше таралып беткәч, Назифә стена газетасына рәсемнәр ясап утырганда ачык ишектә штурман Борһанов күренде һәм стеналардагы Идел күренешләрен, теплоход ветераннарының фоторәсемнәрен, киштәләрдәге экспонатларны өстән-өстән генә күздән кичергәннән соң:

— Белми идем, болар барысы да синең эшмени? — диде.— Үзең дә, яшь пионер кебек, иренмәгәнсең... Инде төн уртасы бит. Бүгенгә җитәр, газетаңны иртәгегә калдырып торсаң да гөнаһ булмас.

Бу юлы Борһанов көндәгечә формадан түгел, кыска җиңле ак футболка кигән, бөрек кебек җирән чәчен артка яткырып тараган, таза муенына нәзек чылбыр белән кулон сыман җиз якорь таккан иде. Назифә балаларча беркатлылык белән:

— Нинди әкәмәт бу? — дип гаҗәпләнде.

— Бумы? Бу — тылсымлы якорь,— диде Борһанов, җитди тонга күчеп.— Дөресрәге, безнең нәселдә буыннан-буынга күчеп бара торган әманәт, ягъни вәгъдәгә, дуслыкка, мәхәббәткә тугрылык символы бу... Безнең нәсел әүвәл-әүвәлдән елгачы бит, бу якорь безгә шуннан килгән. Минем әти өйләнер алдыннан бу якорьне гомергә тугрылык билгесе итеп әнигә биргән. Әти вафат булганнан соң әни аны миңа тапшырды, син дә аның кебек тугры бул, диде.

— Бик әйбәт символ, ә мин аңламый торам. Әткән-әнкәң яхшы кешеләр булган икән.

Бу минутта яшь штурман Назифәгә, моңарчы күренмәгән әчке матур ягы белән ачылгандай, тагын да якынрак булып китте. Тик шунысы сәер, теплоходта егетнең әнә шул рухи күркәмлеген, бай хисләрен күрмиләр, аны никтер өнәп бетермиләр иде.

Менә хәзер ярым караңгы кызыл почмакта иңгә-иң сыенып, серләшеп утырганда Назифә ул кырын карашларны тагын хәтерләде һәм бу хәлне егетнең үзенә дә әйтте. Борһанов исә моны үзе дә күрә, сәбәбен дә яхшы белә икән.

— Булдыксызларга, җыен ялкауга бер дә исең китмәсен. Минем кебек штурман була алмаудан көнләшәләр алар, шуңа кырын карыйлар,— диде ул, Назифәнең биленә кул салып.— Һәр кеше үз тормышын үзе төзи, максатына үз көче белән ирешә. Мин дә үз тырышлыгым белән штурман булдым, тормыш юлымда сине очратуыма шатмын. Атам-анамнан калган бу изге әманәтне менә хәзер сиңа тапшырам.— Борһанов дулкынланып сөйли-сөйли, җиз якорьлы чылбырны салып, Назифә муенына элде, иңнәреннән сыйпап иркәләде.— Сиңа бик тә килешә, сөйдергеч таккан кебек, тагын да сөйкемлерәк булып киттең... Назифә, сизәсеңдер, мин сине үлеп яратам бит. Әйтче, зинһар, син дә мине үз итәсеңме, ышанасыңмы?..

Назифә үзе дә ут эчендә, моңарчы һичкайчан булмаган хәл, егет кочагында балавыздай эреп утыра. Аның кайнар сулышыннан, шашынып кочу-үбүеннән исергән хәлдә, төштә саташкандай:

— М-мин дә үз итәм, ышанам...— дип ишетелер-ишетелмәс кабатлады.

Алар, бер-берсен югалтудан курыккан кебек, кочаклашып озак үбештеләр.

Шулчак тышта нәрсәдер кыштырдаганы ишетелде, ачык тәрәзәгә эленгән ак ефәк пәрдәнең аскы читен җилме, кешеме ялт итеп ачкандай булды. Икесе дә сискәнеп тәрәзәгә карадылар, хәрәкәтсез калдылар һәм бер мәл тын да алмыйча тынлыкка колак салып тордылар.

Беренче булып егет телгә килде:

— Беркем дә юк, җил генә булды бугай,— диде, сагаеп калган

Назифәне тынычландырырга теләп.— Юк, синсез бер көн дә тора алмыйм мин... Назифә җаным, әгәр син дә мине чын-чынлап яратсаң, әйдә без болай эшлик: иртәгә көндез теплоход Камышлыда бодай кабул иткәндә загска барып гариза бирик... Я, ничек, ризамы?

Назифәнең әлегә тикле мондый назлау сүзләрен ишеткәне юк иде. Егетнең кайнар кочагында башы әйләнде.

— Каршы түгел, мин дә риза...— дип пышылдады.— Әмма Камышлыда түгел, гаризаны затонга кайткач, үзебезнең шәһәрдә бирербез. Чөнки безгә башта әнигә күренергә, аның фатихасын алырга кирәк. Шунсыз ярамый. Мин аның бердәнбер кызы бит, юкса хәтере калуы бар.

— Ух, без затонга кайчан әләгәбез әле, аңынчы күпме көтәргә кирәк.— Борһанов чарасыздан авыр сулап, авызын турсайтты. Аннары Назифәне кочагына алып, тагын кабынып китте.— Шуны онытма: әнисңә генә түгел, хәзер син минем дә бердәнберем бит. Һич тә синсез кала алмыйм, гел синең белән бергә буласым килә... Вакыт соң инде, әйдә кызыл почмакны ябыйк. Җаным, син каютаңның ишеген бикләмә, шакылдатмый гына керерлек булсын. Тагын бераз сөйләшеп утырырбыз. Махсус синең үзеңә атап язган шигырем бар, шуны укырмын...

Хәер, Назифә үзе дә аерылып китәргә бик ашыкмый, күңел кошы янында булу, назлану аңа да рәхәт. Һәм ул сөйгәненең өзгәләнеп ялваруын кире кага алмады, ихтыярсыз күндәмлек белән риза булып, шундук өстәлдәге газета, пумала, буяуларны җыештырырга керешә.

Яктыдан палубага чыккач, Назифә беравык һичнәрсә күрә алмыйча торды. Аннары, караңгыга күз ияләшкәч, төн карасы сыегая төшкәндәй булды. Өстә, рубкада һәм машина бүлегендә вахта торучылардан кала, бар кеше йокыга чумган иде. Әйләнә-тирә тып-тын, теплоходның алга баруын сиздереп, түбәндә тынгысыз дулкыннар гына сөйләшә. Еракта, яр буендагы тау сыртларын шомлы яктыртып, ара-тирә аҗаган уйнап куя.

Назифә кызыл почмакта озак тоткарлануына уңайсызланып, тизрәк каютасына кереп китәргә ашыкты. Чирек сәгатьтән ярым караңгы коридорда штурман Борһановның сак адымнары ишетелде, ләкин кызның ишеге никтер ачылмады, ул эчтән бикле булып чыкты.

## VI

Иртәгесен Назифә, гадәттәгечә, сәгать алтыда уянды һәм, кичәге кичне хәтерләп, кәефле елмаеп куйды. Шунда кинәт күңелендә шик туды: чү, чын булдымы бу, матур төш кенә түгелме дип, әйләнә-тирәсенә күз йөртте һәм өстәл өстендәге җиз якорьны күргәч кенә тынычланды.

Иркенләп ятарга вакыт юк иде. Вахталар алмашыну башланганчы иртәнге сигезенче яртыга ашны әзерләп өлгертергә кирәк. Ул тиз генә юынып, көзге каршында чәчен тарады, җиз якорьлы чылбырын муенына такты, ак калфагын киде, алъяпкычын бууды. «Бүген үк әнигә хат язып салырга кирәк, тиздән кияү булачак егет белән очрашасын алдан белеп торсын»,— дип, уйлап куйды.

Төнлә белән теплоход Камышлыга килеп туктаган икән. Хәзер аның трюмнарына тасмалы транспортерлар ярдәмендә бодай төйиләр; алгы якта берничә матрос-практикант каядыр югарыга карана-карана җанланып сөйләшеп торалар иде. Назифә дә шул якка күтәрелеп карады һәм рубка өстендәге оя эченнән чыр-чу ишетеп шаккатты:

— Егетләр, сыерчыклар бала чыгарган лабаса!..

Әмма һәрвакыт ачык йөзле, игътибарлы егетләр бүген аңа борылып та карамадылар, аны бөтенләй күрмәгән-ишетмәгән сыман, үзара сөйләшә бирделәр. Күз карашлары салкын, кемгәдер хәтерләре калгандай, караңгы чырайлы иде алар.

Назифә моны шундук сизеп, бик аптырап калды. Аннары кичә кич кызыл почмакта штурман Борһанов әйткән сүзләрне хәтерләде: безнең дуслыкны сизәләр, мөгаен, шуннан көнләшәләр дип, бүтән игътибар итмәскә булды. Шул фикер белән тынычланып камбузын ачты, титанга су агызып, чәй кайнатырга куйды, плитәсен кабызып җибәрде. Аны күрү белән җим өмет итеп төшкән сыерчыкларга, мәгез, бәгырькәйләрем, нәниләрегезне сыйлагыз, тизрәк үссеннәр, дип сөйләнәсөйләнә кошларга балык эчәгеләре бирде.

Баягынак теге егетләр белән очрашудан туган күңелсез уйлар әш арасында акрынлап юкка чыкты. Күз алдына затон бистәсендәге туганүскән өе, ифрат та кайгыртучан, тынгысыз әнкәсе килеп басты. Хатны алу белән ул чуар йөрәкнең шундук аһ-вах килеп тәшвишләнүе, әллә ниләр уйлавы бар. Димәк, хатны бик уйлап, ничек тә борчымаслык итеп язарга кирәк. Иң мөһиме — мәсьәләнең инде хәл ителгәнлеген, тәмам вәгъдәләшкәнне сизмәсен, хәзергә әле аның киңәшен, ризалыгын сорап кына килгән кебек булсын.

Назифә әнә шулай үзалдына уйлана-уйлана плитә янында маташканда ачык ишек уемына штурман Борһанов килеп басты. Аяк астында чүпләнгән сыерчыклар аны күрү белән сискәнеп читкә ташландылар һәм чыркылдашып ояларына очып менеп киттеләр.

Борһанов ишектән яртылаш башын тыгып бик ягымлы исәнләште, аны-моны сөйләнгәндәй итте. Аннары күз кырые белән әйләнә-тирәгә сагаюлы каранып алды да:

— Җанкисәгем, сүзеңдә тормадың бит, кичә ишегеңне бикләп яткансың,— дип җиңелчә үпкәсен белдерде.

Назифә уңайсызланып калды, эшеннән туктап, акланырга тотынды:

— Юк, бикләмәгән идем, автомат йозак үзеннән-үзе бикләнгән булса кирәк.

— Ярар, анысы зур бәла түгел. Монда бүтән серьезныйрак күңелсезлек бар.— Борһанов палубадагы егетләр ягына шелтәле карап алды да, тавышын акрынайта төшеп, дәвам итте: — Ни бит, төнлә без кызыл почмакта утырганны кайсыдыр күргән һәм бөтен теплоходка таратып өлгергән. Күреп торам, әнә теге булдыксызлар, базарчы хатыннар кебек, хәзер дә шуны чәйнәп утыралар.

— Күрсәләр ни булган, әллә җинаятьчеме без... Теле кычыткан кеше сөйли бирсен, бер дә борчылма.

— Борчылудан түгел, болай гына әйтүем... Шулай да син муеныңдагы бу якорьны салып куй әле. Юкса әдәпсезлек дип уйлаулары ихтимал. Син аны бүтән вакытта, өйләнешеп бергә тора башлагач тагырсың.

— Юкны сорама, гайбәтчеләрдән куркып, салачак түгелмен! Аларга үч итеп, юри тагачакмын! Күрсеннәр, йөрәкләре янсын юньсезләрнең!

— Назифә җаным, хәзер үк салып куюыңны сорыйм. Безнең дуслыкны кешегә бик сиздермәскә тырыш. Аңла мине, шулай кирәк. Ник кирәклеген мин сиңа соңынтын әйтермен. Кич белән минем вахта бетәрәк рубкага мен, шунда сөйләшербез.

Борһановны һәрвакыт ныклы, тәвәккәл итеп күрергә гадәтләнгән Назифәгә аның бу сагаючанлыгы ничектер сәер, артык тоелды. Күңеленнән аның белән килешергә теләмәсә дә, бүтән карышмады:

— Шулай кирәкме?.. Алайса, ярар, хәзер каютага керәм дә салып куям.

## VII

Көнозын кызу плитә, кастрюльләр янында тулганса да, Назифә әллә ни алҗымаган, һәрвакыттагыча җиңел хәрәкәтчән, күңеле күтәренке.

Камбузда кичке эшләреннән бушагач, душта коенды да, тиз генә киенеп, рубкага штурман Борһанов янына менеп китте.

Назифә әлегә хәтле рубкадагы кешеләрнең эшләрен ихтирам белән палубадан карап кына белә иде. Монда гомумән бар нәрсә бүтәнчәрәк күренә икән. Түбәндә машина гүелдәве дә, теплоход кузгаткан дулкыннар шаулавы да ишетелми, әйләнә-тирә тып-тын. Текә тимер баскычтан күтәрелгән саен тирә-юньдә офык киңәя бара. Кичке шәфәкъ балкышы белән өртелгән тын су өстендә бер генә җыерчык та юк. Әңгер-меңгердә йокымсыраган яр буйлары, тау-урләр, алсу томанлы тугайлар күңелдә ямансу уйлар уята.

Иң өстә алгы мачтаның аркылы борысына кунаклаган ике сыерчык оя эчендә йоклаган балаларының тынычлыгын саклап постта тора. Ишек-тәрәзәләре ачык рубка эчендә штурвал янында рулевой Хәйруллин баскан, аннан улдарак штурман Борһанов бинокльдән алга карап бара иде.

— И, син менгән икәнсең,— диде ул, гаҗәпләнгән булып.— Рәхим ит, әйдә кер, безнең эшне күр.

— Мин бераз һава алырга гына менүем. Сезнең монда рәхәт, җиләс икән.

Рубкада тынлык урнашты. Караңгы күктә утлы эз калдырып, йолдыз атылды. Берничә минут сүзсез генә барганнар соң, штурман Борһанов һич тә көтмәгәндә:

— Давыл купмагае... Трюмнар яхшы ябылган микән, бар карап мен әле,— дип рулевойны палубага төшереп җибәрде, штурвал янына үзе басты.

Төз гәүдәсенә сыланып торган ак кительдән, күн козыреклы фуражкадан бу минутта ул бик тә килбәтле һәм мөлаем күренә иде. Назифә гашыйк күзләре белән аңа ихтыярсыз сокланып карап торды һәм, һәрьяктан килгән бу егет әнигә дә ошар, дип канәгатьле уйлап куйды.

— Ят кеше кебек ишек катында торма, мондарак кил,— дип, Борһанов аны үз янына дәшеп алды һәм буш кулы белән иңеннән кочаклады.— Мә, штурвалга тотын, идарә итеп кара... Каушама, кыюрак бул, бернинди куркынычлыгы юк аның. Әнә-ә, теге тау астындагы ак утка таба тот. Аннары, шул турга җитәрәк, аз-азлап сулга таба борыла башларбыз.

Теплоход, чит кешегә буйсынырга теләмәгән сыман, башта әле уңга, әле сулга тайпылып карады. Әмма бераздан, кул күнегә төшкәч, артык чалуламыйча турырак бара башлады. Уңыштан күңеле күтәрелгән Назифә:

— Ничек уйлыйсың, әгәр өйрәнсәм, мин рулевой була алыр идемме? — диде.

— Син — зиһенле кыз бит, әлбәттә, булдырасың. Моның өчен күп кирәкми. Тырышсаң, суднолар йөртү кагыйдәсен бераз ятласаң, вәссәлам, шул җиткән. Мин сине үзем өйрәтермен. Теләсәң, елга техникумына укырга керерсең. Анда минем әшнә кешеләрем бар, тоткарлык-фәлән килеп чыкса, ярдәм итәрләр.

Бу теләк — киләчәктә судно йөртүче штурман булу хыялы — Назифәнең күңелен инде күптән җилкетә, теплоходта эшләве дә әнә шуннан бит. Аның якты ниятен хуплап, дәртләндергеч киңәш әйтүче, ярдәм итәргә әзер торучы штурман егет бу минутта тагын да якынрак, сөйкемлерәк булып тоелды. Ул тик бер нәрсәне — Борһановның бу якынлыкны кешедән яшерүен аңламый. Менә хәзер тагын шуны хәтерләп:

— Без беркемнең дә өлешенә кермибез бит,— диде.— Болай яшерүнең, качып-посып очрашуның нигә кирәге бар, кемнән куркасың?

— Дөрес әйтәсең, беркемнең өлешенә кермибез, мин беркемнән курыкмыйм.— Әйтер сүзен таба алмагандай, беравык сүзсез торганнан соң Борһанов тагын җанланып сөйләп китте: — Үзем өчен түгел, сине уңайсыз хәлгә куюдан, гайбәт таралудан шикләнәм мин. Кешедән ару түгел, бик күренеп йөрүне тыйнаксызлык дип уйлаулары бар... Мин үзем дә гел сине юксынып, синең белән буласым килеп йөрим... Вахта беткәч тә керермен. Кара аны, кичәге кебек, бүген дә ишегең бикле булмасын.

Хәзер инде шәфәкъ балкышы сүнгән иде. Төн карасы куера төшкәч, теплоход су өстеннән түгел, караңгы галәм диңгезендә йөзеп бара кебек.

Шулчак көтмәгәндә тынлыкны бозып стенадагы радиоалгычтан кырыс тавыш белән:

— Әй, теплоходтагылар!.. Сезнең белән судоходство инспекторы сөйләшә,— дип кычкырып әйткән сүзләр яңгырап үтте.— Сигналга ник җавап бирмисез? Чүт безгә килеп бәрелмәдегез... Хәбәр итегез, нинди теплоход бу?

Кара син, ә... Алар монда бер-берсе белән мавыгып китеп, үр яктан төшеп килүче баркас сигналын күрми калганнар икән. Икесе дә бер мәлгә аптырап калдылар. Назифә тиз генә читкә тайпылды. Ә Борһанов, якыннан гына үткән баркас утлары артта калгач, ян стенадагы микрофоннан җавап кайтарды:

— Иптәш инспектор, гафу итегез, сигнал лампочкасы кинәт янды, шуны алмаштырып маташа идек, тоткарлык шуннан килеп чыкты. Андый хәл бүтән кабатланмас.

— Онытлыңмыни, ул безнең теплоходның исемен дә сораган иде бит,— диде Назифә.

— Юк, лампочкаларга берни дә булмаган,— диде Борһанов, хәйләкәр елмаеп.— Мин аны болай гына, инспекторны тынычландырыр өчен генә әйттем. Ул үтеп китте инде, артта калды.

## VIII

Җаваплы рейс уңышлы тәмамланды, «Владивосток» командасы Камышлыда төягән югары сортлы ике мең тонна бодайны бөртеген дә чәчми-түкмичә, чылатмыйча Казанга графиктан элек кайтарып җиткерде. Бодайны элеваторга тапшырып бетергәч, кичен теплоход затонга профилактик ремонтка китәчәк: яздан бирле өйләрендә булмаган команда членнары семьялары, якыннары белән күрешәчәкләр.

Менә Назифәнең дә түземсезлек белән көтеп алган дулкынландыргыч көне килеп җитте. Иртәгә әнисенә күренгәннән соң алар загска барырлар, язылышырга гариза бирерләр.

Теплоход элеваторга килеп туктау белән эштән бушаган бар халык шәһәргә чыгып китте. Башта җыенмаган кебек булса да, штурман Борһанов та, бик мөһим эшем бар дип, көтмәгәндә китеп барды. Назифә исә бүген беркая чыга алмый, аның эше муеннан: көндәгечә аш-су пешереп, теплоходта калган кешеләрне ашатырга-эчертергә, киләсе рейска базадан азык-төлек алырга, Камышлыда Борһанов белән бергә сайлап алган ак ефәк күлмәкне үтүкләргә кирәк. Иң мөһиме — иртәгә әнисе янына кайтканда үз урынына камбузда калып торырга Әнфисә Борисовнаны күндерде. Үзсүзле тутәй Назифәнең бу ниятен хупламавы күренеп тора, бер дә теләмичә, бик ялварып сорагач кына калып торырга көч-хәл белән риза булды.

Казан элеваторы бүген дә һәрвакыттагыча яхшы эшли, пневматик бушаткычлар туктаусыз зырылдап тора, трюмнарда йөк кимегән саен теплоход корпусы судан чыгып, югары күтәрелә бара. Элеватор лаборанты, ак халат кигән зифа буйлы, күпереп торган бөдрә чәчле чибәр кыз, әле бер, әле икенче трюмнан бодай алып, җентекле тикшереп

тора; эшеннән бушап торган минутларда ул, кемнедер эзләгән сыман, әледән-әле каюталар ягына карана, берәр ишек ачылган, коридорда аяк тавышы ишетелгән саен ялт борылып карап ала. Эш арасында берничә мәртәбә күзенә чалынгач, Назифә ирексездән: бу һәүмиз йөзле кызый, нәкъ минем кебек, бөдрә чәчле икән, безнең егетләрдән кемнедер эзли бугай дип, хәтта җәлләп куйды үзен.

Бичара кызның төш выкытында башкалар белән бергә элеватор ашханәсенә китмәве дә ничектер сәер тоелды. Ул теплоходта калып ашыкмый гына террасада, коридорларда йөренә, әйләнә-тирәдә һаман кемнедер эзли иде. Бу хәлне камбуз тәрәзәсеннән күреп торган Назифә кызны отыры кызгана төште һәм, ахыр чиктә, ашханәгә дәшеп алды, балык шулпасы, кыздырган бәрәңге белән ит, чәй бирде.

Команда члennары ашап-эчеп инде таралышкан, Назифә үзе дә эштән бераз бушаган вакыт иде. Ул үзенә чәй салып, өстәл янына барып утырды. Сүз иярә сүз китеп, сөйләшә торгач, лаборант кыз дөрестән дә бер якын егетен эзли булып чыкты.

— Үткән җәйне ул «Баку» теплоходында эшли иде, алар бирегә ашлык төяп еш киләләр иде,— диде ул, бераз ачылып китеп.— Мин аның белән шунда таныштым. Эштән буш вакытларда аның каютасында радиодан концертлар тыңлый идек. Ул бик шигъри җанлы, миңа багышлап шигырьләр яза иде. Аның һәр килүен мин түземсезлек белән сагынып көтеп ала торган идем. Аннары гомерлек тормыш юлдашлары булырга вәгъдәләштек, инде матур гына семья кордык шикелле иде... Ә былтыр көз навигация ябылгач, затонга киткәндә ул тиздән мине дә үз янына чакыртырга вәгъдә иткән иде. Әмма чакыртмады, хатларыма да җавап бирмәде, суга баткан кебек юк булды.— Соңгы сүзләрен лаборант кыз кыенлык белән, ишетелер-ишетелмәс пышылдап әйтте, күз яшьләренә буылып, авыр сулап куйды.— Бер таныш елгачы ул егет быел шушы теплоходта эшли дип әйткән иде. Ялгыш әйткән булса кирәк, сездә күренми шикелле.

Лаборант кызның зарлы дулкынлануы Назифәгә дә күчте, аны кызганудан йөрәге кысылды. Аңа ярдәм итәргә теләп, теге егетнең кем булып эшләгәнен, исемен, фамилиясен сорамакчы булды. Шунда кызның ачык муенындагы җиз чылбырлы якорьны күреп алып, телдән язды: «Бу якорең нәкъ минеке төсле икән, сиңа аны кем бирде?» — дип сораудан чак тыелып калды.

Кичкырын, теплоходның йөге бушатылып бетәрәк, иртән шәһәргә чыгып киткән егетләр кайтып керде. Барысы да бик арыган, ачыккан, әмма күңелләре күтәренке иде. Назифә инде суына төшкән көндезге ашын тиз генә җылытып, аларның ашарларына бирде, кофе кайнатты.

Шул арада ашханәгә тагын теге лаборант кыз килеп керде һәм, сумкасыннан бланклар алып, бодайның элеваторга нормаль кондициядә, һичнинди претензиясез кабул ителүе турында белешмә язарга утырды. Кызуда тамагың кипкәндер дип, Назифә аның алдына бер кружка кофе куйды, егетләрнең сораулы карашына җавап биргәндәй, аның кем икәнен дә әйтте.

Табын янындагы практикантларның берсе шәһәрдә күргәннәрен ашыкмый гына сөйләп утырган җиреннән, кемдер кытыклагандай, кинәт кычкырып көлеп җибәрде:

— И, без анда кемне очратканны белсәгез икән... Берәр кружка салкын сыра эчмәкче булып барга керсәк, ни күрик: аулак кына почмакта безнең штурман бер чытлык хур кызы белән пырх-пырх көлешеп утыра. Шаккаттым, менә бу кияү егет, мин әйтәм.

— Хак сүз, мин дә шунда идем. Безне күрүгә тиз генә читкәрәк күчеп утырды,— дип, рулевой Хәйруллин да практикант сүзләрен раслады.— Карале, Назифәкәй, ул тасма тел белән сак бул син, төпсез көймәгә утырып кала күрмә.

Назифәгә уңайсыз булып китте, дөресен әйтмиләр, һаман шул өнәмәүдән күпертеп сөйлиләр кебек тоелды. Өстәлнең бер почмагында язып утырган лаборант кыз да, нидер сизенгән сыман, эшеннән туктап, сагаеп калды.

Тышта, ачык тәрәзә каршында палубада баядан бирле сыерчыклар чыр-чу килә иде. Менә аларны кемдер куркыттымы, кинәт өркүле пырылдап читкә ташланганнары ишетелде. Шундук ашханәгә штурман Борһанов килеп керде һәм бусагадан атлап үтүгә баскан җирендә тораташ кебек катып калды. Аның кызмача икәнлеге күзгә бәрелеп тора: битләре кызарган, кыңгыр фуражкасы астыннан җирән чәче тырпаеп тора, кителенең өске төймәсе ычкындырылган иде.

Менә ул лаборант кызны күрде дә сискәнеп куйды һәм, ярамаган җиргә эләккән кеше кебек, тиз генә кире чыгып китәргә омтылды, каушап як-ягына күз атып алды, әмма кузгала алмады, кадакланган кебек үзенә төбәлгән салкын карашлар астында сүзсез тора бирде.

Лаборант кызның исә сагышлы йөзе яктырып китте. Җиңел хәрәкәт белән Борһановка каршы кузгалып:

— Күңелем сизеп көткәнмен икән, менә үзе кайтып төште ич... Исәнме, Зөбәер,— диде ул, киеренке тынлыкны бозып.

Борһанов шундук айнып китте, ни әйтергә белмәгәндәй, чак кына сүзсез торганнан соң, лаборант кызга зәһәрле төбәлеп:

— Г-гафу итегез... Миннән ни кирәк сезгә? — диде.

— Зөбәер, ни сөйлисең, син, әллә танымыйсыңмы?.. Ник алай күрмәгән-белмәгән кебек карыйсың?

— Юк, туташ, хәтерләмим. Бөтен күргән-очраган кеше истә торамыни... Сез мине бүтән берәү белән бутыйсыз бугай,— дип ишекне каты ябып чыгып китте.

Ашханәдә авыр тынлык урнашты. Көтмәгәндә уңайсыз хәлдә калган лаборант кыз, нишләргә белмәгәндәй, бер мәл аптырап торды да, китеп барды. Егетләр үзара карашып алдылар, бер-бер артлы таралыша башладылар. Назифә исә бу хәлне аңына сыйдыра алмыйча югалып калды. Штурман Борһановның җан өшеткеч сүзләре, лаборант кыздан бигрәк, аның үзенә әйтелгән кебек тоелды, йөрәгенә тырнап үтте, караңгыда искәрмәстән пычракка баскан сыман, тәне чирканып куйды. Өстәл янында ялгызы утырып калган рулевой Хәйруллин аны дусларча юатып:

— Алай көенмә, Назифә, нык бул, үзеңне горур тот,— диде.

## Әхмәт Гадел

### Моң

Күңелемдә бер моң яши:
Идел суларыдай йомшак, назлы,
Урман җиллередәй тымызык ул.
Күңелемдәге бу моң хәтерләтә
иртә язны:

Бар усаллык юылып төшә, агып китә
Дулкынланса күңелемдә бу моң.

Олимпларны узып җиде кат күккә җитәм.
Бөтен рухны бу моң игелеккә җигә.

●

Казанымда юкә чәчәк ата,
Таңнар, куе балдай, җәйрәп ята.
Һәм бал исе — җилдә...
Замананың бетон, пыяла, корыч
балалары — йортлар туа Илдә.

Казанымда таң мәлендә чәчәк сибелә,
Идел Ослан тавы төбенә йөгерә...

Язмыш безгә аталарча карый:
бүләк итү өчен изге мәлне,
дөнья буйлап эзли, гүя, таба, барлый...

### Әти

Күзләреңнең
сихерләүчән карашларын
оныта алмам инде, әтием.
Нинди каты иде кулларың,—
татыдым.
Сүзләреңнең үткерлеген тойдым,
сиздем, аңладым...
Күзләреңнән сагыш
нур булып ага башласа,
чыгып китә идең урманнарыңа...
Ялгызлыкны сөю заманы
килеп җитте миңа да...

Син җырлаган җырлар
сеңеп калды күңелемә...

Сагыну җырлары яшәтә мине, әтием!..

## Син һәм мин

Иреннәрең азатлыкка очырган җырмын,
төннәрдә күзләрең саклаган нурмын...
Кулларыңда язгы тургай — ул мин.

Бар дөньяга кычкырып сөйләп йөрим:
ярым өчен,
җаным өчен
сынмас, бетмәс кодрәт-көчем!

Тәкъдир — икәү зур уй уйлау!
Тәкъдир — икәү Зур Җир буйлау,
язмыш-кайгыларны җиңү,
күккә ашу, хискә иңү...

Бәхет яшәр — икебездә,
шатлык туар — икебездән.
Яшәешнең гамен, тәмен
күтәрербез — икебез дә!..

## Чакырыгыз!

Кем бирелде алдау шатлыгына,
Кем онытты изге антларны,
Кем атылды ялган кочагына,
Игелектән качып, ташланды?
Үткәннәрнең кайтсын шәүләләре,
Гөлчәчәкле язгы җәйләүләрне,
Ямьләндерсен, матур тауларны...
Чакырыгыз алсу таңнарны,
Чакырыгыз яшел үләннәрне,
Чакырыгыз яшел яфракларны,
Чакырыгыз яңгыр җепләрен,
Чакырыгыз кояш нурларын,
Чакырыгыз шатлык һәм гамьнәрне,
Чакырыгыз җылы сүзләрне,
Чакырыгыз нурлы күзләрне,
Чакырыгыз якты йөзләрне,
Уятыгыз кулларның назын,
Гомерләрнең ялкынлы язын!
Йөрәкләрне уятыгыз,
Саф күз яшьләрен...
Алар әйтер:
— Син яшәдең, сөйдең, яшьнәдең!

..................

Марсель Зарипов

# КАМАЗ НЫКЛЫГЫ

Безнең көннәрдәге башкарылган эшләрнең күз иярмәслек темплары турында уйланганда, ихтыярсыздан, Һади Такташның мәшһүр юллары искә төшә:

…Хыял безнең өчен чит бер нәрсә,
һәрбер теләк — якын киләчәк!—

дип яза ул.

КамАЗ кебек киң колачлы корылманың салыну тарихын гына күз алдына китерик. Бер китапта: «Заводны сафка бастыру өчен барган көрәш 4081 көн эчендә тәгәлләнде»,— диелгән. Төп-төгәл сан. Аңлашыла: 1969 елның 13 декабрендә экскаваторчы Михаил Носков кар-бураннар уйнап торган киң басу түреннән беренче батман туфракны умырып алып, монда автогигант булачак, дип, дөньяга хәбәр салган иде. КПССның XXVI съезды алдыннан исә төзүчеләр комплексның икенче чиратын сафка керттеләр. Ул инде моңа кадәр үк тә биш ел буе автомобильләр чыгарган иде. Шулай да, сүзне үткән заманда алып барып: «Тәгәлләнде!»— дип кистереп әйтү урынсыз кебек тоела. Дөрес, автомобиль гиганты чыннан да салынып бетте, машина төзүчеләрнең ап-ак, өр-яңа каласы да ярты миллионлаган эшчене үзенә сыендырды. Уннарча мәктәпләр, балалар бакчалары, культура сарайлары, кинотеатрлар, кибетләр ачылды. Шәһәр янындагы аграр зона аны йомырка, сөт-май, яшелчә белән тәэмин итә. Политехник институт эшли башлады. Алабуга пединститутының берничә факультеты да — бу шәһәрдә. Брежневтагы иң җитез егетләрдән оештырылган футбол командасы, әлегә әллә ни зур уңышларга ирешмәсә дә, Союз беренчелеге өчен барган ярышларда республика командасы белән бер үк группада чыгыш ясый. Әмма шәһәрнең төп максаты булган автомобиль өчен көрәш... дәвам итә. Хәзерге көрәш заводны сафка бастыру өчен барганыннан кискенрәктер дә әле. Ул инде цехларда гына түгел, моннан ясалып чыккан машиналарны эшкә җиккән 160 автоүзәктә дә җәелеп китте. КамАЗ авыр йөк ташыгычларын йөртүче меңләгән шофер да бу көрәшкә кушылды. Алар, кем кулындагы машина озаккарак чыдар, озынрак юл үтәр, дип ярыш җәелдерделәр. Кем җиңәр? Миллион километрны капиталь ремонтсыз гына узучы булырмы?

Миллион — бик зур сан. Тик бу очракта ул көн тәртибенә түшәмнән генә алып куелмады. Кама автозаводыннан чыккан машиналарның алдан каралган мөмкинлеге дә — 350 мең километр. Соңгы елларда бу чикне ике тапкыр узучы шоферлар артканнанарта бара. Безнең КамАЗ 160 автоүзәк белән бергә, үзенә охшаш заводлардан аермалы буларак, машиналарның ничек эшләвен дә күзәтеп тору җаваплылыгын алып бара. Аның автоүзәкләре запас частьлар өләшү, автохуҗалыкларда машиналарны төзәтү белән генә шөгыльләнмиләр, алар шоферлар һәм ремонтлаучы белгечләр әзерләүдә дә зур эш алып баралар, йөк ташуның отышлырак ысулларын өйрәнәләр. КамАЗ дирекциясенең Брежнев шәһәрендәге файдалану бүлегендә конвейердан төшкән һәр машина турында мәгълүмат туплана: кайчан юлга чыккан, ничә чакрым үткән, ни өчен тукталган? Иң озын юл узган шоферлар — аерым исәптә, алар белән иң яхшы мөнәсәбәтләр булдырыла. Бу мәгамәләне ашлыкларның яңа сортын ачкан селекционер һәм агроном арасындагы элемтә белән чагыштырырга мөмкин. Бер генә машина да һәр яктан камил булып бетә алмый, шунлыктан аны йөртүче кешенең фикере автомобильне тагын да яхшырта төшәргә теләүче конструкторлар өчен бик кадерле.

Свердловскиның «Облколхозстрой» оешмасы шоферы Ю. Берсенев: «Мин «КамАЗ»ны биш елдан артыграк йөртәм инде,— дип яза.— Спидометрда 400 мең километр җыелды. Әлегә кадәр җитди ремонт ясаганым юк. Мин бит әле аңа икенче эрҗә дә тагып йөрим. Тимер-бетон әйберләр, кирпеч ташыйм. Юлыма да асфальт җәелмәгән, гел авыл араларында, чокыр-чакырлардан утәм...»

«Алтайстройтранс» тресты управляющие Н. Иванов яза: «Бездәге «КамАЗ» маркалы унсигез машина капиталь ремонтсыз ярты миллион километрдан артык юл узды. Әле дә иң катлаулы рейсларга шулар чыгып китә...»

500 мең километр — конструкторларның КамАЗ машиналарына биргән гарантиядән бер ярым тапкырга артыграк ара. Әмма әле моны да соңгы чик дип санарга теләмиләр. Инде 10 мең шофер 300 000 км ны уздылар. Мондый осталар көн саен артып тора. Алар үз хезмәтләре белән безнең ил автомобиль транспортындагы төп эшче машинаның иң күркәм сыйфатларын раслыйлар. 300 000 километрны капиталь ремонтсыз үтү гади күренешкә әйләнә.

Казанның 2 нче автотранспорты берләшмәсе шоферлары КамАЗ машиналарын беренчеләрдән булып кабул итеп алдылар. Автомобильләр аларга бик ошады. Техник яктан камиллеген генә түгел, конструкциясенең ышанычлылыгы, күркәмлеге, кабинасының җайлылыгы, эшләү шартларының әйбәтлеге шоферлардагы кызыксынуны арттырып җибәрде. Алар юлга яңа «мал»ны һәрьяклап сынау өчен ашкынып чыгып киттеләр. Шул ук вакытта алар машина өчен җаваплылык та тоялар. Аны тагын да яхшырту әмәлләрен эзлиләр. Ниһаять, без юлларда маңгаена: «Капиталь ремонтсыз — 1 000 000 км!» дигән кыю сүзләр язылган автомобильләр күрә башладык. Бу — констукторлар биргән гарантиядән өч тапкыр артыграк файдалану дигән сүз. Шул ук вакытта мондый тәкъдим белән чыгу ифрат дәрәҗәдә җаваплы да. Шофер халкы сүз белән шаярмый. Буш сүзне бөтенләй яратмый ул. Инде шактый олы сүзне ычкындырырга да батырчылык иткәннәр икән, димәк, аларның моңа ышанычлары бар. Әлеге өндәмә, беренче булып, Михаил Пронин, Әдһәм Сираҗетдинов, Виктор Бухмин, Николай Попков, Әсгат Кашапов кебек үз һөнәрләренең кадерен белүче иң оста шоферлар теленә килеп керде. Аларга Кама буенда ясалган машиналарның бөтен мөмкинлеген сынап карау искиткеч мөһим һәм кызыклы тоелды.

Алты нольле сан башта бер тамаша кебек кенә карала иде. Ярый инде, күңелләрне ашкындырып тору өчен бер зурлык кирәк бит, диештеләр. Әле конструкторлар әйткән контроль санга җиткәнче исән-имин йөри алсаң да, әйбәт булыр иде, янәсе. Еллар үтә торды. Хәзер завод машиналарны ике чираттан чыгара.

Спидометрларга беренче 100 000 километр җыелган көннәр шактый артта калды инде. «300 000» километр да теркәлде. Ә машиналар гарантия чигенә җиттем дип тормыйлар, һаман чабалар да чабалар. Шул рәвешле 1000 000 километрны узу да чынбарлыкка охшый башлады. Унберенче бишьеллык уртасында Әдһәм Сираҗетдинов машинасы — 507 мең, Николай Попковныкы — 650 мең, Александр Елькинныкы — 559 мең, әлеге ярышның башында баручы Михаил Пронинныкы 635 мең километр юл узды. Гарантияне тутырып, юлны дәвам иттерүчеләр саны исә унбиш меңнән артып китте. Мәскәү янындагы бер хуҗалык шоферы Анатолий Гудков, барысыннан да арттырып, 725 мең километр юл үтте. Миллионга тутырырга аз гына калды кебек, тагын бик тырышсаң, тулачак!

Капиталь ремонтсыз шулай күп эшләү кай яклары белән отышлы соң? Беренчедән, экономикага җиңеллек килә. Чөнки капиталь ремонт вакытында автомобильгә беренчел бәясенең сиксән биш проценты күләмендә чыгым сорала. Машина яңабаштан сүтеп җыела. Тулы агрегатлар алмаштырыла. Бүгенге көнгә 2 нче автотранспорты берләшмәсендә кырык шофер машинаны 1000 000 км йөртергә алынган икән һәм инде беренче капиталь ремонт чиген узып эшлиләр икән, аларның бу фидакарьлеге хуҗалыкка 600 000 сум экономия бирде дигән сүз! Афәрин! Бу инде шоферның үз һөнәрен яратуы гына да түгел. Бу — аның илгә никадәр дәрәҗәдә тугры хезмәт итүен раслый торган күренеш, бу — аның патриотизмы!

Мондый зур эшкә тотынганда, әлбәттә, шофер ялгызы гына әллә ни майтара алмас иде. Яңа машинага һәртөрле игътибар кирәк. Ул инженерлык хезмәтләренең дә иң җентеклесен сорый, планлаштыруның, идарә итү системасының иң камил ысулларын таләп итә.

— Безнең машиналар, шөкер, озын-озын юллар урыйлар,— дип аңлата берләшмәнең генераль директоры Әскәр Камалиев.— Тик бу сәфәргә алдан гаражда, мастерскойларда, диспетчерлык пунктларында ук нигез салына. Бүгенге автотранспорттан мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк файдалану теләгең бар икән, идарә итүне, эксплуатация хезмәтләрен, профилактиканы, чираттагы төзәтүләрне бик төгәл оештырырга кирәк.

Шоферның төп максаты тизрәк юлга чыгу һәм күбрәк йөк ташу булырга тиеш. Тонна-километрны арттыру белән генә мавыкмасын ул, кирәкле йөкне көтелгән урынына илтеп җиткерсен!

2 берләшмәдә меңнән артык төрледән-төрле машина бар. Өч йөзләбе — КамАЗ-ныкылар. Эш белән бик төгәл компьютерлар идарә итә. Шоферлар да, ремонтлаучылар да, иртән килү белән үк, ишек төбендә үз шифрларын әйтәләр. Компьютер шул мизгелдән аның һәр адымын исәпли башлый. Приборлар машинаның юлга кузгалуын да, йөк төяү урынына килеп җиткәч, күпме торуын да, бушату вакытын да «күзәтеп» утыралар. Автомобиль экранда күренми башласа, идарә итүнең автоматлаштырылган системасы бу хәбәрне диспетчерга ирештерә: «Машина юлдан чыкты, кичекмәстән булышырга!» Аның янына техник ярдәм машинасы ашыга. Дөрес, кибернетика хәзергә башка шәһәрләргә яки ерак авылларга киткән машиналарны күзәтә алмый, шулай да берләшмәнең йөзләрчә машинасы, эш көне тәмамланганчы, даими күзәтү астында йөри.

Идарә итүнең автоматлаштырылган системасы ремонтчыларга да булыша. Детальләрне комплектлап куя ул, агрегатларны барлый, профилактик төзәтүләрне тизләтергә ярдәм итә. Рейстан кайткан шофер өендә рәхәтләнеп ял иткәндә, машиналар тикшерү үтә. Анысын-монысын төзәтергә кирәк булса, аларны ремонтлаучы слесарьларга тапшыралар. Төнлә аларга профилактика ясала. Төнге эштәгеләр бер сәгать ялга гына тукталып алалар. Ул чакта аларга бушлай аш өлгертелә.

Идарә итүнең автоматлаштырылган ысулына таянганчы шәһәрдәге маршрутларда 340 йөк машинасы йөри һәм алар елына 340 мең тонна йөк ташыйлар иде. Хәзер бу юлларда нибары 120 машина йөри һәм шулар элеккегә караганда ике ярым тапкыр артыграк эш башкаралар. Шоферларның хезмәт җитештерүчәнлеге ике тапкырдан да күбрәккә арткан, ә ремонтчыларныкы — 75 процентка. Фәнгә таянып эшләүнең иң матур күрсәткечләре! Һәр километр араны узуга бүлеп салынган ремонт эшләре 27 процентка кимегән. Машиналар, гомумән алганда, 250 миллион километр юл үтәләр икән, әлеге отыш гомум экономиягә шактый саллы мая булып килеп кушыла. Бу җиңүне КамАЗның тагын бер чираты сафка кертелгән иттереп тә санарга мөмкин!

Шуңа күрә Казан шоферларының бу мактаулы башлангычын бөтен ил хуплап каршылады. Конвейердан төшүче беренче машиналарга гарантия итеп 115 мең километрлык юл күрсәтелгән иде. Завод, машиналарының ныклыгын арттыра барып, бераздан бу санны 300 000 гә күтәрде, ә съезд алды ярышы җәелдерелгәч, 350 000 км күрсәтелә башлады. Монысы да соңгы чик түгел, әлбәттә. Бу сан да үзгәрер. Нинди алмаштырыр — билгесез: миллионмы?

Күрәзәчелек белән баш ватмыйк. Һәрбер машинаның миллион километр үк уза алмавы да ихтимал. Бу нәтиҗәгә ирешү — бик сәләтле, үз һөнәренең иң тирәндә яткан серләрен чишә белүче оста шоферлар теләге. Миллион — рекорд өчен билгеләнгән чик, ә 350 мең километр — һәркем үтә алырлык юл. Монысын заманның иң өлгер исәпләү машиналары белән коралланган экономистлар санап чыгарган.

Кама буендагы яшь-яшь завод чагыштырмача тиз арада илнең автомобиль төзүчеләре арасында флагман ролен яулап, Ватанның иң зур бүләге — Ленин орденына лаек булды. КПССның XXVII съезды алдыннан КамАЗ конвейерларыннан чираттагы машина төшәчәк. Килер бер көн, безнең автопаркларда 1 миллион 500 мең «КамАЗ» эшли башлар. Шулардан һәр ун шоферның берсе генә гарантиядән капиталь ремонтсыз ике тапкыр файдалана икән (Казан шоферлары мондый үрнәкне күрсәттеләр инде), автомобильчеләрнең бу адымы гына да ике миллиард ике йөз илле миллион сум акчаны янга калдырачак!

Бер табыш икенче ачышка юл яра. КамАЗ машиналарының эшчәнлеген игътибар белән өйрәнүчеләр автомобильләрне агымдагы төзәтүләрдән, парктагы эшне отышлырак оештырудан шактый күп экономияләп булуны раслыйлар. СССР Фәннәр Академиясенең Себер бүлегендәге промышленность производствосын оештыру һәм экономика институты директоры Адел Аганбегян КамАЗ машиналарының, Төньяк трассалардагы йөрешен күзәтүче галимнәрнең фикерләрен берләштереп, «Известия» газетасында чыгыш ясады. Ул мондый нәтиҗәгә килә: «КамАЗ»ның заводтан чыккандагы бәясе аңа бөтен эшчәнлеге чорында тотыла торган чыгымнарның нибары өч процентын тәшкил итә. Калган 97 процентка машинага ясала торган профилактик, агымдагы һәм капиталь ремонт бәяләре керә. Хикмәт акчада гына да түгел. Төзәтүләр вакытында кул көче күп сорала, ул хезмәтне завод конвейерындагы уңайлыклар белән чагыштырып та булмый. Юлда, алтын бәясе вакытны исраф итеп, салкын җиргә чалкан ятып, төзәтеп азапланганга караганда, артык чыгымнар тотып булса да, заводның иркен цехында машинаның ныклыгын арттыра төшү күп мәртәбә отышлырак. Бу фикер төгәл исәп-хисапка нигезләнгән. Галим,машина, хәзергесеннән дүрт тапкырга кыйммәткәрәк бәягә төшерелеп ясалса да, әгәр агымдагы төзәтүләргә ике мәртәбә азрак туктался, капиталь ремонтсыз эшләсә, үз хакын бик тиз

аклаячак, диган нәтиҗә чыгара. Максат ачык. Димәк, ремонтларсыз гына эшли торган машина кирәк. Өметсезләр — андый нәрсә буламыни? диярләр. Ә нигә булмасын?! КамАЗ автогиганты үзе дә әле кайчан гына безнең хыялга да килмәгән завод түгелмени?! Елларыбыз, омтылыш-теләкләребез әнә шундый: безнең һәрбер теләк, шагыйрь сүзе белән әйтсәк — якын киләчәк!

* * *

Укучы кызыксынып куярга тиеш: заводның үзендә дә шундый теләк белән канатланып йөрүчеләр бар микән соң? Бу сорауга шатланып җавап кайтарырга мөмкин: бар андыйлар, бар. Инде шул теләкләрне тормышка ашыру юлында кайбер чаралар да күрелә. Дөресрәге, бу төр яңалыклар заводлар, ак кала салынганда ук ярала башлаган иде инде. Шәһәр төзүчеләр елына 400 000 квадрат метр торак мәйдан бирә иде. Бу да шәһәрләр төзү тарихы өчен шаккаткыч яңалык булды. Баш конвейерны сафка бастыру, беренче машиналарны өлгертү өчен көрәш башланды: «Тизрәк! Тизрәк!» Бу тизлек дәүләтнең завод салу өчен тотылган чыгымнарын каплау өчен кирәк иде.

Галим конструкторлар дәртләнеп иҗат иттеләр. Машинаның йөрәге булган двигательне Ярославль осталары бирде. Мәскәүнең Лихачев исемендәге автозаводы белгечләре машинаның конструкциясе өчен җаваплы иделәр. Хәер, бу машинаны бар итүдә көч куйган барлык коллективларга тукталу мөмкин түгел, ул — йөзләрчә предприятиеләрнең, меңнәрчә фидакарь җаннарның бердәм тырышлыгы нәтиҗәсе. Бу җиңүдә социалистик экономика үзенең барлык өстенлекләрен, иң күркәм сыйфатларын күрсәтте.

Әмма, басым ясап әйтергә кирәк: КамАЗ өчен көрәшнең тукталганы юк әле. Өлгер журналистның ашыгыч язмасында китерелгән «4081 көн»енә инде яңа меңнәр өстәлде, көрәш исә дәвам итә. Хезмәт дәвам итә. Һәр көн йөзләрчә, меңнәрчә һөнәр ияләре «КамАЗ»ны камилләштерү юнәлешендә көч түгәләр. Баш конвейерның соңгы ноктасына килеп җиткән машинаның ишеген ачып, берәү кабызу ачкычын бора. Моңа кадәр салкын металлдан ясалган детальләр җыелмасы буларак кына гәүдәләнгән машинага җан иңгәндәй тоела — мотор гүли башлый. Ә шул ук вакытта баш конструктор бүлегендә тып-тын, тик шактый киеренке шартларда киләчәктә конвейерга басарга тиешле камилрәк өлгеләр туа.

Без бу машинаны барыннан да бигрәк көчле йөк ташыгыч итеп күзаллыйбыз. Нәни «КамАЗ»ның булу мөмкинлеге турында уйлаганыбыз да юк. Шулай да андый җиңел машина бар инде. Нәни «КамАЗ»га утырып йөргән сынаучы шоферлар да бар. Ул дүрт урынлы, моторы 30 ат көчле, тизлеге — 100 км/сәгать, ягулыкны «Жигули»га караганда ике тапкыр кимрәк бетерә. Кирәк дип табыла икән, коллектив җиңел машиналар чыгарырга әзер.

«КамАЗ»ның баш конструкторы Рамил Әбдриевич Азаматов:

— Безнең һөнәр шундый инде,— дип сөйли. — Һәрчак юл ярып барырга туры килә. Башта моделен уйларга, машинаның яңа тирән иҗат итәргә кирәк. Аннары аны камилләштерә башлыйсың. Инде булды дип тукталгач та, күңел эзләнүдән тукталмый. Технологларга яңа мәшәкать арттырасың. Алга бару шунсыз мөмкин түгел...

Азаматов бу коллективтагы ветераннардан санала. Аны заводка үнәченчә кеше итеп алганнар. Гореф буенча, юньле сан түгел, тик баш конструктор язмышыннан зарланмый. Завод чыгара торган һәр сигез төрле машина аның җитәкчелегендә иҗат ителгән. Алтысы Дәүләт Сыйфат билгесенә лаек. Машиналарны камилләштерү дәвам итә. Аларның беренчел вариантын хәзергеләре белән чагыштырсаң, һичнинди планнарда каралмаган өч мең (!) үзгәреш табарга була. Болары — эшчеләрнең фидакарьлегенә таянып кертелгән яңалыклар. Мәгълүм булганча, кечкенә бер шөрепне генә үзгәртсәң дә, конвейерга мәшәкать өстәлә. Көн узсынга гына йөрүче, эш сөймәүче кешеләргә тап булсаң, мөгаен, әллә ни кыра алмас идең. Бәхеткә, КамАЗ коллективына завод абруе хакына җаннарын да аямаучы энтузиастлар тупланган. Шул бердәмлек беренче модельләрдә каралган 8 тонна авырлыкка чыдардай машиналарның куәтен 10 тоннага җиткерергә мөмкинлек бирде. Мотор шул ук, тик машина ике тоннага артыграк тарта ала. Унберенче бишьеллык азагына автомобильчеләр «КамАЗ»ның двигатель системасына камиллек кертеп, ягулыкның 3—5 процентын янга калдырырлык иттеләр. Бу машина елга 16 тонна ягулык сорый иде, хәзер бер тонна чамасы кимрәк кирәк булачак. XXVII съезд ачылыр алдыннан шундый машиналар инде конвейердан ук төшәчәк. Ил күләмендә исәпләсәң, янга калган ягулык миллион тонналарга җитә.

Автомобильчеләребез бер үк төрдәге машинаны да үзгәртеп ясыйлар. Әйтик, начар юллы авыллар өчен бик кирәкле өч күчәрле «КамАЗ»ларга, асфальт юлларда йөргәндә, ике күчәр дә җитә. Көпчәкләр дә янга кала, машинаның зуррак йөкне алырлык

мөмкинлеге дә арта. Шул рәвешле иҗат ителгән ике көчәрле машина 1986 елның февралендә үк ясала башлаячак.

Һәр шоферның фикеренә игътибар итүләрен сизеп алгач, Брежнев автомобильчеләренә урманчылардан да, сөт, он, ашламалар, мал-туар ташучылардан да үтенечләр килә икән. Төньяктагы шоферларның теләген искә алып яңа машина ясау — аеруча мавыктыргыч максат. Әлегәчә бу якларга да гадәти техника җибәрелә килде. Тик бу һич тә гадел түгел. Мәсәлән, «КамАЗ» 40-45 градус салкынлыкка чыдый. Шуннан да салкын шартларда ул үз «вазифаларын» үтәүдән баш тартырга да мөмкин. Төньякта исә суыклар 60 градуска җитә. Шофер нишләргә тиеш? Ниһаять, төньяктагы шоферларны да шатландырырга мөмкин: «КамАЗ»ның бу яклар өчен ясала торган төрләрендә двигательләр 210 түгел, ә 230 ат көчле булачак. Өстәвенә аңа махсус җылыту җайланмасы эшләнә. Моторны кабызу алдыннан җылытырга мөмкин. Көпчәкләрдә дә, тормоз системасында да чамадан тыш суыкка каршы торырдай әмәлләр бар. Дөрес, мондый машина кыйммәткәрәк төшә, әмма нәтиҗә барыбер отышлырак булачак.

Иван Паулкин, Геннадий Матросов, Александр Скопин, Владимир Бурыкин кебек кыю сынаучыларыбыз илнең иң салкын якларына, Якутиягә, Магаданга илтә торган Колыма трассасына юл алгач, җирле шоферлар «КамАЗ»га күктән иңгән маҗара күргәндәй караганнар. Термометрлар минус 60 тан да түбәнрәк күрсәткән. Себер шоферлары, иртән кабызып булмас, дип, машиналарын сүндермичә, төне буе двигательне эшләтеп чыгалар икән, ә безнекеләр сүндергәннәр, рәхәтләнеп йоклаганнар. Иртән, һич тә кабаланмыйча, башта — махсус җылыткычны, аннары моторны кабызып, юлга чыкканнар.

Кыскасы, машинаны яхшыртуның чиге юк. Әйтик, салкынга чыдамлы автомобильгә металлның да, резинаның да махсус төрләре кирәк. Өч машинага торырлык була икән, чыгымнардан курыкмаска да мөмкин. Машина санын арттырганчы, булганының ныклыгын арттыра төшү күпкә отышлырак лабаса. Казан шоферларының башлангычы — шуңа дәлил. 2 млрд 250 млн сум экономия — уен эш түгел.

Нәкъ шуңа күрә дә заводның ике чиратын да эшләтә башлау гына безгә, бары да булды дип, кул кушырып утырырга юл куймый. Өченче чират машиналардан дөрес файдалануны күздә тота. Бу юлда двигательләрне төзәтү, запас частьлар ясау заводлары һәм 160 автоүзәк аеруча тырышырга тиеш. Двигательләрне төзәтү заводы инде эшли, ә запас частьлар ясалмый әле, автоүзәкләр дә вакытлыча салынган биналарда гына урнашкан. Бу эшне ашыктырасы иде!

КамАЗ салынып бетте дип кенә яңа чорга лаек машиналар ясау эше тукталып калмас, тукталырга тиеш тә түгел, чөнки бу — тормыш закончалыгыннан килә торган өзлексез көрәшнең бер тармагы.

Тукайның 100 еллыгына

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



Җаек (Уральск) шәһәрендә Киров исемендәге парк. Чаган елгасы буендагы бу бакчага (элек Казенный парк дип аталган) Тукай бик яратып йөргән.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

Флера Сафиуллина

# ШАГЫЙРЬНЕҢ БЕР ТӘРҖЕМӘСЕ

Тукайның социал-демократлар белән тыгыз бәйләнеше турында яңадан-яңа мәгълүматлар табыла тора. Бу бәйләнешләрнең даими һәм ныклы булуы турында сөйләүче дәлилләрдән тагын берсе итеп шуны күрсәтергә мөмкин: эшчеләр арасында сиксәненче еллар азагыннан бирле яшерен рәвештә укылып йөргән «Ачлык-патша» брошюрасы Г. Тукай кулына юкка гына килеп кермәгән булырга тиеш. Тукай бу елларда «Ачлык-патша» белән танышып кына калмый, аны тәрҗемә итеп, 1906—1907 елларда бастырып та чыгара.

«Ачлык-патша»ны кем язган соң? Аның азатлык хәрәкәтендәге роле нидән гыйбарәт? Г. Тукай бу әсәрне татарчага тәрҗемә иткәндә, нинди принципларга карап эш итә?

«Ачлык-патша»ны язучы кеше «Народная воля» әгъзаларыннан берсе революционер А. Н. Бах була. Аның тормышы Казан белән дә бәйләнгән.

Алексей Николаевич Бах 1857 елда Полтава өлкәсенең Золотоноша шәһәрендә техник гаиләсендә туа. Киев университетында укый, 1878 елда политик чыгышлары өчен университеттан куыла һәм өч елга Белозерск шәһәренә сөрелә. Аннан кайткач, Киевтагы «Народная воля» оешмасына керә. 1883 елдан алып ул подпольеда яши, Ярославль, Казан шәһәрләрендә революцион эш алып бара. Эшчеләргә лекцияләр укый, К. Марксның экономик тәгълиматын популярлаштыра һәм пропагандалый. 1885 елдан эмиграциядә — Франциядә, Америкада, Швейцариядә яши, фәнни эш белән шөгыльләнә. 1905—1918 елларда эсерлар ягында була. 1917 елда Россиягә кайта. 1918 елда ул РСФСРның ВСНХ оешмасы каршында үзәк химия лабораториясен оештыра һәм гомеренең соңгы көннәренә хәтле аның директоры булып эшли. 1920 елда А. Н. Бах Наркомздравның Биохимия институтын оештыра. 1944 елда бу Институтка А. Н. Бах исеме бирелә. Бах 1935 елдан Бөтенсоюз химия җәмгыятенең президенты, 1935—1945 елларда СССР Фәннәр академиясенең химик фәннәр бүлегенең академигы. А. Н. Бах — СССР Верховный Советының беренче чакырылыш депутаты. Аңа 1926 елда В. И. Ленин премиясе, 1941 елда СССР Дәүләт премиясе бирелә. Ул 4 тапкыр Ленин ордены, бер Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. 1946 елда үлә.

Хәзер яңадан «Ачлык-патша»ның язылу тарихына кайтыйк. «Народная воля»ның Киев оешмаларында А. Н. Бах фәнни социализм идеяләрен пропагандалауга зур игътибар бирә. Эшче түгәрәкләрдә революцион эш алып бару дәвамында ул эшчеләрнең марксистик политэкономия белән кызыксынуларын күрә, чынбарлыктан алынган конкрет һәм дәлилле мисаллар ярдәмендә аларга иң катлаулы мәсьәләләрне гади итеп аңлатырга тырыша.

Революцион эш өчен Киевтан сөрелгәч 1883 елның августында ул Казанга килә. Автобиографиясендә А. Н. Бах үзенең Казанга килү максатын да яза — Казан кебек зур үзәктә «Народная воля» оешмасын ныгытырга тели. Ул биредә чынлап та берничә түгәрәк оештыра. Түгәрәкләрдән берсе фабрикада эшләүчеләр белән бәйләнешкә керә. Ләкин түгәрәк членнары, яшь булу сәбәпле, пропаганда алып бару алымнарын белмиләр. Алар үтенече буенча А. Н. Бах Киевта эшчеләр белән эшләү тәҗрибәсен сөйләп күрсәтә. Алар Бахтан шушы тәҗрибәне язма рәвештә бирүен үтенәләр. Политэкономия буенча бу әңгәмәләр, язылган өлешләре күләмендә, аерым-аерым бүлекләр рәвешендә гектографияләнә. Бөтен хезмәтнең язылуын көтеп торырга түгәрәкнең вакыты булмый. Җитмәсә, А. Н. Бах Петербургтан хат ала һәм хезмәтне тулысынча язып бетермичә Казаннан китәргә мәҗбүр була. Әңгәмәләр тәмамланмаган хәлендә брошюра итеп гектографияләнә һәм 1896 елда басылып та чыга. Аннан соң брошюра яшерен типографиядә бастырыла һәм эшчеләр арасында тарала.

Тәрҗемә «Царь-Голод, яхуд Ачлык-патша» исеме астында «Әлгасрел-җәдит»нең 1906 елгы — 8, 9, 11 нче һәм 1907 елгы 4, 5 саннарында «Г. Тукаев» имзасы белән басыла. Тукай тәрҗемәсенең беренче юлларында ук ике иҗтимагый сыйныф арасындагы каршылыклар гаять кискен күрсәтелгәннәр: «Берәүләр кан-тирләргә батып эшлиләр, берәүләр бернәрсә дә эшләмиләр; берәүләр ачыгалар, һәртөрле авырулардан чебеннәр шикелле каталар (үләләр); икенчеләре биек-биек пулатларда гына торып, алтын-көмеш савытлардан гына ашыйлар...» Шушы юлларны тәрҗемә иткән Тукайның күңелендә 1912 елны язылган «Көзге җилләр»нең кайбер юллары тумагандыр дип кем әйтер:

Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,
«Бер телем икмәк!» дип анда назлы нечкә бил җылый.

Тукай бу каршылыкны үстерә бара: «Берәүгә ни өчен тормыш яхшы да, берәүгә ни өчен начар? Ни өчен берәүләр корсак киерәләр, кабаралар, күперәләр дә, ни сәбәпле икенчеләр ачлыктан каталар-үләләр?» Ирексездән, тагын «Көзге җилләр»нең соңгы юллары искә төшә:

«...Җил — хәбәр ул, ач үлемнең куркусыннан ил җылый».

Тукайның бу тәрҗемәсе татар телендә политэкономик һәм иҗтимагый-политик терминология мәсьәләләрен хәл итүдә беренче тәҗрибәләрдән иде. Шактый күп сүзләрне Тукай я татарча, я гарәпчә сүз белән тәрҗемә итә дә, җәяләр эчендә аның русчасын да саклап калдыра: капитал — акча (капитал), прибавочный труд — кушылган хезмәт (прибавочный труд).

Тукайның политик экономия терминнарын тәрҗемә итүдә тәҗрибә ясавын тагын бер факт дәлилли: п р о д у к т дигән сүз ул чордагы татар телендә юк. Тексттагы шушы сүзгә килеп җиткәч, Тукай хәтта җәяләр эченә язып та куя: «...без ялгыз тимер эше генә эшлик тә, шул эшләремезне (китапча ничек диләр соң әле), «ма хасәлемезне күрше кавемнәрдән кирәк нәрсәләремезгә алыштырырмыз...»

Биредә турыдан-туры татарчага тәрҗемә ителгән терминнар күп: община — кавем, җәмәгать; ценность — кыйммәт, бәһа; настоящая стоимость — тиешле кыйммәт, чын бәһа; рыночная цена — базар хакы; производство — эшләп чыгару һ. б. Тәрҗемә башында р а б о ч и й сүзе х е з м ә т ч е дип тәрҗемә ителсә дә, соңга таба ул эшче сүзе белән алмашына бара: рабочий люд — эшче халкы, рабочие руки — эшче куллар.

Тукай тәрҗемәсендә кайбер җөмләләр тагын да төгәлрәк төсмер алалар. Мәсәлән, «Так вот частенько и в России надувала царская казна своих подданных» дигән җөмләдә «в России» дигән сүз төшеп калса да, җөмлә шактый усал килеп чыккан: «Менә шулай итеп, падишаһ хәзинәсе үзенең кулы астындагыларны яхшук агач аргамакка атландырды». «Кулаки и мироеды» төшенчәсен Тукай «Җыен әрәмтамаклар, сорыкотлар» дип тәрҗемә итә. «Отчего одни роскошествуют?» — «Ни өчен берәүләр корсак киерәләр, кабаралар, күперәләр?..» «Обернется он в тысячах рук, побывает в тысячах карманах» — «Ул меңнәрчә уч төпләрендә җомарлана, меңнәрчә кесәләрдә ятып чыга...», «Прочитаем эту скорбную повесть человечества» — «Инсаниятнең бу хәсрәтле вә хурлыклы хикәясен укып чыгыйк...», «Некуда теперь уйти от барской и помещичьей неправды, всюду тебя нагонит урядник и становой» — «Хәзер инде алпавытлар, боярлар тырнагыннан котыла алмассың! Кайда барсаң да староста вә становой сине аларның тырнагына куып кертер».

Тукай оригиналдагы җөмләләрне татар җирлегенә якынайта, милли төсмергә ия булган сурәтләр куллана: «Распорядились этим товаром как своим добром» — «Үзләренә ана сөте шикелле хәләл күреп, иябнәнеп алганнар»; «Но скоро тесно стало на святой Руси князьям» — «Ләкин, озак та үтмичә, ул кенәзләргә «печән өсте» булып китте»; «Праздник был для всей Руси» — «Бу хәл Россиягә гаед көне булды» һ. б.

Укучыга якынрак булу максаты белән, Тукай рус исемнәре урынына татар исемнәрен дә иртеп җибәрә: «...на товаре своим велит выбивать клеймо: «Мануфактура (примерно) Петра Калупаева» — «Мәсәлән, ул шул эшләнеп чыккан товарга: «Әхмәтҗан Шалканов мануфактурасы» дип «кләймә» (клеймо) ябыштырырга куша».

Г. Тукай, логик эзлеклелек, аһәңлелек, мәгънәви төгәллеккә ирешү, халык теленә якынрак булу өчен, кайчак тәрҗемәдә аерым җөмләләр, сүзтезмәләр, сүзләр өсти бара. Кайчак оригиналда булмаган терминнар да килеп өстәлә: «Шул рәвешчә син торасың: күңелеңнән гомереңне ситсычы булып үткәрәм дип уйлыйсың: менә бер заман л о к а у т!» «Итекче ткачтан, бер пар итек бирeп, киндер алмакчы була. Җ ә и н д е, итекче үзенең итеге өчен никадәр киндер алырга тиеш». Ачлыкның нинди зур көч икәнен әйткәч, Г. Тукай сорау өстәп куя:

«Менә ул нинди көч!
А ң л а д ы г ы з м ы?»

Г. Тукай тәрҗемәне иҗади эшләгән, халыкчан гыйбарәләр табарга тырышкан. Түбәндәге мисаллар моны бик ачык күрсәтеп торалар. «...выбросит на мостовую или под забор» — «...күпер астынамы, канау төбенәме тота да ыргыта»; «Не стесняться употребить их на обед или ужин» — «Кәндезгә чәйгә жаркой ясаудан да тарсынмый»; «Наши дикари» — «Вәхши әбзыйлар»; «Милый человек» — «дустым» һ. б.

Халык сөйләмендә генә очрый торган сүзләр кулланып, Тукай эмоциональлеккә, гадилеккә, стильдәге җиңеллеккә ирешә. Дөрес, алар А. Н. Бахта да бар, ул да шулай гади язган. Г. Тукай шуларны саклап калдырган: пьянчук, мышкылдап яту, акыллы баш, сыпырмакчы булу, ботка пешмәү, мыгырдану, һавадагы торна, теге дөньяга җибәрү,

үкереп җылау, әрәмтамак, сорыкортлар, бәрәкәтен очыру, җилкәсенә менеп утыру, канын суыру, эш пешмәү һ. б.

Фразеологик берәмлекләрне тәрҗемә иткәндә, Тукай иҗади юлга баса. Күпчелек очракта ул мәгънәви эквивалентлар таба: «пеняй на себя» — «үзеңә төшкән кайгы тауларына үзе сәбәп», «суждено маяться» — «маңлаеңа язылган инде», «возись над ним весь свой век» — «гомере буе мышкылдап ятсын»; «ишь ты» — «акыллы баш икәнсең» һ. б. Халыкка аңлаешлы булсын өчен, Г. Тукай аерым сүзләрне, фразеологик сүзтезмәләрне калькалаштыру алымын да куллана. Ярымкалькалар да шактый. Тукай тәрҗемәдә шактый күп рус сүзләре куллана. Аларның бер ишесе шул чор җанлы сөйләмдә бик актив йөргән.

Бер төркем сүзләрне Тукай тәрҗемә итеп бирсә дә, җәяләр эчендә барыбер аның русчасын калдыра. Күрәсең, ул үз тәрҗемәсеннән үзе дә канәгать булмагандыр. Татар телендә иҗтимагый-политик һәм марксистик терминология әле туып кына килә торган бер чор бит бу. Хәтта Маркс әсәрләренең русчага тәрҗемәләрендә дә ул чакта терминология әле ныклап урнашып җитмәгән була. Шуңа күрә бу чорда Г. Тукайның югарыда күрсәтелгәнчә тәрҗемә итүе аңлашыла да.

Брошюраның тәрҗемәсе капитализмда эшчеләрне эксплуатацияләүнең төп формасы булган өстәмә кыйммәтнең барлыкка килүен аңлату белән тәмамлана:

«Разобранный нами случай извлечения прибавочной стоимости из «рабочих рук» является наиболее резкой и ясной формой эксплуатации рабочего капиталистом» — «Менә бу сөйләп күрсәтдекемез мисал капиталистның эшчене ни рәвештә тунаганын вә талаганын (эксплуатациясен) бик ачык суратта күрсәтте.»


А. Н. Бахның брошюрасы 92 биттән гыйбарәт. 45 бит күләмендәгесен Г. Тукай тәрҗемә иткән. Алтынчы бүлек тәрҗемә ителеп бетмәгән. Брошюрада тагын «Эш халкы», «Капиталистик хуҗалык», «Социалистик хуҗалык» исемендәге VII, VIII, IX бүлекләр дә бар. Кызганычка каршы, алар тәрҗемә ителмичә калганнар. Әмма брошюраның IX бүлегенә нәтиҗә буларак язылган сүзләр игътибарга лаеклы: «Итак, чтобы избавиться от всех зол капиталистического строя, товарного хозяйства и конкуренции, необходимо уничтожить частную собственность на орудия и средства производства и сделать их общей собственностью всех трудящихся». А. Н. Бах «Ачлык-патша»ның юкка чыгуына, азат хезмәт патшалыгы киләчәгенә ышана. Хезмәт халкы үзенең нинди көчкә ия икәнлеген аңлап, башын горур тотып, азатлыкның яңа патшалыгына аяк атлаячагы турында яза ул хезмәтенең соңгы юлларында.

Г. Тукай бу брошюраның социалистик җәмгыятькә караган өлешләре белән дә, әлбәттә, таныш булган. Чөнки 1911 елда язылган «Шартлар» мәкаләсендә, «Мөселман иттифакы»ның, «Тәрҗеман» газетасының капиталга корылган булуын дәлилләп, ул болай дип яза: «Капиталистический строй бетеп: дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм». (Г. Тукай. Әсәрләр, дүрт томда, 3 том, 197 бит.)

Брошюраны тәрҗемә итү Г. Тукайдан күп көч һәм вакыт сораган, әлбәттә. Ләкин, тәрҗемә халыкның җанлы сөйләм теленә якын сүзләр, гыйбарәләр кулланып эшләнгән. Ул Г. Тукайның тәрҗемәче буларак осталыгын да күрсәтеп тора. Үзенең үтемлелеге, образлылыгы, гадилеге белән аерылып торган бу тәрҗемә татарлар арасында революцион эш алып баручыларның зур ярдәмчесе булган дип ышанып әйтергә мөмкин.

## Мәхмүт Хәсәнов

# ЯШЕЛ РОЗА



...Бөек кеше булган урыннарда аның күләгәсе кала, дия торган булганнар борынгылар. Мин дә шундый могҗизага өмет баглагандай, халкыбыз җырларына җуелмас бизәк булып кергән гүзәл Ык елгасы буйларына кайттым. Бу тирәләр, моннан берничә генә ел арабыздан киткән олуг шагыйребез Хәсән Туфан истәлеге белән бәйле. Без монда, тирә-юньнең илаһи гүзәллегенә хозурланып, учаклар ягып, куна-төнә балык чиерттереп яткан идек...

Мине су буена алып төшкән машина бая ук китеп барды. Япа-ялгызым калдым. Янәшәмдәге ярым шәрәләнергә өлгергән куе әрәмәлекләр, җан өшеткеч авазлар чыгарып, шаулашып алдылар. Көзге җилләр басу ягыннан арыш саламы, кибәк исе алып килә. Шундук, болын киңлегендә, ике-өч печән эскерте утыра. Кеше күзеннән качарга теләгәндәй, куе әрәмәлекләр эченә яшеренгән ике күл арасыннан, Тымытыкның Урсай авылына чыгып китә торган өлеше күренеп тора.

Уйлар, елларны кире чигереп, яңадан үткәннәргә алып китте. Әле кайчан гына Хәсән Туфан, Сибгат Хәким — бик зурдан кубып балык тотарга дип, башта Тымытыкка килдек. Кая гына бармыйк, солтанатлы шагыйрьләребез һәркайда, һәрчак игътибар үзәгендә: кадер-хөрмәт, олылау-зурлау. Кызыксынуның бер дә чиге-чамасы юк. Мин үз кеше, серләре сыя, үземә генә ишетелерлек итеп сорау артыннан сорау бирәләр: «Бусы шул Хәсән Туфанмы инде?» — «Әйе». «Икенчесе, көн. дә радио-телевидение аша җырлары-шигырьләре яңгыраган Хәкимме?» — «Нәкъ үзе!..»

Чыннан да, кунакларның кәттәләре. Хәсән ага Туфан үзе генә дә һәркемнең игътибарын тартып, җәлеп итеп торыр иде. Ул, мин сиңа әйтим, мөхтәбәр кыяфәт, озынча буй, төзек гәүдә, салмак-ипле хәрәкәт, ап-ак чәч, аксыл чырай, йөзендә һәрчак балкып-нурланып торган елмаю, һәрчак шәфкатьлелек, изгеләргә генә тиң итагатьлелек, акыл ияләренә генә хас сабыр-тыйнаклык. Кысынкы күзләрендә һәрвакыт диярлек нәрсәгә булса да гаҗәпләнү, соклану нуры сирпелеп торыр иде.

Хәсән Туфанның тагын бер күркәм сыйфаты хәйранга калдыра торган иде мине: бу аның бөтен дөньяны, галәмне кочагына сыйдырырга сәләтле киң күңеллелеге, табигыйлеге, кешеләрне үләп яратуы, олылавы, ихтирам итүе. Бу — һәрбер олы җанлы бөек кешеләргә хас уртак сыйфаттыр, күрәсең. Андый чакта ирексездән, А. П. Чеховның: «Кешене ихтирам итүдән дә ләззәтлерәк хис юктыр», дигән сүзләре искә төшә.

Тагын уйлар. Бу юлы да олуг шагыйрьләребезгә бәйле хатирәләр. Нишләмәк кирәк, Хәсән Туфан белән якыннан аралашкан елларым тормышымның иң якты хатирәләре булып калырлар, ахрысы.

Әле дә булса исемдә, табыннан кузгалуыбызга безне — Хәсән ага белән икебезне — «Беренче парга» дип, мунчага куа башладылар. Кунак, хуҗаның ишәге ди, буйсынмыйча кара, бар! Шунда мине әлкән дустымның, кәндәлек тормышның ибен, җаен, бөтен нечкәлекләренә кадәр белүе, кабат хәйранга калдырды. Мунчаны да үзенчә кыздырды, сабаклы мәтрүшкә кыстырып бәйләгән себеркене дә үз ысулы белән пешерде. Ләүкәгә күтәрелде, пар бөркеп торган хуш исле себеркесен: «Шәп!..» дип, йөзенә каплады да, күпмедер вакыт, ах та вах итеп рәхәтләнеп-ләззәтләнеп иснәп утырды. Чабынуы хәтердә калмаган. Аркаларны ышкышып, һәйбәтләп юынгач, инде чыгарга җыена башлагач, кабат игътибар итәрлек нәрсәләр булып алды. Хәсән ага мунча алдына чыкты. Хәл алырга телидер, дип уйларга да өлгерә алмый калдым, борылып кире керде. Карасам, бер кулында бишлек акча, икенчесендә — иске себерке. «Монысы, мунча ягучыга хезмәте өчен» — дип, акчаны тәрәзә төбендә торган шампунь савыты астына кыстырды. Ә себеркесе белән башта ләүкәне, аннары һәйбәтләп идәнне себерә башлады. Миңа бирмәде, үзе себерде. «Бездән соң керүчеләргә ялт итеп торсын...»

Шул ук көнне Хәсән аганың тагын бер тапкыр: «Шәп!..» дигән сүзен ишетергә туры килде. Ике-өч машинага төялеп су буена төшәргә җыендык. Әйберләрем (палаткам, кармаклар, балта, чиләк-табалар, савыт-сабалар) күптәнге танышым, балыкчы дустым Хәй Гәраевларда иде. Алар капкасы турысында туктадык. Берьюлы Хәсән аганың өс-башын да алыштырырга булдык. Хәй, олуг кунаклар алдында, бишкә ярылырдай булып бөтерелде. Ул болай да бик тә елдам, үтә елгыр, терекөмеш йоткан сыман хәрәкәтчел, ком гарәбе кебек кап-кара, какча йөзле, җыйнак-юка гәүдәле кеше. Шул Хәй, каяндыр иске сырган чалбар, шундый ук сырма һәм гомеренә крем заты күрмәгән кирза итекләре белән аяк чолгаулары чыгарды. Мин, һәрчак зәвык, чиста һәм пөхтә киенеп йөрергә күнеккән Хәсән ага бу киемнәрне кимәс, «җүнлерәк» киемнәр сорарга дип, авызымны ачкан да идем инде. Әмма Хәсән ага, абзар ышыгында яткан бүрәнәләр өстенә барып утырды да, кәндәлектә кия торган киемнәрен кигән кебек, күз ачып йомганчы, баштанаяк, әлеге иске-москыны киеп тә куйды. Агай гынамы әле, шундук кулларын җәеп, биеп китәргә җыенган сыман: «Шәп!..» дип, хәтта кирза итекләре белән җиргә тибеп куйды...

Шундый уйларга бирелеп бераз торгач, әйберләремне күтәрдем дә таныш сукмак буйлап ярым шәрәләнергә өлгергән әрәмәлеккә кереп киттем. Кайчандыр көч-хәл белән, иелә-бөгелә үтә торган сукмак киңәйгән, мотоцикллар, машиналар да үткәләгән булса кирәк: як-яктагы вак таллар сынгалаган, тәмам эштән чыккан.

Һәм менә, ниһаять, минем күп еллар буе палаткалар корып, җәйләр буена кайтмый яткан, үземә генә билгеле аланлыгым! Саумы, оҗмахка тиң яр буйларым, саумы, шигъриятле, җырлы, нурлы Ык елгасы! Үләр дәрәҗәгә җитеп сагынып кайттым үзеңне, каршы ал. Минем өчен син газиз дә, якын да икәнсең ич. Хәер, уйлый калсаң, гаҗәпләнерлеге дә юк: синең буйларыңда гомеремнең иң дәртле-егәрле, алай итәм дә болай итәм диеп яшәгән хыялый еллары үтте. Синең җикән камышлары бизәгән, су өсләреңне төнбоеклар каплаган яр буйларыңда балаларым үсте. Бу төбәккә минем җаннан кадерле каләмдәш дусларым киләләр иде, гүзәллегеңә сокланып, илһам алып китә торганнар иде...

Әмма Ык елгасы буена бәйле булган хатирәләрнең иң яктысы гомерем буена онытылмаслык булып күңел түренә уелып калганы, әлбәттә, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һәм аның тормыш иптәше Мөршидә апалар белән гөр килеп, рәхәтләнеп, күңелләребез булганчы ял иткән чаклар булгандыр.

Әле дә булса хәтеремдә, без төшү белән,ямьле Ык буйлары шау-шу, шат авазлар белән тулды, ах та вах килеп, тирә-юньнең сихри матурлыгына соклanулар башланды. Хәсән ага, текә ярның елга эченәрәк кереп торган урынына барып басты да хәрәкәтсез калды. Сихерләнгән кеше сыман шактый озак торган иде ул яр өстендә.

Әйберләремне, гадәттә палатка кора торган, корыган карт карагай төбенә куйдым да кайчандыр Хәсән ага басып торган урынны эзли киттем. Менә ул урын. Әмма яр буеның таныrлыгы калмаган. Кайчандыр Хәсән ага, такта башы куеп, урындык сыман нәрсә ясап утырган карт агач төбе дә юк. Язгы ташулар мәрхәмәтсез кыланганнар. Яр буйлары да үзгәргән: ишелгәннәр, яр астында яңа чоңгыллар, тугайлар хасил булган. Актарылып-ашкынып аккан суга карыйм. Көчле агым эчендә уйнаклап-шаярышкан чабак балыкларын хәтерләтеп, озынча тал яфраклары йөзеп уза. Сирәк-мирәк кенә, йомры гәүдәле «алтын балыклар» да узгалый, болары — саргайган каен яфраклары...

Юк йомышымны бар итеп, бер-ике тапкыр Хәсән ага янына килгән идем. Шунда ул, һаман да бер урында, яр өстендә утырганы өчен акланырга теләгәндәй, болай дигән иде:

— Агымсу белән янган утка карап, кем туйган, Мәхмүт...

Тагын ул миңа: «Игътибар иткәнең бармы икән, Мәхмүт... Табигать — һәрчак ритмда...» — дигән иде. Нәрсәдән чыгып әйткәндер ул бу сүзләрне, хәзер инде хәтерли алмыйм.

Олуг шагыйребезне нииндирәк могҗиза, ниндирәк көч шул кадәр җәлеп итә алды

икән? — дип, тирә-юньне күздән кичерәм. Кая карама, «алтын көз» хакимлек итә. Шәрәләнергә өлгергән куак ботакларына әбиләр чуагының көмеш пәрәвезләре сузылган. Баю ягына авышкан кояш нурында алар төрле төсләргә кереп тирбәлеп торалар. Тирә-юньне биләп алган әрәмәлекләрдә дә салават күперенең барлык төсләрен күрергә мөмкин. Бер үк төп куакта, аерым агачта, фирәзә, җете кызыл, бурлат кызыл, зәгъфран төсләре чуарлана. Шундук, хәзергә әле кошлар тарафыннан «таланырга» өлгермәгән балан, гөләп җимешләре күзләрне кызартып торалар. Үзе белән байлык-муллык алып килгән көзне халык элек-электән көтеп ала торган булган. Көз — бөтен бер елның нәтиҗәсе бит ул.

Елганың өске ягына күз салам. Анда сары комлы кашлак чите күренеп тора. Ул тирәдә сайлык, шарламак. Шунлыктан агым да көчле-куәтле. Бәлки шуңадыр, ул тирәләр, эре балык түшкәсе ятканга охшап, ялтыр-йолтыр килеп, тәңкәләнеп күренә.

Елганың аръягында, каршы якта, тау тезмәләре. Урал тавы итәкләренең дәвамы алар. Өстән-аска таба, кар сулары, яңгыр гөрләвекләре яргалаган кызыл яр. Кызарып, урман өстенә барып кунган кояш нурында ул ут капканга охшап күренә. Таулар өстендә, җете сиек яшел төскә кереп, уҗым басуы күренә. Шундук, каракучкыл яшел наратлар янында, алтын-сары салам эскерте. Нинди генә төс юк иде ул якта! Бәлки шуңадыр, әлеге күзге манзара, кай яклары беләндер (бәлки төсләрнең җете-ачык булулары беләндер), әрмән халкының мәшһүр рәссамы Сарьян полотноларын хәтерләтәләр иде.

Кармак сала торган урыныма килдем. Бу ни бу? Ничәмә-ничә еллар буена басып утырган урынымның да танырлыгы калмаган. Ярлар бик нык үзгәргән. Саеккан да булса кирәк. Әй-йе, шактый еллар үткән шул инде. Аннары агымсуны тикмәгә генә чыгымчы ат белән чагыштырмый торганнардыр. Елга холкы — агымына бәйле.

Урынымның үзгәрүе кәефемне кырса да, булмаса-булмас дип, барыбер җимшәдем, ягъни, кармаклар саласы урынга бернечә кушуч борчак сиптем. Балык җыелсын, балык иләшә торсын, янәсе. Бары тик шуннан соң гына яр өстенә күтәрелеп, яктыкүздә дип, ут ягар өчен коры-сары хәзерләргә керештем.

...Нәкъ менә хәзергедәй, кояш баю ягына авышкач, Мәршидә апа: «Мәхмүт, Сибгатне төнгелеккә сезнең янда калдыра алмыйм, сәламәтлеген беләсең ич»,— дип, үзенең катгый карарын белдерде. Без, Хәсән ага белән, аларны болынга кадәр озата чыктык. Берьюлы, палаткабыз астына түшәр өчен печән дә алып керергә булдык. Шунда кабат мине гаҗәпләндерерлек бер мәзәкнең шаһиты булырга туры килде. Мин эскерт янына килдем дә, аннан тартып, моннан йолкып, бер кочак печән алдым. Эшне шулай коры тотуыма мактангандай: «Миңа булды...» дидем. Хәсән ага: «Ике тапкыр килеп йөрерлек булмасын инде...» дип, миңа сабыр итәргә кушты. Шунда ук эскерт янына басты да, бөтереп-борып, озын аркансыман итеп, көлтә бавы ишә башлады. Минем печәнем янына тагын шактый гына өстәп, тезе белән басып-изеп, гаять зур төен бәйләде бу. Шул уклау кебек тыгыз итеп боргычланган, үзе бер кибән чамасы печәнне җилкәмә күтәреп салгач, сызгырып җибәрә яздым үзем дә.

Ниһаять, караңгы төште. Аңынчы инде эшебез дә тәгәлләнгән иде: палатка җылытылды, утын хәзерләнгән, кармаклар көйләнгән, урын кабат мул итеп җимшәлгән...

— Ятыр алдыннан чәйләп алсак та ярар...

Хәсән ага, яртылаш сүнгән учак янына килеп, аякларын сузып һәйбәтләп утырганнан соң, кулындагы таяк белән, читкә тәгәрәгән кисәүләрне җыеп өйде. Коры-сары өстәде. Шуны гына көтеп торган кебек, учак гөлт итеп кабынды. Караңгылык тагын да куера төшкән сыман булды. Ике як ярны кавыштырырга теләгән сыман, сиек томан пәрдәсе төште. Ул арада шактый ук югары күтәрелергә өлгергән тулы ай, бөтен нурын-яктылыгын безнең өскә юнәлтергә уйлагандай, күзләрен чекерәйтеп карап тора иде.

Хәсән ага, озаграк янсыннар диптер инде, утка эрерәк утын өстәде. Күмер тартып, олы чәйнекне күмер өстенә куйды. Хәрәкәтләре салмак, әмма бик иппеләр иде.

Ул арада мин җыйнак кына табын хәзерләдем. Күмәч, шикәр, май ише нәрсәләр чыгардым. һәм без, учак янына кырын төшеп, авызларыбызны пешерә-пешерә, калай кружкалардан чәй эчә башладык.

Хәсән ага чәйне мактап күкләргә чөйде.

— Әллә инде рецептың һаман үзгәртеп торасың... Эчкән саен тәмләнә бара.— Аннары чынлап торып кызыксынган кеше сыман, сорау бирер куйды.— Нәрсәләр саласың соң син моңа?..

Мактанырга миңа гына куш. Тезәм дә тезәм. Иң әүвәл, янәсе, чәйне ут өстенә куйганчы ук, гөләп җимеше агачының тамырын алам. Аны балта белән чәрдәклим. һәйбәтләп салкын су белән юам. Бары тик шуннан соң гына чәйнеккә салам. Ә инде чәйнек кайнап чыгар алдыннан, берәр уч чамасы гөләп җимеше үзе өстәлә. (Ә җәй көннәрендә чәчәге дә кулланыла.) Чәйнек кайнап чыгып, ут өстеннән алыр вакыт җиткәч, берәр уч кара карлыган белән кызыл карлыган яфрагы өстисең...

Учак янында утырабыз. Шулчак кайдадыр бик биектә, кирәгеннән артык якты һәм эре булып калтыранып күренгән йолдызлар ягыннан, кыр казлары каңгылдашканга

охшашлы аваз ишетелгән сыман булды. Бу көтелмәгән хәлдән икебез дә тынып калдык. Карасам, Хәсән аганың учакны рәтләргә дип сузылган чыбык тоткан кулы һавада асылынып калган. Кулы гына түгел, чак кына кырын яткан чал башы да хәрәкәтсез иде аның.

Ялгышмаганмын икән, нәкъ шул мизгелдә, баш очыбызда ук, кыр казының яман даһмоңсу итеп аваз салганы аермачык булып ишетелде. Тәнемне чиратып, аркам буенча кындидер салкын йөгерүен тойдым. Киек казлар!..

Хәсән ага да миңа таба борылды. Ялкын шәүләсе уйнаган җитди йөзендә бары тик бер сорау: «Ишеттеңме?..» Мин дә, үз чиратымда, ияк кагып кына җавап кайтардым. Мондый чакта сүзнең кирәге юк, артык алар.

Күңелем түрендә, бөтен барлыгымны үзенә буйсындырып, шигъри юллар гәүдәләнде...

Яңгырларда-явымнарда,
Давылларда-җилләрдә,
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде...

Бераздан тирә-юнь тынды. Шулчак, каяндыр әрәмәлекләр арасыннан, куәтле дулкын булып, салкынча җил исеп куйды. Кисәү башларын каплаган аксыл элпе сыман көлне тузгыту, Хәсән аганың чал чәчләре белән шаярып алу өчен шул бик җиткән иде.

Табынны җыештырдым. Берни дә булмаган кыяфәттә, ут янында, бер көйгә генә гәп корып утырабыз. Хәзер инде хәтерләмим, сүз нәрсәдән башлангандыр, әңгәмәбез тугандаш халыкларның олуг шәхесләре, бөек акыл ияләре турында иде. Шунда мин Хәсән агага: «Нәрсә ул илһам?» — дип сорау бирдем ахрысы.

Хәсән ага, гадәттәгечә, капылт кына җавап кайтарырга ашыкмады. Кулындагы чыбыгы белән әледән-әле учакны рәтләде, кисәүләрне өйде, берәм-сәрәмләп кенә утын өстәде. Сүзен дә шактый читләтеп башлады ул. Кемнәрнеңдер шигъри юлларын укыды, күп төрле мисаллар китерде. Шунда мин олуг шагыйребезнең күпмилләтле совет әдәбиятын бик яхшы белүенә, чын мәгънәсендә интернационалист шагыйрь булуына тагын бер тапкыр төшенгәндәй булдым.

— Илһам дигән изге хис турында ике сүз белән генә җавап биреп булмастыр,— дип башлаган иде Хәсән ага.— һәркем үзенчә аңлый аны. Мин, мәсәлән, аны бөтен сәләтеңне, бар булганыңны тулысынча иҗатка юнәлтә, туплый белү дип аңлыйм. Бөтен эч пошуларыңны, кәефсезлекләреңне, тормышыңда килеп туган мең төрле зилзиләләреңне бер читкә атып, бар нәрсәңне онытып, бары тик иҗатың белән генә кала белү дип аңлыйм. Әмма бу халәт үзеннән-үзе тумый. Моның өчен олуг художник булырга, чын гүзәллекне күрә, гүзәллекне тоемлый, бар нәрсәдән өстен куя, өстен саный белергә кирәктер. Чын гүзәллек, сафлык һәм матурлык кешене гомере буена илһамландырырга сәләтле. Илһам дигән нәрсә — бөек көч ул. Илһамсыз чын иҗат юк. Илһам булган җирдә битарафлык була алмый. Әгәр дә чын гүзәллек, матурлык һәм самимилекне күреп тә җаны кузгалмый, инанмый, шул гүзәллеккә фанатикларча ышанмый икән, андый әдипнең әсәре беркемне дә дулкынландырмаячак, укучының җанына азык, күңеленә якты нур була алмаячак. Чын сәнгать әсәре һәрчак яктылыкка өндәү өчен, җирдә яхшылык җиңсен өчен иҗат ителә...

Үзем тыңлыйм, ә үземнең күңелем түрендә һәрчак гүзәллеккә мөкиббән олуг шагыйребезнең хис нечкәлеге, сафлыгы һәм ихласлыгы белән үзенә җәлеп иткән шигыре гәүдәләнә:

Гөлләр сорый миннән: «Нишләп, Туфан,
Уйга калдың әле син шулай?»
— Белмим, гөлләр, уйга калып шулай,
Гүзәллеккә сокланам бугай...

Гаҗәп хәл! Шушы арада гына шундый уй фикерне мәшһүр рәссам Рерихта да очратырга туры килде. Даһиларның фикере һәрчак тәңгәл дигән сүз хактыр, күрәмсең. Рерих, мәсәлән, аерым халык, аерым ил турында гына түгел, бөтен кешелек турында фикер йөртеп, болай ди: «Многое можно добиться проповедью красоты, распространением культуры».

Сүзебез, ничектер, үзеннән-үзе яшьләргә, яшьләр иҗатына күчте. Белгәнебезчә, Хәсән Туфан яшь һәм башлап язучыларның иң якын дусты, акыллы киңәшчесе, риясыз

ярдәмчесе, ару-талуны белмәс тәрбиячесе иде. Үзе ул һичкайчан да яшьләр белән эшләү турында гәп сатмады, ул эшләде алар белән.

— Әгәр дә әдәбиятка килүче талантлы икән, аңардагы изге очкын үзен шундук сиздерә. Моны яшь әдипнең сайлап алган темасы, әйтергә теләгән фикеренең масштаблылыгы, әдәби сүзнең кадерен ни дәрәҗәдә белүе, фәлсәфи гомумиләштерүе һәм, ниһаять, тормыш турында ни дәрәҗәдә фикер йөртүеннән үк чамалыйсың. Менә шундый өметләрне күрә, сайлап ала белергә кирәк. Андыйларга кичекмәстән ярдәм кулы сузу чарасын күрергә кирәк...

Хәсән ага сөйли. Учак яна. Шулчак, сүзебезне бүлеп, баш очыбыздан гына, һаваны ярып очкан канатлар сызгыруы ишетелде. Бу — үрдәкләр. Чыннан да, нәкъ шул мизгелдә, бер үрдәкнең сак кына тавыш биргәне ишетелеп куйды. «Ба-ак, бак!..» Кешеләр, сак булыгыз! — ди булса кирәк.

Әлеге пауза, Хәсән аганың фикер ээлеклелеген чуалта алмаган, ул дәвам итте.

— Дөрес, язучылык һөнәре индивидуаль хезмәт, анда беренче чиратта үз-үзеңә ышану, үз-үзеңә таяну шарт. Иҗатта кеше тәҗрибәсе — начар таяныч. Башкортстанның олуг шагыйре, минем якын дустым Сәйфи Кудашның бу турыда әйткән бик матур фикере бар. Бөекләр, диган иде ул, биеккә башкалардан күтәртеп, этәртеп менмиләр, кырмыскадай, таудай йөк күтәреп үзләре үрлиләр. Шәп әйтелгән бит, ә! Олы әдәбиятка килергә җыенучы мең төрле кыенлыкларны җиңәргә, чыдый алмаслык авырлыкларны буйсындырырга, алар алдында баш имәскә, чигенмәскә тиеш. Талант белән фанатикларча фидакарь хезмәт — һәрбер олуг сәнгатьнең пар канаты ул. Чөнки язучылык хезмәте, бигрәк тә поэзия, әзер чәчәкләрдән такыя төзү яки букет ясау түгел, ә тере, җанлы чәчәкләр үстерә белү.

Яшьләр турында сүз алып барганда, олы шагыйребезне борчыган нәрсәләр дә барлыгы ачыкланды. Бигрәк тә аны төссез, хиссез шигырь язучыларның күбәюе җанын кыйный иде булса кирәк.

— Чын поэзия әсәренең никадәрле зур көч, фидакарь хезмәт куеп, авыр газаплар белән генә тууын белмәүләре борчый,— дип дәвам итте ул. Сүз уңаенда тагын бер күңелсез күренешкә туктады. Кайберәүләрнең, мөмкинлекләре үз кулларында булудан файдаланып, ел да берәр, хәтта икешәр шигъри җыентыклар чыгаруына чын күңелдән әрнеп сөйләде Хәсән ага.

— Ә бит һәрбер китап — сыналу ул. Укучың, халкың алдында имтихан тоту. Нишләп шул турыда оныталар икән?! Бу хәл, беренчедән, чын поэзиянең дәрәҗәсен төшерсә, икенчедән, олы тарихы, бай традицияләре булган әдәбиятыбызның дәрәҗәсен төшерә. Сугышка кадәр генә әле, теге яки бу газетада шигъри әсәр чыгу үзе бер вакыйгага әверелә торган иде. Андый газетаны тиз генә кулыңа төшерермен димә...

Үзем йотлыгып Хәсән аганы тыңлыйм, ә үзем аның беренче шигырьләр җыентыгының ничегрәк дөньяга чыгарылуы турында уйлыйм.

Билгеле, без төннәр буе гелән иҗат, гелән поэзия турында гына гәп сатмагандыздыр. Әлбәттә, шулай. Хәзер уйлыйм да хәйранга калам. Бәлки Хәсән ага сөйләгәннәрнең күбесен теләсә кемгә чишәргә дә ярамагандыр. Ә миңа сөйли иде. Ул сөйли, ә мин ул хикмәтле могҗизаларның чагылышын, әдипнең гаять бай, катлаулы иҗатыннан табып, барлап барам сыман...

Учак ялкыны сүлпәнләнде. Йоклар вакыт җиткән иде инде. Без, палатка астына түшәлгән печәнне тигезләдек тә, тыныч йокылар теләшеп, сузылышып яттык. Палатка эче җылы. Саф һава. Печәннең хуш исе борыннарны кытыклый.

Сөйләшмибез. Таң белән торасы бар. Тынлык. Әмма шулай булып тоела гына. Чынлап торып колак салып тыңлый калсаң, ишетәсең: һәркайда тормыш кайный. Кайдадыр еракта, болыннар киңлегендә, тартар кычкыра. Бу аның соңгы җыры, башка кошлар белән ул да ерак сәфәргә җыена. Якында, куыш тирәсендә үк, нәрсәдер кыштырдый. Юк, җил түгел бу, берәр төнге җәнлек килгән булса кирәк. Ул да түгел, безнең кармаклар янында гына зур балык чума: чуртан яки сыла ауга чыккандыр... Су өстендә хәзер, ай шәүләсен чайпалдырып, як-якка бары тик дулкын боҗралары гына йөгерешәдер.

Йокы тәтедеме икән ул төнне, белмим. Күпмедер онытылып ятканнан соң, күңелем белән таң ата башлаганны тоемлап, торырга булдым. Хәсән аганы уятмаска ниятләп, тавыш-тынсыз гына күтәрелдем дә, җылы киемнәремне барлап, палатка авызын ача башладым. Хәсән ага күптән уянган булып чыкты.

— Нәрсә, торабыз дамыни инде? — дип сорап куйды.

— Сез йоклагыз әле, Хәсән ага. Мин генә торыйм. Хәзер балыкның иң ала торган чагы... Соңарырга ярамый.

Кая ул! Минем арттан ук калкып чыкты. Төн чат аяз. Күк йөзе тулы йолдыз. Салкынча. Калтыратып алды. Хәсән ага, палаткадан чыгу белән, учакны тергезеп җибәрде. Тирә-юнь яңадан эңгер-меңгергә чумды.

Мин кармаклар янына төштем. Хәсән ага, тын да алмыйча, яр өстендә тора. Эх-х, мин әйтәм, капсын иде бер өч-дүрт килолы корбан, каз канатлары белән суны кыйнаган

авазлар чыгарып, шапы-шопы китереп, сейрәп аласы иде үзен! Чыгарасы иде дә: балыкны аны бездә шулай тоталар дип, яр өстенә, Хәсән аганың аяк астына тондырасы иде. Юк бит, чукындырасыңмыни аны, алты-җиде кармакның хет берәрсе селкенеп карасын, коега салганнармыни үзләрен.

Нићаять, сызылып кына таң белене башлады. Буланган тәрәзә пыяласы аша гына күренгән сыман, теге як ярлар да пәйда булды. Шулчак камыш-таллыкларны сәер кыштырдатып, җил исеп куйды. Таң җиле. Бу тыгыз җил, су өстенә, үзәнлекләргә мул булып төшкән томанны да хәрәкәткә китерде: өзгәләде, таркатты...

Ә балык юк та юк. Мин: шабаш! дип, зарланырга теләп, артыма борылдым. Хәсән ага юк иде инде анда. Учак янына, я йөреп килергә дип китеп баргандыр, дип уйладым мин.

Кичә дә шулай югалып торгалады. Минем урыннан чак кына өстәрәк, тыныч култыклар, куе таллыкларга посып яткан ерымнар бар, шулар тирәсенә киткәндер. Нәкъ шул якта тагын бер искитмәле матур түгәрәк күл дә бар. Ярлары куе яшь таллык, башлы камышлар белән уратып алынган әлеге күл өсте, каракучкыл яшел төстәге бәрхет келәм җәйгән табынны хәтерләтә. Ә эре-эре төнбоек яфраклары — шул табын өстенә таратып куелган тәлинкәләр... Сирәк-мирәк кенә ап-ак һәм сары төстәге төнбоек чәчәкләре күренгәли. Алары — мул табынның башка төр бизәкләре...

Кояш чыгар алдыннан Хәсән ага да күренде. Күңеле канатланган, йөзендә ниндидер билгесез куаныч нуры балкый. Кулында гап-гади тал ботагы.

— Мәхмүт, синең яшел төстәге роза күргәнең бармы? Аны тал розасы дип тә йөртәләр...

Миңа кызык. Барыбер балык чиертми дип, янына күтәрелдем. Менә сиңа мә! Кем әйтмешли, юкәдә булган икән чикләвек. Яңадан мең ел яшәсәм дә, талда роза чәчәк атуын күрмичә үләчәкмен икән.

Ул истәлекле яшел розаны Азнакайдан Зеленый Долга күченеп кайтканчы саклаган идем. Шул ыгы-зыгы вакытында кая тыгылгандыр, күпме генә эзләсәм дә, таба алмадым.

Моннан ике генә ел элек, бертуган, бик яраткан сеңлем Хәлимә, аның һәм безнең балалар җыйнаулашып, Идел буена төшкән идек. Аулак урында, куе әрәмәлек янында, палаткалар корып, сулар коенып, туйганчы кояшта кызынып, ял итеп яткан идек. Шунда сеңлем Хәлимә дә, нәкъ Хәсән ага Туфанныкына охшаган, розалы тал куагы тапты. Хәзер инде ул сеңлем дә юк... Әмма шул ике якын кешемнең якты истәлеге булып өемдәге вазада, башлы камышлар белән аралашып, яшел розалар букеты саклана. Озак торудан шылтырап кипсәләр дә, минем өчен бик кадерлеләр алар.

Ул көн шулай һәйбәт кенә узды. Икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды. Ә мин һаман чиләк-чиләк борчак бүрттерәм дә, урынны җимшәп суга борчак сибәм...

Аңа карап минем хәлем җиңеләймәде, шушы кадәр дә уңайсыз хәлдә калырмын дип, башыма да китермәгән идем. Хикмәт, балык эләкмәүдә генә дә түгел, иң яманы, Ык буена төшкәнче үк чаманы белмичә, кирәгеннән артык мактанып шапырынып ташлавым иде. Көнлек менюларга кадәр төзеп, үч иткәндәй, шул меню белән барысын да бик җентекләп таныштырып та өлгергән идем. Ул менюдан күренгәнчә, иртәнге ашка тау кадәрле итеп өеп балык кыздырылырга тиеш иде. Көндезен, ризык төрләндерү максаты белән, беренчегә берәр «чит» ризык, икенче блюдога — әлеге дә баягы — кыздырылган балык. Ә инде кичен, эчкә җылы керту максаты белән, беренчегә, бөтен шартлары китерелеп пешерелгән (балыкчылар телендә «царская» ягъни «тройная» дип атала торган) уха. Башта шыртлакадыр, алабуга ише вак балык салып кайнатасың. Аны, шулпага кылчыгы-фәләне эләкмәсен өчен, һәйбәтләп марля аша сөзәсең, чүбен чыгарып атасың. Икенче партиягә эрерәк балык салына. Анысын ватмыйча-нитмичә, аерым савытка аласың. (Салкын закуска урынына кулланыла.) Иң соңында, ухага мең төрле тәмләткечләр салынгач, уха ут өстеннән алыныр вакыт җиткәч, сыла, сазан, аҗау ише эре балыклар салына. Анысы, савытларга бүлгәндә, шулпа белән бергә бирелә...

Фатих Хөсни әйтмешли: «мактанчыклыгым бер кузгалгач» тездем дә тездем, моңарчы әле беркем дә ашамаган, хәтта авыз да итмәгән, балыктан хәзерләнгән хикмәтле ризык белән сыйларга иде ниятем. Атаклы антрополог Миклухо-Маклай язмаларында, Океаниянең Яңа Гвинея утрауларында яшәүче папуасларның, балыкны банан яфрагына төреп көлгә күмеп хәзерләүләре турында укыган идем. Мин дә уртача зурлыктагы балыкларны алып, һәйбәтләп чистартып, тоз сибеп, эченә берәр кашык ак май, лавр яфрагы, эре итеп туралган башлы суган, тартылмаган кара борыч, тагы берничә төрле тәмләткеч тыгып, башта чиста кәгазьгә төреп, (банан яфрагы каян аласың, ди!) өстеннән тагын берәр кат юеш кәгазьгә төреп, нәкъ бәрәңге күмгән кебек итеп, уттай кызу көлгә күмү иде ниятем. Бу ысул белән хәзерләнгән балыктан авыз итеп караганым бар иде инде.

Әзер булгач, балыкларны саклык белән генә көлдән чыгарасың, чак кына суынганнан

соң, майланган кәгазеннән арындырасың. Ниһаять, иң эчтәге чиста кәгазьне ачасың... Хуш ис белән бөтен су буе тула, шулпалы бәлешләрең бер кырыйда торсын инде менә! Ике бармак белән генә балыкны аласың да, изрәп пешкән балыкны, әлеге чиста кәгазь өстендә (кискен хәрәкәт ясап) бер генә тапкыр селкисең... Кулыңда балыкның чип-чиста, бөп-бөтен скелеты гына кала... Шулай хәзерләнә ул ашап туйгысыз, телләреңне йотарлык ризык!

Балык капмады дип, ачка тилмермәдек, әлбәттә, ит-маеннан, катык-сөтеннән дә өзелмәдек. Әле дә хәтеремдә, ул юлы ниндидер кош итe салып аш пешергән идек. Табын гадәттәгечә мулдан хәзерләнде. Чирәм өстенә ниндидер ындыр табагы чаклы брезент җәеп хәзерләнгән табын түрендә Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Мөршидә апа, минем хатын, аннан килеп Тымытык балыкчысы Хәй Гәрәев, безне йомшак икмәге, тегесе-монысы белән тәэмин итеп торучы, нефть белгече Марс Гарипов, тагын кемнәрдер бар иде. Табын, башта әйткәнемчә, түгәрәк. Шулай бер көйгә генә гәп сатып утырабыз. Сүзебез, билгеле инде, һаман бер тирәдә чуала: нилектән балык капмый?!.

Мин үземчә аңлаткандай итәм: янәсе, хәзер балык чоры үтте, көз җитте, су тонықланды, тегесе дә монысы...

Шунда, әңгәмәгә әллә ни катышмыйча утырган Сибгат ага, бик гадәти нәрсә турында сүз башлагандай, үзенә генә хас сабыр-тыйнаклык белән әйтә салды:

— Син, Мәхмүт, борчакны артыграк сиптең ахры...

Шулчак әллә нәрсә булды, кинәт шартлап һава ярылдымыни! Кемнеңдер авызына алган шулпасы табын өстенә чәчрәде. Ул да түгел, янымда гына кирза итек чагылып китте. Карасам, ни күрим, Хәсән ага Туфан кырын авып төшкән дә (гомердә булмаган хәл), чал башын артка ташлап, рәхәтләнеп шаркылдап көлеп ята. Күзләреннән яшьләр бәреп чыккан. Үзе һаман да тыела алмый көлә. Икенче ягымда — ком гарәбе — Тымытык балыкчысы Хәй Гәрәев тәгәрәп ята. Бер кулы белән эчен тоткан, икенчесе белән шапы-шопы китереп, җирне кыйный: «Уф-ф, үләм!.. Үтердегез, Сибгат абый... Пычаксыз суйдыгыз...»

Миңа да, Сибгат аганың әлеге сүзен кайта-кайта кабатлап, һаман да тыела алмыйча көлүчеләргә кушылудан башка чара калмаган иде.

Сибгат аганың әлеге «канатлы сүзе» Азнакайга үзебездән алда кайтып җиткән иде. Әлмәткә барып чыксам, анда да шул сүз: син, Мәхмүт, борчакны мулдан сибеп тотасың икән балыкны... Казанга да көнe-сәгате белән кайтып җиткән әлеге сүз. Хәтта, әлеге мәзәккә, башкорт дуслар да хәбәрдар булып чыктылар. Малеевкада Марат Кәримов, Динис Бүләковлар белән еш кына табындаш булырга туры килгәләде. Алар да мине шундагы буага балыкка чакырып теңкәгә тиеп беттеләр: янәсе мин бик оста балыкчы икәнмен...

Соңгы елларда Батулланың, әлеге мәзәкне (бер янына бишне кушып, әлбәттә), сәхнәдән сөйләп, гаять зур уңыш казануы турында ишеттерделәр. Батулланы яхшы беләм мин, һич тә булмас димә...

Чехов турындагы истәлекләрне укыганда мондыйрак сүзләргә юлыктым. Мәшһүр язучы, әсәрләрен тәнкыйтьләгәндә әллә ни исе китми торган булган, ә инде балыкчылык сәләтенә тел-теш тидерсәләр, чынлап торып үпкәли торган булган. Мин үпкәләмәдем. Беренчедән, мин Чехов түгел, икенчедән, үзем гаепле, чаманы белмичәрәк мактанмаска, шапырынмаска кирәк иде.

Ничек кенә булмасын, шактый еракта калган ул көннәр, ул еллар хәзер иң куанычлы, иң кадерле вакытлар булып искә төшәләр.

Ялгызым гына учак янында утырам. Төн. Тынлык. Каршы якта гына, кулындагы чыбыгы белән көйрәгән-янган кисәүләрне төзәткәләп Хәсән ага Туфан утыра сыман... Тавышы колакта, сүзләре истә, йөз-чалымнары күз алдымда. Бераз гына арыган һәм талчыккан кыяфәт, салмак-төгәл хәрәкәт. Ул вакытта, Хәсән ага Туфан белән бергә чакта, Ык буйлары да ямьлерәк, төннәр дә җылырак, йолдызлар да эрерәк һәм яктырак булганнар икән...

Шунда тагын бер ачы хакыйкатькә төшендем мин: кайчандыр булган, эзләрең калган урыннарга кабат килергә мөмкин, әмма үткәннәргә кире кайту юлы юк икән.

Хәсән Туфан белән беренче тапкыр ничегрәк итеп танышуыбыз хәтеремә бик яхшы булып уелып калган. Аның кайтып төшкән еллары гына иде. Куанычыбыз эчебезгә сыймый, башыбыз күкләргә ашты. Әдәбиятыбыз ниндидер могҗиза көче белән кинәт кенә үсеп тә, баеп та киткән сыман булды.

Ул көннәрдә Хәсән Туфан белән очрашып иркенләп сөйләшә алырмын дип уйлама, аны кулдан-кулга күтәреп, очрашудан-очрашуга, кунактан-кунакка йөрткән чак. Нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә, уйламаганда-көтмәгәндә, матбугат йортының икенче катында, кара-каршы килдек тә бастык Хәсән ага белән. Мин инде, гадәттәгечә, башымны

неп сәламләп узып та китмәкче идем, әмма ул, килә-килешли үк нурланып-елмаеп, миңа якынайды да, күрешергә дип, кулын сузды.

— Без бит әле Сезнең белән рәтләп танышмаган да,— диде ул, җилкәмнән кочарга җыенгандай, җиңелчә генә кагылып.

— Әйе шул...— дидем мин, шактый ук югалып-каушап. Сүземнең, ничектер, бик үк урынлы яңгырамавын үзем дә абайлап алдым һәм тизрәк төзәтенү ягын чамаладым.— Ләкин, Хәсән ага, мин Сезне бик яхшы беләм...

Бу сүзләрем, чак кына мактануга охшасалар да, хак иделәр. Чыннан да, Хәсән Туфанны мин шактый үк яхшы белә идем. Һәрхәлдә шулай дип уйлый идем. Аның Галимҗан Ибраһимов шәкерте булуын да остазының яшь Хәсән Туфанга: «...Сез язуга кабилиятле, истигъдатлы күренәсез» дип, хәер-фатиха биреп, олы әдәбиятка озатуын да, озын-озак тормыш юлында яшьли үк күп төрле кыенлыклар күрүен дә, 13 яшендә инде заводта станокчы булып эшләвен дә, чак кына соңрак, нәкъ Максим Горький кебек, аркасына биштәр асып, Себер, Урал, Урта Азия, Кавказ якларына барып чыгуын, тормышның яхшысыннан да, яманыннан да күп төрле хәлләр кичерүе һәм ниһаять, 1924 нче елда Казанга килеп чыгуларын мин яхшы белә идем инде.

Казанга килгәч Һади Такташ, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Муса Җәлилләр белән кулга-кул тотынып, яңа әдәбият өчен көрәш башлый. Бүгенгечәрәк итеп әйтсәк, яшьләр арасында лидерга әверелә Туфан, яңа әдәбият яңа геройлар таләп итүен иң беренчеләрдән тоеп ала. Октябрьнең бөек идеаллары белән рухланып, азат кешенең рухи яңарышын чагылдырган әсәрләр иҗат итә. Аның лидерлыгы моның белән генә чикләнми, гаҗәеп күп төрле агымнар, мең төрле четерекле «изм»нар һәм формалистик каршылыклар белән буталган бер чорда «Яңалиф», «Атака» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәбият теориясенә, бигрәк тә яңа шигырь техникасына кагылышлы мәкаләләр белән чыгыш ясаулары да минем өчен сер түгел иде инде. Аның «Башлана башлады», «Урал эскизлары», «Ике чор арасында» кебек әсәрләрен укып тәмам исәрләнгән кеше идем. Мине, барыннан да элек, Урал кадәр Уралны ял итәргә яткан, әкиятләрдә генә сөйләнә торган баһадир итеп сурәтләве таңга калдырган иде. Төн дими, көн дими, торбаларыннан төтен-сөрем бөркеп яткан гигант заводларны, металлургия комбинатларын, мартен мичләрен, ике авыз сүз белән күз алдына килеп басарлык образ итеп тудырып кара әле! «Кыңгыр яткан Урал челем тарта, челем сабы — озын таш торба!..»

Соңрак Хәсән Туфан СССР язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында катнаша, анда М. Горький, А. Толстой, А. Новиков-Прибой, Лидия Сайфуллина, Ал. Безыменскийлар белән аралаша, алар белән фотоларга төшә. Тагын да соңрак: «Алексей Максимович — безнеке, без — аныкы идек» дип язып та чыгачак. Ә инде Маяковский Казанда булганда, ике шагыйрь якыннан танышалар, хәтта табындаш булалар...

Гомумән, минем өчен Хәсән Туфан, олуг шагыйрь булу белән бергә, бөек шәхес тә иде. Мин аны, зур тарихы, бай традицияләре булган әдәбиятыбызда, бары тик Галимҗан Ибраһимов белән генә янәшә куя идем: прозада — Галимҗан Ибраһимов, поэзиядә — Хәсән Туфан.

Хәсән Туфан белән дуслашуыбыз, Язучылар союзы коридорында шул беренче очрашуда ук башланып киткән икән диган фикер туа күрмәсен. Моның өчен шактый вакыт, аралашу һәм минем тарафтан тагын бер кыю адым ясау кирәк иде. Һәм ясадым мин ул адымны...

Иркенләбрәк сөйләшергә җай чыгу белән, сүзне үзем кузгаттым.

— Хәсән ага, сез үзегез дә белми торгансыздыр әле; мин бит Сезнең улыгыз...— дидем мин.

Ул да гадәттәгечә мөлаем генә елмаеп, шаяру катыш җавап кайтарды.

— Шулайрак шул: мин Хәсән, ә син — Хәсәнов.

— Хикмәт анда гына түгел, Хәсән ага. Сезнең хатыныгыз, ягъни мәрхүмә Луиза апа: «Улымдыр ла, уңганым-булганымдыр ла!» дип, һәркөнне диярлек дөпелдәтеп минем аркамнан сөя иде...

Шагыйрьнең йөзендәге тыйнак, ягымлы, әчкерсез саф елмаюын җил тузгыттымыни,— төс-кыяфәт кинәт җитдиләнде, чал суккан кашлары язылып китеп, көя төшкәнгә охшап йонлачланып калды.

Минем дә күңелем түрендә, бөтен тәнемне тетрәндереп, шагыйрьнең кәтеп ала алмаган сөекле хатыны Луиза Салигаскаровага багышланган «Тамчылар ни диләр?» шигыре гәүдәләнде.

Шунда мин Хәсән агага, 1944 нче елның җәендә, гастрольләр вакытында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистларының бөтен труппа белән бергә төшкән фотоны тоттырдым. Театрның 1944 нче елгы гастрольләре вакытында, Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салигаскарова, минем әнием булып уйнаган иде.

Шушы вакыйгадан соң Хәсән ага мине чыннан да улыдай якын күрә, үз итә башлады,

туры килгәндә хәтта, миңа җил-яңгыр, тел-теш тидертмәү турында да кайгыртыр иде. Вакыты белән борчылып кына да калмый, хәтта мине күздән яздырмау чараларын да күрә иде.

Яшерен-батырын түгел, Азнакайга барып төшкәч тә шактый ук авыр хис иттем үземне, хәтта төшенкелеккә бирелгән чакларым булды бугай. Тормыш бит ул. Түзә алмаслык булып эч пошкан вакытларда, ялт итеп Сибгат ага белән Хәсән Туфан килеп чыгарлар иде. Билгеле инде, кадерле кунаклар килгәч өй дә ямьләнә, күңелләр дә күтәрелә, тормыш та бәйрәм төсе ала.

Азнакай ягы, билгеле булганча, атаклы як, фидакарь хезмәтләре белән үзләрен данга күмгән батырлар төбәге. Илкүләм дан казанган нефтьчеләренең һәм авыл эшчәннәренең исемнәрен кемнәр генә белми икән! Азнакай яклары безнең әдипләргә, яңа әсәрләр иҗат итәргә илһам, дәрт бирә иде. Сибгат ага анда «Азнакай кырларына» дигән җыр иҗат итте. Ә Хәсән Туфан тулы бер шигырьләр циклы язды. Мин дә читтә калмадым, әлбәттә.

...Белмим, кем ничектер, әмма мин Туфан шигырьләрен япа-ялгыз калганда, кычкырып укырга яратам.

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына,
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Туфан поэзиясен күбрәк укыган, якыннанрак танышкан саен, нәкъ кыйммәтле асылташ кебек, моңарчы күрелмәгән төс-бизәкләр уйный, яңа яклары белән ачыла башлый, шигырь мәгънәсе хисләрнең нечкәлеге, ихласлыгы исәбенә тирәнәя, тәэсир итү көче тагын да зурая кебек. Шунда үзеңне ниндидер биек тау башына күтәрелгән сыман, ниндидер могҗизалы манзарага карап сокланып торгандай хис итә башлыйсың. Берүк вакытта, үзеңне, ничектер, олыгая, җитдиләнә, рухи яктан сафлануыңны, баюыңны тоясың.

Еш кына мин: шушындый эмоциональ киеренкелеккә нинди юллар, нинди алымнар белән ирешә әдип? Сине катлаулы кичерешләр дөньясына алып кереп, берсүзсез буйсындыра, җәлеп итә алу көче нидә? Нишләп шул кадәр дулкынландыра, җанны кузгата, күңелне әрнетә, акылны тыңгысызлый бу юллар? Җитмәсә тагын, һәрбер сүзе, строфасы чиксез ышандыра. Моның сере нәрсәдә?..— дип уйланам.

Менә тагын бер мисал:

Якташларым — аппак
кыналарым,—
Ак каеннар тора
каршымда!..

Болай итеп, бәлки, башка шагыйрь дә әйтә алган булыр иде. Әмма мине монда «якташларым» дигән сүз әсир итә. Татар халкында: «Чит-ят җирдә туган якның эте дә якын була», дигән мәкаль бар. Димәк, «якташларым — аппак кыналарым» дип әйтү өчен әдипкә хокук булуы да кирәк икән әле.

Шул бер авыз сүзне бергә җыеп укыгач, никадәрле хис һәм фикер тәңгәллегенә тап буласың, нәфислек, сылулык һәм затлылыкны күреп, образның хисси байлыгын тоемлап кабат хәйранга каласың.

Мин Хәсән Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы» дигән шигырен илаһи әсәрләр рәтенә кертер идем. Шул шигырьдә тормыш юлдашы, сөекле хатыны Луиза Салигаскаровага багышланган юллар бар.

— Кайт! — дип хатлар килделәр...
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы — алкалары,
Бусы — кабере...— диделәр...

Укуымны дәвам итә алмыйм. Чәчләрем селкенеп, аркамны чиратып салкын йөгерә. Күзләр дымлана. Нинди хикмәттер, берүк вакытта, күңел түрендә, ниндидер, якты хисләр дә уяна, үзеңне бик, бик бәхетле кеше итеп сизә башлыйсың. Мондый юллар, мондый сүзләр җаннан кичермичә генә тумыйлардыр. Бары тик кан саркып торган җәрәхәтле йөрәк аша гына тамып төшә торгандыр мондый җанга мәңгегә уелып калырдай сүзләр. Нишләмәк кирәк, дөнья ифрат катлаулы, тормыш юлы сикәлтәле. Бу шигырьдә

сүзләр генә түгел, тыныш билгеләре дә ниндидер хикмәтле тәэсир итү көченә ияләрдер кебек. Хәсән Туфанның шушындыйрак шигырьләрен укыгач, шигърияtнең нинди бөек көчкә ия булуына, әдәбият-сәнгатьнең, чын поэзиянең, чыннан да, язмышлар фәне, хакыйкать һәм вөҗдан дәреслеге икәнлегенә кабат һәм кабат төшенгәндәй буласың.

...Хәсән Туфанда мине тагын бер нәрсә гаҗәпләндерә, сокландыра, таңга калдыра иде: бу аның иҗатта картая белмәве, яшьләргә тиң ялкын белән, чакматаш сыман шигърият очкыннары чәчрәтеп иҗат итүе.

Шунда тагын бер хакыйкатькә төшендем: ил, халык язмышы белән аерылгысыз тыгыз элемтәдә яшәгән олуг шагыйрьнең таланты, бик тирәннән тибеп чыккан чишмә кебек коруны да, корыгаксынуны да белми икән. Олы талант, юмарт талант тынгы белми дип, шуңа әйтә торганнардыр инде.

«Туфан искиткеч намуслы, иманлы, кешелекле шагыйрьләрнең берсе иде». Бу — Сибгат Хәким сүзләре. Әлеге күркәм сыйфатларга мин тагын шагыйрьнең дәрәҗә, дан-шөһрәт, титул, төрле исемнәр, карьера ише яман күренешләрне бар дип тә белмәвен өстәр идем. Андый сыйфатлар Хәсән ага өчен бөтенләй ят нәрсәләр иде. Аның өчен бары тик изгегә санаган, фанатикларча бирелгән иҗаты бар иде дә, үз халкыннан аерылгысыз язмышы бар иде.

Шул уңай белән Мостай Кәримнең дүрт кенә юллык бер шигыре искә төшә.

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә аңа титул?
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул...

Дусларча шаярып, ярым шуклык белән әйтелгән бу сүзләрдә тирән мәгънә, зур хаклык бар.

Тик нишләмәк кирәк, һәрнәрсәнең ахыры бар. Гомер дә нинди генә озын- озак булмасын, азагы бер... Элек-электән халык үзенең олуг әдибе үлүен кояш баю белән чагыштыра торган булган. Хәсән Туфанның арабыздан китүе дә шулайрак тәэсир итте: әдәбиятыбыз кинәт кенә бер башка түбәнәеп калган сыман булды.

Мин дә үземне, сыңар канаты сынган коштай, иң якын кешесен югалтып, яртылаш ятим калгандай хис иттем. Берни белән дә чагыштыргысыз авыр югалту булды ул.

Туфанны юксыну галәмәтедер инде, теләсәм-теләмәсәм дә, күңелем түрендә аның шундый ук олуг, тетрәндергеч югалтуга багышланган шигъри юллары тернәкләнә:

Китте дусым — иң дусым,
Күңеле шундый киң дусым;
Халык өчен утка кергән
Изгеләргә тиң дусым...

Әйе, китәләр...

Әмма үлем генә аларны халкы күңеленнән сызып ташлый алмый, кешелекнең хыял-омтылышларын чагылдырган әсәрләре туган халкының күңелендә мәңге яшәячәк. Әйе, олы художниклар үлмиләр, үзләренең үлүне белмәс әсәрләре белән яшәр өчен кабат туалар. Күп еллар үтәр, буыннар алышыныр, әмма вакыт бөек, чын иҗатның идея һәм художество кыйммәтен киметә алмас. Шул уңай белән Салтыков-Щедрин сүзләрен китерү урынлы булыр кебек: «Литература изъята из законов тления, она одна не признает смерти».

Бөек Тукаебыз: «Вакыт килер, һәр язучыны энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле»,— дигән иде. Күп милләтле совет поэзиясенең аерылгысыз хәзинәсенә әверелгән бай, күпкырлы мирас биргән олуг шагыйребез Хәсән Туфан турында да, республикабыз чикләрен үтеп кенә калмыйча, әле бөтен дөнья халкына җиткерерлек хезмәт чыгарырга шәт вакыттыр. Дөрес, Туфан турында хәзер дә аз язылмый диюләре мөмкин. Әмма мин төрле монографияләр, фәнни хезмәтләр белән берррәттән, «Атаклы кешеләр тормышы» (ЖЗЛ) сериясе белән дә китап чыгару турында сүз алып барам. Андый китапның язылачагына тирәнтен ышанам. Моңа иманым камил. Язылмавы мөмкин түгел. Чөнки моны әдәбиятыбызның гүзәл бизәге булган олуг шагыйребезнең иҗади эшчәнлеге дә, тормыш дип аталган мәшһүр драматург тарафыннан «иҗат ителгән», теләсә кемне тетрәндерерлек гыйбрәтле гомер юлы да, шагыйрьһәрне чын шагыйрь иткән хикмәтле, могҗизалы биографиясе дә таләп итә.

Шул уңай белән күңелдә туган тагын бер теләкне дә әйтеп үтәсе килә: күп миллэтле совет әдәбиятында үзенә генә хас аһәң белән көчле яңгыраш тапкан, халкыбызның бөек улы Хәсән Туфан турындагы китапны язу да, шагыйрь үзе әйтмешли, «җылы куллы», олы җанлы, ихтирамлы һәм саф күңелле кешегә эләгә күрсен иде, берүк...

**Фәрит Хатипов**

# ҮТКӘННӘР АША — КИЛӘЧӘККӘ

Нурихан Фәттах — бар сәләтен, белемен, рухи көчен әдәбиятка багышлаган талантлы язучыларыбызның берсе. Бирелеп, онытылып иҗат итүдән, даими һәм киеренке уй хезмәтеннән ул чын ләззәт таба, тормышын мәгънәле, эчтәлекле итеп тоя. Язучы әдәби әсәрнең ил тормышында никадәр җитди, хөрмәтле урын биләвен тирән аңлый. Шунлыктан китап язуга, аның сыйфатына үтә җаваплы, таләпчән карый, аны халык эше, намус эше дип саный. Иҗатында ул чынбарлыкның мөһим якларына туктала, яшәешнең, кеше күңеленең яңа катламнарын ачып күрсәтә, тормышны, кешеләрне чын итеп, җанлы итеп гәүдәләндерә, әсәрләрен сәнгать камиллеге дәрәҗәсенә җиткереп эшкәртә. Үзенчәлекле иҗаты, фикерле, мавыктыргыч әсәрләре белән Н. Фәттах укучының җылы карашын яулап алды.

Нурихан Фәттах өченче класста укыган чагында ук беренче шигырен яза, ә азрак үсә төшкәч, бер русча пьеса тәрҗемә итә, стена газетасына рәсемнәр ясый. Аның «Ленин яши!» дигән беренче шигыре 1944 елда «Октябрь юлы» исемле район газетасында, ике шигыре «Совет әдәбияты» журналында басылып чыга. Алар берничә тапкыр мәктәп дәреслекләрендә дә күренәләр.

1946 елда, Яңавыл урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, түгәрәкләргә йөри, яшереп кенә хикәяләр яза. 1948 елда беренче хикәясе «Безнең хикәяләр» җыентыгында да дөнья күрә. Н. Фәттах, университет укытучысы Л. Җәләй киңәшен тотып, халык теле, иҗаты, мифологиясе белән кызыксына, авылга кайткан саен җырлар, бәетләр, мәкаль-әйтемнәр язып килә, сөйләм үзенчәлекләрен, канатлы сүзләрне, фразаларны дәфтәренә теркәп бара. Бәетләре ике мәртәбә җыентыкларга да керә. «Халкымның телен, гореф-гадәтләрен аңлауда, үзләштерүдә моның файдасы әйтеп бетергесез зур булды»,— дип язды соңрак әдип (Фәттах Н. Үзем генә түгел.— Азат хатын, 1984, 7 сан).

Уку елларында Н. Фәттах күп яза, язганнары бөтенләй диярлек басылмый. Ул һаман өйрәнә, каләмен чарлый, тәнкыйть фикерләренә колак сала, әсәрләрен кат-кат төзәтеп яза.

Укуын тәмамлагач, Н. Фәттах Татарстан китап нәшриятының яшьләр, балалар әдәбияты редакциясе редакторы итеп билгеләнә, 1952—53 елларда Чистай газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшләп ала. Илленче еллар башында ул рус язучыларының хикәя, повестьларын, В. Гюгоның «Хокуксызлар» романын тәрҗемә итә. Әнә шундый әзерлек баскычын, иҗат мәктәбен үтеп, ул зур күләмле беренче җитди әсәрен — «Сезнеңчә ничек?» (1954) романын яза. Бу вакытта аңа егерме алты яшь була. Әсәр 1956 елда «Совет әдәбияты»ның 1, 2, 4, 5, 6 саннарында, 1957 елда Татарстан китап нәшриятында басыла. Мәскәүнең «Яшь гвардия» нәшрияты 1961 елда аны рус телендә чыгарды.

Бу роман, чордашлары Г. Ахунов, Э. Касыймов, М. Мәһдиев, М. Юныс повестьлары кебек үк, авторга аеруча таныш, якын булган студентлар тор-

мышын яктырта, университет укучылары Сәгыйть белән Ида образларын, хискичерешләрен, бер-берсенә мөнәсәбәтен сурәтли. Ләкин шулай да, әсәрнең колачын студентлар тормышы белән генә чикләү бик үк дөрес тә булып бетмәс кебек күренә. Биредә төп вакыйгалар җәйге каникул вакытында авыл җирендә бара, геройларның хезмәткә, авыл халкына мөнәсәбәте күрсәтелә, бу мөнәсәбәтнең ниндилегенә карап, персонажларның әхлак йөзе, кешелек дәрәҗәсе бәяләнә.

Автор аеруча хезмәтнең фәлсәфи-поэтик мәгънәсен, рухи нәтиҗәсен тойдыруга зур игътибар бирә, колхоздагы болын, кыр эшләренең ямен, ләззәтен сиздерергә тырыша, хезмәт темасын тәүге романының үзәгенә куя, әхлак мәсьәләләрен хезмәткә бәйләп аңлата. Героеның кичерешләрен ул болай тасвирлый: «Сәгыйть, чалгы сабыннан кысып тотты да, беләкләренә, бөтен тәненә тынгысыз рәхәтлек, көч-куәт йөгергәнен тоеп, бер селтәнеп җибәрде». Аңа әнә шулай печән чабудан да күңеллерәк, мавыктыргычрак бүтән берни юктыр шикелле, бөтен болынны берүзе чабып чыга алыр иде кебек тоела, бу вакытта ул тансык эш рәхәтеннән башка берни сизми. Дөрес, бу әле тик эшкә тотынган мәлдәге халәт кенә. Соңга таба аның бүтәнчә төсмерләре дә сизелә: «Баштарак беләкләре, аяк балтырлары, күкрәкләре сызлады, эштән туктагач та мускуллары кайнарланып сулкылдарга тотынды. Кичләрен, арып-алҗып кайткач, авырайган, авыртынган тәнен кузгатасы да килмәде». Кыскасы, Н. Фәттах печән эшен һич тә алай кызыклы уен, күңел ачу чарасы итеп кенә сурәтләми. Хезмәт ул, язучы аңлавынча, тынгысыз көрәш, каршылыкларны, киенлыкларны җиңү, конфликтны хәл итү, ягъни үзеңне пассив торгынлык хәленнән актив хәрәкәткә күчерү. Әсәрдән күренүенчә, кешегә эштән ныграк читләшкән саен гади генә гамәл дә хәл итеп булмастай проблемага әйләнә бара. Ида, мәсәлән, сәләте, тәҗрибәсе бар көйгә, агитбригадага катнашу тәкъдимен дә кабул итә алмый. Бу юлда ул үтеп чыга алмастай әллә никадәр каршылыклар күрә. Әллә нигә бер печән өмәсенә чыккан Әхнәф тә: «Онытылган парин. Арыта. Беләкләрне күтәрерлек тә түгел», дип зарланып йөри, авылдашлары күрмәгәндә куак арасына шылып карлыган чүпләү ягын карый. Әсәрдә бу халәт бик табигый күрсәтелгән. Әгәр дә җан иясе һәрдаим көчен тукмәсә, кызганса, әрәмгә китә дип фараз кылса, ул энергия тәндә һич тә сакланмый, киресенчә, акрынлап сыза бара, кеше зәгыйфьләнә, чирләшкәгә әйләнә. Мондый хәл, шулай итеп, беренче нәүбәттә кешенең үзенә зыян китерә. Сәгыйть үзе дә Идага җибәргән хатында: «Физик хезмәт күңеле, нервысы тыныч түгел кешегә, бигрәк тә безнең кебек интеллигентларга, безнең кебек студентларга бик әйбәт дару икән. Физик хезмәт ул мускулларны гына түгел, күңелне дә чыныктыра икән»,— дип яза.

Әсәрдә Ида образы аркылы да шактый җитди концепция раслана. Гаилә дә, мәктәп тә аны бары тик укырга гына өйрәткән. Шуңа күрә аңа «бөтен тормышның максаты бары тик уку гынадыр шикелле булып тоелды. Ә ни өчен уку, кем булу өчен уку, кемгә файда китерү өчен уку? Ул болар турында бөтенләй уйламады». Университетта политэкономиядән имтихан биргән чакта ул: «Бездә физик хезмәт белән акыл хезмәте арасында аерма көннән-көн бетә бара. Бездә хезмәт кешенең иң беренче таләбенә әйләнде...» — дип сөйли. Әмма үз гамәле сүзеннән бик нык аерыла. Тормышның тик ямьле йөзен генә, җиңел, рәхәт ягын гына күреп үскән, игенче шөгылен кулына тотып карамаган кыз эшне дә, авылын да үз итә алмый. Хезмәтнең кирәклеген, әһәмиятен теоретик белү никадәр генә файдалы булмасын, ул әле үзең тотып карау түгел, пассив, абстракт төшенчә генә булып кала бирә. Эшне авырсынмыйча, җиңел, дәртләнеп башкару сәләте, аннан ләззәт, тәм табу тойгысы бары тик эшнең үзендә генә тәрбияләнә, аның авырлыкларын, рәхәтлекләрен баштан үткәрү нәтиҗәсендә генә туа, дигән фикер үткәрелә әсәрдә.

«Сезнеңчә ничек?» — Н. Фәттахның беренче романы булса да, аның ышанычлы кул белән язылганлыгы күренә. Монда ясалма бизәкләр, сәнгатьчә төгәлсезлекләр, характерлар логикасына хилафлык очрамый диярлек. Автор тасвирлары, персонажлар сөйләме геройның халәтен, холык-фигылен төгәл, образлы итеп күз алдына китереп бастыралар. Шуның белән бергә тәнкыйть персонажлар телендә диалектизмнарның мулрак куллануын да искәртеп үтте.

«Сезнеңчә ничек?» романы илленче еллар прозасы өчен көтелмәгән бер ачыш булды. Ул әдәбиятка үзенчәлекле яңа талант килүен хәбәр итте.

Язучы ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп, туктап калмый, эзләнә, осталык серләрен ачарга тырыша. Ул зур әдипләрнең иҗат казанышларын өйрәнә. Аеруча Л. Толстой стиленең нечкәлекләренә төшенергә тели, аның барлык әсәрләрен дикъкать белән укып чыга. Язучыны бигрәк тә Л. Толстой стилендәге салмак хәрәкәт, эчке киеренкелек кызыксындыра. Н. Фәттах О. Бальзак хикәяләрен тәрҗемә итеп бастыра.

Моннан утыз бер ел элек, 1954 елда, илебездәге бик зур иҗтимагый хәрәкәт — чирәм җирләрне күтәрү башланды. Тыныч хезмәттәге тиңе булмаган бу фидакарь көрәш нәтиҗәсендә дәүләтебезнең чәчүлек мәйданына кырык ике миллион гектар уңдырышлы җир өстәлде.

Н. Фәттах Казахстан чирәмен үз куллары белән күтәрешә. 1955 елда ул үз инициативасы белән Павлодар өлкәсенә китә һәм «Казан» совхозы оештырылуның беренче елында Татарстан яшьләре белән бергә брезент палаткаларда, такта вагоннарда тора, җәй буена плугарь булып эшли. Казанга кайткач, чирәм күтәрүчеләр турындагы романының беренче вариантын язып карый. Әмма ул авторны канәгатьләндереп җиткерми. Икенче елны ул кабат далага юл тота. Ләкин бу юлы инде үзе генә түгел, ә Казан университеты студентлары белән бригада члены булып бара, шулар белән бергә җәйгекөзге кыр эшләрендә эшли. Шулай итеп, ул «Сезнеңчә ничек?» романында акыл хезмәте кешеләре алдына куйган программаны практик рәвештә тормышка ашыра, даланы үзләштерүчеләр белән үзен рухи бердәм итеп сизә, аларның йөрәген, хис-омтылышларын тирәнтен тоя. Иҗатчы һәм игенче бердәмлеге соңыннан аның романына көчә, әдәби әсәрендә тулы гәүдәләнә. «Совет әдәбияты»ның 1956 елгы 11 санында ул башта очерк язып чыга. 1962 елда «Бала күңеле далада» исемле романын тәгәлли. Әсәр, димәк, алты-җиде ел эчендә языла. 1964 елның 10—12 саннарында ул «Совет әдәбияты» журналында,1966, 1978 елларда Татарстан китап нәшриятында басылып чыга.

Әсәрнең үзәгенә гади хезмәт кешесе, материаль байлыкларны үз кулы белән җитештерүче образы куелган. Шулай итеп, гәрчә романның темасы яңа булса да, хезмәт фидакарьлеген сурәтләү җәһәтеннән ул «Матур туганда», «Намус», «Йолдызым», «Авылдашым Нәби»ләр традициясен дәвам иттерә иде.

Яшьләр далага ил дәшүе буенча, романтик дәрт белән килде. Иптәшләренә, дус-ишләренә ияреп кузгалучылар да бар. Ислам исә олы патриотик хәрәкәткә кыңгыр эшен яшерү, эзен себерү нияте беләнрәк килеп кушыла. Авыр язмышлы, усал холыклы, вөҗдан контроленнән арынган хәйләкәр кеше буларак, ул бригадада байтак конфликтларның килеп чыгуына, күпләрнең газаплы кичерешләренә сәбәпче була: хезмәт тәртибен тарката, эшкә комачаулый, шул ук вакытта алдынгылар рәтендә йөрергә, актив булып күренергә тырыша, хәтта бригадир булырга хыяллана. Ул хатынын, баласын ташлап китә, монда Мәрьямне, Фәридәне алдый, Фәридәнең акчасын, киемнәрен, бригаданың мотоциклын урлап качарга җыенганда аны Һарун тотып милициягә тапшыра.

Баш герой Һарун әнә шул Ислам фонында, аңа мөнәсәбәттә, аның белән бәрелешләр вакытында, хезмәттә ачыла. Һарун — тыйнак, басынкы, шул ук вакытта гаҗәп эшлекле, чыдам, төпле егет. Автор аның монда килеп чыгуын бик гади итеп, тормыш җаена нигезләнеп аңлата. Сөйгән кызы — чуар күңелле Хәлимә Һаруннар өенә килен булып төшәргә теләми: «Мин сезнең өйне беләм, балчык белән сыланган, салам белән терәгән, көчәнеп бер эттең исә, шундук җимерелергә тора, анда ничек торырбыз»,— диде. Далага Һарун тырышып эшләү, йортлык акча эзерләү, өйләнү максаты белән килә. Ул чын игенче булуның нәрсә икәнен хәләл көче белән күрсәтә.

Сабанга төшәсе көнне ул аерым бер күтәренкелек белән каршы ала. Караңгылы-яктылыда уяна, тирә-юньдә берәүне дә күрмәгәч, «мине уятмый китеп барганнар», дигән хәвефле уйга төшә. Чынында исә әле берәүнең дә кузгалмаганын күреп, иптәшләрен дәртләнеп уятырга тотына, таң атканда йоклап яталармыни? — дип гаҗәпләнә. Ул иң беренче булып тракторын кабыза, алмашчысы өйдә булмау сәбәпле, тоташ өч смена сөрә. Автор биредә физик нык, чыдам булуның әһәмиятен басым ясап күрсәтә. Буыны йомшаграк Белугин кебекләр бер сменага да түзмиләр, йоклап китәләр, ә Һарун кирәк чакта үзендә көн-төн йокламыйча да эшләрлек көч таба.

«Бала күңеле далада» — асылда производство романы. Чөнки геройлар-

ның рухи-әхлакый сыйфатлары башлыча хезмәт процессында ачыла. Ләкин, шулай да, аны производство романы дип әйтергә берәүнең дә башына килми. Чөнки монда схематизм юк. Каһарманнар җанлы итеп, тормышчан сурәтләнгән. Автор һәрбер эш-гамәлнең рухи ягын яктыртып бара, үзара мөнәсәбәтләрне психологик нигезли, аларның эчке пружинасын күрсәтә, күңел каршылыкларын, уй-хисләр агышындагы борылышларны җентекләп тасвирлый, эчке дөньяны катлаулы итеп, күп бизәкләре белән чагылдыра. Автор тасвирлаганча, бер үк вакыйгалар төрле кешедә, холык-фигыленә карап, капма-каршы реакция кузгата, кайчак бер ситуациянең психологик нәтиҗәсе бөтенләй икенче күренештә килеп чыга.

Н. Фәттах табигатьне кеше хәленә бик сизгер итеп, кайгы-шатлыкларын уртаклашучы итеп гәүдәләндерә. Әсәрдәге бер героиня искәрмәстән даладагы ташландык коега килеп төшкәч, автор болай яза: «Өстә, югарыда иректә җил исеп китте. Кара болытлар арасыннан кызганыч, бик кызганыч итеп, энҗедәй күз яшьләрен түгеп, йолдызлар җемелдәште». Коедан чыга алмый азапланган кеше барыннан да бигрәк җилнең иректә булуына кызыга. Сурәтләү чаралары персонажларның рухи халәтенә туры китереп сайлана.

Романда гәүдәләнгән Һарун, Андронов, Мансур, Барый кебекләр — алар ихлас булсынга йөрүчеләр, нык буынлы, ышанычлы, төпле кешеләр. Мөһим социаль-экономик бурычларны хәл иткәндә ил әнә шундыйларга таяна. Автор биредә фидакарь хезмәт романтикасын чагылдыра, аның поэзиясен тойдыра, хезмәт — намус эше, шунда кешенең гражданлык активлыгы күренә, дигән караш уздыра.

1965 елда Н. Фәттах «Артта калган юллар» хикәясен бастырды. Автор биредә сугыш чорының кырыс чынбарлыгын, Хәмдиянең драматик язмышын, киеренке кичерешләрен тасвирлый, колхозчы хатын-кызларның сагыш-моңнарын, күңелләренең киңлеген, чыдам, күндәм, ярдәмчел булганлыкларын күрсәтә, кешегә игътибарсызлык, хәленә керә белмәү очракларын тәнкыйтьли. Әсәр турында матбугатта төрле фикер әйтелде. Кайберәүләр яктырак төсләр өстәргә иде, дигән теләк белдерделәр. Әмма хикәянең гуманистик рухы инкарь ителмәде.

Алтмышынчы еллар башында Н. Фәттах кабат интеллигенция һәм авыл халкы мәсьәләсенә әйләнеп кайта, бу юлы инде ул белгечнең конкрет хезмәтен, игенчеләргә практик ярдәмен сурәтли, хис-кичерешләрен яктырта. «Мөдир Саҗидә» повестен Н. Фәттах 1962 елда язып бетерә.

Баш герой Саҗидә авылга, техникум бетереп, фельдшер булып килә. Ләкин күңеле белән ул моны вакытлы хәл дип карый, җай чыгу белән институтка китәргә хыяллана, бәхетне тик югары белем алуда гына күрә. Ул хәтта тирән мәгълүматлылык кешенең тышкы кыяфәтен дә үзгәртә, матур итә дип фараз кыла һәм, тормышта үзгәрәк мисалларын очраткач, гаҗәпкә кала: «Исең китәр, институт бетергән кеше дә шундый ямьсез булыр икән!» — ди.

Баштагы мәлдә ул үзен һавалы тота, кешеләргә өстенрәк карый, алар белән аралашмый. Югары белем алмыйча ул клубка да чыкмаска, егетләр белән дә йөрмәскә сүз бирә. Авылда калуны ул әрәм булу дип саный.

Шул ук вакытта Саҗидәнең тырыш гаиләдә үскәнлеге сизелә.

Мөстәкыйль эшкә билгеләнү анда горурлык хисе уята, аның тизрәк үзен хезмәт урынында күрәсе килә, авырулар белән ягымлы сөйләшә, вазифасын күңел биреп, төгәл башкара. Аңа күренергә күрше районнан да килә башлыйлар. Менә бу деталь, кешеләрнең ышанычын казану күрсәткече, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ында да, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ендә дә очрый. Моның белән авторлар, күрәсең, табибка сәламәтлекне, тормышны ышанып тапшыруның ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген раслыйлар.

Күңелендә бөреләнгән мәхәббәт хисе дә Саҗидәнең карашларына билгеле бер эз салып уза. Авылда ул Тимерҗан дигән егетне ярата башлый.

Тора-бара Саҗидә авылга, игенчеләргә үз итеп, ихлас хөрмәт белән карый башлый. Ул үз эшенең әһәмиятле, кешеләргә кирәкле булуын тоя. Әсәр, шулай итеп, яшь белгеч күңелендә туган борылышны чагылдыра, шул үзгәреш җирлегендә конфликтның уңай хәл ителүен сурәтли, моның рухи-иҗтимагый әһәмиятен күрсәтә.

СССР Язучылар союзы идарәсенең 1984 елда булган юбилей Пленумында укучыларны тарих мисалында тәрбияләү мәсьәләсенә махсус тукталынды һәм үткәннәр турында җитди итеп, чама хисен төгәл тоеп, марксистик-ленинчыл караш позициясеннән торып яза белүнең әһәмияте басым ясап күрсәтелде. Н. Фәттах тарих белән бик җитди сөйләшүче әдипләрдән санала.

1957 елда ул археология экспедициясенә бара, Болгар харәбәләрен казуда катнаша, балчык, туфрак катламнары арасыннан килеп чыккан болгар әйберләрен: чүлмәк ватыкларын, кирпечләрен, чуен, бакыр, тимер калдыкларын үз куллары белән тотып карый. Ул әнә шулай яшәешебезнең тирәндәге катламнары белән кызыксынып китә, борынгы бабаларыбыз тарихын, экономикасын, этнографиясен, культурасын, күршеләребез тарихын өйрәнергә тотына. Аңа бигрәк тә беренче чыганаклар — үткән заманның үз кешеләре язып калдырган чын фактлар, чын вакыйгалар, Ибне Фадлан язмалары, «Кабуснамә», Усама ибне Мункызның «Үгет-нәсихәт китабы», «Испания сагалары» нык тәэсир итә. Фән казанышлары белән тирәнтен таныша. Тора-бара анда тарихи күренешләр турында мөстәкыйль фикер, тәнкыйть карашлары туа. Ул үзе дә Болгар дәүләте, экономикасы, һөнәрчелеге, мәдәнияте хакында тирән эчтәлекле хезмәтләр язып чыга. Тарихны шул рәвешчә фәнни үзләштергәннән соң ул аны сәнгатьчә чагылдыру шөгыленә керешә: аны сюжетка сала, аерым кешеләрнең эш-гамәлләренә, хис-кичерешләренә, мөнәсәбәтләренә күчерә, хәрәкәт мәйданын билгеле бер ситуация белән әйләндереп алып, укучыларны гаҗәеп серле, мавыктыргыч дөньяга ияртеп кереп китә. Әдип иҗатында яңа бер бүлек ачыла.

«Әтил суы ака торур» романында вакыйга моннан бер мең дә алтмыш ел элек, 920 еллар тирәсендә, ягъни Болгарда рәсми рәвештә мөселман дине кабул ителгән чорда бара. Автор борынгы бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен, шөгыл-кәсепләрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен, сәнгать, мәдәниятен, яу күренешләрен, халыклар арасындагы мөнәсәбәт-бәйләнешләрне җанлы итеп сурәтли. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы», Ф. Бурнашның «Дала давы», М. Җәлилнең «Алтынчәч», М. Ауэзовның «Абай» әсәрләрендәге кебек үк, монда да таркау кабиләләр көрәше, ыру тартышлары-интригалары хәтсез урын ала. Шуңа күрә әсәрдә, гомумән тарихи романнардагыча коллар, «каралар» — игенчеләр, көтүчеләр, балыкчылар, сакчылар, сугышчылар, сәүдәгәрләр, табиплар, чәчәннәр, дин, йола хезмәтчеләре һәм башка социаль катлам вәкилләре, һөнәр ияләре белән беррәттән, шушы ыруларның башлыклары да шактый тулы гәүдәләнә. Автор аларның эш-гамәлләрен, уй-тойгыларын конкрет тасвирлый. Иң элек ул әлеге даими талаш шартларында персонажлар күңелен күп төрле борчылулы уйлар биләп алганлыгын күрсәтә. Пошыну-хафаланулардан хан да, биләр дә азат түгел. Ырулар ызгышы, сарай интригалары, сәүдәнең тоткарлану ихтималы, авыру-сырхау хәлләре геройлар күңеленә хәвефле уйлар сала. Власть ияләренең рухи дөньясында дәүләтнең хәзерге һәм киләчәк хәле, оборонаны ныгыту, яу чыгу, сату итү, байлык туплау, дингә, йолага мөнәсәбәт, ыру һәм туганлык бәйләнешләре турындагы уйлар зур урын ала.

Илнең экономикасын ныгытуда, халыклар арасында ышаныч, татулык урнаштыруда автор аеруча сату-алу бәйләнешләренең, нормаль сәүдәнең бәрәкәтле уңай йогынтысын басым ясап күрсәтә. Болгар йорты рус, иран, таҗик, гарәп, әрмән, хазар, яһүд, рим сатучылары белән алыш-биреш итә. Әдип князь Родославның туганы Святославка зур күләмдә иген сату күренешенә аерым туктала. Бу сәүдә, автор сурәтләвенчә, ике якка да зур файда китерә, мөшкел хәлдән чыгарга ярдәм итә. Әсәрдә сату-алу бәйләнешләре мәгълүм дәрәҗәдә талау сугышларына каршы куела.Бу хактагы фикерләр романда Күрән би, Алмыш хан уйлары аркылы үткәреп бирелгәләр.

Әсәрдә сурәтләнгән Алмыш хан — тарихи шәхес. Документларда аның ким дигәндә 913—922 еллар арасында Болгарда ханлык иткәнлеге күренә. Автор аны, деспотка хас булганча, кансыз-миһербансыз монарх итеп сурәтли. Ул — туры сүзле чәчәннең телен кистерүче, ыруларны туздыручы, буйсындыручы, талаучы, ясак түләтүче. «Аның еракка төбәлгән ач күзләренә Чулман буе гына түгел, хазары-ние белән, бөтен Әтил буе, далалар күренә башлады»,— ди аның турында автор. Болар һәммәсе дә ханның сыйнфый табигатеннән килә. Әсәрдә социаль тигезсезлекне яктыртуга, халык ихтыярының көч белән бастырылып торуын тасвирлауга, власть ияләренең социаль йөзен күрсәтүгә, кыскасы, иҗтимагый каршылыкларны чагылдыруга җитди игътибар бирелә.

Романдагы барлык бәрелешләрнең үзәгеннән баш герой Тотыш үтә, үз нәүбәтендә, бөтен вакыйгалар, каршылыклы хәлләр, кискен конфликтлар да шушы егет йөрәге аркылы узалар. Тотыш — нечкә хисле, тирән кичерешле, тиз кабынып китүчән, билгесез омтылыш белән яшәүче, алдынартын уйламыйча карар кабул итүче, гайрәтле, баш бирмәс углан. Аның бөеклеге дә, газаплары да бер үк чыганактан — кайнар, ярсу йөрәгеннән килә. Язмышындагы кискен борылышлар белән ул күпмедер дәрәҗәдә Иосыф һәм башка борынгы поэмалардагы геройлар юлын да хәтерләтә, батырлыгы белән «Алтынчәч»тәге каһарманнарны да искә төшерә, холык-фигыле белән Ф. Хәсни геройларына беркадәр тартымлык сизелә. Ләкин шулай да безнең прозада Тотыш кебек типларны сурәтләүнең традициясе әллә ни зур түгел. Бәлки шуңа күрәдер, автор вакыт-вакыт халык авыз иҗаты, экият, дастаннар стиленә дә мөрәҗәгать итеп ала. Бу бигрәк тә Алмыш хан алыплары белән көрәш картинасында ачык күренә. Тотыш, үз ыруын яклап, Алмыш ханның иң гайрәтле өч алыбына каршы чыга. Шуларның беренчесен, Чәкән баһадирны, автор болай тасвирлый: «Чәкән алпагыт богадай таза, арыслandaй көчле иде. Баштанаяк ул тимергә төренгән, шуңа күрә аның сөңге, кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юктыр кебек иде. Үзенең таза, көр кола атында ул таштан уеп ясалган баганадай нык утыра иде. Күп орышларда бите-башы яраланып, ямьсезләнеп беткән бу усал, кансыз, коточкыч алпагыт турында: кылыч белән бер сукса, тимер киемле кешене урталай ярып төшерә дип сөйлиләр иде. Аның белән орышкан бер генә батырның да әле исән калганы юк, дигән сүзләр дә йөри иде».

Шул ук вакытта әдип, экият-дастаннарның поэтик арсеналы чикләрендә генә дә калмый. Ул, борынгы хәятны сурәтләгәндә, фольклорча фикерләү белән хәзерге язма әдәбият казанышларын бергә куша. Шуларның берсе — күңел серләрен яктырту. Язучы әлеге киеренке бәрелешне тасвирлаганда да тышкы хәрәкәтләрне күрсәтү белән генә чикләнми. Ул, орыш хакында хикәяләүне туктатып торып, Тотышның уй-хисләре дөньясына кереп китә, физик көрәш белән янәшә барган рухи процессны — Тотышның ни-нәрсәләрне искә төшерүен, хәйлә-планнарын, әнисе фатихасының, киңәшләренең кабат колагында яңгырап китүен, ягъни экиятләрдә очрамый торган идеаль хәрәкәтне яктыртып ала.

Тотыш өченче батырдан җиңелә. Ул яшәү белән үлем арасында кала. Аның хәлен автор кешеләрнең шул чордагы аң дәрәҗәсенә туры китереп хикәяли: «Бишенче көнне аның күзгә күренмәс күбәләк булып якында гына очып йөргән коты кире авызына керде».

Әсәрдән күренгәнчә, Алмыш хан Тотыш алыпны бик югары бәяли, Күрән би кебек, ул да Тотыш йөзендә дәүләтнең ышанычлы терәген күрә, аңа зур өмет баглый, шунлыктан башсызлыкларын, тупаслыкларын да кичерә. Ә менә Тотышның үзенең Алмыш ханга мөнәсәбәте шактый катлаулы, каршылыклы. Ыруын талаган, үзен тоткынлыкка алган өчен ул Алмыштан үчен кайтарырга тели. Шул ук вакытта Тотыш аның кызы Аппакны ярата: «кемнең тоткыны соң ул — ханныкымы, әллә кызыныкымы?.. Тик шулай да нинди татлы, нинди куанычлы бу тоткынлык?» Әнә шундый катлаулы хәл каршылыклы эш-хәрәкәтләрне китереп чыгара. Тотыш бер арада Алмыш гаскәрләренә каршы кылыч күтәрә, икенче мәлне, Аппакны яклап, казаякларны, Ямгырчы би кешеләрен куып алып китә. Бу борылыш иң әүвәл герой психикасында ярала.

Романның поэтик сурәтләү чаралары сәнгатьчә фикерләүнең хәзерге югарылыгын гәүдәләндерә. Автор ханнар, биләр арасындагы килешү, вәгъдәләрнең тотырыксыз, ышанычсыз булуын күрсәтә. Һәркайсы икенчесенең байлык-мөлкәтен кулына төшерү өчен җай чыгуын көтеп, сагалап кына тора. Шуңа күрә язучы борынгы мәкальне, бераз үзгәртеп, ханны характерлау өчен файдалана: «Ханга ышанма, Әтилгә таянма»,— ди. Алмыш хан гаскәренең якынлашуы хакындагы хәбәрнең Күрән бигә йогынтысын әдип «суларга тын җитмәде, уйларга уй җитмәде» рәвешендәге янәшәлек белән, ханга һәм якыннарына мөнәсәбәтне «җиңүчеләрне елмаеп каршы алдылар, йодрык күрсәтеп озатып калдылар» формасындагы антитеза белән белдерә. Болар әйтемнәргә охшаш яңгырыйлар. Автор сурәтләвенчә, Ямгырчы бинең телдән әйткән сүзе күңелендәге асыл ниятенә капма-каршы килә. Телдән ул Күрән бине хан итәргә кирәк, дип әйтә, чынында исә «аның үзенең хан буласы килә иде». Әчке диалоглар, күңел каршылыклары аркылы герой

халәтенең үзгәреп торуы, хисләр контрасты, кичерешләрнең төрле юнәлеш алуы тасвирланә.

Сюжет барышы дәвамында әсәрдә байтак борылышлар, көтелмәгән хәлләр булып ала. Һәр очракта да алар логик һәм психологик яктан, тормыш закончалыклары, геройлар характеры, күңел дөньясы белән нигезләнеп бирелә. Еш кына автор аерым деталь ярдәмендә шундый бераз кискен үзгәреш килеп чыгачагына алдан ишарә ясап,сиздертеп куя, шул борылышны кабул итүгә укучыны психологик яктан әзерли. «Тотыш белән Ямгырчы би арасында өч-дүрт адымлык буш урын бар иде,— ди автор.— Шул өч-дүрт адымлык буш урында, уртада, кып-кызыл булып, дүрткел палас җәелеп ята иде. Ямгырчы би авызыннан утлар чәчеп тузынганда Тотыш ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышты. Аннары уртадагы әлеге палас та ике араны бүлеп тора шикелле тоелды». Күрәсез, биредә кызыл паласка аерым игътибар юнәлдерелә. Бу, әлбәттә, тиккә генә түгел. Ул палас тирән баз авызын каплап торган булып чыга. Аңа басу белән, палас кинәт убыла, Тотыш базга төшеп китә.

Ерак үткәнне сурәтләүгә дә карамастан, Н. Фәттах кечкенә детальгә кадәр төгәл, дөрес бирергә тырыша. «Мәсәлән, болгарларда һәм, гомумән, төркиләрдә байрак булуы мәгълүм нәрсә,— дип яза ул бер мәкаләсендә.— Ләкин ул байраклар нинди төстә, нинди формада булган соң? Миңа бит «байрак» дип кенә котылырга ярамый, миңа аның төсен, рәвешен сурәтләргә кирәк. Төрки халыкларда байрак һәм штандарт мәсьәләсенә багышланган махсус мәкаләне миңа бары роман журналда басылып чыккач кына укырга туры килде».

Н. Фәттах «Әтил суы ака торур» романы белән озын тарихның мавыктыргыч бер сәхифәсен актарып күрсәтте, аңа сәнгать нуры төшерде.

Тәнкыйть башта әсәрне шактый сабыр, сүлпән кабул итте, үз бәясен, мөнәсәбәтен белдерергә ашыкмады. Рецензияләр өч-дүрт елдан соң гына күренә башлады. Анда да кайчак сүз романның үзе турында, түгел, ә бәлки әсәрдә сурәтләнмәгән тормыш күренешләре турында, ягъни бөтенләй башка мәсьәләләр хакында барды. 1978 елда Татарстан китап нәшрияты романны йөз меңле тираж белән русча бастырып чыгарды. Үзәк матбугат аны дөнья әдәбияты җәүһәрләре белән бер рәткә куеп карады, «классик традицияләрдә, Вальтер Скотт традицияләрендә язылган»,— дип бәяләде. (Литературное обозрение, 1980, № 1, 82 б.) Шундыйрак фикер хәзерге прозабыз турында бәхәсләр вакытында да әйтелде. Ф. Ганиева Н. Фәттах иҗатын «уникаль иҗат, күп әдәбиятлар кызыгырлык, сокланырлык иҗат»,— дип билгеләде. (Казан утлары, 1983, № 9, 150 б.)

Тарихи тематика Н. Фәттахны мавыктырып, үз эченә бөтереп алып кереп китә. Эзләнә, кызыксына торгач, ул хәятның тагы да тирәнрәк катламнарына, моннан ике мең ике йөз еллар элек булып узган гыйбрәтле хәлләргә килеп юлыга. Әдип борынгы төркиләр-сөннәр гомер кичергән якларга — Монголия аймакларына юнәлә, шул тарафның кешеләрен, җирен-суын, далаларын күреп кайта. Монголия Халык Республикасы язучылары, журналистлары аңа ил белән танышырга, бу төбәкнең үзенчәлекләрен, колоритын тоярга булышалар. Н. Фәттах кабат гыйльми чыганакларга кереп чума. Ерак дәверне, ыру-кабиләләр мөнәсәбәтен, катлаулы бәйләнешен ачык итеп күз алдына китерүдә аңа аеруча Сыма Цяньның «Исторические записки»[1] дигән китабы күп ярдәм итә. Н. Фәттах малчылык белән көн күргән борынгы күчмә бабаларыбызның яшәү рәвешен, кәсеп-шөгылен, экономикасын, социаль мөнәсәбәтләрен, этнографиясен, табыну-йолаларын, легендаларын, телен, әхлак нормаларын, күрше халыклар белән бәйләнеш-мөнәсәбәтен җентекләп өйрәнә. Н. Фәттах — борынгы чорның бу катламнарына тәүге тапкыр аяк баскан беренче җитди тарихчы да ул. Бу эзләнүләрнең бер тармагын ул тел тарихы турындагы күләмле мәкаләләрендә җанлы, кызыклы итеп яктыртты[2]. Анда ул бик күптәнге сөйләм үзенчәлекләрен, сүзләрнең, фразаларның килеп чыгышын, этимологиясен күрсәтте.

«Сызгыра торган уклар», Н. Фәттахның башка тарихи әсәрләре кебек үк, үтә киеренке — мавыктыргыч сюжетлы, этнографик бай бизәкле, борын-

---

[1] Сыма Цянь. Исторические записки (Памятники письменности Востока. XXXII, 2.— М.: Наука, 1975 г.

[2] Фәттах Н. Ерак гасырлар авазы. Казан утлары, 1976, 9, 10, 11 саннар.

гы яшәешнең үзенчәлекле якларын сурәтләгән, кабатланмас характерны гәүдәләндергән сәнгать әсәре.

Кайберәүләрнең тарихны искелек, артталык дип кенә карау ихтималын күздә тотып, автор «Сызгыра торган уклар»ның кереш сүзендә: юк, тарих — ул искелек, артталык кына түгел, ул барыннан да бигрәк гыйбрәт, акыл һәм тәҗрибә, дип раслый һәм әсәрендә үткәндәге, ерактагы җитди сабаклар бүгенге иминлекнең кадерен белергә, аны күз карасыдай актив сакларга өнди, яу һәм тынычлык мәсьәләсендә аеруча зирәк булырга, акыл белән, тарих тәҗрибәләренә карап эш итәргә өйрәтә, дигән фикер уздыра.

Әсәрнең үзәгенә Албуга образы куелган. Биредә ил, халык яшәешендәге зур вакыйгалар Албуга язмышына бәйле рәвештә тасвирланалар, аның драматик тормышы укучыны даими рухи киеренкелек хәлендә тотып тора. Шул ук вакытта, гәрчә финал Албуганың тоткынлыкка төшүе белән тәгалләнсә дә, аның юлында әле нииндидер борылыш булу ихтималы турында күңелдә бер якты өмет тә яши. Чөнки укучы Туңгак алыпның алдарак Албугага «бар ышаныч синдә» дигән сүзен яхшы хәтерли. Туңгак алып, гаскәрдән читкә җибәрелгән, авыру, гарип булуына да карамастан, әле үзендә дә зур көч сизә. «Миндә бер бөртекне мең бөртеккә әйләндерә алырдай осталык бар!» — ди ул. Н. Фәттахның зирәк геройлары мондый җитди сүзне тиккә генә ычкындырмауларын истә тотсак, әле бу геройларның зур перспективалы булганлыгы аңлашыла. Беренче китап күләмендә Албуга һәм Туңгак алып язмышлары никадәр генә хәвефле һәм серле булмасын, алда аларның актив хәрәкәте төсмерләнә.

Роман персонажлары Албуганы каганның өлкән бичәсеннән туган өлкән баласы, ягъни тәхеткә хокуклы улы дип йөртәләр. Тик энисе Күрекле-бикә генә аңа: син — Каган баласы түгел, син — Тәңре улы,— ди. Албуга үзе дә күңеленнән Туман каганга охшамаска, аның эзеннән бармаска сүз бирә, ягъни аның Каганнан рухи аермасына, гади, ләкин зирәк, талантлы, затлы токымнан булу ихтималына басым ясала. Әсәрдә Албуга җиткән егет, ыру башлыгы булып формалашкан дәвердә күрсәтелә, аның шул чорга хас эшгамәлләре, уй-кичерешләре сурәтләнә. Романнан аңлашылуынча, геройлар тормышның шактый кырыс шартларында гомер кичерәләр, ләкин табигать каршында бер дә үзләрен көчсез хис итмиләр. Аска коры-сары түшәп, тире җәеп, кышкы далада куну, япан җирдә торак кору яки, киресенчә, ил-көн, мал-туар белән кузгалып китү, көннәр буе юлда булу — алар өчен табигый хәл. Биш-алты яшьлек балалар инде атка атланып, ә ярлыраклары сарыкка, кәҗәгә атланып йөриләр. Ачык далада көчле буран котыргач, Күрекле-бикә, Албуга ыруының барлык кешеләре үзләрен саклаудан бигрәк ишле көтүләрен таратмау хәстәрен күрәләр: «Терлек-туарны үлемнән коткарып калу исә үз-үзеңне ач үлемнән коткарып калу дигән сүз иде». Автор күчмә кешеләрнең дала шартларына җайлашкан, зирәк, чыдам булуларын күрсәтә.

Бу чорда әле һәр кабиләнең иминлеген, мөстәкыйльлеген саклаучы үз гаскәре була. Албуга йончыткыч күченүләр вакытында да ирләр арасында хәрби осталыкны күтәрү, тәртип урнаштыру чараларын күрә, нык куллы гаскәр башлыгына әйләнә, кайчак шактый кискен эш итеп тә куйгалый. Аңа яшьлек масаюлары да бөтенләй үк чит түгел.

Әсәрдә Албуганың ярәшелгән кызы Алтын-Бөртеккә өйләнүе, кәләш куенынннан туры яуга китүе этнографик бай детальләре, шаян-шуклыклары, моңсу бизәкләре белән тасвирлана. Этнографик картиналар, йола, гореф-гадәт ритуаллары, багу, күрәзәчелек күренешләре роман тукымасына бик табигый булып, вакыйга барышында үреләләр.

Романдагы барлык хәл-вакыйгалар, бәйләнеш-мөнәсәбәтләр дә геройларның уй-кичерешләре белән җылытып, җанландырып биреләләр. Әдип тойгы-хисләрнең катлаулы булуын, төрле юнәлеш алуын, бер үк факт уңае белән төрле кешедә капма-каршы фикер тууын сурәтли. Ул күңелдәге бәрелешләрне, эчке конфликтны нечкә төсмерләре белән күрсәтә. Әсәрдәге байтак коллизияләр психологик җирлектә бәреләнә, уйның тиешсез юнәлешкә кереп китүе конфликт тудыра. Әсәрдә социаль тигезсезлекнең кешеләр язмышында, үзара мөнәсәбәтләрдә, кичерешләрдә чагылышын гәүдәләндерүгә зур урын бирелә. Романнан күренгәнгә, чибәр кол кыз Табылдык кулдан-кулга күчеп йөри. Аның үз хисләре белән берәү дә хисаплашмый. Романда Күрекле-бикә акыллы, булдыклы хатын итеп сурәтләнә. Ул Туңгак алыпны үзенә якынайта, аны ихлас күңелдән ярата. Шуңа да карамастан, ул Сөн иленең атаклы гаскәр башлыгының кол икәнлеген һәрчак исенә тө-

шереп тора. Шуңа күрә Туңгак алып ирекне дә өлкән бичә назыннан котылу дип аңлый.

Автор дәрәҗәле аксөякләрнең эгоистик психологиясен яктырта. Каганның анасы Кортка-бикә хакында ул болай яза: «Яшь, сылу кызлар турында ул беркайчан да тыныч кына тыңлый алмый иде. Кулыннан килсә, ул барлык яшь, сылу кызларны үзе кебек корыган агачка әйләндереп бетерер иде».

Психологик атмосфера аеруча каган тирәсендә киеренке. Туманның иң якын киңәшчеләре, аның белән бер табактан ашаучылар, каган үлгәч, аның белән бергә күмелә торган ирләр, каганның кәефен чамалый алмасалар, аңа нинди киңәш бирергә дә белмиләр, кайсын бирсәң дә хәтәр, куркыныч булып чыгуы ихтимал дип уйлыйлар.

Автор геройларның үз чорына хас карашларын, фикер йөртү үзенчәлекләрен гәүдәләндерә. Ыру яңа җиргә күчеп килгәч, Албуга белән осталар арасында шундый сөйләшү булып ала.

«— Сез тау-тау өеп куйган ук, сөңге сапларына ярый ла тимер җиткереп булса!

— Тимер генә им түгел! Тимер җитмәсә, таш, сөяк куярлар,— диде өлкән яшьтәге бер оста.— Бозылды халык — ук башына да тимер, сөңге башына да тимер, пычак та тимер. Элек бер дә тимер дип аптырап тормаганнар».

Әсәрдә борынгы йолаларның бик үзенчәлекле, хәтта кайбер кыргый яклары да күренеп-күренеп китkәли. Әйтик, корбан бирү йоласы кайчак табигый халәтне кискен үзгәртеп җибәрә. Дунху бәге Начин Нойон, үлемнән котылу куанычыннан шашынып: «Тәңрем! Коткаручым! Үз аймагыма кайтып җитә алсам, биш яшьлек улымны сиңа корбан итеп бирәм!» — дип нәзер әйтә, үз яшәеше хакына икенче бер кеше гомерен кисәргә җыена.

Н. Фәттах тормыш күренешләрен мөмкин кадәр гади, төгәл, ачык итеп сурәтләргә тырыша. Бер очрашу вакытында ул романның кимендә яртысын кулдан унтугыз мәртәбә күчереп чыгуы хакында сөйләгән иде. Бу гадилек артында образлы фикерләү, поэтик осталык, тирән мәгънәлелек, экспрессивлык ята. Туңгак алып турында автор болай яза: «Ул ишеккә таба атлады. Ашыгудан, кабаланудан ул аяк астындагы нәрсәгәдер сөрлегеп китте. Аяк астындагы ул нәрсә сөлге булып чыкты. Ләкин ул аны иелеп, аягыннан алып тормады — шул килеш, уралган сөлгесен өстерәп, ишек катына ук килеп җитте». Менә шушы аякка уралган сөлге истә кала, ул алдагы зуррак, хәвефлерәк хәлләр ихтималы турында кисәтеп, искәртеп куя кебек.

Әсәрдә табигать бик актив, тынгысыз хәрәкәттә күрсәтелә, даими үзгәреп торучан, кеше кичерешләренә сизгер итеп сурәтләнә. Автор болай ди: «Кышкы кояш инде бик нык зурайган, кызарган һәм кара җир астына төшеп бара иде». Бу җөмләдән борынгы аң буенча фикер йөртү дә, ниндидер мәгънәле ишарә дә сизелә.

Тарихи тематика буенча Н. Фәттах безнең әдәбиятта аеруча җитди сүз әйтә алды, мөһим концепцияле, йотлыгып укырдай әсәрләр иҗат итте, ерак дәверләр белән бүгенгенең бәйләнешен күрсәтте, сәнгать чаралары белән тарих сабакларының тирән мәгънәсен аңлатып бирде.

Иҗатка, сәнгатькә карата зур таләпчәнлек аның тәнкыйть эшчәнлегендә дә ачык чагыла. Әдәби күренешләргә бәя биргәндә, төп критерий итеп ул сәнгатьчә камиллек дәрәҗәсен ала. Әгәр дә әсәрдә осталык җитенкерәмәү очрагын, йомшаклыкны тоя икән, ул бу хакта гомум сүзләр әйтү белән генә чикләнми — кулына яңа гына каләм алучылар турында да, яшь язучы Нәбирә Гыйматдинова хикәясе, «ирекле» шигырь хакында да, могтәбәр өлкән әдипләребез А. Шамов, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Ә. Еники әсәрләре турында да конкрет сөйли, ул әсәрләрне анализлап күрсәтә. Иҗат серләрен нечкә тою нәтиҗәсендә туган риясыз мәкаләләр укучының игътибарын тарталар, исендә, хәтерендә калалар. Шул ук вакытта Н. Фәттах соклану хисләрен дә ачык итеп әйтә. Ә. Еники иҗаты турында ул: «Әмирхан Еники әсәрләрен мин беркайчан да ялыктырмый торган шигырь укыгандай укыйм»,— ди, андыйларның тәҗрибәсе үзенә иҗат терәге булуы хакында хәбәр итә.

Н. Фәттах талант ияләре белән берлектә әдәбиятыбызны үстерүгә зур өлеш кертеп килә.

## *Культура тормышы көндәлеге*

### ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШЫ

25 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзының гомуми җыелышы булды. Анда КПСС Үзәк Комитетының апрель (1985 ел) Пленумы карарлары яктылыгында Татарстан язучыларының публицистик эшчәнлеген, аларның газета битләрендә, радио һәм телевидение тапшыруларында катнашуын активлаштыру мәсьәләләре каралды.

Р. Мостафин радио һәм телевидение буенча, М. Шабаев «Чаян» һәм «Азат хатын» журналлары, М. Галиев «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре» газеталары, М. Хуҗин «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасы, М. Зарипов «Советская Татария», «Вечерняя Казань», «Комсомолец Татарии» газеталарының бу өлкәдәге эшчәнлеге турында чыгыш ясадылар. Фикер алышуда танылган прозаиклар, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләр һәм публицистлар катнашты.

Җыелышта РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Э. Ю. Зимин чыгыш ясады.

Җыелышта катнашучылар шулай ук Россия Федерациясе Язучылар союзының декабрь аенда булачак VI съездына делегатлар сайладылар.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының 19 сентябрьдә узган чираттагы җыелышында язучы Мәдинә Маликованың иҗат отчеты тыңланды.

Язучының иҗаты турында доклад белән филология фәннәре кандидаты Ф. Галимуллин чыкты. Фикер алышуларда язучылар Л. Ихсанова, Г. Зәйнашева, Р. Мостафин, К. Тимбикова, М. Скороходов, Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясап, бүгенге прозабызга бәйләнешле рәвештә язучы иҗатына анализ ясадылар, уңышлы һәм кимчелекле якларга тукталдылар.

### БРЕЖНЕВ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Язучылар оешмасының 25 июльдә узган чираттагы җыелышында шагыйрьләр Мәхмүт Газизов һәм Ямаш Игәнәйнең иҗат отчетлары тыңланды. Аларның иҗатлары турында фикер алышуда драматург Р. Хәмид, язучы Г. Кашапов, шагыйрьләр К. Сибгатуллин, Х. Хөснуллин һ. б. катнашып, һәр икесенә активрак иҗат итү кирәклеге басым ясап әйтелде.

### ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘМ РӘССАМНАР ФИКЕРЛӘШӘ

28 сентябрьдә Татарстан сынлы сәнгать музеенда шигърият кичәсе булып узды. Шагыйрьләр һәм китап бизәүче рәссамнар катнашкан бу кичәдә поэзия һәм рәсем сәнгате арасындагы уртаклык, аның иҗатта, көндәлек тормышта чагылышы, яшәеше турында зур сөйләшү булды. Шагыйрьләр Ренат Харис, Зөлфәт, танылган рәссамнар Тавил Хаҗиәхмәтов, Александр Туманов һәм сәнгать белгече, яшь шагыйрә Розалина Шаһиева катнашкан бу кичә һәр ике як өчен дә файдалы булды. Татарстан сынлы сәнгать музеенда мондый кичәләр уздыру традициягә әйләнеп бара һәм поэзия һәм рәсем сәнгатен сөючеләр арасында урынлы яклау таба.

### Г. ТУКАЙГА БАГЫШЛАНА

«Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем!» — Мәскәүнең «Планета» нәшрияты Татарстанда шагыйрь Г. Тукай яшәгән, булган җирләр буйлап сәяхәткә багышланган фотооткрыткалар җыелмасын шулай исемләгән.

Кушлавыч, Кырлай, Казан... Татар халкының сөекле шагыйре Г. Тукай җырга салган, мәдхия укыган, илһам алган туган як, туган җир, истәлекле урыннар фотоларда тулы чагылган. Бу җыелма шагыйрьнең 100 еллыгы уңаеннан — 1986 елның башында 100 мең тираж белән басылып чыгачак.

### ТАТАР РОМАНЫ ТУРЫНДА

Мәскәүнең «Наука» нәшриятында СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты тарафыннан әзерләнгән «Күпмиллэтле совет романы» дигән коллектив монография басылып чыкты. Совет романының нык үскән социализм чорындагы үсеш юлын һәм тенденцияләрен яктырткан бу күләмле фәнни тикшеренүгә филология фәннәре докторы Ф. Мусинның «Татар романы офыклары» исемле хезмәте дә кертелгән. Анда хәзерге татар романының проблематикасы, жанр үзенчәлекләре һәм күпмиллэтле совет романы үсешенә керткән өлеше турында сүз бара, әдипләрдән Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, А. Расих, Ш. Бикчурин, Н. Фәттах, Г. Ахунов, М. Хәбибуллин һ. б. романнары анализлана.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост


# Кама Аланының яңа күренеше

## ТатАЭС. 1985 ел.



Татарстан атом электр станциясе һәм Кама Аланы поселогы төзелеше торган саен киңрәк колач ала бара. Быелгы җәйдә аеруча зур эшләр башкарылды. Кама буйлап төзелешкә бик кирәкле йөкләр кайтартылды. Вакытлыча салынган пристаньга «Метеор»лар да туктала башлады. Казан — Кама Аланы маршруты ачык!

Поселоктагы мәһабәт ташпулатларны күргәч, монда берничә ай гына элек иске агач өйләр булганлыгына инде ышанасы да килми. Элекке авылның әби-бабайлары барысы да яшәү өчен ифрат җайлы, тугы-







зар катлы өйләргә урнашканнар. Төзүчеләрне һәм булачак энергетикларны уңайлы торак белән тәэмин итәргә тиешле 12 төзүмонтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәләхов моңа бик канәгать. Рәисә белән Дамир Сабировлар өчен дә шат ул. Дүрт балалы бу гаиләгә дүрт бүлмәле квартира бирделәр.

Яшелле-сарылы торак йортлардан шактый еракта атом электр станциясенә нигез әзерләнә. Экскаваторлар җир казыйлар, «БелАЗ»лар, «КрАЗ»лар туфрак ташыйлар, бульдозерлар мәйданны тигезлиләр. Берничә ел сизелми дә үтәр — монда беренче реакторны урнаштырырлар.

Фоторәсемдә күрсәтелгән Артур Уразаев бригадасы кебек уңганнар эшне озын-озакка сузарга яратмыйлар.

**Рифкать ЯКУПОВ** фотолары.



# ТЫНЫЧЛЫК МАРШЫ

Сәнгать сөючеләргә алдан ук шундый серне ачып үтәсе килә: яшь рәссамнар Илгизәр Самакаев белән Зөфәр Гыймаевның «Тынычлык маршы» исемле картинасындагы колоннада (уң якта) авторларның үзләре дә сурәтләнгән. Әсәр геройларын гәүдәләндергәндә автопортретлаштыру алымыннан файдаланып, иҗатчылар чынбарлыкка мөнәсәбәтләрен белдереп кенә калмыйча, кешелек язмышы өчен шәхси җаваплылыкларын калку итеп күрсәтергә, картина идеясен анык гражданлык позициясе белән ныгытырга омтылганнар.

«Тынычлык маршы» полотносы ВЛКСМның XIX съездына багышлап оештырылган X республика яшьләр күргәзмәсе өчен махсус иҗат ителгән. Әмма әсәрнең идеясе, рәссамнарның соавторлыгы кебек үк, эчке сәбәпләр буенча барлыкка килгән. Эчке сәбәпләр... Алар нидән гыйбарәт? Төрле югары уку йортларын тәмамлаган, иҗат юлларын төрлечә башлап җибәргән әлеге рәссамнарны бергәләп эшләргә нәрсә мәҗбүр иткән? Яшьлекме? Дөньяны танып-белүдә гадәти калыплардан качарга омтылумы? Замандашларының беркемне дә битараф калдырмаган портретын, киләчәккә карап иҗат ителгән портретын тудыру теләгеме?

Барысы да сәбәп булгандыр. Шуларның соңгысына гына тукталыйк. Картинада киләчәккә карауны ничек бирергә? Бүгенге катлаулы заманда киләчәккә бару барыннан да элек яңа сугышны булдырмый калуга бәйле. Рәссамнарның омтылышын менә нинди уртак максат берләштерә, һәм әлеге идеядә бөтен прогрессив кешеләрнең иң олы теләге чагыла.

...Яшьлек тынычлык маршына чыккан. Халык ташкынында җилкәндәй транспарантлар йөзә. Янып торучы рауза чәчәкләрендә кешеләрнең җирдәге матурлыкны кадерләп саклауларына ышаныч чаткылары балкый төсле. Колоннада үзеңне дә күрү тойгысы уяна, күңелдә мәгълүм җырның моңдый сүзләре яңара:

Башлана тынычлык юлы
Безнең Совет иленнән.
Без тоткан кызыл байракның
Нуры ерак сибелгән...

Людмила **КОРОБЦОВА**,
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)